# казан утлары

7

ИЮЛЬ·1975

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

7
ИЮЛЬ
1975

## Бу санда

**Ш. МАННУР.** Олы чишмә. Шигырьләр . . . . . 3
**М. ХӘБИБУЛЛИН.** Чоңгыллар. Роман . . . . . 8
**М. НОГМАН.** Айбулат. Шигырь . . . . . . . . 106
**З. МАНСУРОВ.** Ипи. Шигырьләр . . . . . . . 110
**С. СӨЛӘЙМАНОВА.** Сагы барның сагы ятар. Хикәя . . . . . . . . . . . . . . . . 112

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 123
**Ф. НАСЫЙРОВ.** Рәхмәт сезгә, кешеләр! . . . . 125

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 30 ЕЛ

**А. МАРКЕЛОВ.** Утларда чыныккан . . . . . . 133

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Г. ТАҺИРҖАНОВ.** Татар әдәбиятының катлаулы мәсьәләләре. Беренче мәкалә . . . . . . 143

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**К. ФАСЕЕВ, Ә. БУЛАТОВ.** Мәгърифәтче галим Шәмсетдин Күлтәси . . . . . . . . . . . 155

ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

**Т. ГАЛИУЛЛИН.** Җырдан-җырга . . . . . . . . 164

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. МОСТАФИН.** Күп бизәкле, бердәм әдәбият . 176
**Г. КУКЛУС.** Әмирхан Еникинең күп төрле геройлары . . . . . . . . . . . . . . . . 179

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

**М. МӘҺДИЕВ.** Көтелмәгән сораулар. Парчалар . 182

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 1/IV-1975 ел. Басарга кул куелды 21/V-1975 ел. ПФ 05223. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 90.000 экз. Заказ Я-156. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1975 ел.

## Шәйхи Маннур

### Олы чишмә

Бик борынгы
Тулбай бабам килеп
Бу чишмәне күргәч,
Таң калган:
— Гөбердәп лә җырлап ага! — диеп,
Тирәсеннән китми таптанган.

Дөнья гизгән түбәтәе белән
Авыз иткән көмеш суыннан.
Эчеп туймас татлы тәмен белгән
һәм кырт кисеп әйткән соңыннан:

— Шушы төштә төпләнербез! — дигән.
Шуннан киткән
Тулбай авылы.
Заманнардан күпме михнәт килгән,
Күпме чөйгән язмыш давылы,
Күпме кешеләрен
Туган җирдән
Йолкып аткан дөнья авыры...
Тик Тулбайлар һаман яши биргән,
Киселмәгән йөрәк тамыры!

һаман исән безнең Олы Чишмә,
Гөбердәп лә җырлап ага ул.
Яшь йөрәкләр сере түгелә кичтә,
Мактау җырлый язгы таңга ул.

Бабаларым,
Егет булып монда,
Ат сугарган имән улактан.
Әбиләрем —
Килен елларында
Айкый-чайкый киндер агарткан.

Сыгылдырып чиләк-көянтәсен,
Бу чишмәдән әнкәм су алган.
Егет әткәм аны кич-иртәсен
Күзләп калу белән юанган...

Борыннан ук килгән шундый йола:
Танышканнар чишмә буенда.
Йөрешкәннәр...
һәм алдагы елда
Кавышканнар сабан туенда.

Мин дә сөйдем,
Беренче кат сөйдем.
Иге-чиге юк бу сөенечнең!
Утларында көйдем,
Бу чишмәгә килдем,
Улагына ятып суын эчтем.

Күпме кичләр монда җыр түгелгән,
Күпме кичләр гармун моңайган.
Күпме йөрәк, сөеп чын күңелдән,
Сәлам көткән язгы тургайдан...

Сагынам да
Шул чишмәгә кайтам,
Һаман шулай җырлап ага ул.
Эчкән суым мине һаман тарта,
Әнкәм сөте кебек —
Канда ул.

Шул су белән
Сабый чагыбызда
Ачылып киткән безнең телебез.
Тулбайларның сүзе татлы булса,
Тулбайларның йөзе якты булса, —
Шул чишмәдән диеп белегез!

Сез тапсагыз әгәр бик аз гына
Җырларымда минем якты моң, —
Ул бәхетне чишмәм биргән миңа...
Өмет итмим шуннан артыгын.

Гөбердәп лә җырлап һаман ага,
Һаман тынмый Олы Чишмәбез.
Саф сулары яшьлек бирә җанга,
И юлчылар, эчми китмәгез!

Ул тынмаса,
Мәңге тынмас минем
Тулбай бабам корган илем дә.
Күкрәп яшәр бу борынгы җирем,
Тынмый сайрар туган телем дә.

## Ник әле мин...

Йөз ел бугай
Шигырь язганым юк,
Ни булды соң әле күңелгә?
Элеккедәй нигә янганым юк,
Тәгәриме җырым үлемгә?..

Гомер алып килгән сөенечләр,
Юанычлар инде үттеме?
Сөю арты — ачы көенечләр,
Суынулар хәтта беттеме?..

Җан өшетер яман гадәтләр дә
Юылдымы яшәү күгеннән?
Куанырлык олы сәбәпләр дә,
Яшь тә юкмы күздән түгелгән?

Ник әле мин
Авызга су каптым?
Җыр тавышым әллә чикләме?
Сукмаклары әллә малай чакның
Кыйссаларга алып киттеме?..

Юк, берсе дә
Аклый алмый болар,
Мөмкин түгел моңсыз яшәргә.
Битарафлык саклый алмый җырлар,
Җырның көче —
Тынмый яшьнәүдә.

Газраилне хәтта күргәндә дә
Дәшми калсам,
Көләр сабыйлар.
Тик куяннар гына күләгәдә
Бүреләргә бармак яныйлар...

Җаваплы мин
Кеше каршысында:
Аның уе,
Эше,
Язмышы,
Мәхәббәте,
Кайгы-сагышы —
Борчылдыра мине барысы да!

Юк, тыналмыйм җырсыз.
Бу дөньяның
Буш булачак миңа бар җире.
Уртасына басып давылларның
Җырлап үлгән татар шагыйре.

## Хәл кадәре

Филләр, филләр...
Әдәм баласына
Гомер буе тугры хезмәт иткәч,
Хәлсез картлык көне
Тәмам җиткәч,
Китә, диләр,
Таулар арасына.

Һәм кизләнеп
Тар бер тарлавыкта,
Эзләп тапмас җирдә
Хәтта хуҗаң,
Дөнья куя, имеш, олы бу җан —
Тып-тын гына,
Изге бер авыкта...

Дан-дәрәҗә,
Хөрмәт сорамастан,
Берәүгә дә авыр йөк булмастан,
Хәл кадәре
Актык тирем түгеп,
Гаделлеккә фәкать тезем чүгеп,

Хезмәт иткәч әдәм баласына,
Китә белсәм җирдән
Филләр кебек,
Мин үкенмәс идем башкасына...

## Исе китә микән

Болытларга тияр
Биек таулар
Сокландыра мине һәркайчан.
Күренәдер төсле
Килер таңнар,
Өсләренә менеп карасаң.

Тик кызыкмыйм
Таулар биегенә,
Тауга карап
Булмый тау булып.
Йөгереп төшәр идем киңлегенә,
Кырмыскасын җирнең сагынып.

Кырмыскалар төсле игенчегә
Нигә кирәк
Биек тауларың?
Тау буласы килеп йөрүчегә
Исе китә микән аларның?..

## Яз киче

Яшь баланың
Иң беренче тапкыр
Елмаюы төсле һавага
Тирәкләрнең ахак бөресеннән
Әчкелтем бер хуш ис тарала.

Күк чал зәңгәр,
Аңа җиңел генә
Хәтфә караңгылык сибелгән,
Тик түрендә, көмеш урак төсле,
Яңа туган айның йөзеннән
Йомшак кына якты түгелә:
Әкрен генә язгы эңгер төшә,
Җир өстенә язгы төн килә...

Кабынып киткән сирәк йолдызларның
Елмаешкан күзен күрдемме, —
Синең күзләр
Кинәт искә төшеп,
Куандыра моңсу күңелне...

## Гади сер

— Бер җыерчык заты юк йөзеңдә,
Ә җитмешне узып баруың!
Серләреңне безгә әйтмисең дә...
Бар мәллә соң яшьлек даруың?—

Диган була миңа дус-ишләрем.
Аңлыйм инде:
Юри көләләр.
Нидә булсын минем сер чишмәвем?
Гади хәл бу —
Үзләре дә яхшы беләләр.

Каш җыерып,
Һаман чырай сытып
Яши бирсәң,
Бик тиз сулдыра.
Ә мин көләм,
Көләм
Кайгыларым йотып,
Яшь күрсәтә булыр шул гына...

Кыз елмайса,
Егет балкып китә,
Егет көлсә,
Кызлар — гөлчәчәк.
Кешеләрне көлү матур итә,
Яшьлек сүнмәс,
Көлеп яшәсәк!

## Рәхмәт сүзе

Якында да,
Ерак якларда да
Бик күп икән ихлас дусларым.
Тәрәзәмне җилләр какканда да
Ишетәм мин алар котлавын.

Өстәлемә йөзләп хат җыелган:
Памир, Җаек, Төмән, Алтайдан.
Үзебезнең Арча, Ык буеннан,
Кытай чиге Тарбагатайдан.

Онтылмаслык әйбәт сүзләр язып,
Уңыш тели алар бары да.
Яхшы сүз ул һәрчак җанга азык
Гомер буйлап алга барырга.

Геройларым юлдаш була алса,
Ә шигырем сезнең күңелгә
Әз генә бер җылы бирә калса, —
Мин бәхетле, дуслар, гомергә!

Барчагызга рәхмәт укыйм сезнең
Изге теләк, яхшы сүз өчен.
Мин солдаты һаман илебезнең,
Аңа булсын бөтен җыр көчем!

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ЧОҢГЫЛЛАР

РОМАН

25



Дулкынланып торган бодай басуы кырыеннан, су өстенә калкып-калкып чыккан дельфин сыман, председательнең газигы йөзә. Менә ул сулга борылды, кыр ышыклау урманы буйлап китте.

Бодай кырын үтеп, көнбагыш басуына җиттеләр. Көнбагыш чәчкәгә йомарланган инде, менә-менә күзләрен ачып кояшка багарга җыена. Юл һаҗәр чокыры буйлап сузылды. Тизлеген баса төшеп, машина чокырга төште дә үкереп каршы якка менә башлады. Чокырны чыгуга, дугалы ат күмелерлек кукуруз басуы буйлап элдерделәр. Талип янәшәсендә утырган партком секретарена карамыйча сөйли башлады:

— Киләсе елга бу «кырлар патшасын» бермә-бер ким чәчәчәкбез. Өченче көн Башкортстанга чыккан идем. Кукуруз урынына солы чәчкәннәр. Сезгә мәгълүм булса кирәк,— диде Талип, секретарьның йөзендә канәгатьсезлек билгесе күреп.— Яхшы туфракта солы кукурузга караганда ике бермлек артык азык бирә, аннары солы бит ул безнең як культурасы, аксым да аңарда дүрт тапкыр артыграк икән. Тритикал, беркадәр күләмдә кукуруз, солы, көнбагыш белән аралаштырып йомшак бодай игә башласак, сугарулы болын көйләнсә — менә безнең комплекска азык, Әдһәм абый.

— Анысын дөрес әйтәсең, солы — безнең культура. Революциягә кадәр солы чәчмәгән крестьян булмаган. Сугышка чаклы да бик күп игә идек без аны, бары тик «кыр патшасы» аны кысрыклый алды...

Колхоз председателе белән партком секретаре ике-өч көнгә бер кырларны әйләнеп кайталар. Борчак өлгереп килә иде, бүген шунда юнәлделәр. Талип агрономны да үзе белән алырга уйлаган иде дә, ул каядыр китеп барган булып чыкты.

— Галимебез басуларыбызны башкачарак бүләргә тәкъдим итә, урман полосаларын да үзгәртергә туры киләчәк.

---

Ахыры. Башы 5, 6 саннарда.

— Урман полосаларын кучереп утыртуны җиңел дип уйлыйсызмы, Әдһәм абый?

— Җиңел эш түгел анысы.

— Урман полосасы үз җае белән эшләнер ул, мине комплекс борчый. Сихер белән генә төзисе иде шуны. Материаллар җитми, якшәмбедә Әлмәткә китәм, тимер-бетон әйберләр заводы директоры янына. Әй, сүлпән кыланалар да соң бу төзүчеләр! Җитмәсә, Алексей Михайлович ярдәме белән, йөз илле баш токымлы сыер бирергә ышандырдылар. Килеп алыгыз дип телеграмма суксалар? Ул сыерлар аяк астындагы үләнне дә иелеп ашый белмиләр, ди. Алга салганны гына ашарга өйрәтелгәннәр икән. Эшләр болай барса, быел да комплекссыз кышларга туры килмәгәе безгә.

— Комплекс мәсьәләсендә минем киңәшкә мохтаҗмы син?!

— Их, өф итеп кенә суырып аласы иде шул тимерле бетон материалларны.

— Мин һич аңлап бетермим шул колхозара төзелеш оешмаларының системасын: эшче бездән, материал алардан...

— Өч елга якын гомеремне сарыф иттем мин ул комплекска. Шуннан соң кул селтимме! Юк, иртәгә үк барам директорга, кирәк икән сарык, кирәк икән сыер бирәм...

— Сыеры артык булыр, сарык та бик җиткән. Минем бер карт сарыгым бар, иртәгә барасы итсәң, чалып куярмын.

Талип тизлекне акрынайта төште, партком секретаре ягына күз ташлап алды.

— Юк, Әдһәм абый, сез пенсиягә китсәгез, мин дә бу эштән китәм. Икенче берәү белән шулай эшли алуыма ышанмыйм.

Харисов аның соңгы сүзенә җавап кайтармады.

— Бүген бу борчакны хәл итеп куярга кирәк. Уңмаган икән, нишлисең инде. Бөртеккә икән — бөртеккә, силоска икән — силоска чабып салырга кирәк. Әлмәткә өлгерерсең...

Талип авыз чите белән генә көлемсерәп куйды.

— Минем ул сортлы борчак турында ишетәсем дә килмәгәнне белмисезмени, Әдһәм абый?! Үзегез хәл итегез. Беләсезме, мин ул агрономыбызга ышана башладым. Эшкә бик хирес егет булып чыкты. Җиде басулы чәчү әйләнеше планлаштырды. Чәчү тирәнлеген, чәчү нормасын сыный. Һәр басуда минераль ашламалар кулланудан уңышның үсешен тикшерә. Сортлы борчакка килгәндә... Бу бәхәс аңа да, миңа да файдалы булды дип уйлыйм мин.

— Сезгә файдалыдыр да бит... Колхозга ни файда аннан! Ашлама салган булсак, бәлкем бүген бу турыда бәхәсләшеп тә тормас идек. Ә хәзер ике йөз гектар борчакны силоска салырга туры киләчәк. Үзсүзлелегеңнең дә бер чамасы булырга тиештер...

Талип дәшмәде. Алдагы сортлы борчак басуына карап бара башлады. Басуга урыны-урыны белән саргылт төс иңә башлаган. Әмма борчак тигез өлгерми. Калкурак җирләрдә сарылык куера төшкән.

Газик туктауга, Талип беренче булып җиргә басты һәм, биленә таянып, зәңгәр күккә карады. Анда өзелеп-өзелеп сабан тургае җырлый иде.

Харисов полоса буена игътибар итте. Анда борчак яшелрәк иде. Ләкин бу сиракләнгән агачлар турысында гына шулай. Харисов шунда таба ашыкты. Полоса сиракләнмәгән турыда борчак, кар калын яткангамы, кояш-җил тимәгәнгәме, базда үргән бәрәңге кебек зәгыйфь булып югарыга үрләгән.

Председатель белән агроном арасындагы бәхәсне Харисовның менә шул борчакка бәйле нәтиҗә аша чишәсе килә иде. Кайчак аңа Талип та, Мидхәт тә хаклы күренә. Үзен нинди дә булса нәтиҗә ясарга сә-

ләтле түгел дигән төшенкелеккә бирелә, шул ук вакытта һәркайсының хакыйкатькә якын торуын йөрәге белән тоя да иде.

Харисов үзенә таба килүче Талипка карап торды. Талип аның күз алдында үсте. Рәхим байның туганнан туган энесе Бикмуллин Кәрамнең Наратбашта ике кибете була. НЭП чорында кибетне караклар баса, Талипның әтисе белән әнисен үтерәләр, шул фаҗигадән соң ике яшьлек малайны Таҗылбанат тутасы үзенә ала. Ләкин Таҗылбанат тутасы малайны дин белән агулый башлагач, авыл Советы карары белән, баланы алардан алып, детдомга җибәрәләр.

Килә-килешкә Талип аңа бер уч борчак йолкып бирде.

— Бер дә бүтән түгел, чәчәктә чакта эссе куырган бу борчакны. Агроном маташтыра гына, сүзен өскә чыгарырга маташа. Безнең туфрак борчак үндырылмаслык кынамы! — Талип иелеп бер уч туфрак алды да, җылысын тойган сыман, офык читендәге ашъяулык кадәр генә болытка карап торды.— Безнең туфракны учыңа кыссаң, май чыга. Шушы атнада яңгыр да явып китсә, борчак булачак әле бу басуда, Әдһәм абый.

— Бирсен иде дә бит ходай...

Талип чыраен сытты, черт иттереп җиргә төкерде.

— Гайзулла җизни янына кергәли башладыңмы әллә, Әдһәм абый? Динле кеше сымак сөйләшә башладың.

— Җизнәң янына кереп чыгарга бик ярый иде дә, вакыт җитенкерәми. Бер дә җайга килмәслек кеше түгел, минемчә. Ә менә тутаң белән сөйләшүе кыен, авыз ачарга бирми. Кан дошманы диярсең...

— Бүре баласын бүреккә салсаң да... диләрме әле?...

— Бүреккә салырдай гына түгел шул ул тутаң, Талип туган. Ә Гайзулласы аның болганчык еллар корбаны гына...

Талип дәшмәде, эче-эчкә ябышкан кузакны авызына кабып җибәрде.

— Яшисен яшәгән инде ул картлар, Әдһәм абый, инаналар икән аллаһе тәгаләгә, инана бирсеннәр. Алар буыны китүгә, Карамалыда дингә ышанучы да калмаячак. Комплексны төзеп, терлекчелекне индустриаль юлга гына салыйк. Аннары яңа авыл үсеп чыгар. Колхозчылар менә дигән бөтен шартлары булган өйләргә күчсәләр...

Харисов сул күзен кыса төшеп Талипка карап торды.

— Дингә ышанган кешегә квартир алыштыру бер почмактан икенче почмакка күчеп намаз уку, яисә сурәткә табыну гына ул. Синең җизнәң Гайзулла да, тутаң Таҗылбанат та кигән чалмаларын тиз генә салмаячаклар әле.

— Гайзулла җизни кебекләр безнең дошман була алмый. Бер аягы гүрдә торган кешедән мин курыкмыйм. Киресенчә, кызганам мин аларны. Безнең идеяне, безнең омтылышны, кая таба баруыбызны күрмәгәннәре өчен кызганам.

— Ә синең ул җизнәң кызганыч түгел, Талип. Ул, мөгаен, сине кызганадыр әле. Көн-төн чабасың, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшлисең. Ә ул бит сыпырып сәдака җыеп утыра, җитмәсә, колхоздан ярдәм өмет итә. Юк, кызганыч түгел синең ул җизнәң, Талип, кызганыч түгел. Мин аның белән бер авылда алтмыш еллап яшим. Без икебез дә бер чама кешеләр ич. Тик язмышлар, теләкләр, уй-хыяллар гына башка. Йөргән сукмакларыбыз бер, эчкән суларыбыз бер, колхоз басуыннан ашаган икмәкләребез бер. Тик кыйблаларыбыз гына икебезнеке ике якта.

— Таптыгыз дошман, Әдһәм абый. Үткәннең шәүләсе генә инде ул Гайзулла җизни.

— Ул минем идея дошманым. Авылга мәчет салырга акча бирергә ышандырган. Картлар Фәхригә иске мәчет нигезен сорап килгәннәр...

Талип кулын селекте, ашыкмый гына машинага таба китте.

— Иртәгә бу кырга комиссия җибәрергә булыр. Тикшереп идарәгә житкерсеннәр.

— Син беләсеңме эле Гайзулла җизниеңнең кем икәнен? — дип, баштагы сүзен дәвам иттерде Харисов.

— Әллә соң тотып үзен Себергә озатабызмы? Мәчет тә салырга җыена икән...

Бикмуллин партком секретарен кинаяләп үрти иде. Алар арасында бәхәс еш кына булгалый. Бәхәс житдирәк төс ала башладымы, Талип аны көлке белән бетерергә тырыша иде.

Талипта Харисов дорфарак кыланыш күрә. Ләкин эшенә дәррәү, кыю тотынганы өчен, аннан да бигрәк тотынган эшен җиренә житкермичә тынгы белмәгәне өчен ул аның бу кимчелеген гафу да итә иде. Әле булса хәтерендә: Талип Белгород өлкәсенә барып кайтты. Биш йөз баш савым сыерлык сөт комплексы проектын кулына төшергән. Район идарәсенең план бүлегендә өч көн, өч төн югалып кайтты да идарә утырышы җыйды. Комплекс салу турында карар чыгарылды. Ышандырды бит идарә членнарын, тәмам котыртты. Аннары районга чапты. Әмма Хөснетдинов аның күчәр башын сындырып җибәргән. Имеш, безнең көч житәрлек объект түгел бу. «Берек» моңа керешсә, район колхозларына бирелә торган бөтен төзү материаллары шунда кереп бетәчәк. Бәясе дә җилле: бер миллион сум. Бу инде «Берек»нең бер еллык кереме дигән сүз.

Тотынган, үзе инанган эшен ташлый торган кешеме соң Талип! Харисовның үзе белән үк Казанга китте. Тәкәбберлек, кыюлыкны Талип инде кешедән сорамас. Башта алар госпланда, министрлыкта булдылар. Анда гына хәл итә алмагач, тагын берничә урынга кереп зарландылар. Анда да нәтиҗәле сүз ишетмәгәч, өлкә комитетына юнәлделәр. Шунда Харисов тагын бер тапкыр инанды: Талип, кая гына бармасын, кемгә генә кермәсен, өмет өзми, ышанычын югалтмый.

— Юк, Әдһәм абый, шундый республика да бер комплекслык материал бирә алмаса! Акча туздырып, үкчә ите ашатып нигә килдек соң без монда?!.

Чал чәчле, йөз-кыяфәтен күрү белән кешедә хөрмәт тудыра торган Харисовны тикмәгә генә үзе белән йөртми иде председатель. Башта ул сүзне олы кеше итеп аңа бирә, аннары гына үзе гәпләшә башлый.

Өлкә комитетына керер алдыннан Ирек мәйданындагы Ленин һәйкәле янында ял итеп утырдылар. Һәйкәл тирәсендә кәрзин-кәрзин чәчкәләр, хозурлык, тантана — һәммәсе бергә. Секретарь аларны сәгать дүрттә кабул итәрмен дип ышандырган иде. Офицерлар клубы өстендәге электр саннары белән язылган сәгать әле өчне генә күрсәтә.

Әдһәм алҗудан кымырҗып торган аякларын сузыбрак җибәрде. Аяк астында уралган күгәрченнәргә кесә төпләрендә качып калган бөртекләрне сипте.

— Хәйран калырлык та инде бу шәһәр күгәрченнәре, билләһи, бер дә курыкмыйлар. Үзләре тагын пошмас җаннар...— диде Талип, утыра торгач, аннары өлкә комитеты бинасына күз салды да:— Биредә дә очына чыга алмасак, иртәгә Мәскәүгә китәбез, Әдһәм абый,— дип куйды.

Бу ике-өч көн эчендә Талип йөзгә-биткә ябыгыбрак китте, чырае үзгәргән, күз төпләренә шәмәхә төс иңгән иде. Аңа комплекс җене кагылган — шуннан башка һичбер нәрсә күрми һәм күрергә дә теләми иде кебек.

— Вәгъдә бирсәләр, нишлибез инде?

— Госпланнан язулар алабыз да кайтып китәбез, Әдһәм абый.

— Бу гостиницада төн буе күзгә йокы керми.

— Шау-шуга шулай ул, Әдһәм абый. Бүген дә булмаса, минем бабайларга барып йокларбыз. Аларда тынычрак.

— Ничек тә хәл итәсе иде инде.

— Ни әйттең иде дә бит, Әдһәм абзыкаем,— Талип тез башына шап итеп сугып алды.— Шуңа шаккатам мин: шул эшкә район үзе биш куллап алыныр урынында безне чаптыра.

Талип утырган җиреннән торды да, кулын артка куеп, арлы-бирле йөренергә тотынды. Харисов утырган эскәмиягә берәү килеп арка терәде.

— Их, Әдһәм абый, эшкә кыю керешү, аны тиз тоту кайчакта бик җитми шул әле бездә. Әйтик, госплан, министр шуны хәл итә алмый идеме? Әзер проект бар, сметасы исәпләнгән. Кайда да булса ниндидер бюрократ аяк чала. Кодрәтем җитсә, себереп кенә алыр идем мин шуларны. Һәм утыртыр идем урыннарына чын мәгънәсендә эш кешеләрен.

— Безгә кузгалырга вакыт түгелме инде, Талип?

...Менә алар кабул итү бүлмәсендә утыралар инде. Талип ниндидер тартыну тоеп, төп-төз итеп утырган килеш, башын-муенын бормыйча гына стенадагы рәсемнәрне күзәтте. Харисов бераз дулкынлана, секретарь ягына кергәч әйтәсе сүзләрен барлый кебек иде.

— Хәл итмәсәк, бүген үк кайтып китәбезме? — диде ул утыра torгач.

— Син дә картайдың, Әдһәм абый, Галимә апаны сагына башладыңмы әллә?

— Картлык сиңа килмәс дисеңме?!

— Килерен килер инде ул, Әдһәм абый,— Талип күлмәк якасын тарсынып, муенын як-якка боргалап алды, алай да җиңеллек тоймагач, өске сәдәфен ычкындырды.

Ишектән секретарь килеп керде, «Исәнмесез!» диде дә кабинетка үтте. Аның артыннан ике якка ачылышлы, кара күн тышлы ишеккә кабул итү бүлмәсендәге булышчы юнәлде. Бераздан ул әйләнеп тә чыкты.

— Рәхим итегез, Алексей Михайлович сезне көтә!

Талип Әдһәмнең янбашына терсәге белән төртеп алды.

— Әйдә, сез алдан керегез, Әдһәм абый.

Харисов бер канаты ачык ишеккә юнәлде. Талип аңа иярде. Озын бүлмә буйлап түргә уздылар.

— Исәнмесез!

— Исәнмесез, иптәшләр, әйдәгез, үтегез, утырыгыз,— дип секретарь икесе белән дә кул биреп күреште.— Ялгышмасам, «Берек» колхозының партком секретаре... иптәш Харисов?

— Һәм шул колхозның председателе Бикмуллин,— дип өстәде Харисов.

— Я, иптәшләр, йомышлар нинди? Сөйләп җибәрегез, тыңлап карыйк.

Талип, утырган урынында борсаланып, Харисовка ым какты. Янәсе, әйдә, син башла. Харисов, өсте ялтырап торган өстәлгә куллярын салып, тамак кыргалап алды.

— Партиябез Үзәк Комитеты...

Талип партком секретарена кулындагы папканы селкеп күрсәтте. Бу — кыскарак тот, вакытны бушка әрәм итмә дигән сүз иде.

— Без, Алексей Михайлович, комплекс төзергә исәп тотабыз. Тик менә эшне безнең файдага хәл итүдә булышучы тапмыйбыз. Гафу итегез, әңгәмәне зардан башларга туры килә, шуның өчен сезгә кадәр җиттек тә. Колхозыбызның дүрт мең гектар чәчү җире бар, болыннарыбыз шактый, сугарулы көтүлекләр булдырдык. Ә сыерларны сугышка кадәрге ысул белән үрчетәбез һәм савабыз. Белгород өлкәсендә комплекслар сала башлаганнар. Анда булып, һәммәсен күреп, Бикмуллин иптәш шул комплексның проектын алып кайтты. Без дә тотынып карар-

га телибез. Тик менә күчәр башларыбыз орынып тора, фатиха бирүче кирәк.

Секретарь Талип кулындагы папканы үрелеп алды. Комплексның гомум күренешенә, детальләренә, сметасына күз йөртеп чыкты. Аның шулай дәшми-тынмый кәгазьләр күзәтеп утыруына Талипның эче поша башлады.

— Безнең шартларга ничегрәк җайлашыр икән соң бу комплекс, иптәш Бикмуллин?

— Җайлаштырырлык булмаса, Алексей Михайлович, без сезнең алга килмәгән булыр идек.

— Бер гектарга күпме ит җитештерәсез?

— Унике центнер тирәсе. Комплекс булгач, бу сан егерме центнерга җитәчәк,— диде Бикмуллин нигәдер ашыга төшеп.

— Әгәр без фатиха бирсәк?

— Материал гына кирәк, Алексей Михайлович, эшчене үзебез табабыз. Районыбыз үзәге эшчеләр поселогы бит.

— Бер эшче генә хәл итмәс бит бу мәсьәләне. Иң әүвәл районадагы колхозара төзелеш идарәсен нигездән ныгыту кирәк булыр. Блок, балка, панельләр белән эш ничек торыр? Ә кирпеч булыр.

Талипның күгәрә төшкән иреннәренә алсулык йөгерде, муены сузыла төшеп, кан тамырлары беленеп калды.

Секретарь кнопкага басты, кемнедер чакырды. Бераздан кабинетка юан-таза гәүдәле берәү килеп керде.

— Григорий Иванович, менә бу проектка күз төшерегез әле, безгә сезнең фикер кирәк. Хикмәт менә нәрсәдә: проектта каралган тимерле бетон әйберләр безнең республикада житештереләме? Җитештерелсә, кайда?

Григорий Иванович кәгазьләрне җентекләп карап чыкты.

— М-м-да, Казан ЖБИ сында бу проекттагы детальләр эшләнә.

— Ә Әлмәттә?

— Әлмәттә? — Григорий Иванович чәнчә бармагы белән колак артын кашып алды.— Казан ЖБИларын быел үзгәрттеләр. Әлмәт исә моңа киләсе елда гына керешәчәк.

— Ә Түбән Камада ничек?

— Бу детальләрне хәзерлиләр анда.

— Информациягез өчен рәхмәт, Григорий Иванович.

Григорий Иванович чыгып киткәч, секретарь терсәкләре белән өстәлгә таянды, бер тын маңгаен угалап торды.

— Тәвәккәлләдек болай булгач, иптәшләр. Ләкин бер нәрсәне истән чыгармыйк: авырлык — сезнең җилкәгә!..

Коридорга чыккач, Талип:

— Сиздегезме, Әдһәм абыйсы, ничек эредән җибәрдек, ә?

Харисов җавап бирмәде, маңгаен җыерып тирән итеп сулап кына куйды. Шулай да баскычтан төшкәндә әйтте:

— Чиләнәселәребез алда әле, Талип туган, ул комплекс белән. Шапырынырга ашыкмыйк.

...Ызан буенда, борчак басуына карап, әнә шул чакны исенә төшерде Харисов.

Рә тавы иңкүлегендә комбайн күренде. «Башкортстанда уракка төшкәннәр», дип уйлады Харисов. Урман полосасы буйлап зур тизлек белән чапкан мотоциклны күргәч, Талипны куып җитте.

— Агроном килә түгелме?

— Үзе бугай,— диде Талип.— Бик әйбәт. Уракка төшү мәсьәләсен сөйләшербез. Бишегендә кем? Хатын-кыз түгелме?

Мотоцикл килеп тә җитте. Мидхәт бишектәге кызга төшәргә ярдәм

итте, аннары алар машина янында басып торган председатель белән партком секретарена таба юнәлделәр.

— Исәнмесез!

— Шөкер әлегә,— диде Талип, Харисовтан соң таныш түгел кыз белән күреште.— Кем дип белик инде бу чибәрне, Мидхәт?

— Шәфкать туташы, больницага практикага килгән. Менә кырларыбызны күрсәтергә алып чыктым әле,— диде Мидхәт, үзе авызын җыя алмыйча елмая иде.

— Ярар, Талип абыеңа акланып маташма, күрмәгән-белмәгән кеше белән мотоциклга утырып кырга чыгарга башына тай типкәнме әллә аның! — диде Талип, аннары кыздан сорады:— Кәфия апаң янында практика үтәсең инде алай булгач? Хуш. Бәлкем әле, ошап китсә, Карамалыда да калып куярсың, ә? — Практикант кыз иңбашларын сикертеп алды, каш астыннан гына Мидхәт ягына карады, оялып китте, бит очларына алсу төсләр йөгерде.— Ярар, анысын уйларга вакытың булыр әле, шулай бит? Ә хәзер менә нәрсә, сеңелем...

— Дания,— дип Мидхәт аның исемен әйтте.

— Менә нәрсә, Дания сеңелкәш, син әнә ул ызан буенда чәчәкләр җыя тор, ә без бер биш минут кына киңәшеп алыйк. Нишләргә икән синең белән, җибәрергәме Карамалыдан, юкмы?..

Председательнең болай сөйләшүенә уңайсызлана калган кыз китеп баргач, Талип, соклануын яшермичә, кызның ак чалбарына, сары-күк төскә гөлҗимеш чәчәкләре төшкән кофтасына карап торды.

— Сылу, бик сылу кыз тапкансың, Мидхәт... Я, нишлибез? Башлыйбызмы? Башкортлар әнә теземгә салалар! — диде Талип, борчак басуына ишарәләп.

— Борчакның өлгерү срогын тотуы кыенрак шул. Астагы кузаклары туенган була, ә өстәгеләре эч җыеп кына килә.

— Борчак, Әдһәм абый, ике срокта өлгерә: аскы өлеше үзенә, өскесе үзенә. Без аның тегесен дә, монысын да кулдан ычкындырмаска тиеш. Ә бу басуда ни асты юк, ни өсте юк. Силоска чабып алудан да әйбәте булмас. Тәкә борын Бакиров ашлама салдырып чәчтергән булса, без бу хәлгә калмаган булыр идек, Талип абый,— диде Мидхәт, тавышын күтәрә төшеп.

Талипның чырае сытылды, йөзе караңгыланып китте.

— Куй, үткән белән булышма. Егылганны кыйнамыйлар. Силоска чабып салырга да — вәссәлам! Менә бүгеннән үзеңә ирек бирәм, иген игү белән син командовать ит. Туфракны да үзең теләгәнчә эшкәртерсең, ашлама салуны да үз кулыңа ал, сортлар сайлауны да, кыскасы, урып-җыюга кадәр син хуҗа. Ә хәзер,— Талип Мидхәтне чәчәкләр җыючы Дания ягына таба борып куйды,— кызың янына элдерт. Күрсәт кырларыңны. Үзең утырткан мең төп каенны да күрсәт. Күрсәт-күрсәт, үз кулың белән утырткан агач кадерле була ул...

Мидхәт аптырабрак калды, партком секретаре ягына күз төшереп алды. Секретарь уч төбе белән авызын каплап, мыек астыннан гына елмаеп тора кебек иде.

— Рәхмәт, иптәш Бикмуллин, күрсәтермен,— дип, Мидхәт китеп барды.

— Быел өйләнсәң, өй салып бирәбез үзеңә,— дип калды аның артыннан Талип.— Шулай бит, Әдһәм абый?

— Ә бит, Талип, теге вакытта егетебез каеннарны белеп сирәкләткән булган. Юкка рәнҗеткәнбез. Күрәмсең, агачлар сирәкләнмәгән турыдагы борчакны, рәтле силос та алып булмаячак.

— Инде ачуым сүрелә башлаганда гына, зинһар, ут салма әле йөрәккә, Әдһәм абый. Кеше ялгышмый буламы!

— Юкка кайнарланма. Синең кебек җитәкчегә таләп зур хәзер. Ялгыштың икән, җавап та тота бел.

— Болай булгач, быелгы отчет-сайлау җыелышында авыз чайкаучыларга азык булачак икән. Боерыгыма сукыр көйгә иярегез дип беркемгә дә әйткәнем булмады минем. Әйбәт инициативаны беркайчан да тыймадым. Менә цехлар оештырырбыз да бөтен кырчылык эшен агрономның бер үзенә йөкләрбез. Уңыш өчен тулысы белән ул җавап бирер. Һәрберебез үз урынын белеп эш итәр...

## 26

Эссе, ай-һай, эссе булды бу урак өсте! Чикерткә-корт ауларга, шул җайдан бөртек-башак чүпләргә төшкән карга-чәүкә канатларын салындырып, томшыкларын ачканнар, тәмам әлсерәгәннәр, җим эзләүдән бигрәк, җиләс һава көтәләр, яңгыр яумасмы дигәндәй, күккә караплкарап алалар иде.

Комбайн өстендә тузан болыты. Кыздыра кояш, югарыга үрмәләгән саен усаллана, зәһәрләнә бара. Шулай да «Колос» комбайны кабинасында җиләсрәк. Түбә өстенә беркетелгән һава кудыргыч талгын гына җил өрдерә, тик Зариф аны тоймый иде. Аның ялангач тәне кояшта чуен төсле булып каралган, маңгаенда бөрчек-бөрчек тир-тузан, иреннәре яргаланган. Кояш, ниндидер афәт китерергә теләгәндәй, рәхимсез кыздыра да кыздыра. Зариф бер урап килә дә җир башындагы су мичкәсенә башын тыгып ала. Кайнар тәненә чиләк белән су коя.

Комбайн көйле эшли. Зарифның күзләре — тасма булып барабанга агыла барган тезмәдә. Тезмә калын. Әмма, нык җилләнгәнгәме, мотор көчәнми, җиңел тарта. Зарифка кайчак эсселек нәкъ әнә шул тезмәдән күтәрелә кебек тоела башлый иде.

Зарифны агроном кишәрлек башында көтеп алды. Ул, мотоциклын нәкъ Зариф җыеп килгән тезем ягына туктаткан да җиргә берәм-сәрәм коелган кузакларны учына җыя иде. Комбайн якынлашуга: «Туктап тор әле»,— дип ишарә ясады.

Башта Зарифның башына мондый уй килде: «Курмәмешкә сабышып, узып китәргә, тик йөгерсен арттан!..»

Тик нигәдер алай итмәде, моторын баса төшеп туктады, барабанга эләккән саламның үткәнен көтте, аннары двигательне сүндерде. Кичкә кадәр бу кишәрлекне бетерер ул. Башак калдырасың дип бәйләнсә генә инде, комиссия җибәреп җәфаласа?..

Комбайнын ул юри агроном янына житәр-житмәс туктатты, юри аның үзе килүен көтте. Ләкин агроном ашыкмады, шуңа Зариф үзе җиргә сикерде, биленә бәйләгән кыска җиңле күлмәген чишеп алды да тузанын каккалап торды. Моны да ул агроном аның янына килсен өчен эшләде. Мидхәт якынлашкан саен, аның йөрәген ачу уты көйдерде. Һич нишли алмый ул Бәдретдинов гәүдәсе күзенә чалыну белән, әйләнә дә үткәндәге партия җыелышы күз алдына килә.

— Исәнмесез, Зариф!

— Исән булсак ни дә сезгә, исән булмасак ни. Юллар безнең икебезнең ике якка юнәлгән.

Агроном аның тел очындагы кинаяле үртәүне ишетмәгәнгә салышты.

— Күпме чыга? Иртәнге якта мин килә алмадым.

— Утыз бишләр тирәсе булыр.

Агроном аңа якынрак килде, тик аның җил кискән тутсыл йөзендә Зариф уйлаган, Зариф күрергә теләгән усаллык чалымнары күренмәде.

— Кузаклар калгалый, бу комбайн да шулай койгач, башкаларга ни сан.

— Гаеп бездә түгел, «Колос»ның хидере ялап алгандай итә, тезмә салучыларда гаеп,— диде Зариф.

— Талип абый каршы төшкән булды, звеноларга бүлеп чаптырырга иде исәп. Хәзер әнә гаепләр кеше дә юк. Ундүрт комбайн, ундүрт кеше.

— Гаепләргә остарып киттегез әле, бер дә яман!..

Агроном дәшмәде, офык читендә куера башлаган болытларга карап торды.

— Кузак җыярга әллә кайчан мәктәп балаларын җибәрергә кирәк иде.

— Сөйләштем, иртәгә чыгарга тиешләр.— Агроном Зарифның күзләренә карады.— Сезгә сортлы арышны турыдан суктыруга күчәргә туры килер, иптәш Бакиров.

— Менә бу кишәрлекне бетерәм дә күчәрмен.

— Юк, хәзер үк кирәк.

— Кем боерыгы?

— Минеке,— диде агроном, учындагы кузакларны комбайн барабанына ташлап.

— Ә мин бармасам?

— Бармый хәлегез юк, иптәш Бакиров, чөнки сортлы арышка башка комбайнны кертә алмыйбыз.

Зариф җилкәсен сикертеп куйды, кулындагы күлмәген иң өстенә ташлады.

— Менә бу кишәрлекне бетерәм дә төнгә күчеп куярмын.

— Хәзер үк күчәргә туры килер.

— Әй, сөйләшәсез дә соң, иптәш агроном! Надзиратель генә булып эшлисе икән дә, нигәдер агрономга укыгансыз.

— Бу боерык, иптәш Бакиров. Сортлы арыш бүген суктырылып ындыр табагына кайтарылырга тиеш. Бүген-иртәгә яңгыр буласы.

— Ай-һай, малай, эшләр кая таба китте, әй!

Зариф агрономга төксе генә итеп карады.

— Әйдәгез, әйбәтләп аерылышыйк, Мидхәт. Үлеп үрә торсагыз да, ятып ялынсагыз да, мин сез әйткән җиргә күчеп китмим бүген. Инде алай икән, председательдән язма боерык китерегез. Күчсәм дә, аның боерыгы белән генә күчәчәкмен, ишеттегезме? — Зарифның җилдән-тузаннан күгәрчен күзедәй кызарган күзләре түгәрәкләнеп китте, борын яфраклары калтыранды, яңак сеңерләре уйнап тора башлады.— Сезгә Кыяр тавындагы арышны җыярга кирәк, ә миңа менә бу кишәрлекне бетереп, бүген төнлә төп группага барып кушылырга боерылган...

Зариф, тәкәллефсез генә, китәргә дип борылган иде, агроном аның җилкәсеннән эләктереп алды.

— Я хәзер үк Кыяр тавына китәсез, иптәш Бакиров, я бүгеннән бу комбайнда эшләмисез!

— Ә-тә-тә! — Зариф юри гаҗәпсенгән булды, аскы иренен бүлтәйтте.— Сез куймадыгыз мине бу комбайнга, сез алмассыз да, менә шулай, дус кеше?!

Зариф агроном кулын җилкәсеннән сыпырып төшерде.

— Тәнемә кеше кулы тисә, уч төпләрем кычыта башлый минем. Мөмкин булса, кыскарак тотыгыз әле сез бу ыргакларыгызны!

— Бакиров, сез миңа һаман да уч тотасызмы?

— Сезгә? Минме?

Таз тавы ягындагы офыкта, кара чаршау булып, болытлар кабара иде. Агроном шул якка күз салды. Зариф та карап-карап куйды.

— Бакиров,— диде агроном инде басынкы тавыш белән.— Китегез, хәзер үк китегез арыш җиренә.

— Боерык китерегез.

Зариф комбайнга таба кузгалды. Агроном аның тутсылланып пешкән киң аркасына бер мизгел карап торды.

— Туктагыз!

Зариф аны гүя ишетмәде дә, китүен белде. Кайчандыр анын өстенә көрәкләп пычрак өйгән агрономны Зариф гомумән өнәми иде, күрде исә, тәне кымырҗый башлый, түзмәм, кыйнап ташлармын дип, тизрәк китү ягын карый иде. Әле дә ул китүне хәерлерәк күрде. Ә бит җилкәсенә кулын куйгач та, көчкә тыелып калды, чак кына киерелеп сугып җибәрмәде.

— Туктагыз дим, Бакиров!

Мидхәт аны куып житте, комбайн күперчеге алдына чыгып басты һәм күзләрен очкынландырып:

— Хәзер үк утырыгыз да Кыяр тавына китегез, ишетәсезме?!

— Ишетмәгән кая, саңгыраумы әллә мин. Тик мин сезгә бик аңлаешлы итеп әйттем: бармыйм дидем! — Зариф, күзләрен чекерәйтеп, ямьсез итеп елмаеп куйды.

— Юкса, мин комбайн белән үзем китәм.

— Э-э, юк инде, аңысы булмастыр! — Зариф агрономны сул кулы белән бер якка этебрәк җибәрде. Таза иде Зариф. Юка гына гәүдәле Мидхәткәме аның белән алышу. Ләкин кайчак беләк түгел, йөрәк җиңә, диләр бит. Мидхәт авышып киткәндә генә күперчек тоткасына ябышып өлгерде һәм бер аягын баскычка куйды.

— Комбайнга утырмыйсыз!..

Зарифның беләк мускуллары биешеп куйды, ул сүгенеп ташлады һәм агрономны йолкып алды да, җай гына күтәреп, бер читкә бастырды.

Бер-берсенә кычкырышудан комбайн янына машина килеп туктаганны сизми дә калдылар.

— Исәнме, Зариф дус!..

Шофер Габбас Зарифның ялангач җилкәсенә кулын китереп салды. Башта Зариф та, агроном да, ни булганын аңламыйча, күзгә-күз карап каттылар, аннары исләренә килделәр бугай, Зариф агрономның изүен ычкындырып, кулларына карап алды, ябышкан нәрсәнедер сыпырып төшерергә теләгәндәй, ике кулын да чалбарына сөртештерде.

— Саумы, Габбас! — диде ул, ниһаять.— Борчак алырга килдеңме? Минем бункер да тулмады бит әле.

— Булган борчакны бушатып алыгыз, ул хәзер Кыяр тавына сортлы арышны урырга бара. Сез дә шунда барырсыз,— диде агроном, һични булмаган кебек.

— Әй, син, ашыкма әле ул тиклем боерык бирергә, үс бераз!

— Китмисез икән, үзегезгә үпкәләрсез,— диде агроном һәм ачу белән шофер егеткә кычкырды:— Нәрсә катып торасың, куй машинаңны мөшкә астына!

Моңа кадәр песи кебек кенә йөргән агрономның тамагы чатнаганчы җикерүенә шофер Габбасның да ачуы килде.

— Бар икән күрәселәр,— диде, йөгерә-атлый машинасына элдерде һәм, моторын үкертеп, әрҗәсен мөшкә астына китереп тә куйды.

— Бушатыгыз!

Агроном белән Зариф янә күзгә-күз карашып, сөзешеп алдылар. Әмма икесенең берсе дә комбайнга таба кузгалмады. Ахыр килеп, Мидхәт түзмәде, җил-җил атлап күперчеккә менеп китте.

— Нәрсә булган аңа, нинди черки тешләгән үзен? — дип сорады Габбас, Зариф янына килеп баскач.

Зариф дәшмәде. Ул битараф бер кыяфәттә комбайнга, мөшкә астындагы машинага, Зур күл буена кадәр сузылган теземнәргә күз йөртеп чыкты. Аннары карашын ерактагы болытларга күчерде. Болытлар торган саен куера бара. «Яңгыр явар микәнни?» дип уйлады Зариф, ишләргә белмичә баскан урынында бер тын таптанып торды.

— Ни булды? — дип, Габбас аның терсәгенә кагылды.

— Кирәкмәс, Габбас дус, әйтеләсе әйтелде бугай инде.

— Җуләрләнмә. Түрәләр килә дә китә, безнең брат кала бирә. Өр-яңа комбайн бирделәр үзеңә. Кыяр тавына китәргә куша икән, китә бир. Соң сиңа барыбер түгелмени, сантый нәмәстә!

— Кирәкмәс, Габбас, үгетләмә.

Болытлар кояшны тәмам томалап алды. Көн караңгыланып китте. Ләкин һавада бөркүлек кимемәде, киресенчә, тагы да эсселәнә төшкән кебек булды.

Бункерда борчак бетте, күрәсең, мотор гүләве сүрелде. Зариф моны, артына әйләнеп карамаса да, двигатель тавышыннан ук сизде. Шул мәлдә Зариф башында үзе дә аңлап бетермәгән бер уй туды: йөгереп менәргә дә, агрономны рульдән йолкып төшереп, хидерны күтәрергә һәм зур тизлек белән Кыяр тавындагы арышны суктырырга китеп барырга! Колхоз өчен ул арыш бик кадерле нәрсә. Күз карасыдай карап үстерделәр. Әйбәт кенә җыеп алынса, быел арышны гел сортлыдан чәчтерергә мөмкин булачак. Шуны белә торып нишләде соң әле ул?!

Зариф шулай дип уйлады, әмма үзе авыл ягына таба атлавын дәвам иттерде. Инде комбайн китте дә бугай, тавышы сүрелгәннән-сүрелә бара. Хәзер инде йөгерсә дә җитә алмас. Дөрес, басу уртасында агрономның мотоциклы калды калуын.

Айлар буе явым-төшем булмаганга кипшереп, калын тузан утырган юлдан атлаганда, Зариф ни эшләп ташлавының асылына төшенеп җитмәгән иде әле. Чынлык җитми кебек иде, гүя ул төшендә генә шулай эшләде. Ләкин кайта-кайта зиһене ачыла башлады. Күңелендә кайнаган нәфрәт уты сүрелә төште, йөрәген борчу, пошыну, үкенү-үртәлү, көенү кебек тойгылар биләп алды.

«Дөрес эшләдеме ул? Егетлекме бу?»

Юл читенәрәк чыкты, кыска итеп кыркылган камыл эченнән китте. Баш иелгән, кәеф — хөрт. «Нәрсәгә тагын, эшнең асылына бакмастан, киреләнеп китте соң әле ул? Шул кирелеге, үзсүзлеге аркасында ничәмә тапкыр янды бит инде, менә тагын!»

Җилкәсендә тузан-майга буялып керләнеп беткән күлмәк, аягында — автол-май сеңүдән күнгә охшап калган чүпрәк тышлы җиңел туфли. Чәч-башы тубал сыман тузган, күз төпләре кымырҗый, әчетеп-әчетеп куя. Әллә тузан тулган, әллә эсседән шулай.

Түзмәде, тагын борылып, Таз тау ягына китеп барган комбайнына карады. Талип «Колос»ка утыртканда Зарифка: «Иң яхшы комбайн бирдек үзеңә, кара аны, сынатма»,— дигән иде. Комбайн Таз тауны урталай кисеп үткән юлга җитеп бара иде инде. Шул якта куерып-кабарып килгән болытлар көл төсенә кереп сыегая баралар. Таз тауның төньяк итәгендә — карабодай басуы. Ул кue чәчәктә — ак җәймәдәй дулкынланып ята. Ахрысы, ул тирәдә җил уйный: карабодай кыры чайкала, төсләрен алыштырып, тирбәлеп-тирбәлеп куя.

Күккә карады. Нәкъ аның баш очында канатларын җилпемичә диярлек тилгән оча. Менә ул үткер күзе белән нидер күрде булса кирәк, киң канатларын җыя төште дә таш булып аска атылды. Җиргә җитәрәк, канатларын кисәк кенә җәеп җибәрде һәм камыл арасында кыймылдаган куян баласын тырнаклары белән эләктереп алды, аннары канатларын җил-җил җилпеп күтәрелә башлады. Куян баласы чыелдап җибәрде. Зарифның йөрәге чәнчеп китте. Егет бар көченә ерткыч артыннан йөгерде, иелеп, кулына эләккән беренче ташны алды, тилгәнгә ыргытты. Тилгән табышын ташлады, әмма ерак китмәде, салам чүмәләсе башына барып кунды. Зариф килгәндә, куян баласы кан баскан күзләрен акайтып, тыпырчынып ята иде. Ертык ирен читеннән, дерелдәп торган борын тишекләреннән кара-көрән кан сарка...

Ул тагын берничә тапкыр тартышып, йомшак тәпиләре белән тыпырчынып куйды да, аякларын сузып, тынып калды. Зариф тезләнгән

жиреннән торып басты, күзләрен яндырып чүмәлә өстендә утырган тилгәнгә йодрык селекте:

— Һәй, явыз, синең дә башыңа җитәрләр әле, дөнья бу!..

Нидер сизенеп, тилгән очып китте. Зариф тынсыз яткан куян баласын чүмәлә төбенә илтеп куйды, салам белән каплаштырды. Кем белә, бәлкем гомере булып терелеп китәр.

Юлга төште. Юл читендәге күкбашлар арасында кукраеп утырган шайтан таягына басты. Шайтан таягы кан төсендәге башын тузанлы юлга салды. Ләкин, Зариф үтеп китүгә, тузанга баткан башын селкеп алды да горур рәвештә янә торып басты.

Ни арада болытлар куерып җитте. Ни арада зәһәрләнеп кыздырган кояш юкка чыкты. Карабодай басуы ягыннан борынга тәмле бал исе, яңгыр дымы килеп бөркелде. Яңгыр буласын сизепме, бал кортлары да ашыга. Олы юл өстендә яңгыр җиле өермә кузгатты. Һава тагы да бөркүләнебрәк китте һәм, яңгыр килүен сизенгәндәй, тирәюнь тып-тын булып калды. Ләкин бу тынлык озакка бармады, Зариф атлаган юл өстендә дә, ишелә-бөтерелә, өермә күтәрелде. Ул күзгә күренеп үсте, зурайды һәм күз ачып йомганчы Зариф өстенә ташланды. Өермә, иләмсез ят тавышлар белән улап, Зарифның чәчен-битен салам-солам, вак таш белән чыбыркыларга тотынды. Егетне гүя кемдер күтәреп алды, ләкин икенче мәлдә инде өермә аны узып, китеп тә барды.

Зариф ярсып тибә башлаган йөрәгенә кулын куеп:

— Тфу, җен-пәри арбасы, куркытты,— дип, колак-борыннарына тулган тузан-комны күлмәге белән сөрткәләде.

Ул авылга кермәде. Урманга юнәлде. Анда аның бала чактан таныш булган истәлекле урыннары бар. Үтереп эче поша иде. Хәзер инде ул Карамалыда кала алмастыр. Нефтькәме, берәр төзелешкәме эшкә китәр. Яздан ук шуңа алгысына иде, бу агроном, ярый, тизләтте.

Аю сукмагына төшеп, болын ягына таба атлады. Ул сукмакны үтүгә, Һаҗәр чокыры башлана. Һаҗәр чокыры. Кайчандыр шул чокырга Һаҗәр исемле бер хатын төшеп үлгән, диләр. Аның ике яшьлек баласы Корбан бабасында калган. Корбан бабай беренче председатель булган Әюп Латыйповның бабасы. Шулай дип сөйләгән иде аңа укытучы Варис абыйсы.

Зариф өйгә кайтып кергәч, аның озак йөрүенә тәмам вәсвәсәгә төшкән әбисе өстәлгә чүлмәк белән сөт китереп куйды да, күксел тамырлары беленеп торган кулларын тез өстенә салып:

— Әллә нәмәгә одакладың бүген, улым? Чапкычына ул-бу булмагандыр бит? — дип сорады.

— Юк, чапкычка берни дә булмады, әбекәй.

— Алайсам, гел юк сүд сүлиләр икән. Һи-и, бу Фәһимәне тыңласаң, исләрең китәр. Ни дигән була, имеш, син агрономны кыйнагансың, якаларын умырып бетергәнсең икән, дип сөйләй.

— Әллә соң синең башка кайгың да юкмы, әбекәй? Арыдым мин бүген, сүзең булса, иртәгә әйтерсең...

— И-и ходаем, күңелем сизгән иде аны, төшемә дә әллә ниткән куркыныч иблисләр кергән ие,— хак икән инде алай булгач. Көченә масаясың инде, бала, көчеңә! Беләк көче — җүләр көч бит ул. Атаң мәрхүм дә шулай сугышып йөрер иде, син дә аннан удмадың инде болай булгач, хәерле булсын.

...Зариф гадәттәгедән иртәрәк уянды, ләкин озак кына тормый ятты. Күзләрен көтүгә куып кергән әбисе аның караваты ягына күз атып-атып алгалады да:

— Дарифулла, Дарифулла дим, тор инде, тор! — дип эндәште.— Дәүҗан Равиле әнә мотоциклын тырылдата. Йа аллам, балам, ниткән

җан белән бу вакытка кадәр ятмак кирәк. Тор, тор, бу даман беркем дә йоклап ятмый.

Зариф сыңар күзен ачты, беренче тапкыр күргәндәй, өй түшәменә карады. Тузан бик коела башлагач, былтыр түшәм араларын кысып, акка буяп җибәргән иде, карар күзгә күңелле генә тагын үзе. Зариф икенче күзен ачты һәм әбисенә карамыйча гына:

— Бүген эшкә бармыйм мин, әбекәй, ял итәм,— дип, стена ягына әйләнеп ятты.

— Ниткән ял ди инде ул, яңгыр юк, ни юк дигәндәй. Нигә соң Дәүҗан Равиле кояш чыгар-чыкмас китеп барды?

— Ял булгач ял!..

— Кем бирде сиңа ул ялны, балакаем?

— Үзем алдым. Атнага бер көн ял итәргә хакым бармы, юкмы минем?!

Зариф сикереп торды һәм үзенең дорфа дәшүендә яманлык күреп, кире ятты. Ләкин инде озак ята алмады, торды да юынып керде, кырынгычын гөжләтеп чистарынып алды.

— Әбекәй, минем теге нейлон күлмәк кайда?

— Чынлап торып эшкә бармавыңмыни инде? — дип, әбисе мич каршыннан чыкты.

— Тәмам чат ябыштың, әбкәй, ә! Ичмасам, шушы күлмәкне үтүкләп куяр идең...

— Күр әле моны, нәмәләр кыланып куя бу! Кичә нәмә эшләдең? Көтү куганда синең өчен йөд оятымнан җир тишекләренә кереп китәрлек булдым. Кыйнамадым дигән була бит әле тагын, явыд. Теләсә кем белән якалашып йөрергә Гайдулла Кәнделеме әллә син! Әт-тәт-тә, күрче син үден, шәбәепме-шәбәя. Күлмәкне үтүклә, тегене эшлә, моны тап. Менә өйләнерсең дә хатыныңнан үтүкләтерсең нәйлүн күлмәкләреңне. Үтүгеңнең бавы шәрәләнгән, куркам мин аннан, тотынган ием, тәнемне шундаен калтыратып җибәрде, иманымны әйтеп өлгерә алмадым. Үлеп куйган булса әбекәең, нишләр идең, җуләр баш, — диде Хөббениса карчык һәм яулык очы белән күзләренә кагылып алды.

— Җитмәсме, әбекәй?! Әйтәм бит: кыйнамадым мин аны! Кыйнап ташласам, бәлкем әйбәтрәк тә булган булыр иде.

— Юк сүдме?

— Ипидер менә, чиртмәдем дә.

— Идүләренә кадәр умырып бетергәнсең диләр,— Хөббениса карчык оныгына ышаныр-ышанмас карап торды.— Китәм диеп җүләрләнеп йөри күрмә, мәңге җибәрәсем юк үденне. Өйлән. Бүген үк өйлән.— Карчык үҗәтләнеп китте, яулыгын җәһәт кенә чөеп бәйләде, күлмәк итәген ыштан бавына кыстырып куйды.— Үдем китерәм. Соң бит, балакаем, нәмәкәй дием инде үдеңә. Бусы кылый, тегесе чатан, берәүсенең авыды дур, йә кәттә, йә җылгыр. Садрый Сажидәсе — усалмы? Тәти Фатыйма кыды Ләйсән — җылгыр, чая, үтә үткер диләр, өйлән шуңа. Инде кемне эдлисең? Ниндәен кыд кирәк сиңа? Кем син ул хәтле? Кыдлар сайларлык ниндәен артык җирләрең бар?

— Туктале, әбекәй, тукта инде! Юк белән колак итемне чәйнәмә әле. Болай да, урталай суккан елан кебек, кая барырга, кем белән киңәшергә белми каңгырып йөрим, җитмәсә тагы, син каныма тоз саласың. Өйлән дә өйлән, имеш. Килен ул килер дә синең кебек сөяксез телләрне куып та чыгарыр. Шулай итәләр хәзергеләр.

Хөббениса карчык кәкрәеп каткан кыска бармакларын алъяпкыч тирәсендә кайнаштыра башлады, ни әйтергә белмичә бер тын сүзсез торгач:

— Ядмыштан удмыш юк бит инде, улым,— диде.— Кем килсә дә бәхете белән килер ие бәлкем. Нәмәләр кылыйм соң инде, аптыраганнан әйтүем. Дрә дә бер бәләкәчеңне күреп үләсем килә ие шул...

Зариф әбисенең калак сөякләре төртеп торган аркасыннан сөйде.

— Үләргә җыенма әле, әбекәй, вакыты җиткәч, боерган булса, аны-сы да булыр.

— Яшьлек яме гаиләдә. Ә син, тилекәй, әбиеңнең гүргә кергәнен көтәсең...— Хөббениса карчык тагын яулык очын күзләренә тидереп алды.— Атаңның васыятен онытма. Сугышка киткәндә анаңа, менә шунда ишек төбенә туктап, кат-кат әйтте: «Малайга үскәч әйт, миннән васыять шул: бәхет эдләргә чит якларга чыгып йөрмәсен. Бәхет бәхет туган туфракта», диде. Үде, мәрхүмкәем, бәхет-мал эдләп кайларга гына китмәде. Шахтага төшеп күмер дә чапты, урман да кисте, Себергә китеп алтын да юдырды. Дөнҗа гидде. Шуннан өдлегеп, исәнлеген бетереп кайтты, мескенкәем. Кайтты да ярты ел урында ятты. Инде сихәтләнде, инде аруланды, инде эшли башлады дип куанып торадыр иек, сугыш чыгып куйды. Баенкаматтан яду килү белән күтәренде дә чыгып китте, бахырым...

«Әбине юкка борчыйм, ахры, киткәндә генә әйтәсе булган икән»,— дип, китү турындагы ниятен әбисенә әйтүенә үкенеп куйды Зариф.

Хөббениса карчык, инде әйтәсен әйттем, керәсе кергәндер дип, яңа-дан оныгына сүз катмады, стенадагы сәгатькә күз төшереп алып, табын хәзерләргә кереште.

...Әлбәттә, Талип абыйсы: «Җүләрләнеп йөрмә, ул агрономның үзен Карамалыдан куасы бар, бу ниткән башбаштаклык!» дип, Зарифны авылда калырга үгетләр. Юк инде, житте, егет сүзе бер булыр, китәргә дигәч китәргә. Дөрес, ул дәгъвасыз, талаш-җәнҗалсыз да китә ала иде, һәм эшләр азая төшкәч китәргә иде нияте, рәхмәт, агроном тизләтте.

Бәбкә үләненә мул булып чык төшкән. Баскан саен ярылып эз кала. Тыкрык буена үскән саргылт башлы ромашкаларның таҗларында да энҗе бөртегедәй чык тамчылары. Күк йөзе чалт аяз. Көткән яңгыр яумады. Сортлы арышны бүген дә урырга була иде, югыйсә.

Нидер исенә төшеп, Зариф капыл туктады. Кичә кич бит ул Әдиләгә капка төбегезгә килермен дигән иде. Эх, тинтәк тә соң мин. Ә ул чык-кан булса, көтеп торган булса? Яхшы килеп чыкмады, егетләрчә түгел. Барысына да агроном гаепле.

Идарә тирәсендә кеше-мазар күренми иде. Зариф, язган гаризасын учына кыскан килеш, болдырга менде. Бикмуллин идарәдә иде, теле-фоннан сөйләшүе тышка ишетелеп тора. Ниндидер төзү материаллары даулый.

Кергәч, түргә узмыйча, председательнең телефоннан сөйләшеп бет-кәнен көтеп торды. Талип аңа түргә үтеп утырырга ишарә ясады. Труб-каны куйгач, өстәлнең икенче башында сүзсез генә утырган Зарифка карап торды.

— Я, сөйләп җибәр, батыр, ни бүлешмәдегез анда агроном белән кичәгенәк?

— Бүлерен бүлдек бугай инде. Менә китәргә исәп,— дип, Зариф бөгәрләнеп беткән гаризасын өстәлгә җәеп сыйпаштырды да председа-тельгә сузды.— Берәр яры чыгып эшләргә ният...

— Димәк, чын-чынлап китәргә уйладың?

— Кайбер сәбәпләр мәҗбүр итә.

— Һм-м...— Председатель гаризаны укып чыкты.— Җилле егет тә соң үзең, Зариф. Ифрат та җилле. Батырлыгың-көчең белән масаясың димме.

Юк, Талип аны, ул уйлаганча, үгетләми иде, киресенчә, мыскыл итә кебек иде әле. Зарифның кисәк кенә кәефе китте, һәм ул, ни әйтер-гә белмичә, иреннәрен кыймылдатып, башын түбән иде.

— Калсаң, теш ыржайтырлар дисең инде? Хәлеңне аңлыйм. Дөрес-лекне күкрәк кагып кына исбат итә торган чор үтеп бара шул, дускай.

Таякның саллы башы һәр вакыт шундыйлар сыртына төшә хәзер, заманалар алышына тора бит, сизәсеңме бераз шуны?

— Сизмәгән кая! Тик юкка хафаланасыз, Талип абый. Барыбер китәм мин.

— Юллар кая таба инде? Нефть эшенәме, Түбән Кама тирәсенәме, арыракмы?

— Рөхсәт итсәгез, Талип абый, мин бу сорауларыгызга җавап бирмәс идем.

— Әйе шул, муен синдә бар, камыты табылыр.— Председатель гариза почмагына «Рөхсәт итәм» дип кул куйды, числосын да онытмады.

— Мә, ал. Ләкин белеп кит: авыр миңа сине җибәрүе, Зариф. Эшләүчедән бигрәк акыл сатучылар күбәеп бара колхозда.— Талип урыныннан торды, Зариф янына килде.— Тик, дускай, әйләнеп кайтыр ниятең булса, белеп кит, якын иттем мин сине, үз иттем, туп-туры үзебезгә кайт.

Талип читкә карады, баш селкеп, кашларын сындырып алды. Аннары Зарифны ишеккә таба этебрәк җибәрде.

Зариф каерып ишекне ачты, болдырга чыгып басты. Томыраеп кояшка карап алды, аннары, кире йөгереп кереп, кадрлар бүлегендә утыручы кызның алдына гаризасын җәеп салды һәм:

— Эшләп куй, кичкә килеп алырмын,— дип китеп тә барды.

Идарә каршына дөбер-шатыр итеп йөк машинасы килеп туктады. Кузовтагы савымчы кызлар, болдырдан төшеп килгән Зарифны күргәч, бермәлгә гаҗәпсенеп калдылар. Арадан берсе:

— Карагыз әле, карагыз, Зариф абыйны күрегезче, уттай урак өстендә кияү егетедәй кыбырсып йөри түгелме?

— Күрегезче эреләнүен. Исәнме, Зариф абый!

— Ару кебек болай.

— Аруың җиттемени, шуңа комбайның ташлап кайттыңмы?

«Ләйсән бит бу, кай арада белеп өлгергән», дип уйлады Зариф, торган саен үҗәтләнә барды.

— Өйләнергә йөридер лә ул, кызлар.

Зариф бер сикерүдә болдырдан төшеп, кузов читенә тотынды, машина өстенә менеп тә басты.

— Кайсыгыз кияүгә чыгарга кычына? Их-ма!..

Кызлар, икегә аерылышып, алга китеп өелделәр, кабина түбәсе күренмәс булды. Арадан Ләйсән дигәне батырайды, түшен киереп, башын чөя төшеп, бөерләренә таянган килеш, һавалана-һавалана Зариф янына килде.

— Әйдә, үзем чыгам, тәки быть!..

— Башта биеп күрсәт.

Ләйсән, уттай кара күзләрен уйнатып, кызларга карап алды.

— Кызлар, такмак!.. Биетеп аласың инде алай булгач?

Ләйсән, кулларын кош канатыдай җилпеп, такмак көенә биеп китте. Ул чынлап та кош кебек иде. Җайга гына тыпырдый-тыпырдый, гәүдәсен боргалый-уйната, әле кызлар янына килде, әле Зариф ягына күчте. Әйләнеп алган чакта аның кыска итәкле күлмәге зонт сыман җәелеп-җәелеп китә, шул мәлдә Ләйсәннең ак тез башлары, матур ботлары күренеп кала.

Кызлар, аңа дәррәү кул чаба-чаба, икенче такмак әйтә башладылар. Ләйсән инде башкорт биюе көенә тыпырдап китте. Аннары кинәт кенә Зариф алдына тып итеп китереп басты да, күзләрен уйната-уйната, башын кырын сала төшеп:

— Җырлап та биримме, Зариф абый? — диде һәм күзләрен очкынландырып такмакларга керешге:

Сыер савып карадың,
Кәҗә савып карадың,
Әлегә кадәр буйдак йөреп,
Таптың кызның харабын...

— Я, Зариф абый, әйт сүзеңне! — диде аннары мутланып.

Кызлар шаркылдашып көлеп җибәрделәр. Зариф уңайсызланып кул селтәде, кузов читенә тотынды. Шул вакыт аның күзе кабинага сөялгән Әдиләгә төште.

Йөрәге жу итеп китте егетнең, моны күреп кызлар да шым булдылар. Әгәр Әдилә Ләйсән җырының мәгънәсен аңлаган булса...

Зариф, төшә башлаган җиреннән туктап, Әдилә янына килде. Әдилә терсәге белән кабинага таянган, алга таба караган иде.

— Исәнмесез, Әдилә!

Кызлар, Зарифка кабина яныннан урын биреп, арткарак күчтеләр.

— Саумысыз...

— Әдилә, — Зариф кызлар ягына күз салып алды, — Әдилә, әллә калырга булдыгызмы?

— Әйе, Зариф, калдым. Ә сез китәсезмени?

Кызлар пырх-пырх көлешә башладылар. Кем әйтмешли, җырның ертыгы юк, Зариф Ләйсәнгә үпкәләмәде, ә менә Әдиләне күрүгә, аның бәгырен гүя үткен пычак телеп үтте. Яхшы түгел дип тә уйламый бу чытлыкай Ләйсән. Белә торып, үз алдында...

Гадәттә, кызлар авыл егетләренең чит-ят кызлар белән йөрүен яратмыйлар, шундук чеметтереп җыр чыгаралар, булдыра алган кадәр үч алырга тырышалар. Бу очракта Ләйсән кызлар теләген үтәүче генә иде.

Зариф әнә шул хакта Әдиләгә әйтим генә дигән иде, болдырда шофер Габбас белән председатель күренде.

— Бу ниткән туй тагын?! — диде Талип, моңа чаклы сыер савучы кызларның болай йөрүләрен күрмәгәнгәме, гаҗәпләнә калды.

Барысы өчен дә һаман бер Ләйсән кычкырды.

— Талип абый, сугарулы җәйләүгә төшкән идек. Менә Зариф абыйның китәсен ишеттек тә... җибәрмәгез үзен, Талип абый, китсә өйләнеп китсен!

Талип җиңелчә генә янындагы шоферны этәреп җибәрде. Янәсе, әлдерт бу тирәдән тизрәк. Габбас машинасы янына йөгереп килде, кабина ишеген ачты, анда берәүне күрмәгәч, авызын турсайтты. Кузовка үрелеп карады һәм кирәкле кешесен кызлар арасында күрүгә, каттә генә боерган булды.

— Таибә, ишетәсеңме, хәзер үк кабинага төшеп утыр!

— Төшми ул анда. Телең озын, телең тыя белмисең, ди. Яныңа кызлар утырткачы сөйләшергә өйрән, дускаем! — диде һаман шул бер Ләйсән.

— Һәй, чиркәү чәүкәсе, чәрелдәгән була бит әле. Синнән кем сорый!

— Менә кем сорый! — дип Сажидә исемлесе Габбасның шап иттереп баш түбәсенә сугып алды. Кызлар пырх-пырх көлешергә тотындылар. Сыер савучылар арасында юанлыгы, тазалыгы, шуның янына үтә юашлыгы белән исеме чыккан Сажидәдән моны көтмәгән Габбас башта күзен челт-челт йомгалап аңа карап торды, ахырда айнып китте бугай, яман итеп сүгенергә дип авызын ачты, әмма сүз дә әйтеп өлгерми калды — Сажидә аңа тагын җилле генә берне ямады. Бу юлы инде Габбас тәмам телсез калды. Ялт кына кабинасына чумды. Ачу белән ишекне шапылтатып япты, стартерын гөжләтеп җибәрде һәм, дөбер-шатыр китереп, машинасын кузгата башлады.

— Хушыгыз! — диде Зариф әллә кызларга, әллә бер Әдиләгә һәм, кузов читенә тотынып, җиргә сикерде. Ул да түгел, Зариф басып торган урында әчкелтем төтен калдырып, машина олы юлга таба китеп барды.

Машинадагы кызларның чуар яулыклары арасыннан Зариф тик бер кешене — Әдиләне генә күрде. Яшь хатынның җилкәсенә сибелеп төшкән коңгырт-кара чәчләре машина җилендә ялкынга охшап җилферди иде.

Нииндидер бер мизгел эчендә Зариф хәтта ул чәчнең исен тойгандай булды. Күптән түгел генә алар Зур күл буена төшеп утырганнар иде. Караңгы. Күл өстендә балыклар чумып куя, адашкан үрдәк килеп төшә дә «ба-ак!» дип аваз сала, иптәшен эзли иде. Зур күл өсте кургашындай кара-күк. Алар икәүдән-икәү генә игә-иң терәлеп утыралар. Зарифның йөзенә Әдиләнең чәчләре кагылып-кагылып китә. Юк, әллә ни вәгъдәләр дә бирешмәделәр кебек. Тик бу кичне Зариф яуда җиңеп чыккан мәргәндәй хис итте үзен. Ул үзенә тиңе булмаган көч килүен тойды. Үзенең шәхсән бер теләгенә ирешүдән туган эгоист көч-гайрәт кенә түгел иде бу. Бу чын мәгънәсендә аның өлешенә тигән бәхет иде. Кеше гомерендә мәңге онытылмас хисләр ташып торган минутлар була. Мөгаен, ул минутларны Зариф беренче тапкыр шул күл буенда кичергәндер. Күңелендә һәрчак кечтеки генә кимсенү тоеп йөргән,— аның тиңнәре өйләнешеп, ике-өч бала үстерәләр иде инде,— шуңа карамастан, үзен ифрат горур тоткан, шул ук мәлдә бераз серлерәк табигатьле, кирәкмәгән тәвәккәл, орды-бәрдерәк холыклы, ә инде эшкә килгәндә күп сөйләүдән бигрәк эшләп күрсәтергә яратучан Зариф шушы очрашудан соң Әдиләне үземнеке итеп йөри башлаган иде. Тик ул да аның китүенә бик өзгәләнмәде. Кешедән оялуымы, кичә кич чыкмаган өчен шулай кыландымы? Әй, нигә соң әле ул бер балалы хатын өчен баш алып кайгырта! Бетәсеме бу дөньяда чәчбиләр!..

Шулай дип үз-үзен юатса да, Зарифның бәгырен нидер тырнап-тырнап куя. Шулай ук Әдилә аның бәгыренә эз дә салып өлгердеме? Их, бу дөньяны!.. Кызык та бу кызлар, китәргә йөрүемне кай арада ишетеп алганнар? Бер дә бүтән түгел, көтү куганда әби тараткан. Һәй, бу авылны да инде, бер очында тамак кырсаң, икенче очында сөрән салалар.

Аның җилкәсенә кемдер кулын куйды. Артында кемнеңдер басып торуын сизсә дә, Зариф әйләнеп карамаган булды. Ул белде — аның җилкәсендә председательнең кулы иде.

— Чынлап торып китәсеңмени инде болай булгач? Гаризаны кайнар кулдан гына язганыңны белмим дип уйлавыңдыр инде. Әллә минем кабул итүемне ошатмадыңмы?..

Председатель аңардан сорашмый, гүя үзалдына сөйләнә иде.

— Кирәкмәс иде, Зариф, — дип дәвам итте председатель. — Ашыкма әле син алай. Китүеңә бер агроном сәбәпче икән, сине дә, аны да бизәми бу хәл, бер дә егетлек түгел бу. Монда бит әле без дә бар. Әдһәм абыең, мин, Равил...

— Китсәм ерак китмим бит мин, Талип абый. Колхозара төзелеш идарәсенә урнашырга исәп. Шул ук үзебезнең комплекста эшләргә туры килмәгәе әле. Тәк што, зрә борчыласыз, Талип абый. Ерак китәргә исәп юк минем.

— Әйе, районнан ерак түгел, кайта-килә йөрергә дә була булуын. Тик барыбер инде... Китүченнәрнең берсе дә кайтмый әнә. Шартларны житкереп бетерә алмыйбызмы шунда...

— Кем белә, бәлкем әйләнеп тә кайтырмын әле. Дөнья бит ул...

## 27

Бар да табигый, заман стилендә иде. Талип үзе көне-төне эштә югалса, яңа больницаны өлгерткәч, Кәфия дә еш кына анда төнгә дә калгалый башлады. Нигәдер кичә дә кайтмады ул. Хатынының хәлен

белергә теләп, Талип иртән эшкә барышлый больницага кереп чыгарга булды.

Иртә иде әле. Кояш яңа чыгып килә. Больница тәрәзәсе каршындагы агачларда өздереп-өздереп кычыткан чыпчыгы сайрый, карр да карр кычкырышып баш очыннан гына каргалар очып үтә. Түбән очта һау-һаулап көтүче аваз сала. Кыр ягыннан борчак җирен тырмалаган тракторлар гөрелтесе ишетелә.

Талип, авыруларны уятмас өчен, оекчан гына Кәфия бүлмәсенә таба узды. Ишек ярым ачык иде, шакымый-нитми генә бүлмәгә килеп керде дә баскан җирендә катып калды. Кәфия бүлмәсендә Казан галиме Латыйпов утыра, аның каршысында, өстәл янында — Кәфия, өстәл өстендә чык тамчылары да кипмәгән чәчәкләр бәйләме ята.

— Исәнмесез, хәерле иртә!

Талип түргә узды, галим белән кул биреп күреште дә Кәфиягә карады.

— Әллә ул-бу булдымы, кунарга да кайтмадың?

— Гайзулла җизнине китерделәр. Невроз. Көчкә тынычландырдым үзен,— диде Кәфия. Урыныннан кузгалып, өстәлдәге чәчәкләрне тумбочка өстендәге сулы вазага утыртты, аннары тәрәзәдә бәргәләнгән күбәләккә күзе төшеп, аны тотты һәм ачык форточкадан ирекка җибәрде.

Кәфиянең төн йокламый чыкканнан соң агарынып калган йөзендә әлеге чәчәкләргә соклану, күбәләкнең ирекка чыгуга дәртләнеп очып китүенә куаныч күреп, Талип бер мәлгә аптырап китте. Иллюзия түгелме, аның Кәфиясеме бу? Бу иртәдә ул Кәфиясен бөтенләй башка яктан күрде. Һәм гүя үзе өчен ниндидер ачыш ясады. Ул бит аңа ничәмә еллар авылда яшәп, ичмасам бер тапкыр да чәчкә җыеп алып кайтмады. Ә бит болынга көн аралаш төшә диярлек. Юк, үкенү тоймады ул, шулай да аңа уңайсыз булып китте.

— Кәфия, бүген мин обедка кайталмамдыр. Әлмәткә китәм, нигәдер төзелеш материалларын тоткарлыйлар.

— Тәмам башың әйләнде инде шул комплекс белән!

Талип, хатынына җавап бирүне артык санап, бәрхет пинжәгенең сәдәфләрен ычкындырып утырган Гарифка таба борылды.

— Гариф Эюпович, агрономыбыз борчак җирен сөрдереп, ашламалап арыш чәчәргә исәпли, ул-бу чыкса булышырсыз әле үзенә. Киңәшсабакка мохтаҗрак чагы егетнең...

— Ул басуның картограммасы әзер, килсен, карасын, аңлатырбыз, нигә аңлатмаска, — диде Гариф, нигәдер пинжәк сәдәфләрен бер каптыра, бер ычкындыра башлады.

— Әйтермен мин аңа, керер ул сезнең яныгызга.

— Мальцев алымнары белән хыяллана ул егетегез. Терентий Семенович күрсәткән алымнарга карап туфракны эшкәртү өчен махсус сабаннар, лущильниклар, үткен тешле авыр тырмалар кирәк. Мальцев әнә шундый коралларга йөз тота. Агрономыгызга бу эшне башлап җибәрү өчен иң әүвәл сезнең ярдәмегез кирәк, Талип Кәрамович. Сезнең ярдәмегезгә мохтаҗ кебек ул егет миңа.

Талип ни әйтергә белми чарасыз калып, галимнең урта бер җире эчкә баткан иягенә, ялап алгандай кырынып куйган яңагына, чалара башласа да куе һәм дулкынланып килгән чәченә карап торды.

— Мин аңа ул коралларны табып бирермен, Гариф Эюпович. Тик аптырыйм, нигә ул бу турыда минем үземә әйтми. Гомумән, ул эшләр белән безнең инженерыбыз шөгыльләнә. Ярый, хушыгыз, юл кешесенең юлда булуы әйбәт, — дип, Талип ашыгып чыгып китте.

Кәнзел энисен өйгә ашыктырды. Ул менә-менә үзен алырга милиция киләсен белә, шуңа кадәр әтисе Гайзулладан алтынның кая күмелгәнен белергә тели иде. Кая күмелгәнен белер, икенче төшкә яшерер, аннары биш елын утырып кайтса да үкенмәячәк. Алтын дигән нәрсә аны тәмам сихерләде, хәтта төрмәгә утыруы да аңа ул хәтле авыр фаҗига булып күренмәде. Аннан күпмедер срогын тутырыр да кайтыр ул — чөнки тырышып эшләр. Шуннан соң әтисе белән энисен алып Урта Азиягә китәр. Менә дигән йорт сатып алырлар. Кәнзел муллалыкка укырга керер.

— Инәй, Хәсән абзый чынлап та алтын алып кайтты микән?

— Белмим, балам, мин берни дә белмим. Атаңнан сорарсың.

— Инәй, Шакирҗан кем ул сиңа?

Таҗылбанат улы авызыннан бу сорауны ишетүгә сискәнеп китте.

— Беркем дә түгел. Мин кәнсәләрдә сәркәтип булып эшләгәндә авыл Советы председателе иде.

— Димәк, син аны беләсең?

— Ярдәме тимәсме дим, балакаем. Кайчандыр бабаңнар нигезен алып бирергә ярдәм иткән иде ул безгә. Сине коткарырга теләвем. Район прокуроры иде бит ул, хәзер пенсиядә ди әнә.

— Белмим, инәй, безгә изгелек эшләүдән куркыр ул адәм...

Кояш инде югары күтәрелгән, тиздән халык төшке ашка кайтыр. Күк йөзе зөбәрҗәттәй зәңгәр, кыйбла ягында болытлар кабара. Яңгыр киләсен сизеп, әтәчләр кычкыра, бакча башындагы өянкедә ала карга каркар эндәшеп куя.

Арт капкага җиткәч, Таҗылбанат Кәнзелне туктатты.

— Балам, атаңа каты бәйләнмә. Язган булса, болай да әйтер ул.

— Әйтер, — диде Кәнзел, мунча янында йөргән әтисенә күзләрен чекерәйтеп караштыргалады. — Әйтер... Ә серен гүргә алып китсә нишләрсең?..

Әнисе дәшмәде, килешеп башын иде.

Кәнзел өчен шунысы да бик җиткән иде. Ул энисен култыклады да, очкынланып торган күзләрен аңардан алмыйча, мунчага якынлашты. Аларның кайтуын күреп, Гайзулла, җир казыштырган көрәгенә таянып, карчыгы белән улы килгәнне көтеп торган итте.

Таҗылбанат соңгы тапкыр улына ялварулы караш ташлады. Кәнзелнең күзләрен күрергә теләде.

— Улым, балам, атаңны җәберләмә. Әллә гайбәт, әллә чын.

Кәнзел өчен тик бер генә юл бар иде: әтисенең алдына тезләнеп, ялынып, ялварып, алтынның кая яшерелүен белү һәм табу белән аны икенче урынга яшерү. Ул кайтканчы бу картлар әллә тора, әллә юк. Югыйсә, Шакирҗан кебек кеше сере ачарга өйрәнгән хәйләкәргә әтисенең чишелеп куюы да бар бит. Ә калганы? Калганы турында ул әлегә уйларга теләмәде. Кирәк дип таба икән, ул атасын матчага асып булса да алтын турында әйттерер.

Шунда кылт итеп аның башына яңа бер уй килде. Нигә әле, тиктомалга дигәндәй, төрмәгә утырырга тиеш ул? Нигә аңа өмет өзәргә? Барырга да Тәзкирә алдына тезләнергә, гафу итүен сорарга, ялынырга-ялварырга, еларга, риза булса, өйләнәм дип әйтергә.

Кинәт кенә күңеленә килгән бу уйдан Кәнзелнең кәефе җиңеләеп китте. Хәзер ул әтисе янына туктар, аның кулындагы көрәкне алып, тиз-тиз генә казыштырыр да, энисен алдан җибәреп, әйдә әле, әти, кереп бергәләп чәй эчик, дияр. Әтисен култыклап алыр һәм... Юк, кергәч, чәй янында сорар.

— Исәнме, әтәй? Каяле, үзем казып ташлыйм.

Кәнзел Гайзулланың кулыннан көрәкне алды да ике-өч минут эчендә әллә никадәр җир актарып ташлады.

— Нәрсә утыртырга исәп, инәй, бу җиргә?
— Әтәң кишер сибәрбез дигән иде.

Гайзулла иркенләп бер елмаеп куйды. Яралы йөзенә бик сирәк була торган ягымлылык, мөлаемлык чыкты.

— Нигә соң миңа гына әйтмәдең, әтәй? Кичәгенәк үзем казып ташлаган булыр идем.

Кәнзел эсселәде, пинжәген салып, сукмакка ташлады, уч төпләренә төкереп, тагын да дәртләнебрәк казый башлады.

— Бүгенгә җитеп торыр. Кыяр түтәлен иртәгә казырбыз, — диде Гайзулла, туфраклы кулларын ышкыштырып. — Каты бит җире, бигрәк кәсле, вакламасаң, кишер түгел, әрекмән дә үсмәс...

Гайзулла мунчага кереп китте, кулларын юып чыкты. Тамырлары кабарып торган кул аркасы белән сакалын сыйпаштырды, сәлперәйгән киез эшләпәсен күтәрә төшеп, җыерчыклы маңгаен ачыбрак куйды.

— Җитеп торыр, улым, җитәр. Дөнья эшенең бетәсе түгел аның. Анасы, бар син, булмаса, кереп чәй куя тор.

Таҗылбанат улының сукмакта яткан пинжәген иелеп алды да, беләгенә салып, җил-җил атлап арт капкага таба китте.

Гайзулла аңа өметсез бер төс белән карап калды. Таҗылбанатның бөкресе чыга төшсә дә, йөзе чибәр иде әле. Гайзулла аны үз гомеренә яратып туймады. Берәр сәбәп чыгып, Таҗылбанат бик чәпчи башласа, Гайзулла, һич югы, дәшми, янсә чыгып китә иде. Ә менә малаеннан бераз курка төшә иде ул. Аерата төрмәдән кайткач явызланды Кәнзел. Дорфа сөйләшә, еш кына салып кайта, тамак төбе белән җикерә. Нигәдер әнисенә түгел, атасына җикерә. Төрмә яман итте кешене, Гайзулла моны белмиме! Шуның өчен улына каршы әйтми иде ул. Шундый миһербансыз минутлары була ки Кәнзелнең, күзләре тона, ни эшләгәнен белештерми башлый иде. Бер тапкыр шулай кәҗәләре кайтмый йөдәтте. Бер көн көтүдән кайта, өч көн биләмдә югалып йөри. Теленнән тапты Гайзулла, бу турыда Кәнзелгә әйтте. Кич, көтү кайткач, Кәнзел ишегалдына чыкты да этисеннән:

— Шушысымы? — дип, ристан кәҗәне күрсәтте.

— Шул үзе, муены астына килгере, мут җан!..

— Хәзер өйрәтәм мин аны! — дип, Кәнзел кәҗәне «кәҗ-кәҗ»ләп чакырып алды да, мөгезеннән тотып, әүвәл баш очына күтәрде, аннары бар көче белән тирес өстенә атып бәрде. Лапылдап барып төшкән кәҗә тамак ертып бакырып җибәрде. Әмма торып качарга өлгермәде, Кәнзел аны тагын эләктереп алды һәм, чөйдән бау алып, кәҗәне абзарга кертте, мөгезләреннән өрлеккә элеп куйды, аннары келәттән каеш чыбыркысын алып чыкты, — бу чыбыркыны Гайзулла, очына тимер чыбык кыстырып, үзе үргән иде, колхоз атларына суккан саен кан чәчрәп чыга иде, — һәм кәҗәне акыртып яра башлады. Кәҗә башта яман бер ят тавыш белән кычкырды, ләкин тамагы чатнадымы, кисәк өнсез калды, күзләрен кан басты, куркудан «чикләвек»ләрен коя башлады.

Бу җәзаны карап тора алмады Гайзулла, арт бакчага чыгып китте. Улының миһербансыз булуына Гайзулла әнә шунда инанган иде.

...Өчәүләп чәй эчәргә утырдылар. Таҗылбанат чәшкәләргә чәй койды, табынга бал, май, ак күмәч, карлыган вареньесы, чәк-чәк китерде.

Гайзулла, бисмилласын әйтеп, тәмләп чәй эчәргә кереште. Тезләрен як-якка җибәреп сәкенең түрендә утырыр ул, киң төпле ак ыштанын юри күрсәтергә теләгәндәй, тез өстенә сөлге ябарга онытыр. Чәйне бик ярата ул. Чәй, бал-май, ак күмәч булса, атналар буе аш ашамаса да: «Аһ, шулпа пешермәгәнсең, карчык», — дими. Таҗылбанат үзе дә шулпа дип атлыгып тормый. Тик яшьләр генә төш-кич аш пешерерләр иде.

— Хәзинәңне җыебрак утыр әле, әтәй, болай бер дә килешми...

Тажылбанат дәшмәде, авыз чите белән генә елмайды да чәй эчүен белде. Ул каш астыннан гына әле улына, әле картына күз төшереп ала, әмма бер кәлимә сүз катмый.

Гайзулла тирләп-пешеп чыкты, Тажылбанаттан сөлге сорап алып, әйбәтләп сөртенде.

— Минем хәзинә — урынында, менә син үз хәзинәңә үзең хужа була алмадың, хурлыкка калдык...

— Әтәй, — диде Кәнзел. — Инәй әйтә, безнең бер пот алтын бар, ди. Расмы шул?

Әгәр дә мәгәр улы: «Әтәй, безнең өйгә ут капкан, янабыз!» — дисә, Гайзулла бу хәтле шаккатмас иде. Малаеннан бу сүзне ишетүгә, Гайзулланың чәшкә тоткан кулы, калтырап, авызына җитәр-җитмәс туктап калды, аның йөзенә гүя ак җәймә яптылар, Гайзулла бер мәлгә телсез калды.

— Хакмы шул, әтәй?

Ниһаять, йөрәге тибеп куйды, Кәнзелнең соравы аңына барып җитүгә, картның кулыннан чәшкәсе төшеп үк китте. Чәшкә нәкъ варенье савытына төшкәч, ашъяулыкка куе кан сыман сыекча түгелде.

— Малаебызны утыртмакчылар, атасы, — диде Тажылбанат тыенкы-сабыр гына. Төшкән чәшкәне алып куйды, тыныч булырга тырышты. Әмма карчыгының тавышында эчке бер калтырау тоеп, Гайзулланың колаклары шаулый башлады, башы чатнап китте.

— Ни-н-ди ал-тын ул та-гын?..

Үз тавышын үзе ишетмәде, күз төбе көзән җыергандай тартышып куйды.

— Хәсән абзый алып кайткан алтын.

Гайзулла кан баскан күзләрен тутырып улына текәлде, тез өстендәге бармаклары калтыранып биешергә тотынды.

— Кая күмдең аны, әтәй?

— Атасы, улыбызны тагын төрмәгә утыртмакчылар бит әле. Тәзкирә өчен диләр. Киткәнче аңа әйтергә иде инде, әллә яши алабыз, әллә юк, аллаһе тәгаләдән әҗәл кайчан килгәнне кем белә.

— Нинди алтын, шаштыгызмы әллә сез? — Гайзулла күңелендә яман бер зәһәр ярсу кузгалуын тойды. Ул тамак төбенә тыгылган төерне йотып, сакалына кагылып алды.

— Әтәй, — диде Кәнзел. — Сез яшисен яшәгән инде. Кемгә саклыйсыз ул хәзинәне? Миннән дә якын кемегез бар?

«Кемең бар, имеш, — дип уйлады Гайзулла, Кәнзелнең зәһәрләнә барган йөзенә күзен салгалап. — Кемнең кеме булмас бу дөньяда!»

Шулай диюгә Гайзулланың күңеленә Сабирасы, улы Кәримулласы килде. Сабирасын үтерүенә күңеле рәнҗеми аның. Заманы, көне шундый иде: я ул — Гайзулланы, я Гайзулла — аны. Ә менә малае Кәримулланы үзенә охшатып, әле булса бәгыре телгәләнә Гайзулланың. Кәнзел исә бөтен холкы-фигыле белән үзенә охшаса да, төсе-йөзе белән тәмам Тажылбанат иде. Тик андамы соң хикмәт?! Хикмәт ул хәзинәне кулыннан ычкындырырга теләмәвендә иде. Гайзулла яшәячәк әле. «Төрмәдән дә әйләнеп кайтырсың, насыйп булган булса, өйләнерсең дә, улым, ә әлегә ул кадәр хәзинәне кулыңа төшерергә ашыкма».

Гайзулла, карчыгыннан ярдәм сорап, ялварулы караш ташлады, һич ни белмәгәнгә салышты. Ләкин Тажылбанат шундый иттереп сөзеп карады аңа, Гайзулланың йөрәге кысылып, аркасы кымырҗып китте.

— Анасы, ниткән уй башыгызга төште сезнең, нинди алтын ул?

«Танарга, һич ни белгертмәскә» дип уйлады үзе.

Ул ике кулын күтәреп амин тотты да урыныннан тора башлады. Шунда күзе янә улына төште. Кәнзел тешен кыскан, яңак сеңерләрен

уйната-уйната, кашларын җимереп, әтисен күзәтә иде. Гайзулла аны күрмәмешкә салышты. Иплән кенә идәнгә төште, дисбесен алып, эчке өйгә кереп китте. Кәнзел аның артыннан кереп, атасының җилкәсенә кулын салды, Гайзулланың аркасы янә чымырдап китте.

— Әтәй, — диде Кәнзел, әтисен үзенә таба борып. — Бүген-иртәгә мине алып китәләр. Мин кайтканчы синең гүр иясе булып куюың бар...

Йөзе чытылган Кәнзел ялт кына әтисенең алдына тезләнде һәм аның ак ыштанына йөзен төртте. Гайзулла моны көтмәгән иде — каушый калды, калтыранган бармаклары белән малаеның чәченнән сыйпаштырды. Шулай да бәгыре алтынның кайда икәнен әйтер дәрәҗәдә йомшармады. Атаң да үләргә җыенмый бит әле, диясе килде аның, әмма уфтанудан ары узмады.

— Нинди җүләр уй керде синең башыңа, улым? Кем салды синең күңеленә бу яман коткыны?

Кәнзел башын күтәрде, әтисенең күзләренә сынап карады.

— Шакирҗан карт әйтте...

Гайзулланың эчендә нидер өзелеп киткән кебек булды һәм ул акрын гына идәнгә чүгә башлады. Һич ни аңламаган Кәнзел аның тезеннән кочаклап алды.

— Әтәй, әтәй, җаным, расмы шул?

Малаеның тавышы йомшаруын сизеп, Гайзулла ныгый төште, тураебрак басты.

— Башта Тәзкирәне эзләп тап. Алдына тезлән, ялын, ялвар, елап күрсәт, кулыңнан килгәнен барысын да эшлә. Һич югы, үзеңә өйләнәм дип әйт.

— Аннары әйтәсеңме?

— Башта эшеңне Тәзкирә белән җайла. Начар кеше баласы түгел, өйләнеп торсаң да ярар.

— Аннары әйтерсеңме, әтәй?

Каты бәгырьле кеше иде Гайзулла. Яшәү дәверендә бик күп төрле кешеләр белән очрашырга туры килде аңа, заманында шул алтын өчен генә ничәмә кешенең башына җитте ул. Ут-су кичте, гомерен кыл өстенә куеп сугышларга катнашты, ахыр килеп, ун ел гомерен Себердә урман кисеп уздырды. Ул алтын — аның гомере.

Кәнзел бер тын әтисенең тезләренә сыенып торды да, күтәрелеп, ишеккә юнәлде. Малае ишек тоткасына кулын салуга, Гайзулла:

— Туктап тор, сабыр ит, — диде.

Ике ир-атның аңлашуын ишек янында тыңлап торган Таҗылбанатның колагы торды, йөрәге тибүдән туктаган кебек булды.

— Таҗылбанат, син дим, бире кер әле, — дип дәште Гайзулла карчыгын.

Эчке өйгә Таҗылбанат керде, ул мондагы сөйләшүне белмәгәнгә салышып, малаена карый-карый түргә үтте.

— Ни бар, атасы?

— Тәзкирәгә икәү барыгыз. Кичке якта Хәлиулла янына үзем дә барып чыгармын. Семьясы ишле, мулдан яшәмиләр, әйбәт кенә бирнә әйт. Кызы да, җүләр булмаса, риза булыр...

Малай белән ана күзгә-күз карашып алдылар. Кәнзел әнисенең карашыннан: «Ә бит, бала, атаң дөрес әйтә» дигән мәгънә аңлады.

— Ярый, шулай итәрбез, — диде Таҗылбанат килешеп, картының тәкәбберлегенә кагылмаска тырышты. — Әйдә, улым...

— Ә риза булмаса? — диде Кәнзел шиккә калып.

— Булыр, — диде Гайзулла, тавышын күтәрә төшеп. — Яман атын ил өстенә чыгарасы килмәсә, риза булмый хәле юк.

Гариф халатын киде дә, сәдәфләрен эләктерә-эләктерә, коридорга чыкты. Уң кулдагы беренче бүлмәгә, Вафа янына керде. Вафа анализ ясаган туфракларның нәтиҗәсен картограммаларга төшереп утыра иде, шефы керүгә, ул торып басты.

— Утыр, утыр.

Гариф бер өем дәфтәр арасыннан җиденче кыр дәфтәрен табып алды да шул басуның тулы картограммасын икенче өстәлгә җәеп салды. Туфракның физик-механик сыйфаты, уртача дымлылыгы, төсе, тыгызлыгы, уртача җылылык режимы, җир асты суларының тирәнлеге, структур составы... күп шул туфрактагы компонентлар! Гариф, шуларның барысын да бер фокуска җыеп, хезмәт язарга тиеш: игү мәйданнарын ничек рациональ бүләргә, кайсы елны нинди культура чәчәргә, нинди ашламалар салырга.

— Вафа, җиденче басуның генетик сәләтен нинди прибор белән тикшердегез?

— Тюриннныкы белән.

— Ярый. Ә менә бу картага нигәдер җир асты сулары төшерелмәгән?

Вафа сәерсенеп шефына карады.

— Машина чакырганга атна булды инде. Әле булса сейсмографларның килеп җиткәннәре юк.

— Бүген үк телеграмма бир, минем исемнән,— дип өстәде Гариф.

— Колхоз акча күчерми, ә алар хозрасчеттагы оешма.

— Бүген үк агрономга әйт, акча күчерүнең чарасын күрсен.

— Ярый, Гариф Әюпович, әйтермен.

— Кунак йортына күчтеңме әле, һаман фатирда торасыңмы?

— Юк, Гариф Әюпович, күчмим мин анда.

— Диссертацияңне язарга шартлар бармы соң?

— Бар, Зур күл якын. Бер үземә бер бүлмә...

— Ярый, эшлә. Кыр дәфтәрләрен безгә ашыктыра төшәргә туры килер. Вакыт тараеп бара...

Гариф коридорга чыкты һәм Тамчы бүлмәсенә юнәлде. Кыз, тырышып, анализ нәтиҗәләрен журналларга төшереп утыра иде.

— Я, эшләр барамы?

— Бүген басуга чыкмыйм, эшкәртә торган көнем.

Гариф бу кечкенә буйлы кызның эшчәнлегенә соклана иде. Ул күрә: кыз үзенең хезмәтеннән тәм таба, эшли-эшли онытылып китә һәм лабораториядә куныл та калгалый.

— Уку да, эшләү дә бик кыен түгелме соң? Ярдәмче кирәкмиме үзеңә? Өлгерә алмасаң, Талип абыеңнан кеше сорарга мөмкин.

Тамчының бит очларына алсулык йөгерде.

— Бик әйбәт булыр иде, Гариф Әюпович. Өйрәнеп тә калыр иде бераз.

— Дөрес, сиңа ярдәмче кирәк, юкса, бер үзеңә генә бик авырга килә монда. Авыл хуҗалыгы техникумында читтән торып укучы берәр егет юкмы соң?

Тамчы башта бөтенләй башка нәрсә турында уйлады булса кирәк. Кинәт кызарынып китте.

— Эзләп карармын, — диде ул, нигәдер күзләрен түбән төшерде.

Гариф кабинетка күз йөртеп чыкты. Чисталык, пөхтәлек. Гөлләр, чәчәкләр.

— Диплом темасы алдыңмы соң әле?

— Җәйге сессиягә килгәч бирәбез, диделәр.

— Ә син менә бу эшеңә якынрак тема алырга тырыш. Директорыгыз кем анда сезнең, мин белмимме?

— Хәкимова Җиһан апа,— дип, нигәдер офтанып куйды Тамчы.

— Җиһан, Җиһан? — Белми иде Гариф ул кешене. — Ярый, эшлә.

Кичке якта ул үз хезмәткәрләрен кабинетына җыйды.

— Менә нәрсә, иптәшләр. Бүгенге көннән кем нәрсә эшли, планда билгеләнгән чараларны ничек үти — шул турыда әледән-әле информация тыңлый башлаячакбыз. Тоткарлыклар була икән, бетерү чарасын күрергә тырышырбыз. Я, башлап җибәр, Вафа.

Озын буен бөкрәйтә төшеп, Вафа торып басты. Яшь гыйльми сотрудникның бөтен кыяфәтендә җитдилек һәм үз-үзенә ышанып сөйләвен күреп, Гариф аны торган саен кызыксыныбрак тыңлый башлады. Вафа «тритикал»ны, ягъни арыш белән бодай гибридын, Карамалы басуларында үстереп карарга тели икән. Универсаль галим булырга исәбе. «Була бирсен», дип уйлады Гариф...

Әдилә эштән кичке сәгать сигездә генә кайтты. Өйдә журналлар актарып утырган әтисе:

— Озак эшлисең, һәрнәрсәдә режим булырга тиеш, — диде.

— Муфель миче ватылды, электрикны чакыртырга туры килде. Аннары Талип абый килеп керде. Киләсе елга өч йөз гектар җиргә көнбагыш белән йомшак бодай, солы белән сорго чәчәргә һәм шулардан алынган силосны өч траншеяга салырга тели. Район шаулатырлык сюрприз ясарга исәбе. Кукуруз дип җанга тимәсеннәр өчен эшлим, ди.

— Беләсеңме, ә бит ул хаклы. Кукуруздагы азык берәмлеге солы, көнбагыш, бодай кебек культуралардагы азык берәмлегеннән күп тапкыр түбән. Инерция белән һаман кукурузга ябышып ятуны сизә алган икән инде, ул, Әдилә, начар җитәкче түгел.

— Миңа ул шул силосларның бөтен компонентларын белергә, чагыштырма картограмма ясарга куша. Кушмый, үтенә.

— Башта ашап ал. Фәһимә апаң чыгып китте. Аш плитә өстендә, кастрюльдә.

Әдилә мич каршына керде, шалдыр-шолдыр килеп савыт-саба алды. Аннан ул бер тәлинкә аш тотып чыкты.

— Әти, сиңа сүзем бар иде.

Гариф, журналларны бер якка куеп, диванда тураебрак утырды.

— Мин, әти, бүген үз-үземә бер ачыш ясадым, — дип, сүзгә кереште Әдилә. — Талип абый ярдәм итте. Беләсеңме, нишләргә тиеш монда, әти? Кайда, нинди шартларда һәм ничек саклаганда азык үз сыйфатын югалтмый: эскерттәме, сенаж, он, оерша яисә силос хәлендәме? Һәм минем төп эшем нидән гыйбарәт бирелә, әти...

— Бу бит синең диплом эшең. Укуыңны дәвам иттерәм дисең, язмыш сиңа үзе кулын сузып тора. Тик тыкрыкларга чыгып вакытыңны гына юкка әрәм итмә.

Әтисеннән бу сүзне ишетүгә, Әдиләнең иреннәре уймактай бөреште. Ул, җилләнеп, мич каршына кереп китте. Әтисенең соңгы сүзенә ачуы килмәде аның, шулай да ниндидер кимсетү тойды. Үртәү һәм кызыксынуның да бер чиге булырга тиештер бит. Һәр кешенең иң якын туганнарыннан да яшереп йөри торган эчке серләре булу мөмкин.

Шулай да Әдилә бу кичерүен сиздермәде, мич алдында гына чәй эчеп алды да, алгы якка чыгып, бизәнергә-төзәнергә кереште.

Әтисе журнал укыштырган арада аңа каш астыннан гына карап-карап торды да:

— Чыксаң да озак йөрмә, — диде.

— Бөтенләй кайтмасам, эзләргә чыгар идеңме, әти?

Гариф, кызының тел төбеннән үртәлүен сизеп, соңгы сүзе өчен үкенеп куйды. Чәнчә бармагы белән генә чигәсенә кагылып алды. Күзе тәрәзәдән күренеп торган тупылга төште. Урамнан музыка тавышы ишетелә, кемдер гитара уйныймы, яисә магнитофон кычкырта идеме. Әйе,

биргә дә килә бу шәһәр гадәтләре. Гарифны кызының язмышы борчый иде. Теге вакытта да нидер күрми калды. Артык ышандымы шунда. Ә ул һаман бала икән шул әле.

Гөнаһлы кияүне тыя ала иде бит ул, тыя ала иде. Кысылмаган, катнашмаган булды. Әдилә инде бер тапкыр ялгышты. Житеп тормасмы? Гариф үзе бүген берәү белән, иртәгә икенче белән очрашуны гомумән аңламый иде. Жиңел мавыгулар аңа ят булды. Ул бары тик олы хисләр белән генә янды. Һәм яраткан кешесенең дә шундый ук хисләр белән януын тойганда гына янды.

Ә Әдилә әнә аңа охшамаган. Жәвит янына чапкандагы кебек, бүген тагын күбәләкләнә. Чынмы бу, әллә үз-үзен алдарга гына тырышуымы?

Сабыр ит, Гариф. Жанга чиксез ләззәт хисләре биргән һәм сине вакытлыча булса да бәхет ташкынына алып кереп киткән мәхәббәтне бер селтәнүдә ташлап буламы һәм шуның белән сихерләнгән кешене гаепләргә хакың бармы?

Бар. Бар! Чөнки ул аның баласы.

Гариф көзге каршында утырган кызына ихтирам белән карады.

— Мине дә алып чыгасыңмы?

Әдилә аңа ышанмыйчарак карап алды, авызын тотып, пырхылдап көлде.

— Ә нигә көләсең, мин бит буйдак кеше. Кич чыгарга да хакым юк микәнни әллә?..

— Чынлапмы, әтием?

Гариф сүзсез генә диваннан торды, эчке өйгә кереп киенеп чыкты.

— Я, әйдәме? Мин хәзер.

Әдилә, күзлек астыннан гына карагандай, керфекләрен челт-челт йөртеп алды.

— Әйдә соң, — диде аннары, әтисен култыклап.

Көтү кайтканга шактый вакыт үтсә дә, урамда өер-өер сарык-кәҗә йөри, тоякларын шыртлатып соңга калган сыерлар анда-санда үткәли.

Әтиле-кызлы капка төбендәге эскәмиягә утырдылар.

Авыл өстенә төн пәрдәсе иңеп килә. Жидегән йолдыз нәкъ алар утырган эскәмия каршында.

— Әллә бөтенләй калырга исәбеңме Карамалыда? Кем ул,ниндирәк кеше?

— Синең белән минем кебек үк ике аяклы, ике куллы.

— Минемчә, болай булгач, сиңа биредә калырга мөмкинлек бик үк юк түгел. Әйтик, шуңа кияүгә чыгасың да...

— Мин сине аңламыйм, әти. Мыскыл итүеңме бу? Бая булды бая, әле тагын. Минем үпкәләвем дә бар бит.

— Я, ярый, кәефләребезне бозмыйк. Мин сиңа андый сүзләрне әйтмәдем дип исәплә.

Әдиләнең иңбашына сибелгән чәчләренә сүнеп бетмәгән шәфәкъаллыгы төшкән, Рә тавы артыннан ай урагы калкып килә. Ниндидер томан эченнән гүя Гарифның Саниясе килеп чыкты, янәшәсенә утырды.

Сания артистка иде, театрдан башы кайтмады. Жәй житсә, гастрольләргә чыгып китә, айлар буе күрешмиләр иде. «Жилбәзәгрәк бит ул артист халкы, шундый хатынга өйләнүеңә үкенмисеңме?» диючеләр дә булды. Әмма күпме котkы салсалар да, Гариф Саниясенә гомере буе турылыклы булып калды. Гастрольләргә киткәч, Сания кайтыр, көннәрен көтеп ала алмый иде. Шул тиклем сагынып кайтыр иде ул! Сөепназлап, сагыну-сусауларын баса төшкәч, аякларын жыеп диванга менеп утырыр иде дә, Гарифны янына дәшеп, битләреннән сыйпар иде. Һәм исе китеп: «Карале, Гарифжан, керфекләрең озын да соң синең, кашларың да чем-кара, күзләрең куе-куе чәй төсле!» дияр иде... Аннары ни булды? Сугыш башланды. Беренче көнне үк Гариф фронтка китте. Әйе, сугыш һәммә кешене яралады — тылда идеме ул, фронттамы. Һәм, ни-

һаять, Гарифка 1945 елны да күрергә насыйп булды. Менә ул Казанда. Каршысында исә күзләре эчкә баткан, хәрәкәтләре сабыр Саниясе. Әмма ире кайту куанычыннан аның күзләреннән нур сирпелә иде. Шул көннән алып, күзгә күренеп кипкән Сания сәламәтләнә башлады, бит очлары алсуланып, гәүдәсе тулыланып китте.

Аның хәтеренә сугыштан соң яшәгән бәхетле көннәрнең берсе килә. Алар театрга бардылар. Сания сәхнәдә түгел, ә аның янәшәсендә утыра, йомшак кулын Гарифның учына салып, серле итеп иренең күзләренә карый. Театрдан алар төнге саф һава сулап, җәяү кайттылар. Гарифның аруы житкән иде, кайтып башын мендәргә тәртүгә йокыга да китте. Озак та йокламады, Саниясенең шул ук серле карашын тоепмы, күзләрен ачты. «Ачма күзләреңне, колагыңа бер сүз әйтәм, — дип пышылдады ул. — Уң колагыңа. Ату малай булмас...»

Моны ишетүгә, Гариф сикереп торды да Саниясен кулына күтәреп алды һәм, хәле бетеп, тыны кысылганчы, ишекле-түрле зырылдатып йөртте.

...Гариф уң колагын бирсә дә, Сания аңа малай таба алмады, больницага хатынын алырга килгәч, кып-кызыл чырайлы кыз төреп чыгардылар аңа.

Тик гомере кыска булды Саниясенең. Биш яшьлек Әдиләне ятим калдырып дөнья куйды.

Кеше өлешенә тигән кабатланмас бәхет бар икән ул. Гариф өчен ул бәхет Саниясе белән яшәү еллары булды. Шуннан соң ул Саниягә охшаган сөйкемле оялчан йөзле, күндәмлек, нәфислек алиһәседәй бер затны да очратмады. Мәхәббәт берничә тапкыр була дигән фикер белән Гариф килешмәде. Дөрес, якын иткән хатын-кызлары булды аның, әмма алар белән күрешүләрдән Сания белән яшәгәндәге татлы хатирәләрне сагышка әверелдереп кенә кайтты. Саниянең матур истәлекләре белән яшәве куаныч та, юаныч та, гүзәл сагыш белән дә өртелгән иде. Тол калган кайбер ир затлары кебек, моңа кадәр ялгызлыгыннан зарланмады, сукранмады, сабыр гына фән өлкәсендә хезмәт итте.

Бала да үсте. Унны тәмамлагач, кулына өлгергәнлек аттестаты тотып этисе каршына килде. «Менә, эти, мин дә урта белемле!» — диде.

Аннары кияүле булды...

Тагын ни? Ә, әйе. Кызы Әдилә кулыннан бала алуы. Кияве Җәвит бөтенләй килмәде, ә бит Гариф аңа: «Әдилә кыз тапты», — дип шалтыраткан иде. Кешелеклеген сынау өчен генә түгел, йөрәгендә аз гына булса да ата хисе бармы икән дип шалтыраткан иде. Килмәде.

Куанычы зур иде Гарифның. Ак юрганга төреп, кызыл тасма белән биләүсәләгән баланы кулына алгач, Гарифның күзләренә кайнар яшь килде, һәм ул, моны кызына күрсәтмәскә теләп, ишеккә алданрак китте.

«Әтием, сабыр итче!..»

Гариф әйләнеп карады һәм йөрәге кысылып куйды. Әдиләнең йөзендә ул шундый бер сулыгу күрде, гүя соңгы көннәрдәге Саниясе аның каршында пәйда булды.

Әдилә, «рәхмәт, әтием», дип, килеп аңа сарылды.

Әле булса күз алдында: ишекне чыгуга, Әдилә тирә-юньдәге халыкка күз йөртеп алды. Кемнедер эзләде, кемнеңдер килеп чыгуын көтте...

— Керик, эти, — дип, Әдилә аның уйларын бүлдерде.

— Әйдә соң. Әнә кемдер безгә таба килә. Фәһимә апаң да кайтып килә бугай. Бар, кер дә чәй куй, мин хәзер. Болын тирәсеннән генә әйләнеп киләм.

Әдилә өйгә керде дә, электр самаварын кабызып, ут алмыйча гына, тәрәзә янына барып басты. Күктә йолдызлар җемелдәшә. Ай чалкан төшеп, алар уйнавына кызыгып карап тора иде.

Әллә нишләтте бу Зариф Әдиләнең күңелен. Гамьсез генә сөйләшкән кебек иде, югыйсә, үзе белән. Йөрәген алгысытты да куйды. Хәзер инде әнә күңел кыллары орынмас борын зыңлап китәргә генә тора.

## 30

Көзнең бик матур көннәре була, аны халыкта әбиләр чуагы диләр. Әйтерсең җәй яңадан әйләнеп килә. Җылы, тын һавада пәрәвез җепселләре оча. Кошлар сайрый. Урман авызына килеп керүгә, аяк астында ал, сары, сипкелле эшләпә кигән гөмбәләр күрәсең. Күбәләкләр сыман очкалап яфраклар коела.

Шушындый көннең берендә Мидхәт Данияне мотоциклына утыртып кырга алып чыкты.

Яфраклары саргая башлаган каен төбендә утыралар. Әле кайчан гына алар бер-берсенә ят кешеләр кебек карыйлар иде. Хәзер исә Дания аны бик күптән белә кебек инде. Мидхәт кулларына кагылган саен Даниянең күңеленә рәхәт булып китә, йөрәге талпынып тибә башлый. Әйе, Дания аны күптән көтте. Аллага ышанмый иде ул, ә менә көткәненең чынга ашасына ышана иде.

Мәхәббәт! Менә нинди икән ул. Нигәдер сөелгән саен сөеләсе килә. Күкрәгенә кысып-кысып яратсын, сөйсен, назласын иде. Даниянең күңеле әнә шуңа омтыла, шуңа алгысына. Ул көткән кеше аның янәшәсендә бит.

Дания әтисен, әнисен исенә төшерә. Әтисе аның көн-төн эчте. Дания аның аек чагын рәтләп хәтерләми. Кайчандыр ул әйбәт кенә рәсемнәр ясаган, диләр. Хәтта институтка да кереп караган, тик укый алмаган. Дания аның слесарь булып эшләвен генә хәтерли. Әнисе аның бәлкем яхшы чакларын да белгәндер, ә менә Дания белмәде, күрмәде. Исерек чакларын гына хәтерли. Ул исереп кайтканда әнисе нигәдер дәшмәс була. Почмакка поса да өзгәләнеп лышык-лышык елый иде: «Каргалган язмышларым бардыр инде, ходаем, кайчанга кадәр шулай булыр бу!»

Шушындый гыйбрәтле хәлләрне күреп, Дания моңа кадәр егетләрдән качыбрак йөрде. Артыннан тып басып йөргән егетләр дә булды, ләкин Дания аны бераз салмышрак хәлдә күрсә, һич якты чырай күрсәтмәс иде.

— Дания, әйдә бераз йөреп киләбез...

Кулга-кул тотынышып, чокыр буйлап киттеләр.

Һава зәп-зәңгәр, аяз, самолет койрыгыннан өзелеп калган ак тасмадан башка һич ни күрмәссең. Чокыр сузыла да сузыла. Аяк астында корый башлаган үлән кыштырдый. Алда шәрә башын калкытып Таз тау тора.

— Әйдә, Мидхәт, тауга менәбез. Минем әнә теге вышканы күрәсем килә.

Байтак ара атлыйсы бар. Ләкин беләк-буында көч ташып торганда һәм янәшәсендә сөйгән кызы атлаганда, Мидхәт җиде диңгез читенә барырга да риза.

— Бер, ике, өч. Йөгердек!..

Дания алсу төстәге юбка, тәненә сыланып торган ак свитр кигән, балтырлары елт-елт итә.

Тау биек. Атлый-атлый сулыш кысыла. Шулай да тиз менделәр. Дания, хәле беткәнлеген сиздереп, вышка баганасына сөялде. Аның йөзендә шатлык нуры, ә иңбашына сибелгән чәчләре белән җил уйный иде.

Моннан караганда Карамалы авылы уч төбендәге кебек. Тау астына зәңгәр тасма сузып салгандай, Ык елгасы агып ята. Зур күл башындагы усак урманы төрле төстәге җептән тукылган келәм шикелле.

— Минем менә шушыннан кош кебек очып китәсем килә, Мидхәт. Очып китәсе иде дә, әнә теге Кушкаран тавындагы шушындый ук вышкага барып кунасы иде.

— Очар өчен трамплин кирәк. Әйдә, вышкага менәбез.

Еллар буе яңгыр астында череп каралган имән басмалар. Мидхәт менеп китте. Бер араны үтте, икенчесенә күтәрелде.

— Әйдә! Курыкма. Их, нинди хозурлык, бөтен тирә-юнь күренә.

Баскычлар шагыр-шогыр килә. Менеп житкәндә генә Дания туктады.

— Кыюрак, кыюрак!

Соңгы өч басма калгач, Мидхәт аңа өске мәйданга менеп житәргә булышты.

— Бу могжизаны тагы кайчан күрер идең әле!..

Чынлап та, офык шундый киңәйгән! Бик еракта, зәңгәр күк белән кара жир кушылган төштә, шәмәхә төскә кереп калган Кушкаран тавы күренә. Наратбаш авылы урамнарында хәтта машиналар хәрәкәтен абайлап була иде.

— Әйдә төшәбез, Мидхәт.

— Тукта, без дә бер-ике сүз язып калдырыйк. Менә кара, монда язганнар да инде. «1937 ел. Нуриәхмәт — Фатыйма». «1940 ел. Кадыйр — Сәлимә». «1941 ел. Сау бул, туган авылым. Фәтхуллин Хәбип».

— Берни дә язма, Мидхәт, — диде Дания. — Әйдә, киттек кире. Минем башым әйләнә.

Сакланып кына төштеләр. Жирдә Дания жиңел сулап куйды.

— Әй, Мидхәт, жирдә йөрүгә ни житә! Кояш та түбәнгә тәгәри бит, — диде Дания. Йөзенә сибелеп төшкән чәчен артка ташлады, үз итеп елмаеп куйды.

— Әйдә, әнә теге печән эскерте янына барып киләбез...

Эскертнең күләгәсе, кош канаты шикелле сузылып, алар басып торган төшкә хәтле килеп житкән, эскерт кичке кояш нурларында коена иде.

Мидхәт аңа иң изге теләген шунда әйтер. Кыз бит сизә: ул аңа нидер әйтергә тели, тик әйтә генә алганы юк.

Килеп эскерткә сөяләделәр. Дания печәнгә борынын төртте.

— Һай, хуш исле дә соң!..

Шунда алар күзгә-күз карашып алдылар, икесе берьюлы жиргә утырдылар, икесе берьюлы көлеп куйдылар.

— Дания, сине бу дөньяда мәңге-мәңге шулай калсын дисәләр, риза булыр идеңме?

— Бу дөнья бер безгә генә бирелмәгән шул, Мидхәт. Әнә кояш та баеды, әйдә кайтыйк инде.

— Ә минем кояшым яңа чыгып килә әле!..

Алар баеп барган кояш ягына күз салдылар. Бик биеккә, югарыга таба шәфәкъ нурлары сибелә, офык читенә гүя ки куе кызыл шәлъяулык элгәннәр иде.

— Шушында гына куныйк, Дания. Кайтып йөрмик. Яңа көн туганны каршыларбыз.

— Юк, Мидхәт... Әй, куркам мин. Төнлә мәче башлы ябалак килер. Бу аның эскерте ич.

Ул Мидхәткә шундый якын, егет аның хәтта чәч исен тоя. Нидер сизенеп, Дания торып басты. Мидхәт тә күтәрелде. Шунда ул беренче тапкыр кызны кочаклап алды... Тик кинәт каушап калды. Ни эшләргә тиеш соң ул хәзер? Матур-матур сүзләр әйтергәме, ярсып типкән йөрәкләр сөйләшүен генә тыңлап торсыннармы шулай.

— Дания... мин сине яратам... Ишетәсеңме, яратам!.

Мидхәт Даниянең үзенә таба сизелер-сизелмәс кенә сыена төшүен тойды. Аннары кыз кинәт кенә аның кочагыннан шуып чыкты да, ялгыз каенга таба йөгерде. Мидхәт аны куып житте. Сулышлары капкан хәл-

дә, икесе дә каенга сөялделәр, янә күзгә-күз карашып, елмаешып алдылар, йолдызлар калка башлаган күккә текәлделәр.

Эңгер караңгысы төшеп килә иде. Йомшак кына салкынча кичке һава бит-йөзне сыйпап узды. Мидхәт пинжәген Даниянең иңенә салды...

Мотоцикл уты әле ары бәрелеп, әле бире сугылып үзенә юл эзли. Фара яктысы буй урман каеннарын, туңга сөрелгәннән соң, күпереп калган җир өстен ерактан ялмап ала да такыр юлга сузылып ята.

Алар ишегалдына кайтып керүгә, кунак өе болдырына Хәтимә апа чыгып басты.

— Бу ниткән югалу инде, балалар? Пешергән ашларым суынып бетте ич!

— Хәзер, хәзер керәбез. Хәтимә апа.

Дания белән Мидхәт болдырга менгәндә Хәтимә апа аларга текәлеп карап торды.

— Йөри-йөри уеннан уймак чыгарып куймагыз тагын, балалар...

Дания, кемгә карарга белмичә, җәһәт кенә үз бүлмәсенә таба китте. Мидхәт Хәтимә апасы ягына усал караш ташлап алды да Даниягә иярде. Әмма ишек янында Дания аны туктатты.

— Кермә минем бүлмәгә, Мидхәт. Оялам. Хәтимәападан яхшы түгел. Өстемне алышам да чыгам. Синең дә ашыйсың киләдер бит?

Мидхәт карусыз гына үз бүлмәсенә китте.

Ашханәдә Хәтимә апа аларга аш бүлеп куярга өлгергән иде инде. Мидхәт өстәл янына утыруга, Дания дә керде. Өстендә — зәңгәргә алсу роза чәчәкләре төшкән халат, башында — кызгылт-сары яулык. Ул күзләрен күтәрми генә килеп утырды, тавышсыз гына ашый башлады.

— Их-ма, Хәтимә апа, тәмле дә соң шулпаң, яратам шул сарык ите салып пешергән ашны! Минем әни дә шулай тәмле итеп пешерә торган иде.

Мидхәт ни генә такылдамасын, Хәтимә апа да, Дания дә аңа кушылмадылар. Чәй килгәч, Мидхәт самаварга карап-карап торды да көләргә тотынды.

— Карагыз әле бу әкәмәтне. Бик мәзәк күренәсез сез бу самаварда! Көлке бүлмәсендәмени! Утыралар, мин сиңа әйтим, сөмсерләре коелып. Акча түләп кергәннәр, ә үзләре көлмиләр. Ни булды сезгә, нигә авызыгызга су капкан кебек дәшми утырасыз?

— Мансур килгән иде, — диде, ниһаять, Хәтимә апа. — Сине сорады. Нindидер чәчкеч сыныйбыз иртәгә, дигән булды.

— Иртәгә? Шәп. Беләсезме нинди чәчкеч ул, Хәтимә апа? Әгәр дә мәгәр барып чыкса, без, Хәтимә апа, язгы чәчүне бермә-бер тизрәк һәм сыйфатлырак итеп үткәрәчәкбез. Чөнки ул чәчкеч районда гына түгел, республикада юк әле. Менә нинди сезнең механизатор егетләрегез, Хәтимә апа. Гади чәчкечне бераз гына үзгәрттеләр дә бөртекләрне һәр квадрат сантиметрга сала торган могҗизалы машина иттеләр. Язга чаклы барлык чәчкечне дә шулай үзгәртеп корсалар...— дип, Мидхәт, пафоска бирелеп, әлләниләр такылдарга кереште.

— Шапырынма ул кадәр, энем, — диде Хәтимә апа, башын күтәрә төшеп.

— Әһә, сөйләшә башладыгызмы! Тагын бер ярты сәгать лекция сөйләгән булсам, разбой салуга кала иде эшегез.

Ул каршындагы Даниягә комсызланып дигәндәй карап утырды. Кыз оялды, күзләрен түбән төшерде. Мидхәт шуңамыдыр, тагын да кыюлана төште, янә такылдарга тотынды. Ләкин Дания кисәк кенә торып китте. Мидхәт исә Хәтимә апага күз кысып алды да кызга иярде. Даниянең үкчәсенә басып диярлек, бүлмәсенә килеп керде. Бүлмә эче караңгырак иде. Мидхәт кабызгычны эзләде. Моны сизеп алган Дания:

— Кабызма, Мидхәт, кирәкми. Кил бире, — диде.

Тәрәзә янына килеп янәшә бастылар. Даниянең йөзе шәфәкъ нурыннан алсуланып күренә иде.

— Хәтимә апа мине куркыта, ышанып житмә аңа, ди. Алар барысы да бер чыбыктан сөрелгән, ди.

— Минә сиңа кирәк булса! Син кемгә күбрәк ышанасың, Хәтимә апагамы, әллә миңамы? — Мидхәт почмакка барып радиоалгычны тоташтырды, бүлмәгә музыка моңы тулды. «Рөхсәт булырмы, туташ?» — дип, Дания каршына килеп басты, баш иеп биергә чакырды.

Дәртләнеп танцыда бөтерелә башладылар.

— Беләсеңме, Мидхәт, мин сине болай күз алдыма китермәгән идем. Артык житди, усал күренден син миңа автобуста.

Дания оста бии, ә биюдән алдыра алмаган Мидхәт кызның аягына баскалый.

— Бармакларымны изәсең бит инде, Мидхәт.

— Ә, алаймы, оекбаштан гына бием мин алай булгач. — Мидхәт җәһәт кенә туфлиларын салып ташлады. — Син бас хәзер минем аякка. Бас, бас, син минем аякларыма басып торасы кешем... Мин сине менә ун көн инде һәр төнне төшемдә күрәм. Өнемдә дә гел янәшәмдә йөрисең кебек. Елмайма, рас әйтүем. Әйдә, иртәгә үк язылышабыз!

— Уф аллам, Мидхәт! — дип, Дания биегән төштән читкәрәк тайпылды. — Без бит әле бер-беребезне рәтләп белмибез дә, нинди язылышу ди ул?!

— Алай димә. Мин сине күптән беләм кебек инде. Яратам, Дания. Әйбәт ир булырмын. Ышан!..

— Ә бәлкем мин бик тә явызмындыр?

— Шәфкать туташы явыз була алмый. Авырыйм мин, дәвала мине. Чирем бер сиңа гына билгеле, бер син генә терелтә аласың.

Бүлмә эче караңгыланган инде. Багана башындагы лампочкадан гына тонык якты төшә. Яшьләргә шул якты бик житкән. Дания Мидхәт янына утыруга, егетнең җилкәсенә башын салды. Егетнең йөрәге сабырсызланып җилкенде. Өнме соң бу, әллә төш кенәме?

— Бая син нидер әйтергә җыенган идең, Мидхәт?

— Иртәгә язылышырга барабыз, Дания. — Ул кызның нечкә биленнән кочып алды, чәченә борынын төртте.

— Син мине гел шулай яратырсыңмы, Мидхәт? Мин сине бик аз беләм ич әле? Шуңа карамастан, вәгъдәләр биримме?

— Әти-әниемнең гүр иясе булуларына... Кирәкми ул турыда, Дания. Ике абыем, өч апам — һәммәсе Урта Азия ягында. Ә мин менә монда килеп чыктым. Шунда төпләнергә дә исәп. Ошый миңа бу яклар. Туфрагы әйбәт. Сулары күп.

— Минем әтием дә, әнием дә исән әле, Мидхәт. Алар Октябрьск шәһәрендә торалар.

— Кайтып рөхсәт алырга исәбеңме?

— Юк, хәзер инде мин үз тормышымны үзем хәл итәрдәй яшьтә. Әти мине барыбер аңламас...

Алар, бер-берсенә елышкан хәлдә, сүзсез генә утырдылар. Икесе дә киләчәк тормышларын күз алдына китерергә тырышты.

— Соң инде, Мидхәт, бар бүлмәңә кереп ят.

— Мин бүген биредән бер кая да китмим. Тәнозын аяк очында утырып чыгачакмын. Ә син ят, йокла.

...Иртән иртүк Хәтимә апа, гадәттәгечә, Мидхәтне уятырга килде. Бүлмәсенең ишеген шакыды. Башка вакытта Мидхәт: «Уяндым, Хәтимә апа!» — дип, аваз сала торган иде, бүген исә дәшми. Әллә соң?... Кайда булыр бу? Бүлмә ишеген ачып карады — егетнең караваты буш иде.

«И-и ходаем, бу заман яшьләрен,ниләр уйлап йөриләр икән тагын? Әйтәм аны, битләренә ут капкандай кайтып кергәннәр иде, гөнаһ шомлыклары гына икән... Бергәләрдер, бер дә бүтән түгел!..»

Хәтимә апа, аяк очына гына басып, Дания бүлмәсе янына килде, шакып тормады, шыпырт кына ишекне ачты. Бусаганы атлап керүгә, ике күзе дүрт булды: хагы-нахагы һәммәсе бергә иде биредә. Яшьләр, йөзләрен-йөзгә куеп, изрәп йоклыйлар, шайтан күтәреп алып китсә дә, уяныр хәлдә түгелләр. Хәтимә апа, дәшәргә базмыйча, шыпырт кына кире чыкты да ишекне япты. Бер тын икеләнеп басып торды. Ахырда тәвәккәлләде, вак-вак кына итеп ишекне шакыды. Бераздан аны Мидхәт ачты.

— Эшкә китәргә вакытмы?

— Әйе шул, бик вакыт...

— Без өйләнешәбез, Хәтимә апа, котла!

— Өйләнәм диген, җүләр.

— Бүген үк язылышабыз. Туй Октябрь бәйрәмендә булачак. Әнием урынына иң түрдә син утырырсың, Хәтимә апа!

— Амин, тату-матур яшәгез. Яман аты чыккан кыз түгел, иншалла, холыклы булыр әле.

## 31

Бүген Әдилә фермага гадәттәгедән иртәрәк килде. Соңгы вакытта ул, бигрәк тә кар төшкәч, анализга азык-төлек, сөт алырга фермага үзе йөри башлады. Сыер савучы кызлар арасында ул күңелен ачып кайта, төрле мәзәкләр ишетә иде.

Быел кар ноябрь кергәнче үк төште. Әдилә кыш көннәрен, ак карны бик ярата. Салкын һавада туңып беткәнче йөри, өйгә кергәч, җылы мичкә аркасын сөяп, тын гына уйланырга ярата. Ул кызын, әбисен шулай сагына. Ә фермага баргач, аларны ничектер бераз онытып тора кебек.

Ферма тирәсендә шау-шу. Тракторчы егетләр силос китергәннәр, бушаталар, озак йоклыйсыз, сорхантайлар дип, терлекчеләрне үртиләр. Әдилә ярдәмчесе Гөлүсәгә силос, сенаж алып лабораториягә илтергә кушты да үзе терлекчеләр өенә юнәлде. Коры суык бит очларын рәхәт итеп чеметтереп ала, аяк астында кар шыгырдый. Болдырга менгәч, киез итеге белән ишеккә типкәләде.

— Кем анда тагын?..

Ләйсән тавышы иде бу. Әдиләнең күңеле нигәдер соңгы вакытта шул кызга тартыла. Атна-ун көн элек кенә Котдус исемле егеткә кияүгә чыгам дип шаулап йөргән Ләйсән менә ике көн инде боегып, үз-үзенә йомылып йөри. Әдилә аңардан: «Ни булды сиңа?» — дип сораган иде, Ләйсән күзләрен генә яшерде.

— Ләйсән, мин бу, ач әле.

— Кеше куркытып йөрисең шунда, — дия-дия, Ләйсән ишекнең келәсен ычкындырды. — Котдусны куркыттың әнә...

Ул шулай диюгә, ишек янәгында посып торган Котдус Әдиләгә кагылып диярлек чыгып ычкынды. Бу егетне Әдиләнең кино-мазарларда күргәне булса да, бу хәлдә очратканы юк иде әле. Ул шундый кызу ычкынды — Әдилә хәтта бите белән аның тән эссесен тоеп калды кебек.

— Качты, — диде Ләйсән, кызыл кофтасының сәдәфләрен каптыра-каптыра,— кеше күрсә, коты алына. Төн буе утырды, теттек үзе белән сөйләшеп, авызыннан сүз алырлык түгел. Көләм-көләм дә үзеннән, анналы үз-үземә үпкәләп, тиле кеше кебек еларга тотынам. Бәләкәй чакта инәй: «Кызым, мин сине артистка итәм, чаялыгың, чибәрлегең бар, бар жирең килгән», дип котырта иде.— Әдилә кергәч, Ләйсән ишекне япты, түр якка үттеләр. — Үсә төшкәч, үзем дә сәхнә-театр дип җан ата башладым. Унны тәмамлыйм да театральныйга китәм дип алгысыттым үземне. Хәзер менә башка бөтән кайгылар төште.

Ләйсән тәрәзә каршына килеп басты. Таң атып килә иде. Тоныкяктылык өй эченә үтеп керә, почмакларга үрмәли. Кайнар маңгаен пыялага терәп, Ләйсән тынып калды. Әдилә күз кырые белән генә аңа карады: кызның иңбашлары калтырый, күзләреннән яшь ага. Әдилә аптырап калды. «Их, Ләйсән, Ләйсән, мин бит синнән дә бәхетле кеше юктыр бу дөньяда дип йөри идем. Йөзләреңә чыкмас, күзләреңдә күренмәс нинди кайгы-хәсрәт төште башыңа? Синең дә эчең тулы сагышмы әллә тагын?»

— Елама, Ләйсән. Сөйлә әле миңа, бушат эчләреңне? Мин дә бит гашыйк булып караган кеше. Утларга керергә кушсалар, утка күбәләктәй ташланыр хәлләргә калганым бар. Әмма хәзер үтте, сабырландым. Яңа-яңа да, пыскый-пыскый да сүрелә-сүнә икән ул мәхәббәт ялкыннары... Өргән сулышларымнан утлар бөркелеп торган чаклар булды. Башымны Иделләргә ташларга җитештем. Алай да түздем, үткәрдем. Еламасана, җүләрем.

Ләйсән, үксүеннән туктап, уфтанып куйды. Биш бармагын тунган тәрәзә пыяласына җәеп салды. Аннары, пыялада калган кул эзләренә карап:

— Минем мәхәббәтем дә кояш карауга шушы боз кебек эреп юкка чыгар микәнни? Алай булганда нигә ул мәхәббәт?! — диде.

Әдилә кызның иңенә кулын салды, чәчләреннән сыйпаштырды.

— Кичләр җитсә, кая барырга белми аптыраган чакларым бар. Килеп утыр безгә, клубка да бергә чыгарбыз. Телисеңме, Котдусың белән үзем сөйләшәм?

— Тимә аңа, Әдилә. Мин аның белән ул солдатка киткәнче үк йөргән идем инде. Вәгъдәләр биреештек, хатлар язышып тордык. Язганнарын укысаң икән син аның, җаннарны телә менә. Кайтты, өзелеп сагынып кайтты. Инде өйләнешәбез, инде кавышабыз дип торганда гына әнисе әйткән моңа: «Я башкага өйләнәсең, я минем өемнән чыгып китәсең. Тәти Фатыйма кызы белән ишегалдыма аяк басасы булма!» дигән. Мүкләк сыер бит ул, җебегән нәстә, тугарылды да калды. Хәзер әнә үҗәтләнгән, үземә өй салам дип, агач сатып алып йөри.

— Яратуың хак булса, үртәмә син аны, Ләйсән. Йомык табигатьле кешеләр тиз рәнҗүчән булалар. Ташламас ул сине.

— Өйне салып бетергәч тә өйләнешәбез дип ышандыра.

Ишектә кулына кәрзин тоткан Гөлүсә күренде. Аның артыннан ук Фирдәүсә керде. Ул:

— Һәй, төн пәриләре, тизрәк булыгыз, сыерларны чыгардылар! — дип кычкырды.

32

Пальто якасын күтәргән, бүреген күзенә кадәр батырып кигән берәү ферма өе янында тора. Ул әле, әче җилдән ышыкланып, караңгы якка чыга, әле ишек янына кире килеп баса. Җирдән җәяүле буран себертә. Ферма өенә таба бер төркем сыер савучыларның килүен күргәч, шулай таптанып торган кеше караңгы якка шылды. Кызлар шаулашып өйгә кереп китүгә, ул яшеренгән җиреннән чыкты да, тәрәзә янына килеп, өске өлгегә сыланды. Күрәсең, ул көткән кеше өйдә утыра иде. Шуны күргәч, аның кысылган иреннәре җәелә төште, күз төпләренә җылы йөгерде.

Бераздан ул җан тынычлыгы тойды булса кирәк, тәрәзә яныннан китеп, өй стенасына сөялде, перчаткаларын салып кесәсенә тыкты да сигарет кабызды. Шуны яка эченә яшеренә төшеп көйрәтеп торганда, берәү аның дык иттереп аркасына төртте. Ярыйсы ук нык төртте, ахрысы — егет тәмәке төтененә тончыгып йөткерә башлады.

— Кемне көтәсең? Туңасың бит!..

Иөткерүдән туктагач, егет әйләнде дә тәртүченең җилкәсеннән тотып алды.

— Нишләвең бу, Фирдәүсә?

— Каравыллыйсыңмы? Мине бер дә алай сакламадың. Казан чәүкәсен ката-туңа сагалыйсың. Зариф, нигә шулай иттең? Их, Зариф, белмисең син минем ничекләр эчләрем өзгәләнгәнне...

— Куй инде, Фирдәүсә, маташтырма. Булган — үткән. Искегә тисәң, исең китәр, булганы җитеп торыр.

— Шулай ук бик тиз биздеме Фирдәүсәңнән җаннарың, Зариф? Мин сине беркемгә дә бирмим, бирмим! — Ул Зарифның күкрәгенә башын төртте дә тынып калды. — Син, Зариф, минеке, минеке генә!

— Кыланма булмаганны, тиле!..

— Тилеме?! Элек җаным иде, хәзер тилеме?! — дип, кыз башын күтәрде дә Зарифның җиңеннән тотып үзенәрәк тартып китерде.— Их, үкенепләр карарсың әле бер, җаным, үкенепләр карарсың.

Фирдәүсә кайнар сулышы белән Зарифның бит тирәсен пешерде.

— Яраттым бит мин сине, җүләрем, үлепләр яраттым. Ә ул килде дә тартты да алды. Ичмасам, кыз булса икән, бер балалы кеше калдыгы бит!..

Зариф кызны үзеннән читкәрәк этәрде.

— Бар, кит, Фирдәүсә. Яратам мин аны, йөрмә арттан. Син дә үзеңә тиңне табарсың әле. Җибәр җиңне. Җибәр дим, тиле!..

Ул җиңен көч белән йолкып алды. Борылып тәрәзәгә күз ташлады. Өйдәгеләр утырышалар иде инде. Фирдәүсә үртәлеп йөзен каплады һәм өй почмагына төртелде дә лышык-лышык елый башлады.

— Җаның юктыр синең, таш бәгырь...

— Куй инде, — Зариф тәмәке төпчеген чиртеп җибәрде, ут чаткылары чәчеп, ул кар эченә барып төште. — Яндым-көйдем дә сүндем. Булмыймы шулай?

Фирдәүсә иңбашларын дерелдәтә-дерелдәтә елавын белде, дәшмәде. Зариф уңайсызланып, нишләргә белмичә таптанып торды. Ишекне ачып яптылар. Кемдер дәште.

— Фирдәүсә, башлана!..

Фирдәүсә бияләе белән күзләрен сөртә-сөртә ишеккә таба китте.

— Мин аңа вәгъдәләшкән егетемне тартып алдың дип әйтәм. Бөтен кеше алдында хур итәм.

Зариф ике атлауда кызны куып җитте, җилкәсеннән эләктереп, үзенә таба борды.

— Башың ике булса әйт. Кара аны!..

— Бәгырьсез!..

— Беләсеңме, Фирдәүсә, — диде Зариф, тавышы йомшый төшеп, — тыңла әле мине, алгысытма күңелеңне. Әйдә яхшылап ташлашыйк. Йөрдек. Булды. Яшь чакта кем кем белән йөрмәгән дә, кем кем белән үбешмәгән. Ышан: яратам мин аны. Телисеңме, йөрәгемне ачып күрсәтәм...

Фирдәүсә бияләе белән тагын күзләрен сөртте. Аның эчендә ут яна, дөрләп-ялкынлап яна иде. Ниндидер бер мәлдә ул айнып киткәндәй булды, җилгә кайнар битен куеп, болыт астыннан килеп чыккан айга карап торды. Зарифның тәкәбберлеге аның да горурлыгына кагылды. Беренче мәхәббәте әнә ничек бетте бит. Кыз күңеленә әйтеп бетермәслек кимсенү килде. Аның йөрәге тавышсыз гына сөрән сала, сыкрый, илереп кычкыра. Ләкин бу нибарысы эчке ярсу иде. Ул борылып Зарифка нидер әйтергә теләде, әйтмәде, китәргә дип бер адым ясады, һәм менә шунда төшенде булса кирәк: бу кешедә ул күңеленең беренче сафлыгын калдыра бит. Күңеле ургылып чыккан нәфрәт хисен тыя алды. Ул бер мәлгә тынып торды да кузгалып китте.

Зарифның кыяфәтендә моңа кадәр сизмәгән горурлык, тәкәбберлек күрде һәм күңеленә нииндидер бер шом инде, әлегә үзе дә төшенеп җитмәгән югалту хисе тойды ул.

— Фирдәүсә, гафу ит... Тукта әле, тукта!..

Кыз туктады, тик борылмады.

— Фирдәүсә... теләсәң, алдыңа тезләнәм... кичер мине...

— Минем сине алдыма тезләндерәсем килми, Түбәнсенмә, егет бул.

Ул шулай диде дә ашыгып өйгә кереп китте.

Зарифның йөрәге кысылып куйды. Күңелендә үкенү-үртәлү ачысы тойды. Соңгы минутта гына Фирдәүсә йөзенә чыккан газап күз алдыннан китмәде. Ашыкты бугай, әллә нигә ашыкты ике араны өзәргә. Йөрәк дигәнең кайчакта ут кабынгандай була шул, акылга килеп җиткәнче әллә ниләр әйтеп ташлыйсың.

Зариф тәрәзә янына килде, өй эченә карады. Әнә анда Әдилә утыра. Аның йөзен күрүгә, әле генә булып алган низаг ничектер кичерәеп калды. Гашыйк чагында, акыл-зиһенне томаларлык хисләр дә була икән егет кешедә.

## 33

Әдилә өйгә кайтып кергәндә, этисе костюмын киеп алган һәм каядыр китәргә җыена иде.

— Этием, син җыендың дамыни? Ә мин ашыктым, эш чыкты, — диде Әдилә. Аның битләре алсуланган, кәефе күтәренке иде.

— Әдһәм абыең дәште. Сине көтәм, әйдә, тиз генә киен дә...

Әдилә пальтосын салып чөйгә элде, килеп, этисенең җилкенә сарылды.

— Тукта әле, — диде Гариф һәм түр якка кереп китте, аннан кулына бер төргәк тотып чыкты. — Менә сиңа Яңа ел бүләге. Кыш бабай җибәрде.

Әдилә төргәкне түземсезләнеп сүтә башлады. Төргәк эченнән җемҗем итеп торган укалы әйбер килеп чыккач, күзләрендәге кызыксыну шатлыкка әверелде.

— Укалы күлмәк!.. — Әдилә этисенең битеннән үбеп алды, аннары күлмәкне тотып эчке якка кереп китте. Көзге алдына басып, күлмәкне гәүдәсенә куеп карады. Ут яктысында укалы җепләр җем-җем итә иде. Әдиләнең шатлыгы эченә сыймады. Бүген ул бу күлмәген Яңа ел кичәсенә киеп барыр. Зариф белән биерләр...

Бер көнне аңардан Ләйсән:

— Әдилә, Зариф абый сиңа өйләнәм дисә, чыгар идеңме? — дип сорады.

Әдилә ни әйтергә белмичә аптырады да калды. Чынлап та, аның бит әле Зарифка һич ни ышандырганы юк. Дуслар булырбыз дип кенә башлаганнар иде. Хәзер исә дәртләнеп-көязләнеп аңа ошарга тырыша. Әле ничек кенә! Әллә соң яратамы, яратуымы? Болай ашкыну нигә булыр? Ник бу кадәр катлаулы соң бу дөнья! Әллә ул бер Әдиләгә генә шундый сынаулар куямы, әллә үзе катлауландырамы эшне?! Их, Ләйсән, ни әйтә алыйм мин сиңа?! Минем бит ирем бар. Беренче тапкыр иң изге, иң саф хисләреңне ачкан кешеңне шулай бик тиз онытып, икенче берәүгә кияүгә чыгам дип капыл гына әйтеп буламы?!

Түр якка Фәһимә апасы килеп керде.

— Әдилә, акыллым, әйдә капкалап ал. Яңа ел ризыкларына җитешкәнче ачыгырсың әле.

Аштан соң Әдилә көзге алдына басып озак кына бизәнде-төзәнде. Диванда сабыр гына көтеп утырган этисе аңа карап-карап алды, тамак кырды. Әдилә укалы күлмәген кигән — үзенә үлчәп теккәндәй, гәүдәсенә ятып тора. Шампунь белән юган чәчләре дулкын-дулкын булып, күпереп иңбашларына төшкән.

— Күрәм инде, эти, эчең поша башлады, — диде ул, этисе ягына борылмыйча гына. — Хәзер.

«Хәзер» дигәч тә әле Гарифка кызын ун минутлап көтәргә, журнал актаргалый торырга туры килде.

— Менә, эти, мин булдым да. Тик сине юкка көттермәдем микән?

— Нигә алай дисең? — Гариф, кулындагы журналны куеп, торып басты.— Әдһәм абыең үпкәләр. Аннары син менә моны күрдеңме әле?

Гариф аңа заказ белән җибәрелгән телеграмма бирде. Телеграмма Җәвиттән иде. Әдиләнең иннек сөрткән йөзе нигәдер агарынып китте. Рәсемдә: күктә ай йөзә, Кыш бабай белән Кар кызы пар атка утырып баралар иде. Күзе телеграмманың сүзләренә төште: «Әдилә, сезне Яңа ел белән котлыйм. Яңа ел яңа бәхетләр алып килсен. Сездән мәрхәмәтләр көтеп, Җәвит.»

Бу телеграммасы белән тагын йөрәктәге яраны яңартып җибәрде Җәвит. Әдилә бу арада үзенең аптырашлы бер хәлдә йөрүен аңлый иде, телеграмма моны тагы да көчәйтте.

— Мин сине аңлыйм, Әдилә, — диде этисе, кызының кинәт йөзе үзгәреп китүен күреп. — Нәтиҗә ясарга ашыкма, уйлап эш ит.

— Мин Җәвитне элекке кебек ярата алмамдыр инде, эти. Мин аны, гомумән, яратмыйм бугай, — диде Әдилә, караңгы бер чырай белән.

— Ә син тынычлан. Әле бит бер ни дә булмаган. Бала хакына кайчак гафу ителмәстәй нәрсәләрне дә кичерәсең.

Этисенең тел төбендә Җәвит белән килештерергә нияте барлыгын сизеп, Әдилә үпкәләде. Җәвит аны икенче бер хатынга алыштырып, ташлап чыгып китте бит. Хатын-кыз өчен моннан да түбән кимсенү булырга мөмкинме! Үз башыннан кичермәгән кеше генә белмәс бу хәлне. Ә этисе, аның иң якын, иң кадерле кешесе, әнә нәрсә ди!..

— Син әле, кызым, канат астындагы бәбкә кебек кенә яшисең. Ә тормыш ул без уйлаганнан күп тапкыр катлаулырак.

— Юк, эти, мин үзем ана каз инде, — дип, кисәк кузгалды Әдилә. — Мин, эти, савымчы кызлар янына клубка чакырулы.

— Әйдә, киттек, һич югы, клубка кадәр бергә барырбыз.

Урамда ябалак-ябалак кар ява. Бөртекләре биткә куна да рәхәт итеп кытыклый. Клуб түбәсендәге «Яңа ел белән!» дигән сүзләр бер кабына, бер сүнә. Урам аркылы муенса кебек итеп тезгән аллы-гөлле лампочкалар тәлгәше сузылган. Клуб ягына халык агыла. Адым саен очраган берсе: «Яңа ел котлы булсын!» дип үтә.

— Эти, карале, бу урам бер дә Казанның Бауман урамыннан ким түгел бит бүген.

Клубка җитәрәк бер читтә басып торган ялгыз кеше күренде. Әдилә аңа бөтенләй игътибар итмәде кебек. Гариф аны таныды. Бу район үзәгенә күчеп киткән Зариф исемле егет иде.

— Ярый, мин клубка кереп тормыйм. Матур гына ял ит.

— Озатып куйыйммы соң үзеңне, эти?

— Кирәкмәс. Сине көтәләрдер анда.

Әдилә этисенең җиңенә сарылды, аяк очы белән генә басып, битеннән үбеп алды.

— Ярый, алайса, рәхмәт, эти.

Сизде бит этисе аның көтүен, күңеле белән сизде.

Тирә-юньдә музыка авазы, Яңа ел тантанасы. Этисе чатка кереп югалуга, Әдилә Зариф басып торган якка ашыкты. Йөрәге белән инде ул аның янында иде, ләкин аяклары аны никтер тыңламады. Зариф янына килеп җитәр-җитмәс ул бер мәлгә туктады, тирән итеп сулыш алды. Зариф аны күптән көтә инде, күрәсең — Кар бабайга охшап калган иде.

— Исәнме, Әдилә! Яңа ел белән!..
— Сине дә, Зариф! Озак көттеңме?
Зариф, «юк» дигәндәй кулын селкеде дә, елмаеп, аны култыклап алды. Ә Әдиләнең күз алдыннан күңелен борчуга салган теге телеграмма китмәде. Кемне алдый ул? Үз-үзенме? Җәвитнеме? Зарифнымы?
Һәй, нигә гел үз хисләрендә казынырга ярата соң әле ул! Яңа ел кичәсендә генә булса да шул уйлардан бушанып торырга кирәк!
Әдиләнең уй-хисләре, ташырга торган буа суыдай, чайпала, йөрәге кысылып-кысылып куя. Зариф аңа шундый матур-матур ярату сүзләре тезә — янган йөрәккә шифа булып ята алар.
Әдилә уфтанып куя һәм эченнән: «Җүләр хатын, нигә алай беркайчан да гашыйк булмагандай кыланасың? Ни булды тагын сиңа? Айнырга вакыт түгелме инде? Егерме бишне тутырып киләсең бит. Ә үзең һаман күкләрдә очасың, тилекәй!» — дип, үз-үзен битәрли.
— Нигә алай авыр сулап куйдың, Әдилә?
— Әй, Зариф, үткәннәр искә төшә, җүләр чакларым... Әлеге акылым булса икән шул вакытта.
— Үкенәсеңме, үртәләсеңме? Үкенмә дә, үртәлмә дә. Кайчандыр чын күңелдән ярата алгансың икән, шатлан гына. Хис акылдан өстен чаклар була, ә ул минутлар кабатланмый, яңара гына ала. Ә яңасына таләпләрне күп тапкырлар арттырып куясың. Бактың исә, бу да шул ук мәхәббәт икән. Тик янәшәндә атлаучы гына ул түгел, бөтенләй башка кеше.
— Каян килә бу кадәр тапкыр сүзләр сиңа, Зариф?
— Мин бит гашыйк кеше.
Әдилә тыенкы гына елмаеп куйды.
— Кайчак миңа синсез бик кыен була, Әдилә. Әллә ниләр әйтергә дип гайрәтләнеп киләм янына, сине күрдемме, җил алган тузганак кебек, әйтер сүзләрем тарала да бетә. Синнән башка яшәүне күз алдыма да китерә алмыйм. Син Казанга китсәң, мин анда барырмын, котыпка икән — котыпка китәрмен.
— Җүләрем, син башта туган авылыңа кайт. Райүзәк белән ике арада йөреп, ничә пар итек туздырдың инде?
— Җәйгә мотоцикл алам. Атна саен кайтып торачакмын. Син кайчан да булса миңа бер җылы сүз әйтерсең дип ышанам әле, Әдилә.
Зарифның яратуына ышана Әдилә. Тик күңелендәге шик һаман борчый аны: беренче мәхәббәтен оныттырырлык итеп яраттыра алырмы ул? Бергә яши башлагач, бу да Җәвит кебек үзгәрмәсме?
— Тормыш усал шул, Зариф, бер авызың пешкәч, өребрәк кабасың.
— Әйтмә алай, Әдилә. — Зариф уч төбе белән Әдиләнең авызын каплады.
Әдилә аның күзләренә карый. Ут яктысында аның кашына кунган кар бөртекләренә кадәр күренә. Карый да күңеле белән аңа таба ымсынып куя.
— Син ачуланма, Зариф. Мине бер тапкыр рәнҗеттеләр инде.
— Минем вөҗданым саф, Әдилә.
— Минем әти, беләсеңме, ни ди, Зариф? Яраткан кешеңнән үзең аңа биргәннән күбрәкне таләп итү, гомумән, кеше өчен әйбәт сыйфат түгел, ди. Ә мин сиңа ни бирә алам соң әле? Син бүген гаҗәеп гүзәл һәм саф күңелле. Әйбәт кеше син, Зариф. Кил әле бире...
Әдилә аңа таба тартылуга, Зариф аны кочагына алды, Әдилә аның муенына сарылды, кайнар иреннәренә иренен тидерде.
Күңеле күккә ашты, әмма бер хакыйкатьне белмичә ашты. Кеше кайчак үз гомерендә ирешә алмаган хакыйкатькә минут эчендә ирешә, минут эчендә төшенә. Әдилә чирек гасырына аяк баскан көндә мәхәббәтнең эчкерсез булуына төшенде. Бүген ул аны йөрәге белән генә түгел, акылы белән дә аңлады. Бу егетне ярата икән ул.

Тау-калкулыкларда, басу-кырларда, кар беткәч, язгы дымга туенып калган җир өстеннән күгелҗемләнеп, сызып кына бу күтәрелә башлады. Яз хәбәрчесе тургайлар килде. Аннары кыш буе йоклап яткан йомраннар өннәреннән чыктылар һәм, тукмак кебек баскан хәлдә, әче итеп сызгырырга керештеләр.

Гариф, колхоз агрономы Мидхәтне, лаборант кыз Тамчыны һәм ассистенты Вафаны алып, кырларга чыгарга булды. Көн җылы, күк йөзе аяз, анда-санда күренгәләгән аксыл болытларны санамаганда, зәңгәрлектән күз камашырлык иде. Тымызык кына йомшак җил исеп торган бу көндә бөтен табигать гүя нарасый баладай оеп йоклый.

Басуга атлар белән чыгарга булдылар. Җир кипшергән, җилләгән төшләрдә яшеллек дөньясы терелә башлаган. Шулай да кайбер урында көпчәкләр тырнакларына кадәр бата, кыш буе җиңел чана тартып өйрәнгән атлар өстеннән исле бу күтәрелә. Юл читләрендә, ызан буйларында, кояш нурларын күргәч, сары умырзая баш калкыткан, күзле үлән борын төрткән, эт тигәнәге тернәкләнә башлаган, бәбкә үләне тибеп чыккан. Сөрелмәгән һәммә җирдә яшькелт чирәм шытып килә.

Гариф белән Мидхәт алгы атта бара, Вафа белән Тамчы — икенче олауда. Авылдан чыгуга, өздереп юртып киткән атларның җегәре җир буе ара китүгә сүрелде, тирләп чыгып, адымга күчтеләр.

Гариф арттан килгән атка борылып карады: кара биянең борын тишекләре киңәйгән, камыт, ыңгырчак астыннан саргылт-аксыл күбек тама. Вафа янәшәсендә утырган Тамчыга мавыгып нидер сөйли, лаборант кыз тыенкы гына көлемсерәп, аны тыңлап бара. Тыңлый-тыңлый да аңа күз төшереп ала.

Башта Гариф бу бөтерчек кебек кенә кызны баласынган иде. Аның җете кара күзләреннән мәктәп балаларындагыча кызыксыну, нәүмизлек китмәгән кебек күренгән иде. Ләкин эшли башлагач, ул шуны белде: Тамчы үз эшен һәр вакыт җиренә җиткереп башкара, шытымнарны бик яратып карый. Күз генә тимәсен, лабораторияне ышанып калдырырлык. «Минем эшем төгәлләнеп килә, быел моннан китәрмен, ә Вафаны берәр елга калдырырга булыр, диссертациясен төгәлләп кайтсын», дип уйланды Гариф.

Баш очында гына тургай талпына. Уч төбенә сыярлык кечкенә генә бу кошның чыр-чу килеп сайраган дәртле авазы, кояш нурлары белән бергә кушылып, җиргә коелып тора сыман.

Юл Таз тау үзәненә сузылып ятты.

— Хәлләрең ничек соң, Мидхәт? Киләчәккә планнарың нинди? Биредә калырга исәпме, укуны дәвам иттерү турында уйлыйсыңмы?

— Әлегә ул турыда уйлаганым юк, Гариф Әюпович. Минемчә, оста белгеч булу өчен институт лабораториясендә утыру бар кешегә дә зарур түгелдер кебек. Хәзер әнә доктор булган колхоз председательләре, агрономнар бар.

— Баштарак председатель белән дә бик боткаң пешмәде бугай?

— Булды андый хәлләр. Үзем дә гаепле. Институт эскәмиясеннән генә төшеп килгән чагым, һәр житешсезлек күзгә бәрелеп тора, нигәдер аның чарасын күрмиләр кебек. Хәзер килештек. Цехлар оештыру эшне бик төгәл хәл итте. Кырчылык цехы. Мин шул цехка һәм шул цех житештерәсе продукциягә тулысынча җаваплы. Цех оештыру белән Талип абый минем ике кулымны да бушатты. Юкса, үземне аяк-кулым бәйләнгәндәй хис итә идем. Уңыш өчен җавап бирәм дә, бирмим дә кебек иде. Хәзер председатель дә минем кайбер фикерләр белән килеште. Әйтик, цех эчендә звенолар оештыру. Ә мин ул звеноларны шундый иттереп оештырачакмын, һәр кеше ниндидер бер участокка җаваплы булачак.

— Оештыру эшләре әйбәт, яңа, сүз дә юк. Тик табигатьне саклауда председателегез дуамалрак кылана кебек. Ык буендагы усак урманын синнән башка кистеләрме?

— Мин аны туктаттым. Башта ризалык биргән идем, аннары туктаттым. Комплекска, икмәк заводына, ашлама складына агач материаллары җитми. Җыелып-җыелып шул турыда күп бәхәсләштек. Кисә башлагач, үзем үк үкенеп бетә алмадым.

— Нәкъ болын уртасын каплап торган диләнкә киселү сәбәпле, Мидхәт туган, Ык бозлары бу язда ук туп-турыга агып киттеләр. Усак урманы элек бозларны туктата торган булган, су, буылып, болынга җыелган. Ә су кереп калган болында печән бермә-бер мул була.

— Талип абыйның урта болынны сугарулы итәргә исәбе. Исәбе генә түгел, быел ук ул болын сугарыла башлаячак.

...Таз тау, Кыяр тавы иңкүлегенә җәелгән кыр-басуларның температурасын, дымлылыгын үлчи торгач, көн үткәнне сизми дә калдылар. Алар кайтканда инде кояш баеган, Таз тау ягында шәфәкъ нуры балкый иде.

## 35

Больница тәрәзәсендә кояш нурлары биешә. Болдырда медсестра Дания басып тора иде... Якынлашып килгән Гарифны күреп, ул:

— Гариф абый, ай, чәчәкләрегез нинди матур! — дип елмаеп сүз кушты.

— Хәерле иртә, Дания, менә бусы сиңа, — дип, Гариф букетны икегә бүлде дә аның кулына тоттырды.

— Рәхмәт инде, Гариф абый. Сез көннән-көн матуррак чәчәкләр табасыз. Кәфия апа, күрегезче, бүген Гариф абый ниндиләрне китергән!..

Ишектән чыгып килгән Кәфия муенына аскан стетоскопны кесәсенә алып тыкты.

— Хәерле иртә, Кәфия ханым.

— Исәнмесез, Гариф Әюпович, — Гариф аңа да чәчәк букеты сузды. — Ай-һай, бигрәк матур икән шул, чынлап та, — диде Кәфия, соклануын яшермичә, чәчәкләрне иснәп карады. — Уф, тәмам иләсләнеп китәрлек! Үзегезнең хәлегез ничек соң, Гариф Әюпович? Билегез бик борчымыймы?

— Гомерлек инде ул, фронт елларыннан калган. Блок ясатканнан соң борчыганы юк. Шифалы булды Даниянең куллары. Гайзулла картның хәле ничек соң, Кәфия ханым? Дөресен әйтим, миңа ошап китте ул карт. Күпне күргән. Әтине дә белгән икән, җитмәсә, бергә үскәннәр.

— Хәле бераз аруланды. Минем җизнәй бит ул. Үз итеп дәваларга тырышам инде, — дип көлде Кәфия, аннары житдиләнеп: — Хәле шәптән түгел аның, Гариф Әюпович. Яман чир булмагае...

Хәле начар дисәләр дә, Гайзулла карт йөри иде әле. Сезнең янга Гариф Әюпович килде, дигәч, ул, акрын гына киенеп, бакчага чыкты. Кәфия аңа озак юанмаска кушты, Гайзулла ярар дигәнне аңлатып ияк кенә какты да Гарифка ияреп, агачлар арасындагы эскәмиягә таба китте. Гайзулланың өстендә буйлы пижама, шуның өстеннән бумази халат кигән. Йөзе ап-ак, борын очы хәтта шәмәхә төскә кереп күгәрә башлаган шикелле.

Утырдылар. Гайзулла ияген чукмар башлы таягына терәде, уйга калды, тыңларга җыенды.

— Көннәр коры тора, икмәкләрнең баш кысып килгән вакыты, көйдермәсә икән,— дип куйды Гариф сүзсез утырудан сүз булсын дигәндәй.

— Элек бабайлар болай ди иде: кышны җәйдән, язны көздән аерма, көз ничек килсә — яз шулай, кыш ничек килсә — җәй шулай килер! Хәзергеләр узындылар, картлар сүзенә колак салмый башладылар. Икмәк игү безнең халык канына борын-борыннан сеңә килгән. Алар киңәшеннән йөз чөерү... ай-һай, кайчак икмәктән олы булып куялар...

— Фәнгә таяналар, үзләре тикшереп беләләр.

Гайзулла аңа яралы бите ягындагы күзен кыса төшеп карап алды.

— Минем әти елны айлап түгел, сәгатьләп бүлә торган иде, мәрхүм. Көннең озынлыгына карап бүлә. Һәм ялгышмый иде. Бер елны шулай көз зрә дә коры килде. Юлга төшсәң, аяк астыннан баскан саен тузан бөркелер иде. Аннары исә җир туңды, ярылды. Яңа елга кадәр кар төшмәде. Әти безгә көздән арыш чәчтермәде. Быел арыш елы түгел, диде. Яз килгәч, Рәхим абзыйдан ике пот тары сатып алырга кушты: «Быел тары елы, булган җиребезгә тары чәчәбез, улым»,— ди. Ходайның хикмәте, фалчылыгы булган диярсең, шул җәйне ишелеп тары уңды бит. Алабута елы иде ул. Халык ише-ише белән читкә китте, ачтан үлде, ә без тары әпәе ашап чыктык. — Гайзулла чүәк башына таяк очы белән суккалап алды, һавага күз төшерде һәм янә карашын җиргә текәде.— Быел ел коры булмас, көздән бик матур итеп кар яткан иде. Күп дигәндә атна-ун көннән яңгырга китәр.

— Минем барометр әллә нигә сиздерми әле, — диде Гариф, билен капшап. — Яңгырны бик тиз сизә торган идем.

— Дару эчкәч, укол кадаткач, сизү рәте китә ул билнең. Бер елны мин дә аның белән җәфаланган идем. Син аны, мунча яктыр да, скипидар белән уып кара. Ул да алмаса, кычыткан белән чап, арыш камыры ябып йокла. Спирткә эреткән умарта сагызының да шифасы тия, диләр.

— Сынап карарга булыр, — диде Гариф, күз кырые белән генә Гайзуллага карады.

— Сына, файдасы тими булмас. Менә минем ашказаныма дару таба алмыйлар. Килен бик тырыша инде тырышуын, уколлар да бирә, бер көнне, хәлем бик мөшкелләнгәч, кан да салдылар. Юк кына, рәтләнеп булмый бит. Менәүыннан китереп кыса да, —Гайзулла уң кулы белән күкрәк астын тотты, — үтерә дә сала менә, ходайның хикмәте. Аллаһе тәгаләдән әҗәл дә көтәргә вакыт бик җитте дә бит, әллә нигә үләселәр килми шул. Яшисең дә яшәдек инде, югыйсә... — Гайзулла беравык сүзсез утырды, әйтерсең ул йокыга талган иде. — Менә, Гарифулла, син галим, могтәбәр кеше. Аңлат әле шуны. Әллә, мәйтәм, тәңребездән узып яшәгәнгәме, еллар үзгәрә тора. Җәе җәй түгел хәзер, кышы кыш түгел. Кеше кешене ашый. Әнә теге килмешәк агроном Хөббенисаның Зарифулласын туган авылыннан куган. Беркөнне зарлана Хөббениса, шул мөртәт кенә куды оныгымны, ди. Минем дә Кәнзел баш алып китәргә кызып йөри. Карамалыда элек мең хуҗалык иде, хәзер Талибулла әйтә әнә, биш йөзгә дә җыелмый икән. Сугыш та кырды инде халыкны. Карт көнемдә булса да Мисыр якларына хаҗга барып кайтырмын дигән идем, яһүте кан коя.

— Минемчә, теләгән кешегә рөхсәт бар, сугыш дип тормасагыз...

— Хәзерге заман коралына Мәскәү ни дә, Мәккә ни. Ахыр заман килде, шул гына.

— Сабан туйлары җитте. Киләсе атнага Карамалыда була икән, — диде Гариф, сүзне икенчегә борырга теләп. Ләкин Гайзулла монда да үз ягына сукалап алып китте.

— Сабан туйлар да бер дә шәп түгел хәзер. Элекке сабан туйларында ул нечкә торыклы аргамаклар дисеңме, киң җилкәле җегетләрме... Әюп мәрхүм һәр ходай бирмеш елны батыр калыр иде. Шулай да мин бәрдем моны берсендә, мин батыр чыктым. Сабан туе көненә кадәр һәр көнне су эчеп чыккан бозавыбызны күтәреп ишегалды

буйлап жиде-сигез тапкыр әйләнәм. Көткән сабан туе көне житте. Иртән ни барысы бер чокыр чәй эчтем. Башта батырларны әртилләргә бүлделәр. Берсенә мин батыр чыктым, берсенә — Әюп. Алыша башладык. Батырга Рәхим бай бер байтал бирәчәк. Алышабыз — юк, алышабыз — юк. Туктыйбыз да йомырка эчәбез, туктыйбыз да эчәбез. Ә йомырканы күп эчәргә ярамый, эчне кату ала башлый. Мин берне эчәм, ә Әюп, мәрхүм, икене. Шуннан маташа торгач, алды бит бу мине — аяк очларым чирәмгә тиеп кенә тора. Шуннан, нинди хода көчләре килгәндер беләк-буынга, шуып төштем дә күтәреп алып салдым моны. Мәйдан аһ итте. Мин егармын дип көтмәгәннәр иде. Әюпка чыгучы юк иде бит моңарчы.

Сабан туйлары хәлләрен сөйләгәндә Гайзулланың күзенә яшь пәрдәсе йөгерде, шәмәхә кан тамырлары беленеп торган кулы белән ул маңгай тирәсен ышкыштырды. Гариф аңа дикъкать белән карап торды.

— Һәр чорның үз матурлыгы буладыр инде ул, Гайзулла абзый. Заманалар үзгәрә, яңа кешеләр, яңа уеннар килә. Яшьләр башка, димәк, ихтыяжлары үзгә...

— Аллаһы тәгаләгә кул күтәрделәр шул, бигрәк кәттә кыландылар. Сабан туе түгел ул хәзер, шайтан туе. Даң-доң, даң-доң думбра сугалар. Киенүләре — ташка үлчим! Беркөнне Гыйльметдин малае апаеның хәлен белергә килгән. Янында үзе кебек үк берәү. Яман озын чәчле, чалбардан, олы бар юк, кече бар юк, хи-хи дә һа-һа. Хәер, Тәти Фатыйма төпчеге. Китапта әйтелгән: «Ахыр заман килгәндә ата улны, ана кызны белмәс, улы кыздан, кызы улдан аерылмас» дип, хак икән, ходайның хикмәте.

— Бәлкем «аерылмас» сүзе бергәләп, тату, тигез яшәрләр мәгънәсендә әйтелгәндер ул?

Гайзулла кысык күзен челт-челт йомгалап алды, ябык кулларын тез өстенә салып, бер тын сүзсез утырды.

— Шул изге китапларга яман мәгънәләр сала-сала, улны кыздан, кызны улдан аермас көнгә калдыгыз да инде.

— Чалбар кигәннән мин бернинди дә яманлык күрмим болай. Бар кешегә дә килешми бит ул. Мәсәлән, минем кызның чалбар киеп караганы булмады.

Кирәк бит, әй! Нәкъ шунда әтәч кикригедәй кызыл чалбар, эре яшел парчалы кофта кигән, муенына бакыр чылбыр белән борынгы грекларның алла сурәтен таккан, коңгырт чәчләрен иңбашларына туздырып жибәргән Әдилә килеп чыкмасынмы! Ул ихата аша үрелеп әтисенә дәште:

— Әти, мин сине эзлим бит.

Кызын шул кыяфәттә күрүгә, Гарифның күзләре дүрт булды. Гайзулла Әдиләгә караган да, авыз чите белән генә елмаеп утыра.

— Сабыр ит, кайта тор, мин хәзер, — диде Гариф Әдиләгә, тизрәк китәргә ишарә ясап кул селтәде.

Гайзулла таягы белән жиргә нидер сызгалый башлады, Гариф кесәсеннән газета чыгарды, битләрен караштырырга кереште. Гайзулла да газетага күз төшерде.

— Гәжитләр нәрсә яза?

— Менә монда бик кызык бер хәбәр бар. Берәү стена эченә яшерелгән хәзинә тапкан. Тапкан да берәм-берәм саткалаштырган. Эш милициягә житкән. Ун меңгә якын бәяле алтынны дәүләткә алалар, ә үзен төрмәгә утырталар. Дәүләткә китереп тапшырса, дүрт меңгә якын акча аласы булган икән. Һаман табыла тора тагын хәзинәләр...

Гайзулла шунда кинәт агарынып китте. Шулай да гамьсез булырга теләп, һични булмагандай тыныч утыра бирде. Гариф аңа тагын берничә яңалык укыды. Һәм күрде: карт инде аны тыңламый, бөтенләй үз дөньясына кереп чумган иде. Ахыр килеп ул:

— Әллә нигә хәлем китеп тора, — дип күтәрелә башлады. Гариф аны култыклап алды һәм янәшәдән атлап китте.

— Казанга барып күренергә кирәк сезгә, Гайзулла абзый, профессорларга.

— Казанына түгел, райүзәккә дә барасым юк. Тәкъдирдән узып булмый. Яшәсен яшәдем инде. Әнә син дәвалан, сиңа яшисе дә яшисе әле.

— Рәхмәт киңәшеңә, Гайзулла абзый. Я, сәламәтлән тизрәк.

Гайзулла кереп киткәч, Гариф әле булса капка төбендә үзен көтеп торган Әдиләне күрде.

— Ни бар ул кадәр?

— Әти, сиңа Казанга шалтыратырга куштылар, институттан, — диде Әдилә һәм, әтисенең усалланып үзенә карап торуын күреп: — Казанда алдым, килешәме, әти? — дигән булды.

— Яшьләргә барысы да килешә. Тик синең болай йөрүеңне авыл халкы килештерерме? Шул турыда уйла бераз.

Әдилә аңламады: әллә хуплады әтисе аның шулай киенеп килүен, әллә хурлады.

## 36

Зарифны иртән Равил килеп уятты.

— Әйдә тизрәк, картлач, басуда ашарсың. Синең кайтканыңны ишеткәч, Мәрхәбәттәй итне мул итеп салам, диде. Яратам шул Зарифулланы, әллә кай җире белән Гамирыма охшатам, ди.

Мотоцикл җиле ачык изүдән үтеп күлмәкне күпертә, куенга керә, иртәнге салкын һава кар кебек тәнгә сылана сыман.

— Ай-һай, йоклыйсың да үзең бер төрле итеп. Шәһәр кешесе булып китә язгансың бит, ә! — диде Равил.

— Әйдә элдертә бир, телеңә күп салышма. Яшь кәләш яныннан үзең дә яңа гына торгансыңдыр кебек. Әнәтерәк чәчеңдәге мендәр мамыклары да рәтләп коелмаган.

Равил әле күптән түгел генә өйләнде. Зариф, чакырулы булса да, аның туена кайта алмады, өйләнүен котлап, телеграмма гына сукты.

— Куалама ул тиклем, очып китмик. Авылга кайткач кына әрәм итмә абзаңны!..

Зариф шулай диюгә, мотоцикл урыныннан купты.

— Иплерәк, мин мин инде ул, кәләшеңне ятим итә күрмә.

— Әйе шул, гомерен минем өчен җылап үткәрсә...

Комбайннар тезелеп торган төшкә бик тиз килеп җиттеләр.

— Ай-һай, малай, йөреп тә карыйсың! Канат кына куясы бар синең бу җен арбаңа...

— Заман тизлегенә җитешерлек машина булмагач, ясап та торасы юк аны. Тизлек, сыйфат, җегәр, ныклык — менә нинди булырга тиеш безнең заман машиналары!..

Зариф көнозын «Колос» комбайнын көйләп азапланды. Иртәгә уракка төшәчәкләр. Һәммә узел кат-кат каралса-көйләнсә дә, Зариф тик кичке якта гына үз эшеннән канәгатьләнә алды. Моторны кабызды, агрегатларны эшләтеп карады. Шуннан соң гына күңеле тынычланып, чирәмгә сузылып ятты. Күзләре айда Зарифның, ә күңеле белән ул Әдиләне каршылый.

Нигә кайтмый? Ник болай озак?

Инде кояш та баеп бара, ә күктә һаман тургай сайрый. Аның моңы, чылтыр-чылтыр аккан чишмә тавышыдай, җиргә коела. Зарифның да

ниндидер моңлы көйгә иреннәре кыймылдый. Ул да әнә шулай күккә аша алса икән. Күңел әллә нинди сагышлы хисләр дулкынына чума...

— Кайтасыңмы, Зариф абый?

— Һәй, шайтан, куркыттың, тургай булып күккә ашарга чамалап ятадыр идем.

— Моңаер чагың шул, ялгыз чагың... — диде Равил һәм аннары иелә төшеп: — Әйт әле, яратып йөрисеңме син аны, әллә болай тамак туйдырып кына калыргамы исәп.

Зарифның күзләрендә чаткылар чәчрәп китте кебек. Ул, ачуланып, авыз эченнән мыгырданып алды да каршында чүгәләп утырган Равилне төртеп җиргә аударды.



## 37

Әдилә Казанга китүенең тик сигезенче көнендә генә, Гөлзифа әбисе белән кызы Чәчкәне алып, Карамалыга кайтып җитте. Гариф чын-чынлап борчыла башлаган иде инде. Ниһаять, барысы бергә килеп төшүләрен ишеткәч, өйгә ашыкты.

Башта ул Чәчкәнең чыңлап торган тавышын ишетте. Кече капканы ачкач, Әдиләнең сыер савып утыруын, әнисе Гөлзифа карчык белән баланың шул тирәдә йөренүләрен күрде. Сер түгел, бу минутта ул әнисе, кызы, оныгы янында тагын берәүне — Җәвитне — күрергә теләгән иде. Хатлар язса да, килешә алмаганнар инде болай булгач.

Иң элек аны әнисе күреп алды. Аннары кыз, бабасын күргәч:

— Бабакай, бабакай! — дия-дия аңа каршы йөгерде.

— Үскәнем минем! Авылга, бабакаең янына килдеңме?

Чәчкәне җиргә бастыргач, Гариф әнисе белән күреште.

— Әни, карале, миңа синсез һаман кыен икән бит.

— Ана юк җирдә чама юк, балакаем. Вакытында ашамагансыңдыр, вакытында йокламагансыңдыр...

— Булгандыр, булгандыр, әни, анысы да..

— Исән-сау гына яшисеңме, улым? Билең бик борчымыймы? Казанда чакта ел саен мәтегә барадыр иең, авылга килгәч, әллә аны да оныттыңмы?

— Бабакай, бабакай, мы с әбекәй палное молоко будем пить, правда, мама? — дип такылдарга тотынды Чәчкә. Гариф аны тагы күтәреп алды.

— Әти, килмәс борын ярсытма әле баланы, аннары начар йоклый ул, — диде Әдилә, сыерын савып бетереп, чиләген читкә алгач.

Ләкин Гариф аның сүзен колагына да элмәде, бала белән уйнавын белде.

— Әти дим, куйчы шуны! Аннары төне буе көйсезләнеп чыга ул. Чәчкә, кил әле, мин сиңа җылы сөт салып бирәм.

— Сөт, сөт эсәм, бабакай!

— Татарча да сөйләшәсең икән бит син, ник бабаң белән русча сөйләшеп торган буласың, сары түш!..

Кичке табынга утырышкач, Гариф, Әдиләгә карамыйча гына, Җәвит турында сорады.

— Килдеме теге?

— Килде. Ул хәйләле, әти. Баланы алып калмакчы. Мин әнием белән торам, йөртмә баланы авылга, дигән була.

— Нинди мәкер күрдең инде син аның бу теләгеннән?

— Кем белә, бәлкем ул баланы үзенә алырга телидер. Тегесе олан тапмый икән...

— Аның белән тормый түгелме соң инде ул?

— Барып тикшермәдем.

— Ә бит кайтуына янына килеп җиткән.... Адәм баласы...

— Мин адәм баласы түгелме? Ул битемә төкереп чыгып китте. Хәзер акылга утырган, имеш. Ышанмыйм, ышанмаячакмын да...

— Миңа, балам, ул кеше башта ук ошамаган иде, — дип сүзгә Гөлзифа карчык кушылды. — Шундый итеп төчеләнә, тәмам бохар песие инде менә. Җете кызыл тиз уңа, диләр бит.

— Болай да йөрәге купкан бала күңеленә коткы салып торма әле, әни. Яшьләр бит... Ялгышканнар, бер-берсенең кадерләрен белеп бетермәгәннәр.

— Әнекәй генәм, бу бала нишли анда?!

Өчесе дә идәнгә карадылар. Чәчкә идәнгә газета җәйгән дә ашап утыра, кашыгыннан бер үзе каба, бер мәчегә каптыра.

— Балакаем, нишләвең бу? Гөнаһ шомлыгы, каян килеп кергән соң әле бу мәче?! — дип, Гөлзифа карчык аны эләктереп алды да ачык тәрәзәдән тышка ыргытты.

Чәчкә, ниндидер гаебен аңлагандай, өстәл янына килеп утырды да әбисе чиста савытка салып биргән ашны ашый башлады.

— Мондагы егет белән дуслашып йөрүеңне ничек аңларга инде синең? Җәвит белән уртак тел табарга теләмәвеңнең төп сәбәбе шуннан түгелме?

— Әти, миңа үз киләчәгем турында үземә уйларга ярыймы, әллә юкмы? Яңадан минем белән торырга теләсә, килер дә менә монда, әйбәтләп сөйләшер. Ышандыра алса, китәрмен үзе белән. Булмаса, ялгыз калам. Әнә син буйдак булып яшисең бит әле...

— Ярар, җитеп торыр. Гомерең кысыр үтмәсен дип кенә әйтүем. — Аннары Гариф әнисенә карап алды. — Шулаймы, әни? — Гөлзифа карчык ни әйтергә белми аптырап калгач, Гариф: — Фәһимә апа малае янына шәһәргә китте, хуҗалыкны сиңа алырга туры килер, әни, — диде.

— Минем кулда инде ул, улым. Чәй кирәкме, хәзер китерәм...

## 38

Гайзулла капка төбенә чыгып утырды да урамнан үткән-сүткән халыкны күзәтә башлады. Әнә хат ташучы кыз килә. Кәнзелдән хат бармы икән әллә?

— Сезгә хат, бабакай, — диде ул чыннан да.

— Рәхмәт, кызым! — Гайзулла бер сум көмеш чыгарды, кызга сузды. — Мә, балам, ал.

Кыз «алмыйм, кирәкми!» дип баш чайкады.

— Укып бирсәңче, матурым, күзлегем өйдә калган.

Гайзулла, башын ия төшеп, тыңларга җыенды.

«Исәнме, инәй!..»

«Нигә инәй генә, әтәй кая?» дип уйлады Гайзулла, күңелендә улына карата ризасызлык билгесе калкуын тоеп.

«Мин исән-сау яшәп ятам. Өйләндем. Хатыным ипи пешерүче булып эшли. Бераз әйбер-кара алырга бер дүрт йөз сум акча сал әле, инәй. Әтәйгә әйтмәсәң дә ярар...»

Кыз укудан тукталып, Гайзулла картка карады. Картның сул күз кабагы бертуктаусыз калтырый иде.

— Укы, укы, — диде Гайзулла, йөрәге сулкылдаганга тирән итеп сулыш алды.

«...төпләнә төшкәч, үзегезне дә кайтып алырмын. Бик яхшы урынга эшкә кердем...»

«Кемгә өйләнде икән? Тәнзиләгәме, башка берәүгәме? Нигә шул турыда бер авыз сүз булса да язмаган?!»

— Рәхмәт, кызым.

Гайзулла калтыранган куллары белән хатка үрелде, алып, дүрткә бөкләде дә кире конверт эченә тыкты.

Агач башларын шаулатып җил исеп куйды. Ул да түгел, урам юлында тузан күтәрелде, җылы нурларын тыныч кына коеп торган август кояшы карасу-күксел болыт астына посты. Гайзулла кулына утлы күмердәй тотып кайткан хатны эчке яктагы өстәл өстенә ташлады, чөйдәге дисбесенә үрелде.

Шул чакны йомышчы кыз килеп аны идарәгә чакырды.

— ...Сезне мин дәштергән идем, әйдәгез, узыгыз түргә.

Гайзулла чытырдатып йомган күзеннән чыккан яшьне кул аркасы белән сөртеп алды. Аның каршында Кәримулла басып тора иде.

— Ни булды сезгә, әллә авырып киттегезме?

«Әти дип әйтергә теле бармый, үчле йөрәк белән яши», дип уйлады Гайзулла.

— Киләсе атнада олыгайган колхозчыларны пенсиягә чыгарабыз, кулыгызда булган рәсми документларны бергәләп карап чыгасы бар.

«Колхозда элек һөнәр иясе булдымы? Бригадир кая дәшә, шунда бара идек. Нинди рәсми документ кирәксен ди аңа. Бер дә бүтән түгел, моңа да шул алтын кирәк», дип уйлады Гайзулла һәм акрын гына китәргә кузгала да башлады.

— Гариза язып калдырыгыз, — диде Кәримулла, әтисенең җиңенә кагылып.

Бухгалтер кабинетына керделәр. Кәримулла аны ипләп кенә урындыкка утыртты. Гаризаны ул алдан ук язып куйган икән инде, кул гына куйдырды.

— Менә сезнең хезмәт стажыгызны раслый торган документ.— Кәримулла әтисе алдына колхозның хезмәт кенәгәсен салды.

Гайзулланың хезмәт кенәгәсен күргәне юк иде әле, тышы саргаеп беткән кенәгәне кулына алып, авырлыгын чамалагандай итте дә кире Кәримулла алдына куйды.

— Тик шуны аңламыйм: нишләп сез Бикмуллин фамилиясе белән йөрисез? — дип куйды Кәримулла. Гайзулланың аркасына гүя кайнар су койдылар, ул кинәт куырылып китте.

— Гафил кеше мин, ә фамилиямне кәнсәләрдә эшләгәндә Таҗылбанат алыштырган, бер булсын дигәндер инде.

— Һмм... Ә карчыгыгыз нигә килмәде?

— Аны чакыручы булмады бугай. Өйдә юк иде ул. Калхуз эшенә рәтләп йөрмәде дә. Сәвиттә сәркәтип иде...

— Анда эшләве турында авыл Советыннан справка кирәк булыр. Иртәгәдән калмый китерсен.

Инде сезнең белән эш бетте дигәндәй, Кәримулла аягүрә басты. Гайзулла, Кәримулланың кыяфәтеннән үзенең яшь чагын күргәндәй булып хәйран калды, улына шаккатып карап торды.

— Гафил-гафил дә, коръәнне бетереп яттан беләсез,— диде Кәримулла. — Менә монда кул куярга кирәк.

— Искечәне сукалыйбыз да бит аны, менә яңачасына теш үтми.

Гайзулла резин калошларын лыштырдатып ишеккә юнәлде. «Бу мине болай гына җибәрмәс, чыкканда булса да туктатып сорар», дип нәрсәдер көтте ул.

— Сезгә утыз сум чамасы пенсия чыгар. Карчыгыгызга алай ук булмас. Пенсия кенәгәләре клубта тапшырылачак. Радиодан хәбәр ителәр, килерсез.

Гайзулла ишектән ничек чыгып киткәнен хәтерләми. Өенә ул шактый ашыгып кайтты. Таҗылбанат аны, гадәттәгечә, чәй куеп көтеп тора иде.

— Кая югалдың әле болай?

— Кәнсәләргә дәшкәннәр иде. Пенсия бирмәкчеләр икән безгә. Сәвиттә эшләгәнеңә синә Фәхридән справка алып килергә куштылар.

— Ике аягымның берсе булмас сәвитләрендә. Унҗиде сум акчалары бугазларына тыгылсын.

— Иш янына куш ярап торыр иде ул. Биргәннең битенә бакма. Кәнзелгә булса да җибәргәләрбез.

Гайзулла, калошын салып, түргә узды, бәрхет пинжәген сәкегә ташлады да мич каршындагы җиз таз янына чүгәләп, бик тәфсилләп юынды.

— Хәерчеләр, хәерсезләр. Кешене мыскыл итәргә дисәң үзләренә генә бир. Пенсия, имеш! Талип уйлап тапкандыр әле, бер дә бүтән түгел.

— Талибулла дәшмәде дим ич мине, Кәримулла чакырткан. Пенсияне калхуз бирәчәк...

— Анысына ни житмәгән тагын?

— Я, куйчы! Кәнзел ни яза? Тапканмы Тәнзиләне?

— Тапкан. Укымадыңмыни?

— Күзлегемне әллә кая куйганмын. Ни дигән тагын?

— Тегесе авылга кайтырга ояла икән. Фатирга кергәннәр. Бик эссе, алган бер азык-төлек бозыла, суыткыч кирәк, акча җибәрә алмассызмы? дип язган. Дүрт йөз сум салып кайттым үзенә.

— Узындырдың малайны. Үзе эшләп алса, әйбер кадерен белә төшәр иде.

— Хода бәндәсе, кайчанга кадәр талкырсың мине шул бала өчен! Син җыйганда мин дә җыймаганмы ул малны? — дип чәпченеп алды карчык.

— Шәбәймә әле, шәбәймә ул чаклы, — диде Гайзулла, тастымал белән кул-авызын сөртә-сөртә.

— Шәбәймәм менәтерәк, синең авызыңа гына карап торырмын.

— Картлык көнебездә хәер сорашырга чыгарбызмы? Бүген дүрт йөз, иртәгә биш, каян житкермәк кирәк?

— Ходай бирер әле.

— Ходай...

Тажылбанат башын чайкап торды-торды да кисәк борылып ишеккә таба китте. Күңеленә яман шик килеп, Гайзулла аңа иярергә ымсынган иде, сакалын тотып туктап калды. Кәнзелгә акча салуга каршы да түгел иде ул. Аның кулында дүрт йөз сумлык кына хәзинәме! Урта Азиягә барып, ике катлы таш өй салдыра ала бит ул кулында булган мал белән. Ул гынамы...

Гайзулла нишләргә белмичә аптырап калды.

— Тажылбанат!.. Тажылбанат, син дим!..

Җилкәсенә салган камзулын болдыр терәгенә ташлады да абзарга таба китте Гайзулла. Күңел сизә, тоя диләр, хакмы әллә, ходайның хикмәте. Шунда абзар капкасыннан тимер көрәк тоткан Тажылбанат килеп чыкты.

— Нәстә эшләп йөрисең анда, пәри?

Тажылбанат картына таба әйләнеп тә карамады.

— Тукта диләр сиңа, албасты!..

— Туктамый тор әле, — дип куйды җилкә аша гына Тажылбанат. — Ул алтын өчен минем этием белән абыем газиз башларын салдылар.

Гайзулла, үз-үзен белештермичә, карчыгы артыннан ташланды. Кай арада Тажылбанатны куып житте, нишләп ташлавын сизмәстән:

— Бир! — дип, гыжлап, ике куллап көрәк сабына ябышты. Әмма Тажылбанат аңардан житезрәк булып чыкты, көрәкне тартып алды да картның баш түбәсенә менеп төште. Моны һич көтмәгән Гайзулланың күзләре акайды, ул акрын гына җиргә таба чүгә башлады.

— Авыл гыйбады, дивана, кемгә саклыйсың ул алтынны? — дип, иреннәрен бөрештереп ыслады Таҗылбанат.

— Башым әйләнә, — диде Гайзулла, алга түнә башлап. Таҗылбанат аны, култык астыннан эләктереп, өйгә алып керде. Гайзуллага җиз комганнан башына су койды, баш түбәсенә сөлге каплады да түр өйгә узды, сәкегә сузылып ятты. Кинәт юашланып һәм бераз мескенләнеп калган Таҗылбанат сәке читенә килеп утырды. Гайзулла тамак кырды.

— Малай кайтсын. Шунда хәл итәрбез. Дөньялар үзгәрмәсме дип көтүем иде дә бит, без дигәнчә булмады...

— Җыеныйк та, атасы, китик малай янына. Маллы үлми, малсыз көн күрми, — диде Таҗылбанат, картының кулына кагылып. Гайзулла дәшмәде, ул сүлпән бер халәттә ята бирде. Тик кул бармаклары гына сизелер-сизелмәс хәрәкәтләнеп тора иде. Таҗылбанат күңеленә шул хәрәкәт һәм «малай кайтсын» дигән фикер бераз тынычлык китерде.

### 39

Гөлүсә фермадан кайткач та, Вафа Әдиләләр кабинетына килеп керде, кулларын уа-уа, шешәләр тулы кәрзин янына килде дә:

— Вай-вай, бигрәк аклар инде, кызыкмаслык та түгел үзләренә. Я, кайсысыгыз минем эчкә керергә ашкынып тора. Әһә, менә бусы күз кысып утыра, — дип такылдый-такылдый, ул бер шешәне алды да күкрәгенә кысты. — Җаным, карлыгачым, мин сине иртәннән бирле зарыгып көтәм бит.

Вафа шешәнең бөкесен ачты һәм күтәреп эчә дә башлады.

— Тфу! Хых. — Вафа, авызын тотып, раковинага барып төкеренергә тотынды. — Ни бу, Гөлүсә? Әллә ниткән тәмнәр килә. Ни ашаталар карамалылар бу сыерларына? Башымны кисмәгә бирәм: хлор бар бу сөттә, әллә известьмы!..

Гөлүсә, берни аңламыйча, кәрзиндәге шешәләрне берәм-берәм ачып карап чыкты. Сөт зәңгәрләнеп калган иде.

— Кем тутырды шешәләреңне? — дип сорады аңардан Әдилә.

— Ләйсән апа, — диде Гөлүсә, еларга җитешеп. Аннары әле һаман төкеренгәләп торган Вафаны күргәч, көлүдән тыела алмыйча, авызын учы белән каплады. Аңа ияреп Әдилә дә көлә башлады...

Икенче көнне ферма өенә килеп керүгә, Ләйсән аңардан:

— Әдиләкәй, кичәге сөтнең куелыгына нинди бәя? Теге «сөт җыланы»ның хәле ничек? Кәфия апага балниска алып киткәннәр дип ишеттек, расмы шул? — дип сорады.

Әдилә ачуланырга дип авызын ачкан иде, Ләйсән күзләрендә хәйләкәр елмаю күреп: «Бу шайтан кызны ачуланып кына игә кертеп булмас, я тагын берәр нәрсә эшләп ташлар», дип аңа ияреп үзе дә көлгән итте. Түргә үткәндә Ләйсән аңа ирдә. Әдилә аны күрмәмешкә салышты. Кисәк кенә күңеленә бер уй килде. Ләйсәннең сыерларын савышырга! Дөрес, аның рәтләп савып та караганы юк. Шулай да өйрәнмәстәй эш түгелдер әле. Җор телле, үтә чая Ләйсән аңа башта Фирдәүсәнең иң юаш сыерын савып карарга кушты. Ләкин Әдилә теләсә кайсы сыерны да саварга риза икәнлеген белдерде.

Шунда ул Фирдәүсәнең усал күзләрен күреп алды. Кызның мондый карашын беренче тапкыр гына тоймый иде инде ул. Фирдәүсә ничектер үз эченә йомылыбрак яши. Уен-көлке белән мавыкмый. Ләйсәннең күзләренә гүя игътибар итми иде. Әдилә барында бөтенләй сөйләшми, бер читкә китеп утыра да, боларда берниндн гаме булмагандай, бер ноктага карап тик тора. Әдиләнең йөзенә кан сава, ни әйтергә белмичә теле көрмәкләнә.

Лэйсән исә, ферма өенә Әдилә килеп керүгә күзләрен елтыратыр, аның артыннан нәкъ аныңча янбашларын уйнатып йөреп күрсәтер. Әдилә аңа әйләнеп караса, күзләрен түшәмгә төбәр дә, кулларын күкрәгенә куеп, җырлый башлар:

Агыйделкәйләрем, салкындыр суларың,
Керләр чайкый-чайкый туңадыр кулларым.

Әдилә берничә тапкыр Фирдәүсә белән сөйләшмәкче булып та карады. Ләкин кыз аңа ачылмады, я бөтенләй торып китте. Бу турыда Әдиләнең Лэйсәннән сорашасы килсә дә, нигәдер кыенсынды. Бүген исә ул, Фирдәүсәнең күзләрендә яшь күреп, тәмам аптырый калды. Аның колагына кайчандыр Зариф шушы кыз белән йөргән дигән сүзләр чалынып киткән иде, шул турыда Лэйсәннән сорарга ниятләде. Лэйсәнне түр бүлмәгә чакырып алды да янәшәсенә утыртты. Шул сорауны бирде.

— Бер дә үзең белән сөйләшерлек итмәдең шул! — диде аңа Лэйсән һәм гүя йөрәгенә ут салды: — Сөйгән егетен тартып алдың бит, Әдиләкәй!..

Әдилә ни дип әйтергә белмичә аптырады да калды.

— Кемне? Зарифнымы?!.

— Шул инде, шул! Зариф абый белән йөргәннәр иде бераз. «Онытa алмыйм гына шул мөртәтне», дип уфтана тилекәй.

Әдиләнең йөрәге җуу итеп китте. Ниндидер ярамаган эш эшләп ташлаган кебек тойды үзен.

— Әй, кайгырмасана шуның өчен! Таптыгыз хәсрәтләнер нәрсә. Яратмаганны ябыштырып булмый. Әйдәгез, халат, чиләк алабыз да сыер саварга чыгабыз. — Әдиләнең икеләнеп калуын күргәч, Лэйсән аны култыклап алды. — Әйдә, әйдә, сынатма шул җебегән Фирдәүсәләргә. Яратам да соң шул көнләшкән кешеләрне үртәргә! Егет беткәнме әллә?!.

Әдилә иңбашларын җыерып куйды. Янәсе, минем ни катнашым бар соң әле? Ләкин юри генә шулай кыланды ул. Чынында исә бу хәбәр аңа әллә ниткән сагыш китерде, ниндидер әлегә үзе дә аңлап бетермәгән уңайсызлану хис итте ул.

Абзарга чыккач та ул Фирдәүсә ягына карап-карап алды. Түгәрәк йөзле, чөенкерәк борынлы, бит очлары алсуланып торган, юантыграк гәүдәле кыз... Әмма Әдилә аңа бөтенләй башка яктан килеп карады: кызда Зариф кызыгырлык нәрсә күрер икән?!.

— Менә шуны саварсың, — диде аңа Лэйсән, дәү корсаклы ала сыер янына туктап. — Исеме дә мәхлук, үзе дә. Холыксыз түгел, курыкмагыз.

Алар янына Фирдәүсә килде. Ул Әдиләгә нидер әйтергә дип, авызын гына ачкан иде, Лэйсән аның аягына шундый иттереп басты — кыз чыр-рыйлап кычкырып ук җибәрде.

— Кычкырма юкка, бер көнне минем аякка үгез дә басты әле, түздем. Һәй, кызлар, әйдәгез бирегә, «укытучыбыз» сыер саварга өйрәнә!.. — дип аваз салды Лэйсән.

Шундук аларны кызлар сырып алды. Терлекче егетләр дә килеп басты.

Институтта укыганда бер тапкыр сыер савып карарга туры килгән иде Әдиләгә. Әйтәсеме, рәтләп сава алмады, әлбәттә. Шулай да бу эшкә керешергә өйрәнгән иде, кыю тотынды. Әйдә, шаккатырсын әле үзләрен. Әдилә ашыкмыйча гына халатын киде, сөлгесен җылы суга манып алып, сыерның җиленен юды, имчәкләргә вазелин сөртте. Аннары, халат итәкләрен җыя төшеп, тәбәнәк урындыкка утырды да җайлап кына чиләген куйды. Ала сыер мышный-мышный алдындагы азыкны ашый, нигәдер башын чайкап куя. Әдилә сак кына имчәкләргә кагылгач, малның корсак тиресе көзән җыергандай тартышып куйды. Әдилә

ике кулы белән ике имчәкне кысып тотты да сава башлады. Нечкә генә сөт җебе чиләккә таба сузылды. Чиләк зыңлап, җырлап җибәрде кебек. Аннары Әдилә бүтән имчәкне тартты, ләкин, ни галәмәттер, бу юлы сөт җебе аның битенә сиптерде. Кызлар пырхылдашып алдылар.

Әдилә имчәкләргә катырак ябышкач исә, сыер, яман ачуланып, чиләкне тибеп тә җибәрде. Әдилә чак кына артка очып китмәде, Ләйсән, аның култык астыннан эләктереп, торырга ярдәм итте. Чиләк исә, шалтыр-шолтыр килеп, таш идән буйлап тәгәрәп китте. Әдилә, бит очлары ут кебек януын тоеп:

— Кирәкмәс, Ләйсән, өйрәнмим, булмый! — диде.

Шунда алар янына ферма мөдире Лотфулла килеп керде.

— Һәй, чиркәү чәүкәләре, нишләп җыелдыгыз әле монда?! Марш эшегезгә! Сыерлар салган азыкларын ашап бетерәләр инде! Ләйсән, Ләйсән, син җыйдыңмы? — Лотфулла, Әдиләне күреп, исәнләшеп алды.— Исәнмесез, иптәш Латыйпова.

— Исән-исән, Лотфулла абзый. Ярый әле, килдегез, юкса, эзләп барырга иде исәп, — диде Әдилә өчен Ләйсән.

— Таралыгыз диләр сезгә! — дип, Лотфулла кызларны куа башлады.

Ләйсән дә, күзләрен аның кебек алаландырып, аяк типте.

— Таралыгыз диләр сезгә! Ниндәен эш инде бу!..

Үзен үртәвен күрсә дә, Лотфулла Ләйсәннең сүзләренә игътибар итмәгәнгә салышты. Ләйсән читтә аунап яткан чиләкне алып килде.

— Күрче бу мәхлукне, Лотфулла абзый, өченче чиләкне шулай итә инде. Тибә дә очыра, тибә дә очыра.

— Ничә тапкыр әйттем мин сиңа тышаулап сау шул мур кыргырыны дип! Хәер, сиңа хәзер чиләк кирәкмәс инде. Клуб мөдиренәмедер укырга Казанга җибәрәләр үзеңне, чакыру кәгазе килгән.

Башта Ләйсән Лотфулланың сүзләренә ышанмады булса кирәк, бер тын ни әйтергә белмичә аптырабрак торды. Аннары, каршындагы Әдиләне кочаклап алды да:

— Ур-ра! — дип кычкырып куйды.

— Әй, син Ләтчәгә әйттең ни дә, әйтмәдең ни, — диде Лотфулла, кулын селкеп.

— Чынлапмы, Лотфулла абзыкаем?

— Чын булмыйча! Менә җүләр баш, мин тагын сауган вакытта әйтәм. Ташлый бу хәзер, сыерларын да саумый китә.

— Савам, савам, Лотфулла абзыкаем, сыерларымны да савам, аннары сине дә үзем белән Казанга алып китәм.

— Миңа ни калган анда?

— Укырга, укырга, Лотфулла абзыкаем. Җиде класс белемең белән шулай гомерең буена мөдир булып эшләрмен дисеңме?

— Һәй, яман телле дә соң үзең, Ләйсән. — Лотфулла, кызларның җыелуын күреп, тагын куа башлады. — Ике сәгать кайнашасыз бит инде. Тагын җыелдыгызмы? Марш эшегезгә!.. Таибә, син кал әле! Менә нәрсә, сеңелкәш, мин кичке савуга кала алмамдыр. Әллә нигә баш авыртып тора.

— Начар көмешкәдән ул, Лотфулла абзый,— диде Ләйсән һәм сыер сава башлады.

Фермадан Әдилә авыр тойгы белән кайтты. Ләйсәннең: «Сөйгән егетен тартып алдың бит, Әдиләкәй», дигән сүзләре көн буе күңеленнән китмәде.

Әдилә өйгә кайтып керүгә, Фәһимә апасы аңа Җәвиттән хат тоттырды. Укыгач, Әдилә боегып калды, уфтанып куйды.

— Ниләр яза?

— Бәхетсез мин, апа җаным...

— И-и бала, бала, ниндәйләр генә киңәш бирим соң үзеңә? Бер дә күз яше түгәсе түгел дә бит. Ир-зат сөймәслек сөякләрең бармы әллә?..

«Ни сөйли бу Фәһимә апа. Аңламыйсың шул, белмисең, Фәһимә апакаем, Әдиләнең эчендә ниләр көйрәгәнен».

— Бүген әнә Казан артистлары килгән, ди. Гөлзифа түтәй дә барам, диде. Баланы күршеләргә калдырып торырбыз. Чәчкәне әйтәм, күрше Гөлүсәсе белән шундыен матур уйныйлар, исләрең китмәле инде менә. Ул ашка чакырышалар, бер-берсен кысташалар. Бәхеткәйләрең ташып торган чагында бер дә уфтанасы юк. Алма кебек балаң бар. Ир нәрсә ул?! Хатын-кыз өчен култык таягы гына. Исән кешегә булды ни дә ул таяк, булмады ни.

...Концертка аны Зариф кереп алды. Тыкрыктан клуб ягына киттеләр. Күк йөзендә бер-бер артлы йолдызлар калкып килә, клуб тирәсендә шау-шу, ыгы-зыгы. Алардан алда бер егет белән бер кыз атлый, егетнең кулы — кызның билендә. Тартынып-нитеп тору юк, үбешә-үбешә баралар.

— Соңга калмыйк тагын.

Адымнарын кызулата төштеләр.

Фойеда аларны Ләйсән белән Котдус каршы алды.

— Хәерле кич, картлач, — дип, Котдус Зарифка кул сузды, аннары Әдилә белән күреште.

— Әдилә, — диде Ләйсән, күзләрен елтыратып. — Тәбрикләү берәүне.

— Чынлап җибәрделәрме? — дип сорады Әдилә.

Ләйсән күзләрен йома төшеп баш какты.

— Үзебездә торырсың. Тулай торакка барам дип авызыңны да ачма.

— Ашыкмагыз ул чаклы. Әүвәл керсен, — диде Котдус.

— Биш ел үтә дә китә ул, Котдус, бер дә кайгырма.

— Ә үзегез биш ел көтәр идегезме? Әйтик, йөргән егетегезне биш елга каядыр укырга җибәрсәләр? Сезнең янда ут күзле егетләр урала ди!..

— Яратсаммы? Биш ел түгел, гомерем буе көтәчәкмен, Котдус.

— Сез шул, Әдилә, бөтенләй башка кеше. Бу ут борчасына кем кызыкмас, — диде Котдус, уенын-чынын кушып.

— Син, Әдилә, ул турыда миннән сора. Ләйсәнне җибәрмим дип, авызын тагын бер ача икән бу аю, — Зариф Котдусны җилкәсе белән җиңелчә генә төртеп җибәрде, — эшне минем белән хәл итәргә туры килмәгәе аңа. Мин болай уйлыйм: әлегә аның Ләйсәнне тыярга бернинди хакы юк. Иң әүвәл законлы итеп язылышсын. Аннары сөйләшер. Шулаймы, Ләйсән?

— Җәмәгать, җәмәгать, туктагыз әле, мин монда өй бетереп ятам, ә ул китеп барсын, — диде Котдус, беләгенә ике куллап сарылган Ләйсәнгә карап алды. — Мин, мәсәлән, үз-үземә ышанмыйм. Ләйсәнгә охшаган берәр чәчби килеп: «Котдус, җаным, мин синең хәләл җефетең булам», дия икән, Кәнзел кебек, Гайзулла мулладан никах укытып кына өйләнү коткысыннан ничек котылмак кирәк? Юк инде, менә бу җан кисәк я иртәгә үк минем белән язылыша, я...

— Нәрсә я?.. — диде Зариф. — Әйдә, әйтәсеңне әйтеп бетер...

— Я мин дә аның белән Казанга китәм, — дип елмайды Котдус һәм Ләйсәнне нечкә биленнән эләктереп әйләндереп алды. — Я ул да, мин дә беркая да китмибез, Зариф дус.

Алар яныннан Талип белән Кәфия узды.

— Хәерле кич, — диде аларга Кәфия. Талип ияк кагып кына китте.

Галимә карчыгын ияртеп, Харисов та яшьләр яныннан үтте. Чошын-пошын сөйләшеп үсмерләр үтеп-сүтеп торды. Таибәне култыклаган шофер Габбас күренде.

— Ярый ла укытып-укытып әйләнеп кайтса. Диплом алуга берәрсенә ябышып китеп барса? — дип, һаман үзенекен тукыды Котдус.

— Китте ди менә. Үзең берәр пумала баш табып куйма!

Клубта кыңгырау чыңлады, фойедагы халык залга керә башлады.

...Түбән очта ләң-ләң этләр өрә. Аларга кушылып саташкан бер әтәч тамак ертып кычкыра, ындыр табагы ягыннан мәче башлы ябалакның еламсыраган тавышы ишетелеп куя.

Зариф сүзсез генә Әдилә янәшәсендә атлый. Алар концерт турында сөйләштеләр-сөйләштеләр дә кисәк тынып калдылар. Борынга аяк астындагы бөтнек исе, Әдилә чәченнән ислемай исе керә.

— Әдилә, сиңа күптән инде бер сүз әйтергә теләп йөрим. Мин беләм...

— Берни дә белмисең шул әле, Зариф. Берни дә белмисең, дускаем. Мин бит әле аның белән аерылышмаган да. Без дуслар, ни барысы дуслар гына булып калыйк. Мин куркам, нигә куркам, нидән? Үзем дә аңламыйм. Әмма куркам, нигәдер хурланам мин, Зариф!..

Һава салкыная төште, тәнне куырып, салкын җил исеп куйды.

— Син киткәч, изге җанын җуйган кешедәй, мин һәр кичне шушы тыкрыкка килермен инде...

— Кирәкми, Зариф. Андый сүзләр сөйләмә.

Күктә тулган ай йөзә. Аның нурлары бу минуттагы Әдилә йөрәгедәй салкын, сүрән төсле.

Капка төбенә килеп җиттеләр. Әдилә аңа кул бирде.

— Үпкәләмә миңа, Зариф, кәефем юк бүген.

Зариф аңа үпкәләми, шулай да аның күңеле әрни иде.

Шыгырдап капка ачылды. Менә инде ул ябылды да. Шылтырап келә төште.

Көнчыгыштан күк йөзенә аксыл-сары нурлар сузылып килә. Караңгы пәрдә акрын гына көнбатышка таба шуыша. Зариф өенә кайтып житте, ишегалдына керде һәм, әбисен уятырга кызганып, печәнлеккә кереп ятты.

## 40

Кичләрен, бүлмәләрдә утлар сүнгәч, район комитеты бинасының коридорларында тынлык урнаша.

Хөснетдиновның секретаре ишектән башын тыкты:

— Ирек Нәҗмиевич, мин киттем.

Кәгазьләргә күмелгән Хөснетдинов сводкалардан күзен алмыйча гына баш какты. Ул әле яңа гына киңәшмә үткәрде. Кинәт урнашкан тынлыктанмы колак җиңелчә генә шаулый. Тиздән хатыны шалтыратыр. «Ирек, кайт инде, аш суына» дияр. Хөснетдинов: «Ярый», дип әйтсә дә, һаман утыра бирер.

Ачык тәрәзәдән саф һава керә. Кояш инде баеп бара.

Хөснетдинов, мәктәп балаларыдай, яңагына таянды да уйга калды. Районда икмәк тапшыру планы үтәлде. Ә менә ит? Ит тапшыруны «Берек» колхозы тоткарлый. Талип Бикмуллин комплекс сала башлагач ук шикләнгән иде ул. Каян алыр «Берек» тагын ике йөз баш мөгезле эре терлек? Бүген анда өч йөз баш савым сыеры бар. Талиптан аның берсен дә алып булмый. Димәк, бөтен авырлыкны башка колхозлар өстенә салып, «Берек»нең планын киметергә туры килә. Бу юл мәшәкатьле дә, бәхәслерәк тә. Председательләр арасында канәгатьсезлек туар, беренче киңәшмәдә үк үпкә белдерүләре бар...

Райком бинасының түбәнге катында ишек ачылган тавыш ишетел-

де. Һәм берәү шак-шок басып икенче катка менә башлады. Аяк тавышы алгы бүлмәдә ишетелде. Ишек ачылды.

— Мөмкин булырмы, Ирек Нәҗмиевич?

— Кер әйдә.

Талип өстәл янына килеп утырды, тез өстендәге папкасында бармакларын биетеп алды.

Хөснетдинов тураебрак утырды, тыңларга җыенды.

— Ирек Нәҗмиевич, минем кайбер фикерләрем бар иде. Алар менә бу папкада.

— Үзең генә яздыңмы?

— Район идарәсе начальнигы Куклина иптәш белән эшләдек. Идеясе минеке, исәпләүләр, хисап эше — аныкы.

— Димәк, икәү яздыгыз? Нәтиҗәсен генә әйтеп чык әле?

— Сезгә мәгълүм булганча, без комплекслы бригадаларны бетереп, цех системасына күчтек. Һәр цех хуҗалык исәбендә. Ярдәмчем юк. Председательнең урынбасары булып өлкән диспетчер калды, — Талип мыек астыннан гына көлемсерәп сүзен дәвам итте. — Партком секретаре — киңәшчем, юл күрсәтүчем инде ул. Шулай булды да, шулай калды да. Бусы булды бер. Икенчедән, Ирек Нәҗмиевич, колхозга экономист алдык, баш бухгалтер, баш агроном берәмлекләре кертелде. Баш инженер да — һәммәсе дә начальник дәрәҗәсенә күтәрелделәр. Исемнән җисеме алышынмаса да, безгә бу чараны үткәрү кырчылык, терлекчелек, бакчачылык, төзелештәге тәртипләрне производствога нигезләп үзгәртергә мөмкинлек бирде. Хәер, сез боларның барысын да беләсез, киңәшмичә эшләнмәде. Хәзер менә нәрсә турында әйтәсем килә, Ирек Нәҗмиевич. Миңа калса инде район авыл хуҗалыгы идарәсе безнең өчен сукыр эчәк кенә.

Хөснетдинов: «Я, я, дәвам ит, кызык бу», дигәндәй, аркасын урындыгына терәбрәк утырды. Талип Бикмуллинның тәкъдимнәре аны ул хәтле кызыксындырмады, чөнки аларны ул күптән белә иде, ә менә соңгысы Хөснетдиновны сагаерга мәҗбүр итте.

— Инде терлек продуктларын колхозлардан сатып алу мәсьәләсенә күчик. Бездә һичнинди исәпләүләр белән дә акланмый торган перекупщиклар бар. Нигә, әйтик, район үзәгендә шундый бер звено тотарга? Хаҗәте бармы? Юк. Терлекне без турыдан-туры Бөгелмә ит комбинатына да илтеп тапшыра алабыз ич. Инде элеваторга килгәндә, эш катлаулырак. — Талип, папкасын ачып, берничә бит алды. — Элеватор белән колхозлар арасында эшне гадел алып бару өчен район үзәгендә лаборатория булдырырга кирәк, Ирек Нәҗмиевич. Бу лаборатория күзгә бәрелеп торган бәхәсләрне чишүдә ярдәмче звено булыр иде. Нефтьчеләрдәге кебек. Алар бит менә ничек итәләр: промыселчылар үзләренә тикшерә, нефть кудыручылар үзләренә. Ул гынамы, промыселчыларның лаборанты нефть кудыручыларда эшли, ә нефть кудыручыларныкы промыселчыларда. Ике катлы контроль. Әйтик, шул тәртипкә нигезләнеп, без дә элеваторга үзебезнең лаборантны куйсак. Контроль өчен? Хезмәт хакы колхозлардан. Һәм ике арадагы бәхәс тә шуның белән бетәр иде...

Хөснетдинов, түземен җуеп, утырган җирендә борсаланып алды, ахырда торып, ишекле-түрле йөреп килде.

— Әйдә, әйдә, дәвам ит, — диде ул тәрәзә каршына басып, утлар янып торган урамга карады.

— Бетерәм, Ирек Нәҗмиевич. Тракторларны ремонтлау мәсьәләсе турында. Сезгә дә мәгълүм: «Берек»нең кырык ике тракторы бар. Шуларның егерме дүртенә «Сельхозтехника» капиталь ремонт ясарга тиеш иде. Әмма анда ун тракторыбыз гына ремонтланды. Калганнарын үзебезнең мастерскойда эшләдек. Ә акчаны «Сельхозтехника», егерме дүрт тракторга гарантияле ремонт ясадык дип, тулысынча кае-

рып алды. Минемчә, Ирек Нәҗмиевич, трактор-комбайннарны ремонтлау өчен үзебездә дә база камил хәзер, ә безнең районга «Сельхозтехника» түгел, «Сельхозснаб» кирәк...

Хөснетдинов өстәл янына килеп утырды да Талипка елмаеп карап торды.

— Сиңа ирек бирсәң, Талип, колхозларны бүгеннән завод итәр идең, мөгаен, — диде секретарь, битен кулы белән сыпырып. — Гомумән алганда кызыклы гына тәкъдимнәрең бар, уйланырлык. Ләкин боларның берсе дә ашыгып эшләнә торган нәрсә түгел. Докладыңны укып чыгыйк, киңәшик, уйлашыйк. Аннары күз күрер. Кая, бир папкаңны?

— Аннары, Ирек Нәҗмиевич, минем тагын бер сүзем бар иде. Безнең механизаторлар берничә чәчкечне үзгәртеп кордылар. Аркылыга-буйга чәчмичә, бер үтүдә сибеп төшерә торган чәчкеч турында бара сүз. Идеясен Гариф Әюпович бирде. Андый чәчкечне Алтай механизаторлары ясап караганнар икән инде. Инженерым барып кайтты, чертеж-эскизлары бездә дә бар.

Сельхозтехника гына үзгәртә алмыймыни ул чәчкечләрне?

— Үзгәртә ала, нигә үзгәртмәсен. Тик планында каралмаган, шуңа эшләми. Без аны үзебез дә үзгәртер идек, тутыкмый торган калай кирәк...

— Син мине тәэминатчы итәргә исәп тотасыңдыр инде. Комплекс өчен торбалар-җиһазлар кирәк — миңа киләсең, төзелеш материаллары җитми — тагын миңа... — Хөснетдинов блокнотына нәрсәдер язып куйды.

— Теләсәм, башка юл белән дә таба алам. Тик ул юлга басасым килми, Ирек Нәҗмиевич. Бу дәүләт предприятиеләрендәге тәэминатчыларга шаккатам. Болай саталар, ә документ белән алырга теләсәң, һичкайдан табып булмый...

—Бик күп алмыйсыңмы үзеңә, Талип? Һәркем үз эшендә җаваплы. Ә калай мәсьәләсендә ярдәм итәргә тырышырбыз...

Хөснетдинов беренче булып урыныннан кузгалды һәм кием шкафына таба китте. Талип та ишеккә юнәлде.

— Ул чәчкечне сынап карадыгызмы соң әле?

— Йөз гектар көзге бодайны шуның белән чәчтек.

Секретарь ишек янына җиткәч кенә телефон шалтырады.

— Хатын шалтырата, — диде Хөснетдинов. — Вакытында ашамыйсың, язвань тагын кузгала инде, дип борчыла. Ә синең борчылучың да юк дип ишеттем мин, хакмы шул?

— Кәфия белемен күтәрергә Казанга китте, — диде Талип һәм нигәдер үзалдына кызарып куйды.

Урамга чыктылар.

— Машинаң кая?

— Колхоз йортында.

— Син кем янына алай кергәләп йөрисең?

— Сабакташым ул минем, Ирек Нәҗмиевич.

— Сабакташың! — диде Хөснетдинов кинаялэп. — Бирермен мин сиңа сабакташыңны. Кара аны, Талип, хатыныңнан сүз була икән, миннән мәрхәмәт көтмә.

Талип дәшмәде, Хөснетдиновның сузылган кулын җиңелчә кысты да тиз-тиз китеп барды.

## 41

Җыелышны бүген колхозның өлкәннәр советы председателе Чапай Мөлек алып барачак. Пенсиягә чыгасы картлар әкрен генә җыелалар. Чапай Мөлек, гадәтенчә ашыга, борчыла иде. Ишек янында торган йомышчы кызны чакырып алды.

— Җәмилә кызым, бар әле идарәгә, ашыктыр үзләрен. Халык җыелды диген.

— Люция барды инде, Талип абый, хәзер керәбез, дигән.

— Ә син тиз генә тагын барып кил.

Йомышчы кыз: «Хәзер!» дип чыгып китте. Ләкин бу вакытта идарәдә бәхәс кызып кына бара иде әле. Һәммә колхозчыга пенсия мәсьәләсе әллә кайчан хәл ителгән булса да, Тажылбанат белән Гайзулла Бикмуллиннар исем-фамилиясе чыгуга, Харисов кулын күтәрде.

— Бу кешеләргә пенсия бирүгә мин каршы. Исемлекне мин әле җентекләп карамаган идем. Уйлавымча, бу кешеләргә колхоз пенсиясе хәрам. Кодрәтем житсә, мин аларны колхоздан куар идем...

Идарә эчендә тынлык урнашты. Кәгазьләр актарып утырган баш бухгалтер Кәримулла да, өстәл читендә нидер язып торган экономист та, диван терәгенә кунаклаган Равил дә, Харисов шулай диюгә, ни әйтергә белмичәрәк аптырап калдылар.

Талип күлмәк сәдәфен ычкындырып, муенын уңлы-суллы боргалап алды. Баш агрономга, яңа елдан соң гына эшкә килгән экономист Исмәгыйловка, аннары баш инженерга күз төшереп чыкты. Ахырда комсомол оешмасы секретаре Кадыйровка төбәлде. Күренеп тора: аның үзенә Бикмуллиннар турында сүз әйтүе кыен иде. Ләкин Кадыйров та, башкалар да сүз әйтергә ашыкмадылар.

— Әдһәм абый,— диде Талип, сабыры төкәнеп.— Андыйлар бездә бер Бикмуллиннар гына түгел бит. Җиделәп кеше җыела. Һәм җидесенең берсе колхоз эшенә рәтләп катнашмаган. Ләкин алар җилкәсендә сугыш еллары... Нигә әле, әйтик, бер Бикмуллиннарны гына пенсиядән мәхрүм итәргә тиеш без? Минем карендәшләр булганы өчен түгелдер бит? Алай булмаган хәлдә, нигә, әйтик, Нәгыймә Фәттаховага пенсия билгеләргә? Илледән соң гомумән башы шәһәрдән кайтмады?

— Нәгыймә башка, Нәгыймәнең ире сугышта үлеп калды, — диде Харисов.

— Минем уемча, кем генә булмасын, ул, колхозга хезмәт иткән икән, без аңарга ниндидер күләмдә пенсия билгеләргә тиеш булабыз,— дип телгә килде, ниһаять, Равил Кадыйров.

— Хак, хак әйтәсең, Равил туган. Хезмәт иткән һәр кеше хөрмәткә лаек,— диде баш бухгалтер.— Тик шулай да бизмәнгә салып үлчәгәндә...

Кабинетка шофер Фәрит килеп керде.

— Гафу итегез, Талип абый, тагын кемне китерим?

— Бикмуллиннарны алып кил, — диде Талип, башын күтәрмичә генә.

— Менә мин монда Бикмуллина Тажылбанатның хезмәт кенәгәсе белән танышып утырам, — дип, урыныннан күтәрелде Мидхәт. — Мин аны эшләмәгән дип әйтмәс идем. Дөрес, башкалар белән чагыштырганда Бикмуллиннарның хезмәт көннәре шактый ким күренә. Шуңа карамастан, мин бу кешеләргә, бу картларга пенсия бирү ягында. Бер аларны гына пенсиядән мәхрүм итү безнең файдага булмас кебек. Җитмәсә, берсе авылның мулла кисәге, икенчесе абыстай исемен йөртә. Халык арасында моның ялгыш яңгыраш алуы бар. Шуңа охшаш кимсетүләр, кимсетү булмаган хәлдә дә, иртәме-соңмы безнең дошманнарыбыз колагына да барып житә. Дәүләт күләмендә фикер йөрткәндә бу мисал безгә бер дә кулай түгел кебек...

Харисов эчтән Талип белән дә, Равил белән дә, Мидхәт белән дә килешә иде. Тик барыбер ачыктан-ачык ризалыгын бирмәде. Аны бу яшьләр аңлыймы соң! Бикмуллина Тажылбанат гомер буена Совет дәүләтенең яманатын сатты. Тажылбанат өйдән-өйгә ашка йөргәндә Харисов җык чигеп, үгезләр белән колхоз җирен сөрде. Ул елларда арык атлар белән район үзәгенә икмәк ташулары, бер барышлый буранда адашып үлгән өч солдатканы күмүе, ятим калган биш баланы үзендә

тәрбияләве... Боларгамы соң аңлау Тажылбанатның кем икәнен. Авыр сугыш елларында да игелек күрсәтмәде диярлек ул Тажылбанат. Уракка чыкса чыкты, чыкмаса юк. Дөрес, Гайзулласы сыерлар фермасында эшләде.

— Тажылбанатка пенсия билгеләү мәсьәләсендә мин үз фикеремдә калам,— диде Харисов, кузгала башлап.— Тик, ай-һай, эттән сөяк артыр микән?

— Ул аны үзе дә алмас әле,— диде баш бухгалтер.

— Алмаса, бик әйбәт булыр,— диде Харисов, ишеккә таба атлап.

Болдырга чыгып бастылар. Идарә алдыннан үтеп баручы Минһаж бабай аларга сәлам-шәрифләр җиткерде.

— Үзең исәнме-саумы, Минһаж бабай? Нигә ашыктың, Фәрит килгәнне көтмәдең?

— Рәхмәт, Талибулла, шыгырдабрак булса да, аллага шөкер, йөрибез әле. Хәрәкәттә — бәрәкәт,— диде Минһаж карт һәм калошларын лаштыр-лоштыр өстерәп клубка таба китте.

— Фәрит кермәде микәнни бу Минһаж бабайга?— диде Талип.

— Утыртырсың син аны машинага. Кичке якта күл тирәли бер урамасам, йокым йокы түгел дип әйтә, ди. Җәй килдеме, мәтедән чыкмый,— диде Кәримулла.

— Биле сызлап йөргәндә ул Гариф Әюповичка да шул мәтегә керәп ятарга киңәш иткән. Галим кеше зур күл башындагы мәтегә барып ята буламы инде?!

— Башыңа төшсә, әле ничек ятарсың, Мидхәт туган.

— Кемне көтәбез, Талип абый?— диде Равил.

— Әнә кемне,— диде Талип, тыкрык чатыннан Фәритнең газигы килеп чыгуга.

— Күрче бу беткән баш Фәритне,— диде Харисов болдырдан төшә башлап.— Әллә чынлап торып шуларны китерә инде.

Талип күккә карады. Сәләмә болытлар клуб түбәсендәге телевизор антеннасына тия язып йөзә иде. Пыскып кына, иләктән сипкән кебек, яңгыр сибәли.

— Бирмәде икмәкләрне җыярга, тәмам томалады бу, әй. Яумый да, аязмый да дигәндәй...

Харисов та, туктап, һавага күз салды. Әмма сүз әйтмәде, плащына төренә төшеп, клубка таба кузгалды. Идарә каршыннан Әдилә узып китте, клуб ягында Зариф гәүдәсе күренде. Талип, шуны күрде дә, янәшәсендә басып торган Кәримулладан:

— Әллә соң безнең бу Зариф моңа өйләнергә йөриме?— дип сорады.

— Кем белә инде аларны! Шулайрак сөйли халык. Бәлкем берәүнең тагын да бер тапкыр бәхет сынап карарга исәбедер.

Идарәдән экономист чыкты.

— Талип абый, сезне беренче секретарь дәшә.

— Тагын шул ит турындадыр инде,— диде Бикмуллин һәм ашыгып идарәгә кереп китте.

Машина идарә каршына килеп туктады. Фәрит җәһәт кенә төште дә, әйләнеп килеп, Тажылбанат ягындагы ишекне ачты.

— Рәхим итегез, абыстай!

Алдан елкылдап торган кара бәрхет җинел пальто кигән, эре роза чәчәкләре төшкән француз яулык бәйләгән Тажылбанат, аның артыннан Гайзулла чыкты. Тажылбанат башын күтәрә төшебрәк болдырга таба атлады, аңа тагылып диярлек, кипарис куләгәсенә эләккән тал сыман, Гайзулла кузгалды. Мулланың башында шул ук читләре шәлперәйгән киез эшләпә, аягында читек өстеннән кидергән резин калош. Болдырга менгәч, Тажылбанат туктады, клубка таба китеп баручы Харисовның бөкрәя башлаган аркасына карап торды. Нигәдер кортканың

иреннәре бөреште, күзләре чекерәйде. Аннары, башын тагын да чөя төшеп, идарәгә юнәлде.

— Күрче син, әй ниндәен һавалы кылана абыстаебыз,—диде Фәрит, янәшәсендә басып торган Равилнең касыгына төртеп алды.

— Талибулла, исәнме-саумы! Син чакырттыңмы тутаңны? — дип, гөлдердәп килеп керде председатель кабинетына Таҗылбанат.

Талип телефон трубкасын аппаратка куйды һәм ачулы рәвештә:

— Түткәй, бу ни дигән сүз инде тагын? Чынмы пенсиядән баш тартуың?!— дип сорады.

— Башта исәнме-саумы диген, урын бир, тәрбиясез!

Талип бераз кызарынып китте.

Ул тутсылрак чырайлы, бите вак кына җыерчыклар белән ермачланып беткән, әмма шуңа да карамастан, чибәрлеген җуймаган тутасының күзләренә туры карады.

— Кешедән оял бераз, түткәй...

Таҗылбанат дәшмәде, күлмәк итәкләрен җыя төшеп, диванга утырды. Карты Гайзулла да шунда кысылды. Талип зур диванны бер итеп утырган тутасына беравык ни әйтергә белми аптырап торды. Ниндидер бер мизгел эчендә күңел күгеннән бөтен сабый чагы үтте. Бер тапкыр аны тутасы салкын кыш көнендә ишегалдына куып чыгарган иде. Талипның бозлы идәнгә аяклары ябышты, үкчәләре туймас булды. Башта Талип илереп елап карады, анда да тутасы гамьсез калгач, ике куллап ишекне төяргә кереште. Әмма тутасы барыбер ишекне ачмады. Талип, өметен өзеп, болдыр почмагына чүмәште, юк-бар күлмәк итәген аякларына капларга тырышты. Шунда каяндыр җизнәсе кайтып керде. Ул аны күтәреп алды да өйгә кертте, җылы тунга төреп, мич башына утыртты. Баланы өйгә керткән өчен чәрелдәгән хатынына ул:— «Тик тор!» — дип аяк кына типте.

— Без синең ул акчаңа калмаган,— диде Таҗылбанат, Талипны уйларыннан бүлдереп.

— Бик бай булсаң, җизнәйгә адәм рәтле бирәр нәрсә алып бирер идең. Мин белгәннән бирле кия бит шул эшләпәсен.

Таҗылбанатның чем-кара күзләре як-якка йөри башлады, тутсыл чыраена сизелер-сизелмәс алсулык йөгерде.

— Хәер сорашканабыз юк әле, аллага шөкер. Өстебез бөтен, тамагыбыз тук дигәндәй...

— Я инде, куйсана, иш янына куш ярап торыр диген дә...— дип, карчыгының җиңенә җиңелчә генә кагылып алды Гайзулла.

— Абыстай башым белән калхуздан сәдака алыйммы?!

— Куй диләр сиңа! — диде Гайзулла ачуы чыгып.— Җитмәсме!

— Кәмит уйнап утырма әле. Үзем үстергән кеше. Ни әйтсәм дә сыяр. Кермим мин ул җыелышыгызга, Талибулла. Илтеп куйсын мине Фәритең!

Таҗылбанат жилләнеп торды да ишеккә таба китте. Аның бала итәкле озын күлмәге идәннән сөйрәлә, вак-вак атлап барган җайга кара калош кигән бизәкле кызыл читеге ялтырап күренеп китә иде.

— Туктале, Таҗылбанаттәй...— Талип та торып ишеккә таба кузгалды.— Кешедән оял бераз!..

Ишек янына житкән Таҗылбанат туктады, бәрхетен җемелдәтеп аңа таба борылды.

— Бәрәкалла, ни дип оялтасың әле син тутаңны? Оят түгелме дигән була. Кемнән оялаем мин, синнәнме? Бик итәгем селкенә меңә!..

Шулай диде дә Таҗылбанат чыгып китте. Гайзулла да аның артыннан кузгала башлаган иде, Талип тегене туктатты.

— Әйдә, китә бирсен. Тәмам җен алыштырды бу түтәйне. Син дә ир була белмәдең инде, җизнәй!..

— Нилəр кылыйм соң инде? Үзем дə аптыраган. Холкы холык түгел. Яман, бик яман холыклы...

Талип, жизнəсенең рəнҗүен күреп, аны чын күңеленнəн кызганып куйды. Əйе, жиңел түгел җизнəйгə бу карчык белəн яшəүлəре, җиңел түгелдер һəм җиңел дə булмагандыр. Җизнəсенең кояшта уңып беткəн күксел-кара пинҗəгенең җиңнəре киндер ыштан балагыдай җыерылып килгəн, аннан коргаксыган киң сөякле белəге күренеп тора. Куе төк баскан кул аркасы нигəдер шəмəхə төсенə кергəн. Болай да бөкресе калкып торган карт, Таҗылбанат җенлəнеп чыгып киткəч, тагы да бөкрəя төшеп, ишеккə таба атлады.



42

Гайзулла егет чакта да, ир уртасы булгач та, картаеп җиткəч тə, хəтта йөрəге туктый язып, больница караватында ятканда да үлем турында уйламады. Үлемне ул бик күп күрсə дə, бу сүз аңа кагылмый, гүя дөньяга ул мəңгегə килгəн кебек иде. Бик күплəргə ясин чыкты ул, бик күплəрне җирлəште, уч тутырып сəдака җыйды, ə менə үзен дə такта кабык өстенə яткырып юарлар һəм кəфенгə төреп соңгы юлга алып китəрлəр дип уйлап та карамады. Ул гомере буена ниндидер яңа тормышның килүен көтте. Бабасы заманнары əйлəнеп кайтмаса да, шуңа охшаш тормышның иртəме-соңмы килəчəгенə ул һаман ышанды. Гомере аның шуны көтеп узып та бара бугай инде.

Картның башына мең төрле уй килде. Əюп малае газетадагы гыйбрəтле хəлне укып киткəннəн соң, ул тəмам аптырашта калды. Үзе телəп алтынны дəүлəткə илтеп бирсə, аның бер өлешен дəүлəттəн акчалата хуҗасына кайтаралар икəн бит.

Гайзулла, эче авыртуына түзə алмыйча, əле бер ягына, əле икенче ягына əйлəнде, тезлəрен иягенə кадəр җиткереп, бөтəрлəнде, тартышты, ахыр түзмəде, аллага дəште.

— Йа ходай, мəрхəмəтеңнəн ташлама...

— Ни булды сиңа, əллə бик хəлең авырайдымы? — диде Таҗылбанат, уянып китеп.— Киленне дəшимме соң?

— Ул Наратбашка киткəн дидeлəр. Талибулла шулай дип сөйлəгəн иде.

— Йөрер инде шунда,— диде Таҗылбанат һəм җəһəт кенə торып утырды.— Грелка биримме əллə?

— Бир булмаса, чыдар əмəлем калмады.

Таҗылбанат ут алмыйча гына өй эчендə йөренə башлады. Аның актан киенгəн гəүдəсе күктəн төшкəн фəрештə сыман күренде Гайзуллага. Грелка куйгач, авыртуы басыла төште, карт йокымсырап күзлəрен йомды.

Иртəн аңа Таҗылбанат баллап чəй бирде, мəтрүшкə кайнатып эчерде. Аннары йомшак түшəк-ястыкка яткырды да өстенə ике кат юрган япты.

— Тирлəп чыкканчы ят əле шулай.

Мəтрүшкə шифасы тидеме, бераздан Гайзулла тагын изрəп йокыга китте.

Ул уянганда кич җиткəн иде инде. Гайзулла күзлəрен ачты да, гəүдəсенең җиңелəеп калуын сизеп, аякларын сузып җибəрде.

Ишегалдында кемдер йөри, чилəк-тазларны кузгата иде. Менə тимер көрəк тавышы килде... Гайзулла кай арада киенүен һəм кай арада кадала-каплана ишегалдына чыгуын сизми дə калды. Иң əүвəл аның күзе абзар капкасына сөялгəн тимер көрəккə төште. Əйе, шик юк, тимер көрəк Таҗылбанат кулында булып алган иде.

Гайзулла арт капкага таба китте. Карчыгын күрмəмешкə салышты. Ул келəт янында кайнаша калды.

— Хәлең ничек, җиңеләйдеме бераз?
— Аллага шөкер, аруландым кебек.
— Шәяхмәт Нуриәхмәте кечке ашка дәшкән ие сине.
Гайзулла сүз катмады, артка чыкты, бакча башындагы тал-тирәкләргә карап торды. Барып караса белер иде, эзсез казый алмагандыр. Шулай бер тын торды да ул, ишегалдына кире керде. Тажылбанат өйдә иде инде. Гайзулла капка янына килде, аннары келәт тирәсен урап чыкты, шуннан соң гына абзар капкасына сөялгән көрәкне барып алды да шул тирәдәге чүпләрне көрәштергәндәй итте. Көрәкне селкетеп карады, сабы селкенмиме, янәсе. Аннары аны күзенә якынрак китерде һәм йөрәге жуу итеп китте: көрәккә бакча балчыгы ябышкан иде. Яңа гына казылган балчык!
Гайзулла каш астыннан гына тәрәзә ягына күз төшереп алды. Тәрәзәгә капланып диярлек Тажылбанат карап тора иде. Гайзулла утынлыкка таба китте, балта алды, түмәр өстенә куеп, көрәк сабының кадагын нигыткандай итте. Аннары, шулай ук гамьсез булырга тырышып, көрәкне лапас башына кертеп ташлады.
Өйгә кергәч ул юынды, өстен-башын алыштырды, сакал-мыегын кырды.
— Кайчанга дәште?
— Кояш баюга килсен дип әйтеп әйтте.
Юлда аңа Харисов очрады.
— Исәнме, Гайзулла абзый!
— Аллага шөкер,— дип, авыз эченнән генә мыгырданды Гайзулла. «Минем исән булуым ни дә сиңа, исән булмавым ни» дип эчтән сөйләнә-сөйләнә, ул тимерче тыкрыгына таба борылды. Ашыгуы ярамадымы, ул тамак төбендә эчкелтем тәм тойды. Кая болай ашыга соң әле? Кемнән курка? Тажылбанаттанмы? Харисовтанмы?
Гайзулланың таллыклар арасына килеп керүе булды, күз алдына беренче хатыны килеп басты. Ул аның турында беркайчан да «Ни өчен менә нәкъ шул таллар арасындагы сукмакка җиткәч кенә Сабира исенә төшә икән?» дип уйламады. Чөнки нәкъ менә шул сукмактан тапты ул аның үле гәүдәсен. Үтерүчеләрне ул белә иде, кайда үтерүләрен дә белде, җаны түзмәде, гәүдәсен үз күзе белән килеп карады. Сабираны көпә-көндез үтерделәр. Ыкка кер чайкарга төшкәч. Актив булганы өчен, хатын-кызларга ирек даулаганы өчен үтерделәр. Әнә ул кер чиләге өстенә капланып ята. Балта түтәсе сытып кергән башыннан куе кан саркый иде. Бу сурәт Гайзулланың гомер буена күз алдыннан китмәде.
Гайзулла бердәнбер серле урынына — өянкеләр янына җитте. Тезләнеп җирне кулы белән капшанды. Тимер казык үз урынында иде. Казыкны суырып чыгарды, яшергән көрәген алып килде, сулышына буыла-буыла казыды. Менә көрәк чүлмәк өстенә каплаган табага тиде, Гайзулланың йөрәге кысылды.
Тырнакларын каера-каера чүлмәкне тартып чыгарды. Ул авыр иде... чүлмәкне тез арасына куеп, беравык күзләрен йомып утырды. Исән! Беркем дә тимәгән!..
Тәңкәләр. Менә алар. Шома, авыр, салкын тәңкәләр. Гайзулла берсен алып тешләп карады. Дымсу тәм килә иде.
Тагын шул ук уй зиһенне телеп үтте: «Кәримуллага илтеп бирсә, ә ул дәүләткә тапшырса. Шул акчага мәчет салдырса?».
Аяк тавышы. Юк, йөрәге шулай тибә. Дөп-дөп, дөп-дөп? Гүя киндер төяләр.
Юк инде, тәгаен аяк тавышы бу. Кемдер бирегә таба килә. Гайзулланың күңеленә гомер буена тынычлык килмәде, тирәк төбенә күмгән алтыны исенә төштеме, аркасы кымырҗып китә, йөрәге кагарга тотына иде.
Үпкәсе авызына килгәнче әлсерәп, ул иске тимерче алачыгына таба

Әдһәмдер, шулдыр, мөртәт. Ул гына, бер дә бүтән түгел, шул кяфер генә сагалый аны. Кая китүемне карап торуы булды, күрәсең, явызның.

Гайзуллага тыкрыкта да инде кемдер бар кебек тоела башлады. Ул, бүредән курыккан яшь колындай, читән буена килеп сыенды. Чүгәләде. Тын калды. Юк, йөриләр. Кемдер тыенкы гына кеткелдәп көлеп алды. Гайзулланың эченә җылы йөгерде. Тыкрык буйлап бер кыз белән егет төшеп килә иде. Гайзулла аларны хәтта таныды да: «Лотфулла Котдусы белән Тәти Фатыйма Ләйсәне бугай.

Корсакны салкын чүлмәк өшетә башлады. Ул чүлмәкне тез өстенә куйды да, аркасы белән читәнгә терәлеп, җиргә үк утырды. Эчәкләрне борып-борып эче авырта башлады. Шул авырту күкрәкне яндырып чигәгә җитте, чигәсе кысуга түзә алмыйча, Гайзулла ыңгырашып куйды.

— Котдус, бередә кемдер бар, мин куркам, әйдә китик,— диде кыз, Гайзулланың ыңгырашуын ишетеп булса кирәк.

— Кәҗә-фәләндер, кем йөрсен мондый төндә?!— диде егет, батырая төшеп.

Шулай дисә дә, алар бик тиз борылып авыл ягына таба киттеләр. Гайзулла аларның караңгылык эчендә эреп югалган гәүдәләрен күздән язганчы озатып калды. Эче борчуга чыдый алмый башлагач, Гайзулла бөяттәй бөгәрләнеп укмашты.

Шулай ята торгач, эч авыртуы әкрен генә басылды. Чүлмәкне ул кычыткан арасына утыртты, чүп-чар белән каплаштырды. Кулларын көйдерсә дә, Гайзулла кычыткан чагуны сизмәде.

Зур урамга чыкты да, Гайзулла Кәримуллаларга юнәлде. Кәримулла урам тәрәзәләре алдына агачлар утырткан. Тәрәзә башларын матурлап сырлап-сырлап ясаткан.

Кече капканы төртеп карады. Капка эчтән бикле иде, күрәсең, ачылмады. Келә бавын тартты. Келә, сикереп, шылтырап, тимер тавышы чыгарды. Гайзулла ишегалдындагы хәрәкәткә колак салды, тавыш-фәлән ишетмәгәч, капкага кулы белән суккалады.

— Кем бар анда? Хәзер ачам!..

Улының тавышын ишеткәч, Гайзулла сабырсызланып алды. Килешкилбәтне, гәүдә-сынны гына түгел, Кәримуллага Гайзулланың төс-йөзен дә биргән иде ходай. Кәримулла капкага якынаюга, Гайзулланың йөрәге тынгысызлана башлады. Секунд эчендә башыннан әллә нинди уйлар үтте. Сабирасы гүр иясе булгач, Кәримулласын үзенә алала иде бит ул. Юк, алмады, Таҗылбанаттан курыкты, Кәримулла карендәшләрендә үсте.

— Кем ул?

— Мин бу, Кәримулла, атаң,— диде Гайзулла, тавышының думбра кылыдай калтырап китүен тоеп, капка баганасына сөялде. Кәримулла да аның болай соң килүенә аптырабрак калган иде, күрәсең, капка шудыргычын ача алмый азапланды. Ниһаять, ачылды капка. Улының өстендә кара күлмәк, аягында җылы чүәк иде. Болдырдан кече капкага кадәр ак тасмадай таш җәелгән. Ишегалдында энә саплардай якты, болдыр кыегында бала башы кадәр лампочка яна.

— Кһм, йомыш төште әле, сиңа, кем, улым, Кәримулла. Әйтәсе васыятьләрем бар иде. Әллә нишләп сырхаулап торам...

Кәримулла аны аңламаудан газиз калып, тамак кырды. Шуңамы, ул-бу сизенепме, ире артында өстенә чәчәкле-чуклы атлас халат кигән хатыны Җәрия пәйда булды.

— Кем ул, нишләп йөри болай бик соң? — Җәрия, ире җилкәсе аша үрелеп, капка баганасына тотынган Гайзуллага күз ташлады.

— Әткәй килгән.

— Кем?! — дип кайтарып сорады Җәрия, ирен читкәрәк этәреп, алгарак чыкты. Килен тавышында зәһәрлек сизеп, Гайзулла баганага сөялеп үк басты.

— Мин бу, килен, Гайзулла атаң.
— Картайгачтын малаең кирәктеме?..
— Алай кирәкмәс иде,— дигән булды Кәримулла Җәриясенә. Ләкин хатыны аңа авызын ачарга да бирмәде:
— Бар әле, кер, ашның кадерен җибәреп юк белән вакыт калдырып йөрмә, карткаем, тавыш чыгармас борын!
Гайзулла кинәт кенә югалып калды. Кәримулладан да, килене Җәриядән дә ул моны һич көтмәгән иде. Ул, капкага учларын салып, бер тын нидер өмет итеп, көтеп торды. Юк, капка янына яңадан килүче булмады. Гайзулла акрын гына кузгалды да Талиплар яшәгән югарочка таба китте.

## 43

Талип Кәфияне машинага чаклы озатты. Шунда Кәфия иренең төк баскан яңагына кагылып алды.
— Матур йөре. Вакытында кырын. Эшләрең җиңеләю белән безнең янга килеп чык. Кара аны, онытма Кәфияңне.
Хатынның зәңгәр күзләрендә яшерен моңсулык күрде Талип. Ләкин начарга юрарга теләмәде.
— Балаларга сәлам юлла. Тырышып укысыннар.
Талип аңа машинага утырырга булышты.
— Комплексны җибәрмичә барып булмас. Җай табып үзегез кайтып китәрсез...
Фәрит машинасын кабызды.
— Я, әнисе, исән-имин барып җит. Хуш!
— Яхшы тор. Андый-мондый хәлләрең ишетсәм, кайтмам да, бел аны!
Кәфия аңа тәрәзә аша кул изәде. Талип та урам уртасына баскан килеш кул болгап калды. Машина ерагая башлагач, Талипка да моңсу булып китте. Кәфия аңа нидер әйтергә тиеш иде кебек, әмма әйтмәде.
Талип икейөзле кеше түгел. Сынау алдында калганда ул Кәфиягә барысын сөйләп бирүдән дә курыкмас иде. Ләкин алар арасында андый сөйләшү булмады. Талип үзе кузгатмады. Чөнки Миңнисаны кинәт кенә ташлый алуыннан курка иде. Иң гаҗәбе: ул моңа — ике хатын белән, ике хис белән яшәүгә гадәтләнә башлаган иде, оялмады. Бер хакыйкать бар: бу дөньяда һәммә кеше, һич югы, бер тапкыр булса да мәхәббәт ялкынында янып алырга тиеш. Шунсыз аның хәтта үләргә дә хакы юк. Талип үзен бу бәхеттән мәхрүм ителгәннәр рәтенә куя алмый. Заманында ул үлә язып Кәфияне яратты. Әле дә ярата... Ә Миңниса? Юк, юк, ул Миңнисаны кызгану хисе аша гына яратты. Кияүгә чыккан, мәгәр уңмаган, чын гаилә бәхетен татымаган. Шуның өчен кызгандымы, шуның өчен йөрдеме ул аның белән?..
Талип аяк астындагы ташны тибеп җибәрде. Таш юл уртасына чаклы тәгәрәде дә очлы кыры белән утырып калды. «Машина баллонына кермәсен тагын». Талип ташны иелеп алды, койма буендагы кычыткан арасына ташлады.
Шунда ул үзләренә килүче Гайзулла жизнәсен күрде. Җизнәсе кадала-каплана атлый иде. Киез эшләпәсе сәлперәеп төшкән, күк төстәге бәрхет чалбарына балчык каткан.
— Әссәләмәгаләйкум, Талибулла!..
— Исәнме-саумы, җизни. Ни булды, нишләп болай чыраең качкан? Чирләмисеңдер бит?
Бу сүзләрдән Гайзулланың күңеленә җылылык йөгерде.
— Арыдым мин, Талибулла. Кәнзел китеп югалды, тоткәннең кансыраудан узганы юк.

Талип йөзенә дә елмаю чыкты. Ул җизнәсен терсәгеннән тотты да өйгә әйдәде.
— Әйдә, әүвәл чәйләп алыйк. Аннары кайгыларны уртаклашырбыз. Ишегалдына кергәч, Гайзулла туктап капкага сөялде.
— Рәхмәт, улым. Яңа гына чәйдән торган идем. Кичен килеп чыгармын,— диде һәм борылып китеп тә барды. Талип арт капка аша идарәгә атлады.
...Болдырда аны агроном каршылады.
— Талип абый, сезне көтәбез. Комплексның бер башнясы тулды, ә икенчесе әзер түгел. Эш туктальш тора.
— Зиннуров нишли анда? Мин бит аңа башняларны силос-сенаж салыр өчен хәзерләп куярга кушкан идем. — Талип ишекне каерып ачты да кабинетка җил-җил үтеп, аппаратка ябышты. — Каюм! Каюм дим, кем белән сөйләшәсең әле син анда? Куеп тор бүтән эшләреңне. Менә нәрсә: ярты сәгатьтән башня янында булам.
Талип аппарат төймәсеннән бармагын алды да Мидхәттән:
— Тритикалны чәчү ничек бара? — дип сорады.
— Туфрак әзер. Вафа чәчтерә.
— Үзең дә күзәт. Ярый, анысы бер хәл. Менә биш йөз баш терлеккә сугарулы болын булдыруны ничек хәл итәбез? Каян башлыйбыз? Урта болын белән генә чыгышып булмас. Бераз урман буен кистерсәк?
— Урманга тимибез.
Талип каш астыннан гына агрономга сөзеп карап алды.
— Мин аны белмимме? Биш йөз баш савым сыерга ни ашатырбыз?
— Колхозчыларның болын янындагы бакчаларын кисәргә кирәк. Бәрәңге бакчасын кырдан бирербез.
— Иртәгә колхозчыларның бәрәңге бакчаларын тотып кисә башла әле син! Юк, халык белән дәгъвага керәсем килми минем. Шулай ук синең фикерең белән дә килешмичә булмастыр...
Талип, Мидхәт янына килеп, аның чәч арасына кергән салам кисәген алып ташлады, иңбашына кулын куеп торды.
— Нигә ябык син бу хәтле, Мидхәт? Хатының ашатмыймы әллә? «Жигули»га акча җыясыңмы?
— Ябыклык ягына килгәндә,— агроном җилкәсен сикертеп куйды,— тән шундый минем. Ашавын нык ашыйм.
— Ничек әле, ашаган малда өмет бар, диләрме?..
Талип, Мидхәтнең аркасына суккалап, кет-кет көлеп алды.
— Өчтәгәрмәчең бирәдәме?
— Бирәдә.
— Әйдә, утыртып алып бар әле мине комплекска. Ябыклык турында әйткәнгә син тагын үпкәли күрмә.
— Юк ла,— диде Мидхәт һәм торып ишеккә китте.

*
* *

Талип кичке уннарда гына өенә кайтты. Өйдә ут булуга гаҗәпләнмәде, Миңлекамал карчык еш кына ярты төнгә хәтле бәйләү бәйләп утыра иде. Ләкин ул, түр якка үтүгә, диванда утырган Гайзулла җизнәсен күреп, бераз аптырабрак калды. Аптырарлык та иде шул: өстәл, өстәл өстендә чуен таба каплаган чүлмәк. Миңлекамал карчык чүлмәкне ачкан да үрелеп-үрелеп нидер карый.
— Талибулла, — дип кузгала башлады җизнәсе. — Мин сиңа...
— Миңлекамал әби, бар әле алгы өйгә чыгып тор,— диде Талип, чүлмәктә ни булуын сизенеп.
— Җизни, әллә чынлап та?...
— Бабаң белән абыең хәзинәсе. Дөньялар үзгәрмәсме...

Талип аны инде тыңламады, өстәл янына килде, табаны алып, чүлмәк эченә тыгылды. Бармаклары салкын металлга тиюгә, аркасы кымыржып китте .Учына көрәп тәңкәләр чыгарды. Талипның алтын күргәне бар иде барын. Әмма монда бит бер чүлмәк алтын!.. Шул вакыт бер тәңкә бармак арасыннан идәнгә төште, зыңгылдап китте, тәгәрәп барды-барды да идән ярыгына чумды. Талип тәңкәләрне шыбырдатып чүлмәккә кире койды.

— Гомерең буе шул кадәр алтынны яшереп тоттыңмы, җизнәй?

— Мин әйтмим, син төпченмә. Биргәннең битенә бакмыйлар. Дәүләттән тигән акчаның бер өлешен миңа бирсәң, шул җиткән... Талип ишеккә таба кузгалган җизнәсенең җиңеннән эләктереп алды.

— Җизнәй, бу алтын чынлап та Рәхим бабайныкымы?

— Аның хәзинәсе. Башсыз түгелсең. Үзең җаен табарсың.

Талипның бер мәлгә зиһене чуалды.

— Их, җизни, җизни, нинди катлаулы кеше булгансың син! Соң аны әлегә кадәр...

— Китим мин, Талибулла, әллә нигә хәлем бетеп тора.

— Туктале. Нигә миңа китердең моны?

— Сырхаулап торам, үлеп китүем бар. Акыл белән тота белсәң, балаларыңның балаларына да җитәр. Ходай-тәгалә шаһит, рәхәт яшәмәдем. Дөньялар үзгәрмәсме дип саклаган идем...

Талип ишектән чыгып барган җизнәсенә исе-акылы китеп карап калды. Картның кояшта уңган бәрхет пинжәге чөйгә элеп куйган кебек буш сыман күренде. Гүя ишектән җизнәсе түгел, карачкы чыгып бара иде.

## 44

Талип ярты төнгә кадәр ишекле-түрле йөреп чыкты. Сәгать төнге берләрдә ул район прокурорына шалтыратты. Прокурор аңа алтынны алырга иртән иртүк махсус комиссия җибәрергә булды.

Шуннан соң гына Талип ятып йокыга китә алды.

...Иртән ул өй ишегенең ачылуына сискәнеп уянып китте. Кичә булган хәл зиһенен телеп, янә аңына җитте. Ә бит Талип җизнәсендә алтын бар дигән Харисовка ышанмаган булды, юк сүз дип көлде. Тиенләп сәдака җыюдан узмаган шул картларда бу кадәр алтын булуына кем ышаныр!

Өйгә кемдер керде, өстәл янына килде, табаны ачып, чүлмәк эченә карады. Күзен ачмаса да, Талип аның һәр хәрәкәтен тоеп торды. Кеше ул яткан диван янына сак кына килде. Талип күзләрен ачты, каршында Харисовны күреп, ул булуга ышанмыйчамы, башын чайкап куйды.

— Төшемдә сезне күреп ята идем. Өнемдә күрәмме дип ышанмыйча торам. Утырыгыз әйдә, Әдһәм абый...

Талип торды, уч төбе белән маңгаен угалаштырды.

— Саташырлык булгандыр шул. Киен әйдә, эш чыкты!

— Нинди яна торган эш тагын?

Харисов уч төбендәге алтын тәңкәне сикертеп яңадан тотты да, учын ачып, Талипның борын төбенә үк китерде.

— Ә-э,— диде Талип, кул селкеп. — Булды монда эшләр кичә бераз. Теге вакытта әйткән сүзегез дөрескә чыкты бит, Әдһәм абый. Булса була икән кешеләр. Өстеннән иске бишмәт төшмәде, егерме ел буена бер киез эшләпәдән йөрде. Ә менә потка якын алтыны булган.

— Алтынны дәүләткә тапшырабыздыр бит?

Талип сәерсенеп партком секретарена карап торды. Ахыр, кулына сөлге алды да, бер сүз әйтмичә, юынырга чыгып китте. Аннан ул бераз тынычланып керде.

— Әйдәгез баштан чәйләп алыйк, Әдһәм абый.

Алгы өйгә чыгып, әзер табынга утырдылар. Миңлекамал карчык, кеше килгәнгәме, авызын яулыгы белән яба төшеп, кухня ишеге янында торды.

Алтынны колхоз исәбенә тапшырыйк, Талип.

— Мондый очракларда дәүләт алтынны тапшырган кешегә генә акча бирә. Алтын Гайзулла Бикмуллинныкы бит...

— Менә анысы булмастыр. Алтын дәүләтнеке һәм дәүләткә әйләнеп кайтты гына. Беләсеңме, каян килә бу алтын? Юк. Ә мин беләм. 1918 елның август аенда аклар Казанны ала. Яшь Совет властеның Казан дәүләт банкысындагы 1 миллиард 100 миллион сумлык алтыны Колчак кулына эләгә. Ул запас Уфага күчерелә. Аңа начальник итеп Уфа штабының контрразведчигы подполковник Солодовников билгеләнә. Подполковникның уң кулы булып, Рәхим байның улы подпоручик Хәсән Бикмуллин хезмәт итә. Солодовников үзе генә сигез пот алтын урлый. Хәсән дә өлешсез калмый. Бер пот алтын урлап әтисенә кайтара. Ләкин аны кемдер биредә атып үтерә. Шул алтын Гайзулла кулына төшә.

— Гафу итегез, Әдһәм абый, мин боларның берсен дә белми идем. Тик барыбер дәүләт аңа тиешле акчасын бирер дип уйлыйм...

Талипның бу сүзенә партком секретареның чырае караңгыланып китте, күзләрендә усал чаткылар биеште. Ләкин Талипка һич ни әйтмәде. Чәй өчен Миңлекамал карчыкка рәхмәт әйтте дә чыгып китте.

*

* *

Үзәк диспетчерлыктан чыккач, Талип ындыр артлары аша авылга таба җәяүләп атлады. Бу атна-ун көн эчендә шактый катлаулы хәлләр булып алды. Иң мөһиме — комплексны монтажлауга керештеләр. Яңа культура буларак, тритикал гаҗәп матур булып шытып чыкты. Цехлар оештырылганнан соң агроном белән дә юк-барга дәгъвалашмый башладылар. Тик менә үз тормышында гына чатаклыклар чыгып тора. Киткәннән бирле Кәфиянең хат язганы юк. Шалтыратсын иде, ичмасам.

— Нигә болай бик әкрен кайтасыз, Талип абый?

Мидхәт, аны куып җитеп, янәшә атлап китте.

— Ашыктыручым калмады. Көтүчем юк. Ә син, күрәм, кәләшең янына ашыгасың?

— Бәби көтәбез бит, Талип абый. Дания курка. Хатын-кыз күңеле ефәк җебедәй нечкә бит ул. Теге атнада Казанга киңәшмәгә киткәч, кайтып җитмәссең инде дип, елый-елый шешенеп беткән.

— Бик нык яратамыни шулай? Үзең соң яратасыңмы?

— Ярату гына аз, Талип абый. Әйтәм бит, көн күрмәсәм, күңелем ашкына башлый. Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз — юк, кайчак үзен янымда микән дип капшап карыйм.

— Әйтерең бармы, бәхетле чакларың!..

Кояш баеп бара. Алар ашлыклар озатылып беткәч тынып калган ындыр табагы турыннан үттеләр.

— Тиздән сыерчыклар китәр, аннары каргалар...

Мидхәт председательгә кырын күзе белән генә карап алды, елмаеп куйды. Соңгы вакытта нигәдер төшенкелеккә бирелеп киткән председательне аңламый башлады ул.

— Кызык кеше дә соң үзегез, Талип абый. Юк кына нәрсә турында да якага-яка килеп бәхәсләшергә тотынасыз.

— Хакыйкать бер бәхәстә генә табылса табыла, Мидхәт. Ә синең, күрәм, килешәсең килми.

— Ачыктан-ачык әйтергә ярыймы, Талип абый.

— Әйдә, тыңлап карыйк.

— Мин беләм, сезнең белән бәхәсләшүе кыен. Минемчә, Талип абый, цехлар оештырып бераз арттырып җибәрдегез. Алдан күрә белү әйбәт билгеле, башлык өчен бу бик яхшы сыйфат. Ләкин практикага килгәндә, беркайчан да бүгенгә ирешелгән фәнни-техник мөмкинлекләрдән алда барып булмый. Миңа калса, без бераз алгарак чыктык.

Талип бер тын дәшми барды. Ни әйтергә тиеш ул бу агрономга? Бу кешене яңалык белән гаҗәпләндерү мөмкин түгел. Әллә соң инде сыналган Хөснетдинов гадәтен кулланыргамы? Ул да бит шулай җавап тапмаудан чарасыз калганда югартынрак менә дә инде шаблонга әверелгән хакыйкать турында сөйләргә керешә. Һәм һәр вакыт өстен чыга.

— Сиңа мәгълүмме соң әле, Мидхәт, авыл хуҗалыгы безгә тапшырылган бит? Партия бездән дөрес идарә итүне сорый. Дәүләт бездән узкыйммәте түбән булган продукция көтә. Без хәзер шуңа таба барабыз. Колхозда зур гына үзгәрешләр булды. Авылга эшче килә. Белгечләр. Андый-мондый гына белгечләр түгел, югары квалификацияле техник белгечләр. Шул кешеләр белән искечә идарә итү гафу ителмәслек нәрсә булыр иде. Чор таләпләреннән беркайчан да артта сөйрәлергә ярамый. — Талип Мидхәткә күз салып алды. — Менә нәрсә, Мидхәт. Минем кешеләрне соңга калып таный торган гадәтем бар. Үткәндәге хәлләр өчен миңа рәнҗемисеңдер бит?

— Минем ул турыда уйлап та караганым булмады, Талип абый. Дөресен әйткәндә, бераз булды. Эш өчен бәхәс барганда үпкәләшүне мин алай да егетлек димәс идем...

— Рәхмәт, Мидхәт. Кеше белән кеше сугышмыйча танышмый диләр, хак икән...

— Куклина киләм дип шалтыратты. Колхозчылар алдында чыгыш ясарга,— диде Мидхәт, ике арадагы артык җылынып киткән мөнәсәбәтне бераз рәсмиләштерү өчен.

— Үзем чакырдым мин аны. Халык районның, Карамалының киләчәген дә белеп торырга тиеш. Югыйсә, колхозчылар арасында төрле сүз йөри. Бөтен өйләрне бетерәләр дә уналты катлы бер йорт салып, бөтенебезне шунда күчерәләр икән дигән гайбәтләр бара...

Талип олы юлдан Карамалыга таба баручы «газик»ны күреп Мидхәткә:

— Кәләшеңне дә калдырма, икәүләп килегез,— диде.

*

* *

Талип клубка килгәндә Куклина сөйли башлаган иде инде. Председательнең залга керүе булды, берәү аңа урын бушатты. Миңниса сүзләрендә үзенә яңалык ишетмәсә дә, Талип аны кызыксынып тыңлады.

— Өйләр турында бу бер сүз дә әйтмәде бит,— диде Талип артында утыручы бер ир, Миңнисаның сүзе беткәч.

Зал гөжли башлады, Харисов торып, алдындагы графинга карандашы белән суккалады.

— Иптәшләр, сорауларыгыз булса, язма төстәме, телдәнме, бирә аласыз.

Урта рәтләрнең берсеннән чәчләре иңбашларына сибелеп төшкән бер кыз күтәрелде. Талип аны таныды. Ташчы Әхмәтсафа кызы, былтыр медицина училищесына барам дип, колхоздан справка алган иде.

— Карамалының генераль планында ателье каралганмы?

— Карале син моны! — дип гаҗәпләнә калды Талип артындагы ир кеше янә. — Ателье бир аңа. Тәмам узынды бу яшьләр. Без үскәндә...

Талип аңа борылды.

— Әй, син икәнсең әле, Сиражи абзый. Кем шулай сукрана дип торам. Минемчә, сеңелкәш бик урынлы сорау бирде, җитәрдер искечә яшәү.

— Һәй, синмени әле бу, бик җилкәле кеше кем бу дип торам. Гафу, гафу, Талип туган. Барысы да булсын — ательесы да, әйтик, пивнушкасы да...

— Менә анысы булмастыр.

— Иштек инде алай булгач. Пиво эчәргә тагын шәһәргә йөрергә кала икән. Өй дә өй диләр, ярамаган тагын торырга куыш булгач. Әнә юлларны карасыннар иде. Өй нәрсә ул, өйне аны мүклисе дә чутлыйсы гына. Икешәр, өчәр катлы өй тагын. Юк, бармый андый өйләр безгә. Бармый! — дип, торып ук басты Сиражи. — Җәмәгать, иптәш Харисов, миңа да сүз бирегез әле... Без бит, агай-эне, мал-туар тотабыз. Ул күп катлы өй янына абзарлар тезеп куябызмы? Крестьянның абзары гомер-гомергә йортта булды, шунда калсын да. Кирәкми безгә күп катлы өйләр!..

— Утыр әле, утыр, Сиражи абзый,— дип, Талип җилләнеп сөйли башлаган күршесен урынына чүктерде.

— Әй лә, тыңлыйлармы алар безне. Әйе, дип калалар, үзләренчә эшлиләр. Бәрәңге бакчасын кисмибез дигән идегез әнә, кистегез.

— Кызма әле, Сиражи абзый!

— Кызмыйм мин, нигә кызыйм. Туры әйткән — туганына ярамый, шул гына. Сиңа ни, сиңа рәхәт. Сыерны калхузга илтеп бирдең дә курма да кирәкми сиңа, абзар да. Ә минем...

— Кайнарланма юкка, күп катлы йортлар булмый Карамалыда. Электр белән генә җылыта торган, абзары да янына салынган бер катлы була...

— Анысы ни тагын? — дип, Сиражи Талипка елыша төште.

— Шулай менә, өйләрне электр җылытачак. Суны торба белән китерәбез.

— Бар икән әле күрәселәребез.

— Ник алай дисең, Сиражи абзый?

— Соң электры болай да көнгә өч-дүрт мәртәбә сүнеп тора. Җиткерә алырлар дисеңме шуны?

— Җиткерерләр. Махсус подстанция салыначак.

— Шулай дип котылсаң гына инде...

Талип аңа кабат дәшмәде. Ул бераз Сиражига рәнҗеде. «Әйе, мин сыерымны колхозга илтеп бирдем. Килер бер көн — син дә ул малны асраудан баш тартырсың. Мин бит сизәм: мин бахырдан көләсең син. Миңлекамал әбинең көн саен үзегезгә сөт сатып алырга кергәне өчен көләсең».

...Талипның Харисов күзенә чалынасы килми иде, сөйләшүләр бетүгә, ул клубтан чыкты да, бер читкәрәк китеп басты. Алтын мажарасыннан соң председатель белән партком секретаре арасында ниндидер салкынлык сизелә.

Гөр килеп клубтан халык чыга. Менә соңгы кешеләрне дә караңгылык йотты. Ниһаять, Харисов, Куклина, Кадыйров күренде. Аларга ияреп хатыны белән Мидхәт чыкты.

— Үзе чакырды иптәш Бикмуллин, үзе күренмәде,— диде Миңниса.

— Монда иде ул. Мин күрдем,— диде Мидхәт.

Ике ай элек кенә район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы дәрәҗәсенә күтәрелгән Миңниса Куклинаны Талип койма буендагы агачлар ябалдашлары астында көтеп торды.

— Егетләр, сез Ниса Хәйдәровнаны кунак йортына кадәр озатып куегыз инде,— диде Харисов.

— Юк, юк, зинһар борчылмагыз. Минем бераз һавада йөрисем килә. Хушыгыз...

Миңниса әкрен генә ындыр табагына таба китте. Ул Талип басып торган ихата кырыеннан ук үтте. Миңниса бер ара киткәч, аны күрер-күрмәс, Талип кузгалды.

Кыяр тавы ягында тракторлар гөрелтесе ишетелә — туңга сөрәләр. Күк йөзендә тулган ай яктысыннан уңып калган сирәк йолдызлар җемелди.

Талип адымын ешайта төште. Миңниса күздән язар кебек тоелды аңа. Үткәнне сагыну күңелләрдә озак саклана. Ә менә мәхәббәт җәйге җылы җил кебек үтә дә китә. Нигә болай йөри ул? Шулай ук Кәфиясен яратмый башладымы? Казанга китәргә ике-өч көн калгач, тик торганда Кәфия аңа: «Әллә нигә сүрелдең син, Талип. Хәерле булсын!» — диде.

Артыннан берәүнең аяк тавышларын ишетепме, Миңниса туктады, колак салды. Шик юк, кемдер аңа таба килә иде. Һәм ул аны таныды.

— Гафу ит, каршы ала алмадым, эш чыкты,— диде Талип, килеп җитүгә.— Шоферны кайтарып җибәргәнсең дип ишеттем, борчылма, үзем илтеп куярмын...

## 45

Таҗылбанат алдагы тормышын җәннәттәй итеп күз алдына китереп яшәде. Ә ул җәннәт килмәде дә килмәде. Шулай да матур өметләр белән яшәү җанга булса да рәхәтлек бирә иде. Мәгәр аның да бер чиге була икән. Соңгы вакытта Таҗылбанат бу өмете өзелүен сизә, моңа эчтән сызып кына кайгыра башлаган иде. Гайзулласы алтынның кая яшерелүен һаман исә әйтми. Ни кәтә, бер ходай үзе белсен. Ә бит бер аягы белән гүрдә тора инде! «Әллә соң Кәнзелнең кайтуын көтәме?» дигән шиккә калгалый башлады Таҗылбанат. Шулай дип үз-үзен юатты, сабыр итәргә булды — кем әйтмешли, сабыр төбе — сары алтын бит.

Көн аралаш аш-суга йөрде, һични булмаган кебек, карты белән ачык сөйләште. Йорт эшен җиренә җиткереп үтәде. Ләкин, ичмасам, азга гына булса да күңел хәтереннән алтын чыкмады. Җитмәсә тагын, шик өстенә шик өстәп, Гайзулла карты тәнозын диярлек югалып йөрде. Чыбык очы карендәшләре Шаяхмәтләрдә кундым дигән була. Таҗылбанат төне буе күз йоммады.

Яман хәбәрне аңа бөтенләй көтмәгәндә мәҗлестә җиткерделәр. Ул, гадәтенчә, табынның иң түрендә иде. Һәр мәҗлестәгечә, аш килер алдыннан карчык-коры, хатын-кыз арасында гәп-гайбәт кузгалды. Берсен-берсе бүлә-бүлә соңгы яңалыкларны сөйли башладылар. Шунда Миңлекамал әйтеп куймасынмы:

— Һәй, белмәйсез, кичә бездә бер әкәмәт хәл булды бит әле. Әндри вакытларында Гайзулла кияү килеп керде. Әйтсәм ышанмассыз, балакайларым, бер чүлмәк алтын китергән. Талибулланың исе-акыллары китте менәтерәк...

Таҗылбанат җиңгәчәсенең тешсез авызына, туксан яше тулып килүгә карамастан, әле булса шактый җитез йөргән кулына карады да кайтарып сорады:

— Минем картыммы шулай йөри, җиңгәчәй?

— Бәрәкалла, үз киявемне танымаска. Аллага шөкер, күзләрем бик әйбәт күрә әлегә.

Таҗылбанат кабат кайтарып инде сорамады. Ул кинәт күтәрелде дә, сукыр тавык кебек, табын уртасыннан ишеккә китте.

Өйләренә ул сулышына капланып кайтып керде. Гайзулласы намазлык өстендә утыра иде.

Карчыгының һич нигә карамыйча күзе-башы тонган хәлдә якынына килүен күреп алган Гайзулла тамак кырды, намазын сузып-сузыбрак укый башлады.

— Хакмы Талибуллага әтием хәзинәсен илтеп бирүең?

Гайзулла ишетмәгәнгә салышты, укуында дәвам итте. Шунда Таҗылбанат баскан җиреннән, капчык кебек, идәнгә ава башлады.

Гайзулла намазлыгыннан торды, инде, егылып өлгергән карчыгын култык астыннан алды да түр өйгә алып керде, идәнне тутырып җәйгән киезгә сузып салды. Калтыранган куллары белән самавардан йомрыга су агызды, кучкардагы йөрәк даруы шешәсенә үрелде. Ләкин аның кулына өч кырлы серкә шешәсе эләкте. Гайзулланың аркасы өшеп китте. Күз алдына, бүгенгедәй булып, илле ел элеккегә бер хәл килде. Шешәне бармак буыннары агарганчы каты итеп уч төбенә кысты. Менә-менә уалып китәр кебек иде ул. Гайзулланың маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Ул, агарынган бармакларын бушатып, өч кырлы серкә шешәсенә бакты. Кисәк аңа куркыныч булып китте. «Йа аллам, үзең кичер, үзең ярлыка гөнаһлы бәндәңне!»

Гайзулла шешәне тиз генә урынына куйды да, йомрыга унбиш тамчы корвалол агызып, түр өйгә керде. Таҗылбанат җансыз кыяфәттә ята бирә иде. Ул аның башын күтәрде, бисмилласын әйтеп, авызына дару салды. Таҗылбанатның күз кабагы тартышып-тартышып куйды. Гайзулла аны гомерендә беренче тапкыр диярлек чын күңеленнән кызганды. Шул чак Таҗылбанат һич уйламаганда Гайзулланың сакалына ябышты. Сакалы авыртудан битәр куркудан Гайзулла яшелле-зәңгәрле тавыш белән кычкырып җибәрде.

— Алла-ла-ла!

Икенче мәлдә инде исенә килде.

— Җибәр сакалны, албасты!

Таҗылбанат ләтчәдәй сикереп торды да, картының сакалын тагы да гайрәтләнебрәк йолыккаларга тотынды.

— Җибәрермен мин сиңа, җибәрми ни! Кая, кая илттең атам малын, кемгә бирдең?..

Таҗылбанат тәмам шашты, күзләрен алаландырып сөрән салырга кереште, гүя Гайзулланың сакалына ул ябышмаган, киресенчә, карты аның берәр җирен үзәгенә үткәреп чеметә иде.

Шушы йөрәк өзгеч тавышны Миңниса белән урам буйлап узган Талип ишетте. Ул юлдашына: «Сабыр ит бераз» дип, түтәенең ишегалдына атлады. Атылып өйгә керде. Керде дә, каккан казык кебек, баскан җирендә катып калды.

— Нишләвегез бу, түткәй!?

Бу вакытта инде Гайзулла, ярты сакалын йолыктырып булса да, Таҗылбанат кулыннан ычкынган, ярсып киткән карчыгын тыярга теләп, тегенең өстенә менеп атланган иде. Ишек төбендә Талипны күргәч, ул торды, кулларын сәлендереп, гаепле бер кыяфәттә алгы якка чыга башлады. Таҗылбанат тутасы гына кузгалмады, терсәгенә таянып күтәрелә төште дә, теш арасыннан ысылдап:

— Нәстә кирәк сиңа тагын, ыштыр бит! Катының озаттың да итәк иснәп йөрергә калдыңмы? Кая илттең безнең алтынны, кемгә бирдең? Дәүләткә озаттыңмы?!

Талипның болай да кызыл чыраена гүя ут капты. Ул бәреләсугыла өйдән чыкты да, электр баганасы янында аны көтеп торган Миңнисага җиткәч, йодрыгы белән шул багананы төяргә тотынды.

— Убырлы, убырлы карчык, оятсыз!

— Ни булды, Талип, ник алай дисең?

Талип, электр баганасына маңгаен терәде дә, әчтән сыкранып, башын як-якка чайкады. Аннары тагын багананы төяргә кереште. Ул суккан саен чыбыклар зыңлап китте. Кемдер караңгыдан аваз салды.

— Һәй, кем анда багана белән шаяра!

Талип баганадан читкә тайпылды, Миңнисаны култыклап алды да алар зират тыкрыгына юнәлделәр.

— Җүләр картлар, диваналар! Күпме яшәп акыл кермәсә кермәс икән үзләренә...

— Талип, нишләвең бу, кемне орышасың шулай?

— Кемне?! Түткәйләрне. Нинди тавыш-буза дип өйләренә кергән идем, алар, җүләр беткәннәр, идәндә кыйнашып яталар. Ник кердең дип, түткәй әйтмәгәнен калдырмады...

— Талип, кәефең дә юк, илтеп куй әле мине тизрәк...

...Машинага утыргач, Миңниса аңардан:

— Мин килгәнгә үпкәләмисеңдер бит, Талип. Нигә сөйләшмисең? — Миңниса аның руль тоткан кулына җылы учын салды. — Мин сине аңламый башладым. Әллә бик кыенмы? Комплексны срогына өлгертә алмавыңа шулай өтәләнәсеңме?

Талип дәшмәде. Иөрәкләр гәпләшкәндә тел очына сүз килмәме соң.

— Әйдә, Миңниса, бу турыда сөйләшмик. Мин Кәфия белән егерме ел гомер иттем, арабыздан җил дә үтмәгән иде, тату яшәдек... Калсын барысы да искечә, кузгатмыйк...

— Беләсеңме, Талип, — дип башлады бөтенләй башка нәрсә турында Миңниса. — Ирек Нәҗмиевич пенсиягә китә бит, гариза биргән.

— Изге урын буш тормас, курыкма, кеше табылыр.

— Ирек абыйга өйрәнеп беткән идем инде. Бу урынга ул мине күтәрде бит.

— Яңасына да өйрәнерсең. Хатын-кыз ир-атка тиз җайлаша ул.

— Оят түгелме сиңа, Талип.

Талипка оят түгел иде. Нигәдер аның бер кизәнүдә барысын өзәсе килде бүген. Шуңа гасабилана, шуңа дорфа сөйләшә.

— Моны белгән булсам, үз машинамны җибәрмәс идем...

Сөйләшмичә, һәркем үз дөньясына бикләнеп, ярты юлны үттеләр. Талип такыр асфальт юлдан машинаны йөз километр тизлек белән куды. Мотор тавышы рәтләп ишетелми кебек, тик пыяла аша җил сызгырганы гына ишетелә.

— Бер нәрсә исемә төште әле, — дип сүз башлады, ниһаять, Миңниса. — Исеңдәме, унны бетергән елны экскурсиягә барган идек. Бер төнне әскерт астына кереп йокладык. Син минем янәшәмә туры килдең. Мин йоклаганга сабышып яттым. Шунда син мине үбеп алган идең...

— Маташтырма. Мин үпмәдем сине анда, сорнай Нәсим үпкәндер. Ул чакта Нәсим синең арттан киләп сала иде.

Шуннан соң алар райүзәккә барып җиткәнче сөйләшмәделәр.

## 46

Бу өйдән тынычлык киткәнне күршеләре дә сизенде. Бүген тагын энә. Чоланга кереп, иләгән оның ашаган кәҗәсенең мөгезеннән элэктереп алган да тал чыбыгы белән яра. Кәҗә мескен әллә нинди тавышлар чыгарып бакыра. Моны койма аша ишетеп торган Хәмдиянең ике күзе дүрт булды. Ул түзмәде, коймадан башын калкытып:

— Тажылбанаттәй, нишләвең бу! Үтерәсең бит, мал хакы бар лаба-са! — дип ачыргаланып алды.

Ләкин Тажылбанат аңа хәтта күтәрелеп тә карамады.

Кәҗә бакыруына урамда туп тибүче бер төркем малай-шалай, уеннарын ташлап, Гайзуллаларның капкасына килеп сыландылар. Каршы өйдә торучы Чапай Мөлек: «Бу ни инде тагын?» дип урамга чыкты, ары-бире карангалап тора башлады. Урам буйлап сөйләшеп килгән ике яшүсмер капкага сыланган малайлар янына чапты. Кәҗә бакыруы Гайзулланың икенче як күршесе Сәмигулланы да өйдән чыгарды. Эштән кайтып яткан гына булса кирәк, чәче-башы тузган, өстендә күлмәкыштан гына, аягында ишек төбеннән элеп алган зур шахтер калошы. Ул берни аңламый, югары очка да, түбән очка да күз ташлап алды да,

күршесе капкасына сыланган малайларны күргәч, «Тфү! дип төкерде һәм кире кереп китте. «И-и ходаем, ни булды икән!» дип магазинга баручы ике хатын туктап калды.

Шунда Тажылбанат сынып беткән чыбыгын ташлады да кәҗәне җибәрде. Һәм шунда гына койма аша карап торучы Хәмдияне күрде.

— И-и илаһым, ил иләге, чүп чиләге, ни күрмәдең, нәмәрсәмә күзең тондырдың!?

Тажылбанатның зәһәр сүзләреннән Хәмдия нишләргә белмичә катып торды. Аннары абыстайның сүзләре аңына житте булса кирәк, тиз генә өенә чапты.

Өйгә кергәч, Тажылбанат сәке янагына килеп утырды. Гайзулла маңгаен сәкегә тидерә-тидерә ахшам намазын укый иде. Аның күзләре йомылыр-йомылмас кына калган, ул гүя күккә ашкан иде. Ниһаять, намазын тәмамлаган Гайзулла да түр почмактагы миндәргә килеп утырды. Һәм кадак чөйдән дисбесен алып авыз эченнән генә нидер укуын дәвам иттерде. Түзмәде Тажылбанат, тамак кырды. Гайзулла, дисбесен кадакка элде дә:

— Хайван хакы бар, нәстәгә шул тикле кыйныйсың малны? Кәнзел кыйнаганнан соң да өч атна көтүгә куа алмадык бит, — диде.

Тажылбанат иреннәрен чәйнәде, күзләрен чекерәйтте.

— Атам тапкан хәзинәне игелексез Талибуллага бирдең дә, инде алладан мәрхәмәт сорыйсыңмы?! Кемгә, кемгә диген, үз туганын төрмәгә утырткан кешегә илтеп бирдең бит!.. Әюпне үтерүеңне генә сизсеннәр, күрсәтерләр әле күрмәгәнеңне. Талибуллаң үз кулы белән озатачак үзеңне, сукыр шайтан!!

Тажылбанат үрсәләнеп, сәке буена башын салды, илереп еларга тотынды.

Гайзулла чарасыз калып, исенә килә алмый торды. Бу сөйләшүгә кадәр ул алтынны Талибуллага илтеп дөрес эшләдем дип йөри иде, ә менә хәзер, барыр юнәлешен югалткан мөсафирдай, икеләнә калды. Алтыны кулында булса ул нишләргә белер иде. Хәзер ни кыларга тиеш соң ул?..

— Кешегә әйтсәң кеше ышанмастай ялгышлык эшләдем, ахры мин.

Тажылбанат, яшьле күзләрен яулык очына сөрткәли-сөрткәли, картына күтәрелеп карады. Күрмәс күзләре белән, өметен өзгән кешедәй, карады. Аның бу карашында Гайзулла мыскал да теләктәшлек күрмәде. Тажылбанат гүя теге дөньяга киткән, киткән дә аллаһе тәгаләнең үз алдына басып, инде нишләем, тәңрем, дип, ходайдан җавап көтә иде кебек.

Ләкин Тажылбанат телгә килде:

— Талибулла алтынны хөкүмәткә биргән, диләр. Каян алдың дип төпченә башларлар, Әюпне үтерүеңә кадәр чокынырлар. Барысы да беленер...

— Син әйтмәсәң белмәсләр, кыжрама бик!

— Белерләр, боларның белмәгәннәре юк. Башың Себер китәчәк. Картайган көнеңдә җир тырнап кан-яшь түгәселәрең алда әле, алда...

*
* *

Гайзулла төннең төнозын йоклый алмады. Таң беленер-беленмәс торып киенде дә ишегалдына чыкты. Бөтен тирә-юньне караңгылык баскан. Һава саф, ишегалдындагы бәбкә үләненә көзге йомшак кырау төшкән.

Гайзулла келәт янына килеп бүрәнәгә утырды. Тән-буында сын юк, йөрәк оеп тора, кайчак туктар дәрәҗәгә җитеп: убылып-убылып китә сыман. Көндездән үк сыздырып авыртып торган эче дә тагын кузгалды.

— Илаһым, ходаем, кылган гөнаһлары өчен шулай әрнештерәсеңме бәндәңне?..

## 47

Плащ якасын күтәргән Гариф яңгыр җиленә йөзен куеп, акрен генә кыр юлыннан авылга таба атлады. Кырга ул тритикал уҗымын карарга барган иде, яңа культураның гаҗәеп матур булып яшәреп утыруын күрде.

Басулар каралып калган. Тирә-юньдәге бөтен нәрсәне көзге көннең сәленке болытлары йоткан. Гарифка Карамалының кырлары бик тә якын булып китте. Кызлар кашына сөртердәй кара бу туфракны кирәгенчә эшкәртеп, тиешле ашлама салганда, җиренә җиткереп сугарганда гектарына илле-алтмыш центнер икмәк үстереп булыр иде.

Көннәр артык яңгырга киткәнгәме, Гарифның бил тирәсе чатнап-чатнап куя. Тик аның больницага барасы килми. Белгән, гадәтләнгән кешеләр киткән. Кәфия — Казанда, Дания — бәби үстерә.

Бер биле авыртканда гына Кәфияне исенә төшерәме ул? Юк, ул аның хәтеренә бик еш килеп тора. Кәфиянең уйчан һәм нигәдер бераз гына сагышлы зәңгәр күзләрен, йомшак-ягымлы тавышын ишеткән саен йөрәге ешрак тибә башлый...

Олы юлдан автобус үтеп бара. Туктады. Берәү төшеп калды. Карамалы кадәр Карамалыга бер кеше. Хәер, кем йөрсен мондый көннәрдә. Баткак. Гариф юл читендәге чирәмнән китте. Ләкин ниндидер эчке сизем аны туктарга, автобустан төшеп калган кешене көтеп алырга мәҗбүр итте. Таныш йөреш, күңелгә сеңеп калган килеш-килбәт. Кем булыр бу? Җәвит түгелме? Шул үзе бит! Өстендә күк плащ, башында тар читле эшләпә, аягында калын табанлы туфли.

Гариф, кияве килеп җитәр-җитмәс, кузгалып китте. Җәвит тә аны таныды, куып җитеп, бабасына кулын бирде.

— Кайчан килдең дип сорамыйм, автобустан төшүеңне үзем күрдем. Нинди ният-теләкләр белән?..

— Җитәрдер инде, әти, безгә дә аерым яшәргә. Гафу итегез, килүем турында телеграмма сугып тормадым инде.

— Киләм дип хат язгансыңдыр бит?

— Талашып-сугышып аерылышмадык. Әйтеп торасымы, ялгышлык миндә булды.

— Шулай укмы? — диде Гариф, киявенә карамый гына барган җайдан. — Ялгыштың укмыни? Ә ул кияүгә чыгып куйгандыр дип башыңа да китермәдеңме?

— Алай дип уйларга нигез юк, әти. Мин Әдиләнең сафлыгына ышанам.

— Алай, алай. Ә соң Әдилә сине кичерерме, гафу итәрме?

— Балабыз бар бит, бала хакына булса да...

— Бала хакына... Әйе, бала бар барын. Тик бит, кадерлем, ул балага башка берәү дә ата булып куя ала. Һәм ул бик гади эшләнә. Баланы үземнеке дип документлаштыра да...

— Минем алай булыр дип уйлыйсым килми, әти. Тормыш без уйлаганнан катлаулырак икән. Әдиләне мин соңга калыбрак булса да аңладым...

— Һәм шуны аңлап бүген аны алырга килдеңме?

— Шулайрак иде исәп...

Гариф ниндидер могҗиза белән зират тыкрыгын менеп килгән машинага карап:

«Тәки менә бит егет, оста шофер. Тик күпме чирәмне бозды икән? Сорыйсы иде үзеннән»...

Җәвит тә шул машинага карады, тик бабасының йөк машинасына инде ничәмә минут игътибар итүен генә аңламады.

— Һаман шунда эшлисеңме?

— Шунда утырам.

— Утырасың шул менә, утырасың гына, — диде Гариф.

— Әдиләгә дә үз янымда урын таптым, — диде Җәвит, бабасының мыскыллы сүзләрен гүя ишетмәде дә.

— Аңа да җылы урын әзерләдем дисең инде?

— Җылы урын дип, әти, кеше түгел, балык та суның чистарагын, тирәнрәген эзли диләр бит. Минемчә, безгә дә акылга утырырга вакыттыр инде.

— Ни әйттең иде дә бит...

Гариф ачуын басарга тырышты. Ләкин үз-үзен тыя алмады. Бик күп тоз салды шул бу кеше аның йөрәк ярасына. Ә хәзер акылга утырган, имеш. Гафу үтенергә килгән. Үзе күзләрен яшерә. Сүгәсе иде дә бит эт итеп үзен, ярамый.

Шул ук мәлдә аның кинәт килеп төшкән «кияү балакаена» ул хәтле каты бәреләсе дә килми иде. Кем белә, бәлкем килешеп китәрләр. Күренеп тора: кияүнең элекке кикриге шиңгән. Димәк, каты егылган, ә егылганны кыйнаудан ни файда?

— Мин ишеттем, аерылышуыгызга бераз әнкәң дә сәбәпче булган икән дип?

— Әнинең гүр иясе булуына өч ай тулды инде.

— Гафу ит, мәрхүмәне рәнҗетермен дип уйламаган идем, авыр туфрагы җиңел булсын, минем өчен яхшы кеше иде ул.

Ындыр артын узып, авылның түбән очына килеп керделәр.

— Төзек авыл, урман, болын, күл, елга. Матур җиргә утырган, — диде Җәвит.

— Халкы тырыш. Хикмәт халыкта. Яшеллекне, урман-суларны ул гына саклаcа саклый ала. Быел әнә шул күл буендагы урман кисәген кистерә яздылар.

— Агачларны түгел, кешеләрне дә кыралар. Һәркем үз идеясен алга сөрә, үз интересларын яклый.

— Карап-карап торам да, син төшенкелеккә бирелә башлагансың бит, дускай. Тормыш бар, димәк, көрәш бар. Бу — мәңгелек хакыйкать лабаса.

— Гафу итегез, мин сезне аңламыйм, әти. Икебез ике нәрсә турында сөйлибез сыман.

— Ә миңа калса, син мине бик яхшы аңладың. Син мезонеистларга хас фикер йөртәсең кебек.

— Миңа бу сүз нигәдер таныш түгел.

— Бик мөмкин. Мезонеизм ул — яңалыкка каршы торучы агым. Романтик хәрәкәтләргә турыдан-туры дошман булган скептиклар агымы.

Гариф үзенең артыграк сөйләп ташлавын да аңлый, әмма «мәхәббәте» зур иде бүген киявенә. Әйтми дә булдыра алмады.

— Миңа мондый тамгалар сугуыгызның сәбәбен аңлап бетермим мин, әти.

— Бу материаль дөньяны, күрәсең, без икебез ике төрле итеп күз алдына китерәбездер. Табигатькә мөнәсәбәтебез дә икебезнеке ике төрле. Әйтик, мин үзем хатын-кыздагы сафлыкны аның иң-иң өстен сыйфаты итеп карадым. Ә сезнең фәлсәфәгездә ул башкачарак.

— Хатын-кыз акыллы затның иң хәйләкәре. Аннан да мәкерлерәкне табу мөмкин түгел,— диде Җәвит, кыза башлап.— Кирәк дип таба икән, хатын-кыз ифрат та каты бәгырьле була ала. Шулай ук зур ихтыяр көченә дә ия ул хатын-кыз.

— Саф фикерле хатын-кыз каты бәгырьле була алмый. Бу — хакыйкать.

Җәвит дәшмәде. Аның инде бабасы белән бәхәсләшәсе килми иде.

Кайтып җиттеләр. Ә Гарифка Әдиләнең уй-теләге билгеле түгел. Яңа елдан соң аларның бу турыда сөйләшкәннәре булмады. Ләкин бер нәрсәне күргәләде Гариф: кызы Җәвиттән хат арты хат алып торды. Җавап яза идеме Әдилә, юкмы — кызыксынмады. Җәвиткә чишенергә кушты.

Алгы өйдә берәү дә юк иде. Гариф тамак кырды, плащын салып элде.

— Әни, өйдә кеше бармы?

Җәвит ашкынып типкән йөрәген тыюдан гаҗиз калып, эчке өйдән Әдиләне көтте. Тик аннан Әдилә түгел, Гөлзифа әби килеп чыкты. Ул ишек янында басып торган Җәвитне күрде дә, күптән көткән кешесен каршылагандай, көйли-такмаклый:

— Әнием-балам, кем бар, кем килгән! — дия-дия исәнләшергә кулларын сузды.

— Исәнмесез-саумысыз, әби! Исән-сау торасызмы? Әдилә белән кызыбыз кайда? Күренмиләр...

— Әдилә кайтып җитмәде әле, ә кызыбыз өйдә. Каяле үзе. Чәчкә, Чәчкә, кызым, килче әле бире, күрәмсең кем килгән! — дип, баланы чакырды әби һәм ягымлы итеп киявенә елмайды. Эчке өйдән кулына зур курчак күтәргән Чәчкә килеп чыкты. Гөлзифа баланың кулыннан уенчыкны алды да авызын җыя алмыйча елмайган Җәвитне күрсәтеп:

— Күрче, кызым, кем килгән безгә, — дип, баланы Җәвиткә табарак этте.

Бала Җәвиттән ятсынды, кисәк борылды да эчке өйгә кереп китте һәм бабасына барып елышты. Җәвит тә түр өйгә керде.

— Әни, чәй куй әле,— дип, Гариф алдына утырган Чәчкәнең аркасыннан сөя башлады.

Җәвит кесәсеннән бер кап шоколад чыгарып, кызына сузды.

— Сиңа бу, кызым!

Нигәдер үз тавышын үзе танымады Җәвит. Бу сүзләрне үзе әйтмәде, гүя башка бер кеше әйткәндәй булды. Тамак төбе сәер итеп әчетеп китте. Кызы шоколадны алмады, ятсынды. Җәвитнең шоколад тоткан кулы сузылган килеш калды.

— Ал инде, Чәчкә, бар ал, әтиең бирә ич! — диде бабасы.

Шоколадка алданыпмы, Чәчкә бабасы алдыннан төште дә, кулларын авыз тирәсендә тотып, Җәвиткә таба атлады. Ул шундый кыюсыз килде, Җәвитнең сабыры төкәнде. Ниһаять, кызы үрелеп шоколадны алды һәм йөгереп әбисе янына чыгып китте.

— Рәхмәтне кем әйтер, Чәчкә, — диде бабасы.

Чәчкә әйләнеп килде һәм Җәвиткә:

— Рәхмәт, әти, — диде.

Җәвитнең йөрәге дерт итеп китте. Күңелендә моңа кадәр томан эчендә генә тибрәлеп йөргән ата булу хисе калыкты. Тамак төбен янәнидер кытыклап алды.

Бераздан Чәчкә тагын әйләнеп керде. Ул кылтая төшебрәк бабасы тезләренә килеп сыенды. Баланың торган саен кыюлана баруы, шоколад ашаганнан соң авыз читләрен сөртмәстән, янә Җәвитнең кабарыбрак торган кесәсенә карап-карап алуы Җәвиткә хуш килде.

— Казан якларында да шулай явамы?

— Шул ук хәл.

Бала Җәвитнең куллары инде бушап калуын күреп, аның белән кызыксынмый башлады, бабасының аякларына басты.

— Бабакай, әйдә үчтекәй уйныйбыз.

Гариф аны аякларына бастырды да, ике кулыннан тотып:
— Без, без, без идек,
Без унике кыз идек.
Без унике кыз идек.
Базга төштек — май каптык,
Келәткә кердек — бал каптык.
Кап та коп!..

Җәвит бабасы белән Чәчкәнең уйнавына кызыгып карап торды. Аларның авызларын йомып, бер-берсенә елмаеп торулары, ләкин берсенең дә беренче булып күләргә теләмәве матур иде. Җәвитнең бу уенны бөтенләй белмәве аны кимсетте. Түзмәде, беренче булып бабасы көлеп җибәрде. Чәчкә кул чәбәкләп сикергәләргә тотынды.

— Бабакай, мин җиңдем, мин җиңдем!..

— Җәза, җәзаңны бир, — диде Гариф.

Чәчкә бармагын иреннәренә куеп уйланып торды.

— Мин бүген песи белән йоклыйм, ә син миңа ачуланмыйсың, әйеме?

— Белмим шул. Мин ачуланмам да бит, әниең белән әбиең рөхсәт итәрләр микән? Булды, сөйләштек, мин сиңа ул песибикәне әниең йокыга киткәч кертермен.

— Ә мин көтеп ятылмын, яме, бабакай!

— Я, я, шулай эшләрбез. Хәзер бар инде курчагыңны түшәгенә сал. Ату аның йокысы киләдер.

Кызы алгы якка чыгып киткәч, Җәвит тәрәзә янына барып басты. Пыскып яуган яңгыр бөтен күк йөзен томалаган. Сәгать алты тулып килә, ә Әдилә һаман кайтмый. Җәвит белә: Әдиләдә аз-маз кылану бар. Кайчак ул шушы кыланчыклыгына мәкер дә өстәп җибәрә. Ни генә булмасын, хәзер Җәвитнең язмышы Әдилә кулында. Ул ничек әйтә, шулай булачак. Җәвит үз ягыннан барысын да эшләде; түбәнсенеп, баш иеп аның каршына килде.

Ул арада Гөлзифа әби табын хәзерләде, гөжләп торган электр самаварны өстәлгә китереп утыртты.

— Килүең туры Казаннандыр бит? — дип сорады Җәвиттән Гариф. Алар икесе дә сөйләшер сүз таба алмыйча интегәләр иде кебек.

— Казаннан.

— Әллә, мәйтәм, бу якка командировка җаена гына сугылдыңмы?

— Мин бирегә бер максат белән генә килдем, эти...

— Анысы әйбәт. Әйдә, утырыйк, чәйләп алыйк.

Чәй янында сүз авыл турында булды. Гариф Карамалының киләчәген сурәтләргә тырышты. Сүз арасында ул киявенә күз төшергәләп алды. Юк, Җәвит аны тыңламый иде. «Әйе, кияүнең үз хәле хәл», дип уйлады Гариф. Киявенең теле ачылмасмы дип, бер шешә «Плиски» алып килде.

— Берәрне тотыйк, булмаса. Нигәдер кәефләр шәптән түгел, — дияйия рюмкаларга коньяк койды.

Чәкәшмичә генә эчеп куйдылар. Җәвит рюмканы кулында әйләндергәләп торды. Гариф аның төс-йөзенә игътибар белән карап утырды.

Гөлзифа аларны кирә-чыга йөргәндә кысташтырды.

— Житешеп утырыгыз әле, хәзер коймагым да өлгерер...

*
* *

Ашап-эчкәч, Гариф эш өстәле янына күчте, Җәвит тә кузгалды.

— Мин бераз йөреп керим әле, эти.

— Ятарга итсәң, менә бирегә, минем урынга ятарсың. Мин үзем чиңлеккә чыгармын. Әдилә кайтыр ул. Бу арада эше күбәйде шул.

Җәвит плащын алып, туфлиен киде дә ишегалдына чыкты. Җил тагы да көчәя төшкән. Урам яктагы бакчада өянкеләр шаулый. Шифер түбәдән өзелә-йолкына яңгыр суы ага, я тып-тып тамчы тама башлый.

Капка төбенә чыкты, баганага сөялде. Биредә ышыграк, җил килеп житми. Урам буш. Бер ялгыз эт кенә электр баганасы саен туктап иснә-нә-иснәнә йөри. Муенында элмәк. Үзе ычкынганмы, хуҗасы җибәргән-ме — иреккә чыккан.

Ниһаять, урамда берничә кеше күренде. Алар шаулаша-шаулаша кайталар иде, капкага сөялгән ят кешене күреп, бер мәлгә тын калдылар. Шуннан берсе:

— Безнең авыл кешеләре баганаңы нык утырта, тәрәп тормасаң да аумас ул, абзый кеше, — диде.

— Кит инде, Фирдәүсә, ят кешегә шулай әйтәләрмени! — дип, икенчесе Фирдәүсә дигәненә ачулангандай итте.

— Кызлар, беләсезме кем бу?! — дип әйтергә өлгермәде өченчесе, барысы бергә Җәвит ягына карадылар. Һәм барысы да аңладылар бугай Җәвитнең кем булуын, тавыш-тынсыз гына, чышын-пышын гына сөйләшә-сөйләшә, әйләнеп карый-карый китеп бардылар. Төркем артыннан тагын ике кеше килүе күренде. Җәвитнең йөрәге уйнап куйды. Әдиләгә охшаган иде берсе. Караңгы төшеп килгәндә тануы кыен, әмма ул бит, ул!

Юк, ул түгел икән.

— Исәнмесез, хәерле кич! — диде үтүче хатыннарның берсе.

— Саумысыз!

— Әдиләне көтәсезме?

Җәвит ни әйтергә белми аптырап калды, сизелер-сизелмәс кенә «юк» дип башын чайкады. Ниндидер бермәлдә оялды. Кирәк идеме? Ул бит чынлап та Әдиләне көтә. Нигә оялды, нигә яхшысынмады?

Хатыннарның өсләрендә плащ, аякларында зур размерлы итек. «Әдилә дә шулай киенеп йөри микән?» дигән уй килде Җәвитнең башына. Һәм ул аны да нәкъ шундый киемнән күз алдына китерүгә, күңелендә үзенең шулай түбәнсенеп йөрүенә үкенеп алды. Бәлкем гел юкка килгәндер? Алар арасында һичнинди уртаклык та калмагандыр?

Масаю юк иде Җәвитнең бу фикерендә, әмма тик аңа гына хас эрелек бар иде. «Кияүгә чыкмаса да, берәрсе белән чуалуы дөрес булып куйса?..»

Җил көчәйгәннән-көчәя бара. Өянкеләр тоташ шаулый башлады. Караңгы төште. Клуб ягыннан сүнеп-тынып кына радио тавышы ишетелеп куя.

Күпме басып тора инде ул?

Әллә кереп ятаргамы? Болай торып салкын тидереп куюың бар. Шул гына житмәгән иде тагын.

Җәвит өйгә керде. Сак кына түргә узды, чишенде, әзер урынга ятты. Юрган жиңел иде. Бөгәрләнеп килде, жылына алмый изаланды. Уйлар, уйлар. Күзгә һич йокы керми. Җәвит, ята-ята, ниндидер, эле үзе дә аңлап бетермәгән хурлану тойды. Ә бит ул бу очрашуны бөтенләй башкача күз алдына китергән иде: ул килеп төшә, Әдилә аның килүен ишетә янсә күрә дә, каршысына атылып чыга. Аннары балага:

— Чәчкә, кызым, әтиең кайтты, әтиең! — дия-дия, куанычын сиздерә.

Җәвит кызын күз алдына китерә. Һәм аның күңеле яктырып китә. Юк, килеп дөрес эшләде ул, бик дөрес эшләде. Аннары кемгә сер инде, сагынды бит Әдиләне, сагынды, юксынды. Юкса, ялгызы жылы якка да китә ала иде. Гүзәл затлар тапмаслык ир-егетме әллә ул! Тапты да бит инде ул аны. Тик тора гына алмады. Икесе ике юл кешесе булып чыктылар. Ә гаилә бер сулыш белән яшәргә тиеш. Әйе, сыналмаган — сынган. Алар Әдилә белән, ниһаять, сыналдылар. Аннары аларның жан-

каннары кушылудан туган нарасыйлары бар. Ә бала бит үзе яртысемья.

Җәвит көрсенеп куйды, икенче ягына әйләнеп ятты.

## 48

Таибәне, комплекска өлкән оператор итү нияте белән, алты айга Мәскәү өлкәсендәге совхозларның берсенә укырга җибәрделәр. Аның урынына ферма мөдире булып Халисә калды. Кулыннан эш килсә дә, кыюсыз, йомшак табигатьле бу кыз читтән торып Казан зооветеринария институтында укый иде. Җәйләүгә килгәч, шушы кызның елап торуын күреп, Әдилә аның янәшәсенә утырды.

— Ни булды сиңа, Халисә? Кем рәнҗетте? — дип шаяртырга теләде Әдилә. Будкадагы башка кызлар карашларын читкә алдылар, берсе дә көлмәде дә, елмаймады да.

— Сөт савабыз, ә илтергә машина юк. Күпме шулай булыр соң бу? — дип тузынып алды Фирдәүсә.

— Дөрес әйтәсең, нәмәмә завод үзе килеп алмый ул сөтне? Сау да, житмәсә, илтеп тә бир. Нигә алай булгач, колхозларга машинасын бирмиләр? Әй, бу Талип абыйны, ачуым килмәсә әйтмәс идем, шундый көннәрдә генә Казанга киткән. Әдһәм абый Мансурны жиңә алмыйм дигән була, имеш, өч машина жимердек инде шул сөт заводы юлында. Каюм кулларын гына җәя, ни чаралар кылыйм соң инде дип аклана, кап корсак.

Фирдәүсә бүген барысы өчен дә әйтергә булган иде, күрәсең.

Әдилә Халисәне кулыннан житәкләде дә туп-туры диспетчер Каюмга алып килде. Зиннуров юан гәүдәсен креслога батырып пульт янында утыра. Диспетчер түгел, космонавт диярсең үзен.

Кызларны күрүгә ул, әдәп йөзеннән, аларга урын тәкъдим итте.

— Хуш киләсез, чибәркәйләр, түрдән узыгыз, утырыгыз.

— Тагын машина турындамы, диярсең инде, Каюм абый, — диде Халисә һәм түрдәге йомшак креслога узып утырды.

— Бу юлы ярдәмче белән килдеңме? Менә, ышанмасаң, тагын бер тапкыр сөйләшәм. — Каюм каршындагы аппаратның бер төймәсенә басты. Динамикта Мансур тавышы ишетелде.

— Әйе, Каюм абый, тыңлыйм сине.

— Тыңласаң, менә нәрсә, Мансур. Хәзер үк сөт илтергә бер машина бирәсең.

— Шоферлар риза була икән, барсыннар. Һәр шофер капиталь ремонтка кадәр фәлән хәтле километр үтәргә дип йөкләмә алды. Мондый юлларда бер еллыкны бер рейста туздырып кайта бит ул. Гафу итәсез, Каюм абый, ирексезли алмыйм. Аннары техник кагыйдәләрне үзем үк бозарга кушкан булам ич.

— Телеңә күп салынма, унбиш минуттан бер йөк машинаң җәйләүдә булсын!

— Юк, ирексезләп җибәрә алмыйм, теләсәгез нишләгез. Ә сөтне аертып, май итеп тапшырып та була аны. Ә жимерелгән машинаны гамәлдән сызарга туры киләчәк. Бер рейска бер машина жимерикме?! Бик кыйммәткә төшмәсме соң ул сөт колхозга?

— Сине генә куясы калган икән ферма башлыгы итеп, Мансур?

— Әйе, ялгышкансыз булып чыга. Бюро члены буларак, иң әүвәл сез ялгышкансыз булып чыга, Каюм абый, — дип, Мансур бөтенләй сөйләшмәс булды, күрәсең, трубкасын куйды.

Зиннуров төймәдән бармагын алды да тагын кулларын җәйде. Бу аның: «Күрәсез, гаеп миндә түгел, кызлар», диюе кебегрәк килеп чыкты.

Әдилә урыныннан торды.

— Әйдә, Халисә, гаражга.

— Трактор да ярамыймы? — дип сорады Халисә.

— Тракторларны завод ишегалдына кертмиләр.

— Әйдә инде, Халисә, — диде ишек төбендә басып торган Әдилә, сабырын җуеп.

— Бармыйм мин анда, Әдилә, шоферлар авыз ера.

Кайчак кешедә һич тә үзенә кагылмаган эшне башкару, кемгәдер ярдәм итү теләге туа. Әгәр дә мәгәр Әдиләдән:

«Нигә Халисәне гаражга чакырасың, шоферлар барыбер бармаячак», — дип сорасалар, ул, мөгаен, үзе дә аңлатып бирә алмас иде.

— Бу ниткән хатын булды соң әле, колхоз эшенә кысылып йөри,— диде Каюм Әдиләдән кала төшкән Халисәгә. Халисә аның бу сүзләренә ачуланып кызарынды.

— Бүрткән бүкән, шуны да эшли алмагач, нигә син монда утырасың?! Менә Талип абый гына кайтсын әле! — дип сөйләнә-сөйләнә, Әдилә артыннан йөгерде.

...Машиналарны, җепкә тезгән кебек, бер рәткә куйганнар. Әдилә белән Халисә машиналар рәте буйлап киттеләр.

— Шундый көндә биредә йөриме соң алар! — диде Халисә, ачу белән.

— Кемнәр? — дип, кинәт машина кабинасыннан сикереп төште берәү.— Абау, мәхәббәтсез, куркыттың,— диде Халисә, йөрәген тотып.

— Исәнме, Габбас!

— Сәлам, туташлар. Нинди җил ташлады сезне монда?

— Нужа китерде,— диде Әдилә.

Габбасның кашлары маңгаена сикерде.

— Казанлыларга да безнең хаҗәтебез чыгар икән!

— Көлмә әле, Габбас, Җәйләүдә энә кырык фляга сөт әчи.

— Һы. Һәм сез мине шул сөтне заводка илтергә димләргә килдегезме?

— Шулай булса ни әйтер идең?

— Син үзең барсаң — риза.

Әрсез дә соң бу шофер халкы. Һәрхәлдә, Әдиләгә шулай тоелды.

— Ә чынлап та барсам?

— Син дә барасыңмы? — Габбас кепкасын маңгаена төшереп баш чирәбен кашыштырды. — Хәзер үк китәбезме, иртәгәне көтәбезме?

Халисә белән Әдилә күзгә-күз карашып алдылар.

— Әдилә нишләп йөрсен анда, тиле! — диде Халисә.

— Башка кеше белән бармыйм, шул гына.— Габбас әрсез итеп елмайды. Ул машинасына менеп утырды да ишекне икенче яктан ачты. — Рәхим итегез, Әдилә туташ!

...Флягаларны терлекчеләр тиз төяделәр. Әдиләгә кирәк кәгазьләрне тоттырдылар. Ул кабинага кереп утыруга, Габбас:

— Аллага тапшырдык, Әдилә, бәхетегезне сыныйк әле, — диде һәм моторны кабызды.

Чирәмнән, такыр, калкурак төшләрдән машина алга узды. Яңгыр ява-ява юлны лыжырдатып җибәргән. Машина әле салулап юл читенә төшә, әле бер урында таптана. Габбас андый чакларда бер артка чиктә, бер алга кузгалды.

— Их, юллар, юллар!..

Машина эчендә тимер-корыч чырылдый, мотор әле сүнәргә җитешеп тартыша, әле өздереп алып китә. Кабинада бөркү, эссе. Әдилә ишек пыяласын төшерде. Кабинага саф һава, кыр һавасы агылып керде. Габбас сөйләшми. Башта үзен әрсез генә тоткан шофер бөтен дикъкатен юлга юнәлткән.

— Акташ үрен менсәк, синнән дә бәхетле кеше юк, Әдилә, — дип, бераздан гына телгә килде Габбас.

— Бәхет бер шунда гына сыналса иде икән ул, Габбас.

— Барыбер син бәхетле, Әдилә. Чибәрсең, ә акыллы һәм чибәр хатын-кыз бәхетсез була алмый. Аны яраталар, ә инде кем дә булса сине ярата икән, син инде ул хәтле үк бәхетсез түгел.

— Дөнья тулы сылулар, Габбас.

— Әйе, сылулар ерып йөргесез. Тик өйләнәм дисәң рәтлесен очрата алмый гына җәфа чигәсең. Җәй буе җәйләүгә киләп сардым. Машина белән дә чаптым, җәяү дә йөрдем, барыбер рәт чыкмады әнә. Яратмады дип әйтәсем килми, көн аралаш хат яза. Үткәнем өчен үртәләм. Ашыгыбрак өйләнгән идем. Кайтып төшәр дә, ияреп китеп барырсың, ди, ышанмыйчарак йөрде.

Әдилә Габбасның Таибә белән йөрүен белә, аның кем турында сөйләвен дә чамалый иде, шуңа күрә дәшмәүне артык күрде.

— Саф мәхәббәт бармы соң ул?

— Нигә булмасын, бар, — диде Әдилә, тәрәзәдән кергән җилгә йөзен куйды.

—Минем башымнан үтте шул инде ул. Янып-көеп сөеп тә карадым, юксыну-сагыну чорын да күрергә язды, тик өйрәнеп-гадәтләнеп кенә китә алмадым. Аннары кызгану килде. Армиядән кайтуга Кадрия атлы берәүгә өйләнгән идем. Бер ел узмады: «Мин синең белән тормыйм, холкың начар», — дия башлады бу. Анысы хак, эшләр беткәч бераз ычкынып алгалый торган гадәт бар иде. Эчкече булып китәр дип куркуы иде, күрәсең. Ахыр килеп, әйдә читкә китәбез дия башлады. Минем китәсе килми. Әйтешеп алдык. Теленә ни килә шуны чәпи бу миңа, мин дә сүз сайланудан уздым. Бер мәлне биленә таянды да бу: «Мескен!» — диде. Җитмәсә, кабатлый. Тәмам җанымны актарып чыгарды шул сүзе. Яңагына сугып җибәргәнемне сизми дә калдым. Аһ-ваһ та килмәде, дәгъвалап та йөрмәде, икенче көнне җыенды да китте-барды. Бер елдан әйләнеп кайткан бу. Битләре акшарлаган, күз тирәләренә куе шәмәхә иңдергән, керфекләрен буяуга катырган, курчак диярсең. Ел эчендә ни галәмәтләр үзгәргән дә куйган. Бераз кәкре сыйраклары да турая төшкән кебек, кәҗә сыман керт-керт басып кына йөри. Танау, мин сиңа әйтәм, Таз тауда. Җитмәсә, егетләр: «Нинди хатынны ычкындыргансың, Габбас, малай»,— дип, йөрәккә ут өстиләр. Алай да мах бирергә исәп юк. Бик кәпрәймә, әллә кем түгелсең, шул ук Карамалы катыгын ашап үскән бит дим тегеңә. Шулай дим, ә эчне нидер тырный. Күреп сөйләшәсе килә үзе белән. Кич клубка чыктым. Бу да килде. Үтеп китте бермәлне бу минем яннан, миңа хуш исләр генә кагылып калды. Ул үзенә усал, мин үземә. Исәнләшмәдем, күрмәмешкә салыштым. Җитмәсә, Таибә артыннан киләп салып йөргән чак. Таибәсе дә, күрде дә минем иләс-миләс йөргәнне, кайтып китте. Аңлады мин тиленең хәлен. Ул кайтып киткәч, тагын аның өчен эч яна башлады. Кул селкеп чыктым да киттем. Кайтып киләм шулай, баш иелгән, күңелдә давыл, өермә. Әллә урам тар, әллә үзем чайкалам. Таибә дә җәл, көзгә өйләнешәбез дип сүзләр куешып, вәгъдәләр бирешкән идек. Кайтам шулай. Бермәл башым күтәреп карасам, Кадрия басып тора. Ай яктысы якты иде, таныды. «Исәнме, Габбас», ди. Их-ма, түзсә түзә ирләр йөрәге дә. Урамның нәкъ уртасына баскан. Күрмәмешкә салышып, әйләнеп чыгарга исәп үзен. Юк, җибәрми, мин күчәм, ул күчә. Ул да түгел, килде дә күкрәгемә капланды бу. Әллә кайчангы чәч исенә башларым әйләнеп китте. Йөрәк кочарга өнди, куллар исә катты да калды. Күз алдыма теге чакта кәпрәеп чыгып китүе килмәсенме! Кинәт борылдым да йөгерә-атлый китеп бардым. «Габбас!» дип дәште. Туктамадым. Киселгән икмәк кире ябышамы? Тик һаман аерылыша алган юк әле...

Машина үкереп үр менә. Ара-тирә көпчәкләр бушка әйләнеп торгалый. Тау башында ялгыз каен утыра. Берүзе булгангамы, җәелеп, таралып, мәһабәт булып үскән. Габбас, аркасын утыргычка терәп, рульгә

ябышкан. Машина бөтенләй алга бармас булды. Көпчәк гел бер урында әйләнә башлады. Габбас ишекне ачып артка карады һәм машинасын түбән җибәрде. Тау битенәрәк төшкәч, ул туктады, моторын сүндереп, кабинадан җиргә сикерде.

— Менә бәхетеңне сынап та карадың, Әдилә. Шулай инде ул безнең брат белән юлга чыксаң,— диде ул һәм тирләп чыккан маңгаен кепкасы белән сөртеп алды.

— Менеп булмас микәнни, Габбас?

— Өметсез шайтан ди. Җан биргәнгә җүн бирер әле.

Габбас папирос кабызды, авызыннан төтен бoжралары чыгара-чыгара тарта башлады. Аннары кулларын чалбар кесәсенә тыкты да машина тирәли әйләнеп чыкты. Һәм алгы көпчәкләргә типкәләп алды. Артка узды да арт көпчәкләрнең һавасын чаж-чож чыгарырга кереште. Әдилә кабинадан төште.

— Габбас, нишләвең бу?

— Хикмәтле хәл. Балоннар кызган икән бит. Менә хәзер һавасын җибәрәм дә...

— Шаяртмачы, Габбас!

— Мин болай уйлыйм әле, безгә синең белән, Әдилә, башны башка куеп, кабинада йокларга туры килмәгәе, — диде Габбас, әмма Әдиләнең йөзендә үзгәрү күреп: — Курыкмасана! Шәһәр халкы кинаялəп сөйләшүне аңламый дигәннәр иде, хак икән,— дип, аны юатырга кереште.

— Ә нигә баллоннарның тынын чыгарасың?

— Басым кимегәч, көпчәкләр җәелә төшә, баллоннарның җиргә ятуы бермә-бер арта. Физика законнарын оныттыңмы әллә?

...Әдилә өйгә ярты төн узгач кына кайтып җитә алды. Габбас аны озатып куйды. Әдилә кургаштай авыраеп калган итекләрен көчкә сөйрәп, капка янына житте. Шул вакыт капка баганасыннан берәү аерылды. Әдилә куркып китте.

— Кем бу?

— Бу мин, Әдилә.

— Аһ, Зариф! Җүләрем, куркыттың ич. Нишләп йөрисең ярты төндә?

— Сине көттем.

— Күрче моны! Әлегә кадәрме? Уф, арыдым мин, Зариф. Әдилә Зарифка якын килде һәм салкын кулы белән аның яңагына кагылды.

— Рәхмәт сиңа, Зариф. Барыбер син яхшы кеше.

Ни өчен алай дисең?

— Менә мине шулай көтеп алганың өчен.

— Әдилә, мин...

— Бүген түгел, Зариф, яме? Хуш. Тыныч йокы сиңа.— Әдилә келәне тартты. Капканы җилкәсе белән төртеп ачты да ишегалдына керде. Алгы өйдә чишенде. Плащын чөйгә элде, итеген ишек төбендә калдырды. Аягына чүәк табып киде. Мич янына узды, ут алмыйча гына, әбисе калдырган бер банка сөтне эчте, чәйнектәге су белән авызын чайкады һәм аяк очларына гына басып түр өйгә үтте. Диванда әтисе йоклый, ябынган юрганы идәнгә төшкән. Шулай ук аяк очына гына баса-баса түргә килде, юрганны алып рәтләп ябарга тотынды. Шунда аның кулына кайнар бармаклар ябышты.

— Абау!

— Курыкма, мин бу, Җәвит!

— Җәвит, — диде Әдилә пышылдап һәм буыннары бушап диванга утырды. Җәвит аны кочагына алды һәм шашынып үбә башлады.

— Җәвит, туктале! Нишләвең бу?!

— ...Мин сагындым сине, шундый сагындым, Әдилә. Син кирәк миңа бу дөньяда! Син һәм Чәчкә! Кичер мине, Әдилә, ялгыштым мин, гафу ит...

Кисәк кенә башына ишелеп төшкән бу назга ул бермәлгә югалып калды. Акылга сыярдай нәрсә түгел иде бу — айнымый азапланды. Җәвит аның иреннәрен, битен, күзен үбә, чәчләрен сыйпый. Төшме әллә тагын?

Җәвитнең кайнар сулышы колак артын, муенын пешерә. Иркәләү сүзләре тоныклык кына булып аңына җитә башлады.

Шундый җәйләр була. Айлар буе яңгыр яумый. Корый, кибә яшеллек дөньясы. Иртән кояш чыкканчы таҗларын җәеп, алкаларына чык тамчылары җыйган чәчкәләр, көн килүгә, куырылып, шиңеп калалар. Чирәмнәр саргая, аяк астында коры үлән кыштырдый. Шунда кинәт кенә коеп яңгыр явып уза. Шиңә башлаган чәчәкләр терелә, таҗларын җәеп, тирә-юньгә хуш ис таратып, бал кортларын котырта.

— Әдилә, мин бирегә сезне алырга дип килдем.

Әдилә суырылып ычкынды да тәрәзә төбендәге урындыкка барып утырды. Һәм кулы белән йөзен каплап әрнү-үртәлүдән, күңеле тулышудан гаҗиз калып, елап җибәрде. Ул кычкырып еламады, ул эчке сыкрау белән тын гына елады.

Җәвит аның янына килде, иңбашына кулын салды.

— Әдилә, зинһар тынычлана күр. Гафу ит, кичер мине. Китик моннан. Үткәнне беркайчан искә төшермичә, яңабаштан тату гына яши башлыйк.

— Җәвит, — диде Әдилә, кинәт кенә ниндидер бер катгый фикергә килеп, — соң инде, мин кияүгә чыктым.

— Кияүгә?! Юк, юк, ялган бу. Син кияүгә чыкмагансың!

— Юк, Җәвит, ялганламыйм. Минем йөргән кешем бар.

— Йөргән кешеләр күп булыр, Әдилә. Сөйгән кешең бер генә була. Мин синсез тора алмыйм, Әдилә. Аңла мине...

— Сиңа карата күңелем йомшарган чаклары булды, Җәвит. Тик син бәгырем каткан чакка туры килдең. Эремәс ачу ташлар салдың син минем җаныма. Шуннан соң сине гафу итәргәме, бар кимсетүләреңне онытып...

Әдилә соңгы сүзләрен ачыргаланып әйтте, торырга дип хәрәкәт ясады.

— Әдилә, зинһар, үткәннәрне искә алмыйк. Ялгыштым мин, егылдым. Кыйнама егылганны! Безнең балабыз бар бит, Әдилә. Бала хакына кичер син мине. Ерак авылда яшисең. Гомер ике килми, китик моннан.

— Куйчы, Җәвит, төчеләнмә ул хәтле. Мин сине артыгы белән беләм бит. Үзеңне артык иркле тотасың. Телисең — китәсең, инде хәзер кавышуыбызны сорыйсың. Башым эшләми минем, башым катты. Син ят, йокла...

— Әдилә, безгә бүген аңлашырга кирәк, ату минем йокым йокы булмаячак.

— Әйе, сиңа бер төнлек йокы әрәм. Ә мин, җүләр, син киткәч, айлар буе рәтләп йоклый алмадым, суларга ташланып һәлакә җиттем.

Җәвит аны әрсезләнеп тагын кочагына алды, үбәргә теләде. Әдилә кочактан тиз генә ычкынып ишеккә таба китте.

— Арыдым мин, Җәвит. Тыныч йокы сиңа. Иртәгә сөйләшербез.

Әдилә ашыгып итеген, плащын киде һәм урамга йөгерде. Йөрәге ашкынып типте, тыкрыкка җитүгә, бөтен буыны калтырый башлады. Юк инде, ул монда да калалмый. Йөгерә-атлый ындырга таба китте, аннан җәйләүгә юнәлде. Ындыр табагы янында берәү күзенә чалынды, ләкин Әдилә туктамады. Урман полосасы буйлап атлый торгач, ниндидер салам эскерте янына килеп чыкты.

«Кая барам мин? Шушы юлдан бераз баргач, сулга борыласы һәм җәйләү шунда. Анда кызлар, анда»...

Таллар куелыгында ике вагон күренде. Җәйләү шунда. Тоныклык кына

яктылык җемелди. Нигә вагоннарда ут юк? Бүген кызлар кунарга калмадылар микәнни?

Мул сулы чишмәгә җитте. Чишмә чылтырап агып ята. Таң алдыннан бирегә пошилар килә, кояш чыгар алдыннан кошлар төшә.

Күк йөзе аяза башлады. Пәрдәсе ачылып барган тәрәзәдәй, көнчыгыштан таң нурлары сибелде. Яңгыр туктаган. Чишмә буйлап бара торгач, һаҗәр чокырына килеп җитте. Чокырны чыкты да вагоннарга таба китте.

«Нишләп болай йөрим әле? Ул бит мине алырга килгән. Гафу үтенә, үзе белән китүемне сорый?»..

Аяк астында юеш үлән. Резин итекләр авыр, атлыйсы килми. Утырасы иде дә әнә шул агач төбенә... Әдилә карт өянке астына туктады да, аркасын кәүсәгә терәп, таң нурлары сибелгән Рә тавы ягына карады. Кояш нурлары ал-зәңгәр зөбәрҗәт төсенә кереп күк гөмбәзен буяган. Җил дә туктаган, яңгыр да юк.

Әдилә уйга калды. Нигә китәргә тиеш соң әле ул? Зарифны танылапмы?.. Вазифамы? Ана вазифасымы? Ана булуымы аңа шулай күтәрә алмастай авыр йөк салды?..

Чишмә ягында төтен сыман куе томан тора. Димәк, ниһаять, көн матур, кояшлы, аяз булачак. Әдиләнең генә күңелендә куе болыт. Кузгалды. Чишмәгә, вагоннарга таба китте. Йөгереп килсәң, чишмәне сикереп чыгып була. Әдилә бүген алҗыган иде, йөгерү түгел, атларга да хәле калмады. Шуңа күрә ул чишмә аша терәкләп-сырлап ясалган басмага таба китте. Аның шул басмага басып, су өстендә йөгерешкән коңгызларны күзәтеп торганы бар.

Кинәт ул баскан җирендә шым булды. Аның каршында, томан эченнән чыккандай, чатлы-ботлы мөгезләрен як-якка җәеп, поши тора иде. Әдиләнең өне алынды. Поши башын чайкап, усалланды, аннары сагышлы итеп мөңгерәде. Әдилә баскан урынында тораташтай катып калды. Поши башын иеп аяк астын иснәп алды, зәһәрләнеп баш чайкады. Ул да түгел, мөгезләрен сөзәргә җайлап, Әдиләгә таба кузгалды.

— Әнием!

Тавышы зәгыйфь чыкты. Юк, бөтенләй чыкмады, эченә йотылды. Поши нәрсәдер ишеттеме, янә башын чайкап алды. Әдилә кычкырырга дип авызын ачты, ләкин кычкыра да, кузгала да алмады, һушы китеп, акрын гына җиргә чүкте.

Шул чакта якында гына яшь бозауның куанычлы мөгрәве ишетелде. Бу тавышка поши сискәнеп китте, Әдилә өстенә килүдән туктады, «һо-һо-һо-һо!» дип, өзеп-өзеп аваз салды.

Куе томан эченнән бозавын ияртеп ана поши килеп чыкты. Кеше күрүгә, кинәт туктады да сабыр гына мөгрәп алды. Әдиләгә ис-аң килде. Ул тәпен-тәпен артка чикте һәм инде пошиның үз артыннан килмәвен искәрүгә, борылды да вагоннарга таба йөгерде. Шунда ул кемгәдер килеп бәрелде.

— Аллам, кем бу?!

— Мин бу, Әдилә. Пошиның бозавы баткан иде анда. Шуны чыгарып маташтым да...

Әдилә аның кочагына инде һәм, хәлсезләнеп калуын сиздереп, башын Зарифның күкрәгенә төртте дә балаларча кычкырып елап җибәрде. Аның калтыранган иңбашларын сыпырып торган Зариф, аны юатырдай сүз табудан гаҗиз калып:

— Тынычлан, Әдилә, киттеләр инде ул пошилар, киттеләр, — дию-дән гайре сүз тапмады.

Әдилә яшьле күзләрен күтәреп Зарифка карады.

— Беләсеңме, Зариф?.. Син берни дә белмисең бит... Ул мине сөзәязды... Әйт әле, Зариф, син кичтән бирле мине эзләп йөрдеңме?

Зариф бермәл дәшмичә башын иеп торды.

— Әйдә вагонга кереп утырыйк әле, Әдилә.

Зариф Әдиләгә баскычтан менәргә ярдәм итте. Вагонда берәү дә юк иде. Ут алмадылар. Көн тумаса да, вагон эчендәге әйберләрне шәйләрлек иде инде.

— Әллә бүген биредә беркем дә юкмы?

— Сыер савучылар кайтып киткәннәр. Каравылчы бабай теге вагонда. Син аргансың, Әдилә.

Зариф аны кушеткага утыртты, үзе янәшәсендә урнашты.

— Әдилә, — диде ул кыюсыз гына, — Әдилә, кал Карамалыда!

Әдилә дәшмәде, башын түбән иеп утыра бирде. Аннары уфтанып алды, күтәрелеп Зарифка карады. Күзләрен йомып, башын чайкады, битен аның йөзенә терәде. Зариф аның битләреннән тотып, күзләреннән үпте.

— Кал, Әдилә. Мин сине бүген төне буе көттем. Син кая барсаң, шунда чаптым. Мин беләм, ул сине алырга килгән... Кал, Әдилә!..

— Их, Зариф, Зариф. Ни хәлләр итим соң? Ниләр әйтим? Ниләргенә әйтсәм дә, аңламассың кебек син мине...

Зариф аны кочагына алды. Көчле беләкләре белән күкрәгенә кысты, кайнарланып кысты.

Ихтыяр көче. Каян килә ул кешегә? Хис ташкынына эләккән кешене нинди илаһи көч шушындый минутларда коткарып кала — акыл беләнэш итәргә өнди?!

Зариф үзе дә аңламаган нииндидер гарьләнү хисләре кичерде. Ул муеныннан кочаклаган Әдиләнең кулларын иплэп кенә тотып алды да, аны үз күкрәгенә куйды.

— Минем сине җибәрәсем килми, Әдилә. Кал. Язылышыйк. Торыйк бергә?

Әдилә бермәлгә башын түшенә иеп сүзсез торды. Аның кайнарланып, йөгәнсезләнеп китә язган йөрәге суына, сүрелә төште, менә-менә чарпалырга торган хис дулкыннары үз ярларына чигенде.

— Син язмышка ышанасыңмы, Зариф?

— Күп очракта үз язмышын кеше үзе ясый хәзер.

— Син ясыйсыңдыр да бит... Менә мин ясый алмадым шул инде...

Әдилә торды да, плащын алып киде, ишеккә таба кузгалды, әмма тоткага кулын салгач, башын түбән иеп, уйланып торды. Тәрәзә каршына барып баскан Зарифка күз салды. Зариф чыгып килгән кояшка караган да уйга калган. Ә кояш инде беренче нурлары белән тәрәзә пыялаларын, аның аша Зарифның йөзен иркәли иде.

Әдилә килде дә аның җилкәсенә кулын куйды, киң аркасына сыенды.

— Зариф, син минем күңелемдә иң изге, иң саф кешем булып каларсың. Аңла мине. Кер хәлемә. Ана булгач, барысын да исәпкә алырга туры килә икән ул...

Зариф аның соңгы сүзләрен ишетмәде, колагы чыңлады, борылып Әдиләгә сүз әйтүдән чак кына тыелып калды.

— Әдилә, — диде ул, тәрәзәгә караган килеш, — Китмә, кал...

Зарифның кайнар сулышыннан тәрәзә пыяласы тирләп чыкты. Ул ишеккә таба борылганда Әдилә вагонда юк иде инде. Зариф килеп ишекне ачты. Вагоннар янына машина туктаган. Сыер савучылар эшкә килгәннәр. Әдилә шул машинаның кабинасына утырып маташа. Зариф баскычтан төшкәләгәнче, машина кузгалып китеп тә барды.

Зариф ни кылырга белмәүдән гаҗиз калып чишмә ягына юнәлде. Аны сыер савучылар әллә күрделәр, әллә күреп тә күрмәмешкә салыштылар, аңа дәшүче булмады. Таллар арасыннан узасың да чишмә аркылы салган басмага килеп чыгасың. Зариф шул басмага керүгә туктап

калды. Тибеп чыккан урынынnan кило-кило талгынланып калган суда чукмарбашлар йөзә, маймычлар күренә, су чебеннәре йөгереп уза.

Басманың икенче башына килеп баскан Фирдәүсәне ул әүвәл күрмәде. Мәгәр күрсә дә аптырамас иде. Һәм күрүгә аптырамады да.

— Инде жаның тынычландымы?! — диде Фирдәүсә, басма терәгенә күкрәге белән ята төште, тимераякчылардай су өстендә йөгерешкән су чебеннәренә карап тора башлады.

Зариф дәшмәде. Хәер, ни әйтә алсын ул аңа? Фирдәүсәнең үзе артыннан шулай йөрүенә ачуы килгән чаклары да булды, бүген исә аңа барыбер иде.

— Их, Фирдәүсә, Фирдәүсә!..

— Зариф, егетме син! Тиң түгел бит ул сиңа, жүләрем, тиң түгел! Аның үз дөньясы, үз тиңнәре бар, ире килгән... — Фирдәүсә кузгалды, бер кеше үтәрлек басмадан узып, Зариф каршына килеп басты. — Бирмим мин сине аңа, Зариф, бирмим!

Фирдәүсәнең якын торуыннан, аның сулыш кайнарлыгыннан, агарынып калган иреннәренең дерелдәп китүеннән үк Зарифның зиһене чуала башлады.

— Фирдәүсә, син эшкә килдеңме? Бар эшеңә!

— Икәүдән-икәү генә бер вагонда кундыгызмы? Төн буе янында тоттыңмы? Ире аны авыл бетереп эзләп йөри. Ничек оялмый ул, ничек оялмый, битсез!..

— Фирдәүсә, житте сиңа! Кит юлымнан!..

Фирдәүсәнең аскы ирене калтырап китте, ул күзләрен йомды һәм, үжәтләнеп, юк, китмим, беркая да китмим дип, як-якка башын чайкады. Ул да түгел, кыз Зарифның күкрәгенә капланды. Зариф тирә-ягына күз ташлады, ни кыларга белмичә тәпен-тәпен артка чигеп, басмадан чыкты.

— Нишләвең бу синең, тиле!

— Бирмим мин сине аңа, ишетәсеңме, бирмим! Китсен. Жаны жәһәннәмгә олаксын!..

Фирдәүсә, тыгыз күкрәген аңа тери төшеп, һаман елышты. Зариф аның сөт катыш хушбуй исе килеп торган чәч исен тоеп һәм Фирдәүсә кыланышында нәүмизлек, самимилек күреп, кызны кызганып куйды. Кисәк кенә аның кызны матур-матур сүзләр белән юатасы, жанын эретердәй жылы сүзләр әйтәсе килеп китте. Ләкин ул аңа бер сүз дә әйтмәде, корыган агачтай тик басып торды.

Фирдәүсә Зариф ягыннан теләктәшлек, юату, һич югы, хәленә керү сүзе ишетмәгәч, теле белән әйтмәсә дә, егет тарафыннан жылы хәрәкәт тоймагач, кинәт кенә читкә тайпылды һәм башын игән килеш, йөгерәатлый, вагоннарга таба китеп барды.

Иртән алар аз сөйләштеләр. Йокысызлыктанмы, Жәвитнең кәефенык кына кырылган иде, хәтта ул Гөлзифа әби пешергән төче коймакка да үрелмәде. Ясап куйган чәйне дә эчсә эчте, эчмәсә юк. Гариф тангәдер кияү белән сөйләшеп китә алмады. Әдиләне аңларга була иде. Бигрәк кинәт булды шул. Йөкле көйгә ялгыз калгач, көн-төн елады, кеше күзенә күренергә оялып йөрде. Ашаудан язды, күзләре эчкә батты, жил иссә авар чиккә житеп ябыкты. Юк инде, шушы рәнжү-хәсрәтләр кичергәннән соң болай жиңел генә гафу итмәс ул сине, кияү балакай.

Гариф табыннан торды да эшкә жыена башлады. Алгы өйгә чыгып нидер эзләнеп керде. Кияве суынып беткән чәен болгата-болгата тәрәзәгә караган да уйга чумган. Монын да хәлен аңларга була иде, әлбәттә. Баш иеп килгән, ә ул каядыр йөри.

— Безнең янга да килеп чык, — диде киявенә Гариф.
Җәвит баш кагып кына җавап бирде. Бабасы янадан дәшмәде, чытып китте. Өстәл белән мич арасында тастымал тотып йөргән Гөлзифа әби генә чит бер кешегә әйткәндәй:
— Кияүгә чыкмады, юкка янма, — диде. — Күрәм-карыйм да, кияүкәем, фәрештәләр кебек тыйнакланып киткәнсең димме...
Җәвит килешсез генә елмаеп куйды.
— Үзем табын түрендә утырам, үзем әйтерсең чит берәүләргә килгәнмен. Бабайга да рәтле бер сүз әйтә алмадым. Әдилә сөйләшергә дә теләмәде.
— Менә күр дә тор, әйләнер дә кайтып керер әле. Хатын-кыз бер бичара инде ул. Күнәр, күнми кая китсен. Күңелләрен бер дә кинәт кенә йомшартырлык итмәдең шул, кияүкәем. Теге вакытта ташлап киткәч, кайгыруларын күрсәң икән син аның...
— Шулай ярыймыни, әби? Миндә дә горурлык бар бит. Мин аңа бала хакына баш иеп килдем, ә ул... Тату яшәгән чакларыбыз да аз булмады ич! Алай ук кырт кисәргә без бит әле законлап аерылышмаган да.
— Шуңа үпкәлисеңме, җүләрем?
— Әйтәсеме,гаеп миндә дә булды. Тик бит, әби, ул да фәрештә түгел, еллар буе бары мине көтеп яшәмәгәндер. Әйтәм бит, булды, аерылышып торып карадык, бер-беребезне сынадык... Житәрдер кебек инде. Үзең уйлап карале, миңа бирегә баш иеп килү җиңел булды дип беләсеңме? Мин бит ир кеше, — Җәвит йодрыгы белән күкрәгенә төйде. — Менә монда таш ята дип уйлый, күрәсең, ул!
— Һәй, улым, нишләсен соң инде ул да... Теге вакытта бигрәкләр каты рәнҗеттең шул. Кинәт кенә ничек гафу итмәк кирәк.
Җәвит суынып беткән чәен күтәреп эчеп куйды.
— Бала кайда, әби?
— Кая булсын, әнә, күрше бүлмәдә йоклый...
Җәвит, кысан бүлмәгә керү белән, түр яктагы караватка күз төшерде. Чәчкә, уң кулын яңак астына куеп, изрәп йоклый иде. Коңгырткара чәчләре йөзенә сибелеп төшкән, сул кулы белән курчагын кочаклаган, юрган астыннан бер аягы чыккан. Җәвит караватъ янына килде, кызның юрганын рәтләп аягына япты. Артыннан кергән Гөлзифа әби моны күрде дә:
— Һәй аллам, ниләр генә житми соң сезгә? Алма кебек балагыз бар. Фәрештәләр көнләшердәй чагыгыз. Бер-берегезнең кадерен белеп тату гомер итәргә генә дә бит...
Алгы өйдә кемнеңдер аяк тавышлары ишетелде. Бусагада Әдилә күренде.
— Синең белән сөйләшәсем бар, Җәвит. Әби, чыгып тор әле, — диде ул.
Әдилә карават башындагы бала урындыгына утырды, бермәл аяк очларына карап торды. Җәвит тыңларга җыенды. Ләкин, Әдилә озак сүзсез калгач, түзмәде:
— Әдилә, мин бирегә сезне алырга дип килдем! — диде.
Җәвит кинәт аның алдына иелде. Әдиләнең салкынча кулын кысып тотты. Йокысыз төннән соң күз төпләре күгелҗемләнеп калган Әдилә тәрәзәгә текәлде.
— Биздем мин синнән, Җәвит, күңелем кайтты...
Җәвит башын иде. Ихлас күңелдән әйтелгән сүзләр аның аңына тик бераздан гына барып житте.
— Кичер мине, Әдилә. Күрерсең, без, элеккечә, бер-беребезне яратып яшәрбез. Арабыздан җил дә үтмәс...
— Ни дип әйтергә дә белмим инде...
— Ышан, Әдилә, мин сине юатырга дип килмәдем. Кайчандыр на-

хакка рәнҗеткәнмен икән, гафу ит. Ышан, ул ялгышым яңадан кабатланмас.

«Югалтулар булмаса, мөгаен, тормышның кадерен бу кадәр белмәс идек. Югалтулар, сыналулар аша әйләнеп кайткан кавышулар, табышулар...» дип уйлады Әдилә һәм күңеле нечкәреп, инде алдына тезләнергә өлгергән Җәвитнең чәчләренә бармакларын батырды, аның чигә тирәсенә кырау төшә башлаган башын күкрәгенә кысты.

*
* *

Машина көткән арада юлга җыена-җыена, Әдилә туктап-туктап уйга калгалады. Җәвит бик тырышып әйберләр төенләшә, ике-өч ел аерым тормаганнар да кебек, гап-гади итеп сөйләшә, киңәшә. Шуларның тәэсиреме, Әдиләнең аңа ачуы әкренләп сүрелеп бара сыман. Әллә шулай тоела гынамы? Ни генә булмасын, күңелендәге тәүге нәфрәте кимемәгән, булган хәл белән килешү хисе килгән иде аңа.

Җәвит, әйбер-чемоданнарны рәтләп бетергәч, Әдилә янына килде, иппәп кенә иңбашына кагылды.

— Машина килде, әйберләрне чыгара башлыйк.

Әдилә өй эченә күз йөртеп чыкты.

— Ярый, чыга башлыйк. Әби,— Әдилә кызын җитәкләп күрше бүлмәдән чыгып килгән әбисенә дәште. — Сагынсаң Казанга кайт. Әтинең дә эше бетеп килә, бер үзең биредә калма.

— Калсам да, торсам да, чит-ят җирем түгел, туган авылым. Туган җирен ташлап киткән кеше ике тапкыр шатлык кичерер, ди, бер киткәндә, бер кайткач, дигәндәй, әбиең өчен борчылма әле алай. Әйбәт торыгыз, миннән фатиха шул сезгә,— диде Гөлзифа карчык һәм, әйтәсен әйттем инде дип, баланы җитәкләп ишегалдына чыгып китте.

Әйберләрне тиз төяделәр. Чәчкә инде машинага кереп үк утырган иде. Әдилә машина янына килгәч, Җәвит кабина ишеген ачты. Әдилә әбисен, әтисен күзеннән кичерде, саубуллашты. Шунда аның күзе тыкрык башында басып торган Зарифка төште. Зариф алар ягына караган да тик тора. Әдиләнең карашы шул тарафка юнәлүен күреп, Җәвит тә шунда карады. Нindидер мизгелдә ир белән хатынның күзләре очрашты. Аннары Әдилә тиз генә машинага кереп утырды, Җәвит ирен чите белән генә елмаеп куйды. Ниһаять, куллар кысышылды, өлкәннәр тарафыннан үгетләр бирелде, машина кузгалып китте. Әдилә тагын тыкрык башына карады. Тик анда Зариф юк иде инде.

Ындыр артын уздылар. Комплексның абзарлары, терлекчеләр өе, ялтырап торган сенаж башнялары күзгә чалынып калды. Таныш юллар, йөргән сукмаклар... Бөтенесе дә кала. Ә ул китә. Көн эчендә эштән чыкты, көн эчендә шуларны ташлап китәргә риза булды? Әнә инде Чәчәганак тавына җитеп киләләр. Шунда Карамалының чиге. Шофер да, Җәвит тә сөйләшмиләр. Фәрит рулена ята төшкән дә юлга төбәлгән. Менә Карамалының буй урман каеннары да артта калды. Чәчәганак чишмәсен чыктылар. Машина, үкереп, тауга менә башлады. Кояш инде өйләгә таба киткән. Үрне менүләре булды, Әдилә юл читендә басып торган берәүне күрде. Бу — Зариф иде. Мотоциклын бер читкәрәк — ялгыз каенга сөяп куйган. Фәрит машинаны акрынайта төшкәч, Әдиләнең күңеле айкалып китте. Юк, яшерә алмады. Каерылып Зариф ягына карады, кулын күтәрде.

Зариф артта калды. Әдилә алга карап утырды. Шунда ул алгы пыяла өстендәге көзгедә Җәвитнең сәер елмаеп утыруын күрде.

— Фәлит абый, Фәлит абый, мин алга утылам, — дип, Чәчкә алгы урынга күчәргә сорый башлады.

Артка күчеп утыргач, Җәвит тәрәзәдән кыр-басуларга карап барды һәм үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Күрәм-карыйм да, дускай, син дә миннән ерак китә алмагансың икән. Ә мин, җүләр, аның кичерүен сорап торам тагын. Бәйрәм ашы — кара каршы гына булган икән ич!..

Әдилә, нишләргә белмичә, комачтай кызарып чыкты. Ни сөйли бу Җәвит! Фәрит ишетми дип уйлый микәнни?! Бу мыскыллы сүзләрдән Әдиләнең йөрәге кысылды, уй-фикерләре, буасы ташырга торган елга суыдай, болганып китте.

Аның шулай бүртенеп утыруына гаҗәпсенгәнен белдереп, Җәвит баш чайкап куйды. Аннары шоферга күз салып алды да, Әдиләгә таба шуыша төшеп:

— Без синең белән квиты, дускай. Дөньяда шулай булмыймыни? — диде.

Әдилә дәшмәде, иреннәрен кысып, күзләрен генә яшерә төште. Нахакка рәнҗетелүдән аның күңеленә болай тәвәккәлләп чыгып китүе өчен үкенү-үртәлү килде. Ләкин иреннәрен тешләп булса да түзде, дәшмәде.

Машина асфальт юлга чыкты. Кабинага җил тавышы керде. Чәчкә тоткага ике куллап ябышкан да алгы тәрәзәдән күзләрен дә алмый карап бара. Вакыт-вакыт ул:

— Әнием, әнием, калале зул көймә, — дип, көнбагыш уручы комбайнга күрсәтеп, куанып ала.

Бөгелмәгә җиткәч, Фәрит машинасына бензин салырга туктады. Инде бераз тынычлана төшкән Әдилә дә машинадан чыкты. Машиналар тирәсендә шоферлар, йөк төяүчеләр кайнаша.

Җәвит кызчык белән машинада калды, Фәрит, бензин салган арада, бер читтә басып торган Әдиләгә карап-карап алды. Хәтта нидер әйтергә дип ымсынып та куйды. Ләкин Әдилә аны юри күрмәмешкә салышты. Күккә карады. Кояш төшкелеккә җиткән. Кичкә Казанда булырлар. Кемнәргә төшәрләр? Җәвитләргәме, туры үзләренәме?.. Күңелдә нинди дер бушлык. Беркая барасы да, хәтта уйлыйсы да килми.

Утырышып яңадан кузгалгач, Җәвит Әдилә ягына каерылып каерылып карады да, хатын йөзендә күләгә куыра баруын күрепме:

— Куйчы, Әдилә, юк-барга үпкәләп, тиктомалга турсаеп утырмыйк әле. Шаяртырга да ярамый башлаган бераү белән, ай-һай — дип сөйләнде. Әдиләгә кыен иде. Гомумән, очрашуларын болай күз алдына китермәгән иде ул. Әдилә, үз-үзен юатырга тырышып, бергә яшәгәндәге бәхетле минутларын күз алдына китереп карады. «Әле бит, әле ул хәтле бернәрсә дә булмады, түзим», — дип уйлады. Әмма барыбер тынычлану килмәде. Аның хәзерге халәтен аңламаган, аның көн эчендә тәвәккәлләп ияреп китәргә риза булуын гадәти бер хәл итеп күргән Җәвитне чын күңеленнән кызганды ул. Җәвит дәшмәгән саен күңеленә кереп урнаша башлаган шул уйны инде ул куа алмады. Ни уйлый ул?! Һич югы, юатсын, ялварсын, ялынсын иде!..

Күз алдына Зариф белән аерылышу минутлары килде. Әдиләгә бермәлгә хәтта оят булып китте. Зариф белән шулай аерылышыр дип ул күз алдына да китермәгән иде. Ә бит ул аны — бик теләгән булса — алып та кала алган булыр иде. Кыюлыгымы җитмәде шунда? Юк, Зариф аны аңлап, үзе читкә тайпылды. «Бәлкем, ул дөрес эшләгәндер», дип уйлады Әдилә.

Әнә инде алда аэропорт та күренде. Алар хәзер машинадан төшеп калырлар, ә Фәрит борылып китеп барыр. Нишләргә тиеш соң ул? Нигә болай Казанга күңеле тартмый.

Әдилә күз кыры белән генә Җәвиткә карап ала. Нигә бер сүз дә әйтми ул? Ичмасам, юатсын, тынычландырсын, һич югы, сорашсын, бала белән сөйләшсен иде. Әти: «Чир китә, гадәт кала» — ди, әллә шул хак микән?..

— Әдилә, син мине ачулана күрмә тагын, — диде Җәвит, ниһаять, Әдиләнең тезенә кулын салып. Әдилә нигәдер кинәт сискәнеп куйды. — Күптәнге шундый сүз бар, Әдилә: көнләшү мәхәббәтне ныгыта, диләр.

— Юк инде, брат, ул мәхәббәтне ныгытмый, ә хәсрәтне арттыра, — дип, сүзгә кушылды моңа чаклы тын гына килгән Фәрит. — Беләсегез килсә, көнләшү кешене кимсетә, рәнҗетә, аның тормышка ышанычын югалта. Шундый нәтиҗәгә килдем мин үземнең кара акылым белән.

Җәвит шофер ягына хәтта күз дә ташламады, гүя ул аның сүзләрен ишетмәде дә, гүя алар машинада Әдилә белән икәүдән-икәү генә иделәр.

— Без бик әйбәт яшәрбез. Мин сине үз яныма эшкә алырмын. Әлеге эшеңне элек-электән үк яратмадым. Гомумән, мин сине бу эштә күрергә теләмим.

— Юк инде, Җәвит, мин өйрәнгән эшемне ташламамдыр. Мин аны яратам. Аннары, эшләп үлмиләр, чирләп үләләр, дигәне дә бар бит.

— Яраткан эшнең дә төрлесе була. Синең урыныңда булсам, мин гарьләнер идем. Ә син ничәмә елыңны терлек азыгы тикшереп сарыф иттең.

— Әнием, әнием, айлапут. Әнием, әнә шул самолетта очабызмы? Ул безне көтелде, әйе бит?

— Юк, кызым, без әтиеңне генә озата килдек...

Бу сүзләрнең тайгак бозга эләккән чана кебек телдән шуып төшкәнен Әдилә үзе дә абайламый калды. Әмма юл буе нәкъ шуны әйтергә җыенып, теле кычытып килүе хак иде.

Җәвит, берни аңламаган хәлдә, күзләрен шарландырып хатынына карап торды.

— Бу ни дигән сүз инде, Әдилә? Нинди бала-чага уены тагын?!.

— Гафу ит, Җәвит, мин калырга булдым. Бер-ике айдан кайтырмын әле. Эшләремне дә әйбәтләп тапшыра алмадым.

— Әдиләкәем, куй инде, ни сөйлисең син?!.

— Сумкаң менә монда, Җәвит,— дип, Әдилә аяк астыннан Җәвитнең шомарып беткән портфелен алып бирде. — Хәерле юл сиңа.

Җәвит аптырап калды, нидер көтеп, бер тын машинадан төшми торды. Фәрит тә, һич ни аңламыйча, бер Әдиләгә, бер аңа карап-карап алды. Чәчкә нигәдер әнисе янына күчәргә теләде. Фәрит баланы арткы утыргычка алып бирде. Чәчкә әтисе белән әнисе арасына килеп кысылды. Һәм Җәвиткә ятсынып күз салып алды да әнисенә табарак елыша төште.

— Бар, Җәвит, мин үзем кайтырмын...

Җәвит машинадан чыкты, әмма ишекне япмый торды, нидер көтте.

Фәрит сүндергән моторын кабызды. Җәвит шофер ягына күзләрен алаландырып карап алды да, шапылдатып ишекне япты һәм кырт борылып аэропорт бинасына таба китеп барды.

## 49

Харисовка да картлык килде. Күзлекнең дүртлесен кия, кайчак ул да күрсәтми башлый, китап юллары пәрәвезгә әверелеп китә. Кичә Зариф Бакировны партиягә алдылар. Колхозда коммунистлар саны елданел арта бара. Куанычлы хәл бу. Соңгы елларда партия сафына тагын да сәләтле, югары белемле яшьләр килә. Алар белән эшләү үзе бер бәхет тә бит...

«Үз урыныма Равилне тәкъдим итәрмен, быелдан да кала алмамдыр», дип, кабинетында уйланып утырды Харисов.

Сейф өстендә келт-келт итеп сәгать йөри. Бик күптәнге сәгать инде ул. Мәрхүм Шакирҗан бүләк иткән иде. Унҗиде еллап гомер үтте бугай

инде. Шуннан бирле сәгать йөри дә йөри. Һәм һаман сейф өстендә. Харисов сәгатькә кагылган саен Шакирҗанны исенә төшерә. Уфаларда йөреп кайткач, Шакирҗан Карамалыга килде. Подполковник Солодовников Карамалыга җибәргән отрядның офицеры авылда үлеп кала. «Алтын эшелон»нан бер пот алтын эзләре дә бирегә китерә. Сейфта офицерның кесәсеннән табылган рәсми кәгазь ята. Колчакның уң кулы булган подполковникның кадерле офицерларыннан берсе Карамалыда һәлак була. Һәм кем үтерә диген — Рәхим бай кызы Таҗылбанат. Имеш, яшь хатынны көчләргә теләгән...

Харисов кайтырга җыенды, ләкин коридорга чыккач, Талип ягында сөйләшү ишетеп, председатель янына кереп чыгарга булды. Керүгә, ишек төбендә таптанып торуының сәбәбе шул булды: диванда Гайзулла утыра, Талип аның каршысына баскан да кычкырып-кычкырып нидер сөйли иде. Харисовны күргәч, ул аңа түргә узарга дип ишарә ясады.

— Сиңа килми, кемгә килим соң инде, балакай?..

— Картайган көнегездә кеше көлдермәгез инде, җизни. Җитмештән узган картлар тату яши алмыйлар! — Талип кулларын җәеп җибәрде. — Түткәй янына кайтмыйм дисең икән, әйда, кунак өендә торып кара.

Гайзулла Харисовны әллә күрә, әллә күрми иде, аның өчен гүя юк иде ул, партком секретаре ягына, ичмасам, күз дә төшермәде.

— Миндәй каһәрләнгән кеше юктыр инде бу дөньяда...

Гайзулла торды да, галошын лаштор-лоштыр өстерәп, ишеккә юнәлде. Талип плащына үрелде, кепкасын киде, Харисов аңа:

— Иртәгә райүзәккә барабыз, Хөснетдинов дәшә, — диде.

— Мин аңа шалтыраттым инде, Әдһәм абый, үз урыныма Бәдретдиновны җибәрергә булдым. Иртәгә монтажчылар кормацехны җибәреп карарга телиләр.

— Ярый Бәдретдинов барса да...

Ишектән чыккач, алар икесе ике якка атлады.

Талип Гайзулланы куып җитте дә:

— Берәр атна кунак йортында торып торырсың, аннары күз күрер. Ул арада акчаң да килеп җитәр. Мин белештем инде, бүген-иртәгә булыр, — диде.

— Әнә ул бәндә генә бозды сине, денсез нәстә! Хөкүмәт авызына илтеп ташламаган булсаң, балаларыңның балаларына җитәсе иде ул хәзинә.

— Сихерләгән икән тәмам шул алтын үзеңне, җизни.

— Алтын,— диде Гайзулла кисәк туктап һәм аның йөз-кыяфәтенә бөтенләй ят булган сурәт кунды. — Ул алтын өчен мин башым сала яздым. Дәүләт казнасының бугазы киң аның, ни ташласаң — шуны йота тора. Акча бирәчәкләр, имеш. Бирерләр, биргәннәр ди әнә. Дүрттән бер өлешен түгел, чирегенең чиреген бирсәләр дә, Әдһәмең йокыдан калыр, чиргә сабышыр...

— Акча бирүләре хак. Документлары килде инде. Телисең икән — Мәккәгә кит, телисең икән — Америкага. Бу мәсьәләдә Совет дәүләте гаделләрнең гаделе.

— Берәүгә гадел, икенче берәүләргә кабер казый.

— Капиталистларгамы? Әйе, аларга казый һәм бик дөрес эшли. Карале, җизни, — дип, кинәт кузгалып китте Талип, үзе белән Гайзулланы да ияртеп, — сөйлә әле шул чорда Карамалыда булган мажараларны, әй, җизни? Шулай ук Карамалыга килгән офицерны түткәй үтерде микәнни? Нигәдер ышанасы килми.

Гайзулла, барган җирдән туктап, сары яры сарган күзләрен челтчелт йомгалап торды.

— Әюп турында да беләсең киләме? Ул да сиңа хаҗәтме?

— Хаҗәтме дип, җизни, тарих хәлләре ич, кызыксынам.

— Тарих... Ул елларда, — дип атлап китте, үзалдына сөйләнгән-

дәй, — кем-кем яклы булуына төшенерлек идеме? Кара аны, җизнәңә тозак салырга йөрсәң, миңге бәхиллегем юк.

— Куйчы, җизни, шикләнүеңне, шул чордагы хәлләр кызыксындыра мине. Хәсән абзыйны кем үтерде икән?

— Әюп алтатардан аткан дип сөйләделәр.

— Никадәр сер синдә җизни!

— Сер түгел, балакай, газиз баштан үткән хәлләр,— диде Гайзулла һәм эчен тотты да, туктап, бермәлгә йөзен чытып торды. — Сер саклардык гомерем калмады бугай инде...

— Әюп Латыйповның да гәүдәсен тапмыйлар. Уфадан килгән казаклар Карамалының өч кешесен атып китәләр. Икесенең гәүдәсен табып күмәләр, ә менә Әюпнеке табылмый...

— Кем белә инде аны, балакай. Ул елларда кеше эттән дә кадерсез иде, кая булса ташлап киткәннәрдер дә киек-җәнлек ашагандыр. Саз-суга ташлап киткәннәр дип тә сөйләнә халык...

Авыр иде Гайзуллага бу турыда сөйләү. Ул хәтта эч авыртуын да онытып торды. Талипка аның барысын да сөйләп бирәсе дә килә, шуның янына Әдһәм Харисовка җиткерер дип тә курка иде. Карт көнендә, бер аягы гүрдә торганда, яңадан прокурор каршына барасы килми иде аның. Ә Гайзулла белә: Әюпнең гәүдәсе кая ташлануын белүгә, аны эзләргә керешәчәкләр. Шунда инде аның үзенә үк җавап бирергә туры киләчәк.

Кунак йортында Талип җизнәсе белән бик озак сөйләшеп утырды. Йорт караучы Хәтимәгә картны ашатып-эчереп торырга, барлык чыгымны председатель исәбенә язарга кушты. Талип китәргә дип кузгала башлагач, Гайзулла аның кулларына ябышты, ялварулы нурсыз күзләре белән аңа текәлде.

— Талибулла, аллаһе тәгалә үзе шаһит, Әюпне үтерүче мин түгел. Карт көнемдә мәсхәрә иттермә. Кеше ни сөйләмәс, дошман сүзенә ышанма...

Икенче көнне кич белән Гайзуллага, ничәмә-ничә документка кул куйдырып, ун меңгә якын акча биреп киттеләр. Кулына шул хәтле мал кергәч, бермәл үз күзләренә үзе ышанмыйча торды. Аннары ул; барысы да киткәч, бүлмәсенә бикләнде дә калтыранган куллары белән шуның сумын-сумга санап чыкты. Бу шатлыкны Таҗылбанаты белән уртаклашасы килде, ләкин тышта караңгы иде инде, икенче көнне көтәргә булды.

Тик икенче көнне өйгә кайтырга туры килмәде. Коточкыч яман хәбәр ишетеп хәле начарланды һәм аны... больницага алып киттеләр.

Ә ул болай булды.

Алар тирәсендә бала-чага уйнамый иде, юк-бар йомыш белән күрше-күлән дә бик борчымый иде үзләрен. Сәламәтлекләре начарлангач, моның өстенә буза-низаг та ишетелгәләп торгач, халык та бик ашка дәшми башлады мулла белән абыстайны. Дөрес, дини бәйрәмнәр життеме, алар ишегалдыннан кеше өзелми, кайсы ашка чакыра, кайсы корьән чыгарга, кайсы баласын өшкертергә дәшә. Бүген гадәти көн иде. Икенче көн инде абыстайлар ишегалдында кеше-мазар күренмәгәч, күршеләре Хәмдия: «Ни булды икән бу картларга?» дип кереп чыгарга булды.

— Таҗылбанаттәй, абыстай! — дип эндәште ул өй тәрәзәсе аша гына. Әмма пәрдәләре корган өй ягыннан бернинди дә тавыш килмәгәч, бусаганы атлап алгы өйгә үтте һәм тагын эндәште.

— Таҗылбанаттәй дим!..

«И-и ходаем, әллә үлделәрме соң, нигә болай тавыш-тыннары юк»,— дия-дия, эчке өйгә узса — исе-акылы китеп баскан җирендә катып калды. Түшәмдәге бала бишеге тага торган боҗрага кер бавы ташлап, абыстай асылынган иде. Аяк очындагы урындык ауган, как-

чанланып беткән ялан аягы күгәреп каткан иде. Шыксыз йөзе ишек ягына карап чалшайган, телен аркылы тешләгән, күзләре кот алгыч булып акайган иде.

Моны күреп, күрше хатыны аһ! итте дә, бер тын исен җуеп, һушына килә алмый торды, аннары гына, иңке-тиңке килеп, өйдән чыгып йөгерде...



## 50

Авыл советы председателе Фәхри Басыйров Тажылбанат гәүдәсен Рәхим бай янәшәсенә күмәргә кушты. Ә больницадагы Гайзулла күзләрен акайтып торудан гайре берни белмәде, һичкемне танымады, ни сорасалар да җавап бирмәде. Уколлар ясагач һәм дару эчкәч кенә ул йокыга китте.

— Хәле авыр картның, — диде райүзәктән килеп эшләп торган врач җизнәсенең хәлен белергә кергән Талипка. — Күп яшәмәс.

Гайзулла тик икенче көнне генә уянды. Уяну белән күкрәк тирәсен капшаштырды һәм, эзләгән әйберен тапмагач, күзләрен шарландырып, терсәгенә таянып күтәрелә башлады. Аңа күз-колак булып торучы санитарка картның бу кыяфәтеннән курка калды.

— Акчам кая? Акчам кайда?!.

— Сезгә борчылырга ярамый, тыныч кына ятыгыз, — дип, няня Гайзулланы тынычландырырга теләде.

— Акчамны бирегез!..

Гайзулланың әйтерсең тамагы чатнап китте. Аның бу җикерүенә тәмам шүрли калган няня врачны чакырды.

— Ни бар, ни булды?

— Ниндидер акча сорый.

— Киемнәрен карагыз, кесәләрен. Нәрсәсе бар, шуны китерегез,— дип боерды врач.

Минут эчендә няня әйләнеп тә керде. Аның кулында керләнеп беткән кулъяулыкка төргән нәрсә иде.

Гайзулла төргәкне кулына алды да, башыннан ук капланып, юрганын ябынып ятты.

Көн урталарында аңа аш китерделәр. Ләкин ул ашка кагылмады да. Кичкә чаклы күзен йомып тын гына ятты. Алай да кичке ашны ярты савыт булса да капкалады.

— Ашагыз, аша, тамагыгызга үтсә ашый гына күрегез, — диде аңа няня — Әйберләрегез өчен борчылмагыз. Бирелә берни дә югалмый.

Гайзулла аңа өнәми генә карап алды да аштан соң амин тотып урынына ятты.

Икенче көнне иртән ул палатада бераз йөренде дә, хәле бик тиз бетсә дә, тәрәзәдән тышка карап торды. Һавада көтү-көтү сыерчыклар оча — җылы якка китәргә канатларын нығыталар. Ә аның әнә ике канаты тиң сынды. Кадерле хатыны Тажылбанаты да гүр иясе инде. Аның фаҗигале үлеме Гайзулланың күз алдыннан бер генә минутка да китми. Бү үлемдә ул үзенең дә гаебе барлыгын сизә, шуның өчен сызып кына эчтән кайгыра иде. Үз гомерләренә мал бүлделәр, тату яшәмәгән чаклары да булды, ә менә үлгәч, Тажылбанаты аңа аерата якынаеп китте. Ник тыңламады ул аны, ник тыңламады икән!..

Гайзулланың башы әйләнеп китте. Ул ике куллап тәрәзә төбенә ябышты. Хәле торган саен мөшкелләнә башлап, ул башының бер яккa түнеп китүен тоеп, аваз салды.

— А-а-а, с-е-с-тра!..

Аяк астында гүя идән убылды, ул аңкы-миңке килеп як-якка чайкалып торды да чалкан авып китте — гөрселдәп идәнгә егылды. Па-

латага сестра, няня керделәр, ачык калган ишеккә коридорда йөргән авырулар килеп өелде. Врач килде. Алар сестра белән күзгә-күз карашып алдылар.

— Строфантин яса, тиз бул! Кордиамин бирегез! Кислород!..

Гайзулла исә сәгатьтән соң гына аңына килде. Ул үзе тирәсендәге сестра Алиягә, няняга күз төшереп алды да:

— Балалар, мулла чакырыгыз. Газраил пәйгамбәр янымда тора, Мөхәммәтҗанны чакырыгыз, ясин чыксын, — диде.

— Бабакай, больницада ясин чыкмыйлар, катгый тыела,— диде аңа сестра Алия. Няня аның сүзен куәтләп ияк какты.

— Алайса, мине өемә илтеп куегыз. Илтмәсәгез үзем китәм, — дип, Гайзулла күтәрелә башлады, ләкин шунда ук кире мендәренә ауды.

Район үзәк больницасы белән телефоннан сөйләшергә чыгып торган врач әйләнеп керде.

— Менә теле дә ачылды, ә сез курыккан идегез, — диде ул сестра белән няняга. — Бабаебыз яшәячәк әле, шулаймы? — дип, Гайзулланың өстенә иелде врач.

— Мине өемә илтегез! — дип кабатлады Гайзулла.

— Өегезгә?

— Бабаебыз мулла чакырырга куша, Нәҗип абый.

— Мулла? Нинди мулла? Нигә ул безгә?

— Диагнозы билгеле. Өенә генә илтик тә, Нәҗип абый, мин барып-барып укол салырмын, Фәрханә апа саклап, күз-колак булып торыр.

— Ярый, уйлашырбыз. Әлегә бабай ял итсен, — диде врач. — Бүгенгә биредә кунар.

*

* *

Гайзулла төне буе күз йоммады. Әйе, гомер дигәнең узды да китте. Нигә ирешә, нәрсәгә омтылды ул? Юк, ихтыярсыз бу кеше бернигә дә ирешмәде. Тормыш елгасы кая акса, ул да шул елгага эләккән йомычкадай акты да акты.

Кояш чыкты. Гайзулла палатадагы әйберләрнең төсләре үзгәрә баруын күреп торды. Форточкага песнәк кунып бер-ике тапкыр чи-чи итте дә очып китте.

Палатага Алия кергәндә Гайзулла караватына торып утырган, авыз эченнән генә дога укына иде.

— Хәлегез аруландымы, бабай? Йокыгыз туйдымы? Бүген үзегезне өегезгә илтербез. Талип абый үзем килеп алырмын дигән.

— Мин машинага утырмыйм. Үз аягым белән кайтам. Ашыгасым калмады, барасы җиремә барып җиттем бугай инде, балам...

— Мин сезне җәяү җибәрмим, бабай. Ярамый.

— Җибәрерсең.

Гайзулла шулай диде дә киемнәрен таптыра башлады. Ашыкмый гына киенде, үзенә булышырга теләгән няняга ул:

— Мин патша түгел, ялагайланма, — диде.

Гайзулла няня ягына хәтта әйләнеп тә карамады. Янында ни кылырга белми аптырап торган сестрага ул:

— Рәхмәт, бала, кулларың сызлаусыз булсын. Әйбәт карадың, — диде.

— Бабай, мин сезне җибәрмим, моның өчен врач безне орышачак, — дип, Алия картның каршына чыгып басты.

Гайзулла аңа өстән генә күз ташлап алды да түш кесәсендәге әйберен капшаштырды һәм ишеккә юнәлде. Юк, ул Алияне әйләнеп узмады. Ә Алия үзе читкә тайпылды. Куркыныч иде картның күзләре.

— Орышмас, миңа инде духтыр кирәкми.

Гайзулла карт болдырдан акрын гына төште дә салмак-сабыр ат-

лап тыкрыкка таба узды. Менә шул тыкрыктан атка салып алып менде ул Әюп гәүдәсен. Гәүдәне аңа бабасы Ыкка ташларга кушты. Таң беленеп килә иде инде. Гайзулла ашыкты. Зур күл башына житкәч, авыл ягында атышлар купты. Гайзулла Әюп гәүдәсен күл башындагы сазга ташлады да кыл дилбегә белән урап-урап бәйләгән мәет шунда күмелгәнче карап торды. Аннары ул анда коры-сары сипте.

Бүген әллә нигә шул эз, шул вакытта үткән сукмак тартты аны. Белә иде ул: зур күл буена ниндидер ял йорты салалар, бораулаучылар казып киткәч, атып чыккан шифалы суны китермәкчеләрме шунда, канау казыйлар. Кайчандыр быкырдык саз булган күл башы катып киткән, өсте яргаланган балчыкка әверелгән. Тыкрыкны узгач, Гайзулланы аяклары шунда тартты. Килеп житәрәк нәкъ шул төбәктә бер төркем халык күрүгә, Гайзулла адымын тизләтә төште. Башында әллә нинди уйлар чуалды. Ни китерде шулай аны бирегә! Ник шулай ашкына ул? Бер алла үзе белә иде.

Килеп житкәч күрде: ял йортына шифалы су үткәрү өчен казылган канау тирәсен халык уратып алган. Гайзулла төркем арасына керә башлады. Аны танып, төркем икегә аерылды.

— Әй, егетләр, мулла абзыйга юл бирегез.

Гайзулла шаккатты: кеше сөякләре тапканнар... Сөяк өеме янында кыл дилбегә, дилбегә очына жиз бәжралар бәйләнгән... Кинәт башы әйләнеп китте картның.

— Безнең авыл кешесе булмагандыр бу, егетләр. Кем белми бу сазны...

— Әле кипкән булса да, элек якын килмәслек булган диләр бу тирәне, шулаймы, мулла абзый? — дип сорады берсе Гайзулладан.

— Сугыш елларында бер исерек чегән шунда батып үлгән дип сөйләгәннәр иде, шул чегән сөякләре бу, егетләр, бер дә бүтән түгел, — диде икенчесе, сөякләрне бер төшкәрәк өя төшеп.

Гайзулла дилбегә очындагы бәжраны кулына алды, әйләндереп-әйләндереп карады. Кинәт йөзе агарынып китте, кәжә сакалы калтырап тора башлады.

— Әллә синең дилбегәң идеме, мулла абзый, тәмам телсез калдың?

Гайзулла дәшмәде, бәжраны сөяк өеме өстенә әкрен генә куйды да, сирәк сакалына ябышып, бер тын торды. Аның яралы күз кабагы сикергәләп тартыша иде. Аннары ул һичкемгә күтәрелеп карамыйча:

— Мәрхүм Әюп сөякләре бу, кулыгыздан килсә, кадерләп күмегез,— диде дә авыл ягына китеп барды.

Минут үтүгә, халык бу сүзләрнең чын булуы турында сөйли башлады.

— Агай-эне, Карамалының беренче председателе булган Әюп Латыйпов сөякләре диде түгелме бу карт? Әле бездә эшләп яткан Гариф Латыйповның этисе. Хәтерегездәме, бер тапкыр клубта шул турыда сөйләгән иде. Балалар мәктәптә Латыйпов истәлегенә музей оештырып йөрделәр...

Бу хәбәр авылга бик тиз таралды. Кайсыдыр Гариф Әюповичны, аның әнисен чакырырга йөгерде. Беришеләре ышанмыйчарак:

— Ай-һай, егетләр, кеше көлкесенә калмасак ярый ла, — дип сөйләнделәр.

*

* *

Гайзулла бәрәңге бакчаларына көч-хәл белән кайтып житте. Бакчаның аргы башына, күл буен уратып, ул үзе читән үргән иде. Шунда ук колач житмәслек карт өянке үсеп утыра. Читән буена житүгә, Гайзулла ихатага түше белән капланды. Бераз хәл алып торды. Ләкин гәүдәсенә хәл кермәде. Бөтен тәне буйлап, сеңерләрен тартыштырып

авырту йөрде. Аяк буыннары бушады, һәм ул акрын гына читән буена шуып төште, сынын югалтудан кинәт чалкан әйләнеп китте. Күзләрен ачты, зәп-зәңгәр күккә карады. Читән буенда утырган өянкенең яфракларына сары төс кергән. Кайчандыр яшел кәүсәләрен кояшта ялтыратып, күл буена су коенырга төшкән кызлардай чәчләрен туздырып утырган өянке картайган, калынаеп, кантарланып беткән каерылары купшарган, тәне шәрәләнеп калган төшләре бар. Көньякка караган ботакларының кайберләре корыган, шүрәле кулларын хәтерләтеп, ходайдан мәрхәмәт сорыйлар кебек иде. Ниндидер могҗиза белән эленеп калган карга оясы гына быел язда да бу өянке тирәсендә тереклек кайнаганны искәрә әле.

Гайзулла куллары белән читәнгә үрелде, чыбыкларны сындырасындыра, тормакчы итте. Артык көч салдымы, эчендә ниндидер җылы тойды. Ләкин шундук күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китте.

Әллә соң әҗәл дигәннең килүе шулаймы?

Юк, тора алмады, кире сузылды. Укшып алды, күңеле айкалып китте. Көч-хәл белән күзләрен ачты. Җиһан киңлеге күз чагылырдай зәңгәр иде.

Нигә, ни өчен ходай тәгалә шулай җәзалый аны?!

— Сабира... Кәримул-ла!.. — дип кыймылдады аның кипшереп ярга-ланган иреннәре. — Кичерегез мине, ходай хакы өчен...

Ләкин аның бу тавышын ишетүче булмады. Тик читән буенда үскән кычыткан гына, табигатькә рәхмәт әйткәндәй, исеп-исеп куйган йомшак җилдә селкенеп-чайкалып китә һәм каны качкан Гайзулланың йөзенә тиеп-тиеп ала иде.

## 51

Көнозын сибәләп яуган яңгыр кичке якта басылды, күп тә үтми, төньяк тарафтан юнәлеш алган җил кар китерде. Күз бәйләнер алдыннан инде һавада тәңкә-тәңкә кар бөртекләре оча башлады...

Сәгать сигезләрдә идарә бушап калды. Галим Гариф Латыйпов эшләп калдырган картограмма, очерк-тәкъдимнәрне бүлмәсендә өйрәнеп утырган агроном Мидхәтне Талип үз янына чакырды.

Өстенә җиңелчә бәрхет пинжәк кигән, чәчләре туза төшкән Мидхәт кабинетка керде. Талип аңа түрдән урын күрсәтте.

— Ишеттегезме әле, Талип абый, Ләйсән кайткан. Кайта-кайтышлый ук Котдусларга кергән ди.

— Килделәр инде алар миңа. Өйләнешәләр. Равил комсомол туе үткәрик дип бара. Мин риза булдым. Бишенче ноябрьга билгеләдек. Син әнә клубта үткәрмәгән булдың, — диде Талип, Мидхәтне үртәгәндәй.

— Вакыты ул түгел иде. Мәхәббәт бит ул синнән-миннән сорап килми, Талип абый.

— Алай, — диде Талип көлемсерәп. — Сорап килми диген, ә?..

— Бер үзегезгә сезгә дә күңелсездер, Талип абый. Кәфия апа кайчан кайта инде?

Талип утырган җирендә борсаланып алды, өстәл тартмасыннан папка чыгарды да Мидхәт алдынарак этәреп куйды.

— Әйт әле, Мидхәт, урман полосаларын утыртканда агачлар арасына канау казу турында үзеңнең башың җиттеме, әллә булмаса галим абыең киңәш иттеме?

— Басуларда дым туплау чарасы буларак бу алым күптән билгеле инде. Ләкин полосаларны утыртканда канау казырга дигән фикерне Гариф Әюпович әйтте. Канауга көзге якта салам-тирес тутырып куясың, нинди коры килгән җәйләрдә дә бер генә үсенте дә чирләми, әйбәт китә...

Талип башын иеп, ияк кагып утырды, нигәдер көрсенеп алды, аннары, тураебрак, Мидхәтнең күзләренә карады. Председательнең шулай текәлеп каравыннан Мидхәт уңайсызлана калды.

— Латыйповның хезмәтен болай аңлатуың өчен сиңа рәхмәттән гайре сүзем юк. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә белеме саерак булган миндәй кешегә бик ярый ул. Тик, зинһар, син мине бу турыда белми дип уйлама. Азмы-күпме белә идем. Шулай да Латыйповның бу хезмәте мине уйга калдырды. Әллә, мәйтәм, бу өлкәгә кучәргә ашыга төштемме? Җир эшен үтә җиңел дип карауданмы килде бу уй...

— Бар җитәкченең дә авыл хуҗалыгы белгече булуы мәҗбүри түгел дип уйлыйм мин. Аннары сез әйбәт оештыручы...

Талип каш астыннан гына Мидхәткә карап торды.

— Маташтырма. Рас андый җитәкче икәнмен, син белгәнне мин дә белергә тиеш. Шулай булмаганда, — Талип кисәк кенә урыныннан купты, ишекле-түрле йөреп китте, — нинди председатель мин?.. Хәер, килер бер заман — колхоз урынына госхоз булыр. Инде ул чакта председатель булып фән кандидатлары, галимнәр эшләр.

— Бик алай фәлсәфәгә бирелмәгез әле, Талип абый. Җитәкче булуның үз хикмәтләре бар, минемчә.

— Куй, уйланырлык бар минем җебекләргә. Биредә калсам, халык ышанып тапшырган бурычны җиренә җиткереп башкара алырмынмы? — Талип көзге кебек ялтырап торган өстәлгә таянды да бераз сүзсез торды. — Иртәгә Әдһәм абый урынына башка берәүне сайларбыз. Кем килер? Белеп торам, ул да авыл хуҗалыгы белгече булыр. Һәрхәлдә, минем кебек юрист түгел. Равил турында әйтәм. Егет читтән торып авыл хуҗалыгы институтында укый. Әдһәм абый белән эшләп була иде әле. Тупасрак булса да, мине аңлый иде ул.

Телефон шалтырады, Талип трубканы алды.

— Әйе, исәнме, Әдилә! Гатадан сорадыңмы соң?.. Ул риза икән, миндә эш тормас. Укуны дәвам иттерергә исәбегез инде алай булгач? Зариф укыгач, нигә миңа гына калырга дисезме?! Хак әйтәсез. Бергәләп барыгыз. Ул — энә, син — җеп...

Талип телефон трубкасын куйды да, аппараттан кулын алмыйча, Мидхәткә карап торды.

— Менә хәлләр, Мидхәт. Зариф Бакиров иртәгә Казан авыл хуҗалыгы институтына читтән торып укырга керергә китә, бусының да каласы килми. Лабораториядә кем калыр икән соң? Боларын да җибәрмичә булмастыр бит? Ничек уйлыйсың, кырчылык хуҗасы?..

## 52

Хөснетдинов Карамалыга өлкәдән кунаклар көткәндә килеп төште. Талип аны баскычка чыгып каршы алды.

— Бар нәрсәң дә әзерме инде?

— Нәрсәгә әзерләнергә тиеш соң без, Ирек Нәҗмиевич?

— Нәрсәгә! Корнеев абзаң нигә килә дип беләсең бирегә?

— Үзе фатиха биргән комплексны күрергәдер...

Хөснетдинов дәшмәде, Талип кабинетына кереп өстен салды, түргә узып диванга утырды, аягын аяк өстенә куйды.

— Комплексны тәмамладың, ә абзарларыңда нибарысы ике йөз илле баш савым сыер, — диде Хөснетдинов һәм, кучеп, өстәле янына килеп утырды. — Комплекс ничә баш терлеккә исәпләнгән?

— Биш йөзгә.

— Менә, күрәсең. Димәк, сезгә кимендә ике йөз баш савым сыер кирәк. Каян алырга исәбегез?

— Җан биргәнгә җүн бирер әле.

— Бу хәлгә карата безнең кайбер киңәш-сабаклар бар, — диде дә Хөснетдинов тәрәзә янына китте. — Өлкәдән шул уңай белән килэләр.
— Рәхим итсеннәр, чәй-бал бар.
— Чәй-бал, — диде Хөснетдинов чал чәчен сыпырып.
— Кунак йортына барып килик булмаса, Ирек Нәҗмиевич?
— Өлгерербез. Нәрсә, үзеңә чакырырга рәтең дә калмадымы? Кәфиян кайчан кайта инде?
Талип, ни әйтергә белмичә, галстугын бушаткандай итте.
— Җитәдер кебек, Талип. Ике якның берсен сайла. Я — ул, я — Кәфия. Башка берәү турында сүз барса, мин бу мәсьәләне икенче төрлерәк итеп куяр идем. Синең белән бу хакта соңгы тапкыр сөйләшүем дип уйла. — Хөснетдинов янә өстәл янына килеп утырды. — Син беләсеңме соң әле: минем урыныма кеше эзлиләр? Беләсеңме, юкмы?!
— Беренче тапкыр ишетүем.
— Миңа да килде ул картлык, Талип. Ашказаны борчый, бил ката, иртән тора алмый җәфаланам. Ничек уйлыйсың, үз урыныма мин кемне тәкъдим итәргә тиеш?
Талипның гаҗәпләнүдән күзләре түгәрәкләнде, як-якка башын боргалап, ул изүен бушата төште.
— Шул хакта миннән киңәш сорарга килдегезме, Ирек Нәҗмиевич? Хөснетдинов көрсенеп куйды, теше сызлаган кеше шикелле, яңагын тотты һәм ишекле-түрле йөренергә керешде. — Өлкәдә докладыңны укыганнар. Әйбәт киңәшләреңне ЦКга җиткерергә булганнар. Комплексыңнан бигрәк, өлкә кунакларын синең цехларың кызыксындыра. Өлкә кадәр өлкәгә җиткердек, инде йөзгә кызыллык китермәскә кирәктер. Шулаймы?!
— Бергәләп җавап тотарбыз, Ирек Нәҗмиевич. Сезнең белән киңәшмичә бернәрсә дә эшләмәдем мин «Берек»тә.
— Үзсүзле кешесең дә соң, Талип! Галәмәт үзсүзле кешесең! Бел аны: комплекс һәм цехлар мәсьәләсендә бөтен җаваплылык сиңа төшәчәк. Аерата цехлар мәсьәләсендә. Үзең башладың, инде җавабын да үзең тота бел. Авыл хуҗалыгын тулысы белән промышленность нигезенә көйләргә алынгансың икән, шулай дәвам ит, чигенмә. Яңа секретарең кем булачак?
— Бу сорауны «Үз урыныңа кемне тәкъдим итәсең?» дип, иптәш Харисовка бирсәгез иде, Ирек Нәҗмиевич.
— Кайда соң әле ул Харисов?
— Ял итә, «Васильево»га китте.
— Партком секретарен бер айга санаторийга җибәргән, безгә шул турыда әйтү дә юк. Ничек инде сине үзсүзле димәскә, Талип?
— Сәламәтлеге какшый башлады секретаребызның, картайды.
— Картайса, алыштырыгыз. Без беребез дә бу дөньяга мәңгегә килмәгән. — Хөснетдинов түше белән өстәлгә ята төште. — Алдан килүемнең хикмәте шунда, Талип. Пенсиягә китәр алдыннан гына башка бер уй төште әле. «Берек»тәге комплекска «Урал» колхозының да савым сыерларын күчерергә, ә «Берек»тә ит өчен үстерелә торган малларны «Урал»га күчерергә. Кыскасы, сөт һәм ит хәзерләүне эрелэндерергә, берләштерергә.
Талип, һич ни аңламыйча, урындыкка аркасы белән терәлә төште.
— Ә табышлар уртак, дифференциаллаштырыла, — дип дәвам итте Хөснетдинов. — Азык хәзерләү дә уртак, ит я сөт җитештерүгә карап специальләштерелә.
— Нигәдер бу миңа барып җитмәде әле, Ирек Нәҗмиевич. Минемчә, башта бу мәсьәләдә белгечләр белән киңәшергә кирәктер. Исәпләсеннәр, ЭВМга куеп карасыннар.

— Комплекс сала-сала, «Берек» дәүләткә бурычка керде, ә «Урал» колхозы моны бүген үк түли ала.
— Уйлап карарга кирәк булыр.
— Уйлап кара, уйлап кара. Ә хәзер, әйдә, чәй эчеп килик.

*
* *

Өлкә комитеты секретаре Корнеев «Берек»кә иртәнге сәгать уннарга килеп житте. Юл уңаенда ул Наратбашка кереп чыккан икән. Идарә тирәсендә гәпләшеп торучы бер төркем ир-ат, чаттан килеп чыккан дүрт жиңел машинаны күргәч, шул якка төбәлделәр.
— Нәчальство килә, җәмәгать, Талип галиҗәнабләренә тагын кесә капшарга туры килә инде.
— Кунак йортында иртәдән бирле пешеренәләр ди бит. Талипка ни, Кәфиясе укуда, белемен күтәрә диме...
— Күрегез әле, күр, Фәритнең «кәҗә тәкәсе» әйтерсең куалап килә тегеләрне!
— Талипны районга димләп йөрмиме бу Корнеев, агай-эне? Хөснетдинов бабагыз пенсиягә китә, имеш.
Ул арада машиналар идарә каршына килеп тә туктадылар. Иң алдагы зәңгәрсу төстәге «Волга»дан какча гәүдәле Корнеев төште, аңа район авыл хуҗалыгы идарәсенең начальнигы Куклина иярде.
— Биргән бу катынга хода гәүдәне! — дип сөйләнеп алдылар идарә каршындагы ир-атлар. — Кочам дисәң, колачларың җитмәс...
Кунаклар идарәгә кереп киткәч, Фәрит машинасын коймa буенда гайбәт сатып торган ирләр ягына туп-туры юнәлтте. Төркемгә житәржитмәс, шофер, юри булса кирәк, моторын яман үкертеп җибәрде. Ир-атның беришесе кар эченә кереп батты, икенчеләре коймага сыенды.
— Т-р-р, ләгънәт, кая болай тормозың юктай чабасың, күрмисең мәллә: кичә генә Таибәне төшергән Габбас дусның котын ала яздың, — дип сөйләнә-сөйләнә, Фәрит машинасыннан төште, һич ни булмагандай, тәмәке алырга дип кесәсенә тыгылуы булды, егетләрнең берсе шоферның арт чүмеченә китереп төртте. Фәрит аңа хәтта әйләнеп тә карамады, бүреген рәтли төште дә:
— Беләсең килсә, Габбас дускай, Чәчәганак тавыннан ук сагалап киләм мин аларны. Батмасыннар, юлдан язмасыннар дип.
— Әйт әле, Фәрит, Бикмуллинны районга димләп йөриләр, диләр, хакмы шул?
— Ә-ә, Габбас, синмени әле бу? Баш чүмечемә кем чиртте дип торам. Синең кул икән. Каты, парень, кулың, каты. Бер тапкыр Кәнзел белән сөйләшкәне өчен теге ташлап киткән катыныңны коймa аша күршеләр ягына аткансың дип сөйләгәннәр иде, хактыр, ахры, — диде Фәрит, артында басып торган Габбаска карамыйча гына.
— Тәкәрлек син, Фәрит-мөрит. Телеңә күп салышсаң, күтәрдем аттым сине дә мынау коймa аша, — дип, Габбас шоферның алдына чыгып басты.
— Берәүләр аттылар, икенчеләре сузылып яттылар ди әнә. Хәер, сиңа ышанма, Таибәңә килгән Наратбаш егетен эт итеп ярып җибәргәнсең дип сөйләделәр. Сиңа ирек бирсәң, ботарлап ташларга да күп алмассың...
Фәрит шулай диюгә, Габбас чынлап та аны эһ дигәнче баш өстенә күтәреп алды һәм чынлап та коймa аша идарә бакчасына ташлады.
Ап-ак карга баткан Фәрит коймa аша төшеп килгәндә, идарәдән кунаклар чыга башлады. Фәрит Габбаска йодрык селки-селки машина-

сына таба йөгергәндә, койма буендагы ир-ат, эчләрен тотып, һаман көлешәләр иде әле.

Машина кузгалып киткәч, Фәрит председательдән сорап куйды:

— Талип абый, сезне районга эшкә алалар, имеш, хакмы шул?

Талип шап иттереп тез башына сугып куйды.

— Мин соң шунда эшләр кешегә охшаганмы, Фәрит?

— Сезнең кебек кеше кая да эшли ала. Ирек Нәҗмиевич пенсиягә китә икән бит. Минемчә, ул урынга тик ике генә кандидатура бар: сез дә Куклина Миңниса апа.

Талип бүреген маңгаена төшерде, башын кашыштырды. Аннары шоферның иңбашына сугып куйды.

— Мин анда китәсе кеше түгел, Фәрит туган!

*

* *

— Иң мөһим булган урыннарны гына күрсәтегез, Талип Кәрамович, — диде Корнеев һәм артына әйләнеп карады, Куклинаны күтәп алды. — Ниса Хәйдәровна, сезнең исәпләүләргә караганда, бу комплекс ничә елда үз-үзен акларга тиеш?

— Алты-җиде елда. Тик моның өчен кимендә ярты еллык азык запасы булырга тиеш. «Берек»тә исә моңа материаль мөмкинлекләр, экономистлар теле белән әйтсәк, ныклы база юк әле.

— Киләсе елдан алып сорго гибриды чәчә башлыйбыз. Бу культура гектарына 70 центнер бөртек, 400 центнерга чаклы яшел азык бирә,— диде Талип.

— Ә ул сорго сез теләгән уңышны бирмәсә? — дип сорады Корнеев.

— Азык җитештерү юнәлешендә без нык эшлибез, запас булачак, — диде Талип һәм нигәдер Куклина ягына күз төшереп алды.

*

* *

Абзарларны карап чыккач, идарәгә кайттылар. Аннан кунаклар кичке алтыда гына чыктылар. Чәйләп алырга дип кайберәүләр гостиницага таба юнәлгәч тә әле дүрт кеше идарә алдында ярты сәгать чамасы сөйләшеп тордылар: Корнеев, Хөснетдинов, Бикмуллин, Садыйков. Сөйләшүнең җитди булганы шуннан күренә иде: Талип баскан урыныннан кинәт кузгалып китә дә җилләнеп әйләнеп килә, кулын болгый-болгый нидер аңлатырга тотына. Машина тәрәзәсеннән моны күреп торган Фәрит: «Әллә соң чынлап алалармы Талип абыйны Карамалыдан?» дип пошынып куя иде.

## 53

Кеше йөрәге — дәрья ул. Аның бер ритмда талгын гына тибрәнеп торган чаклары да була, шаулы дулкыннарын ярларына бәреп ярсый да ала. Кичә, ниһаять, «Урал»дан ике йөз баш савым сыер китерделәр. Шунда ук сыер савучылар арасында бәхәс купты: берәүләре, ике сменага күчик, дип баралар, икенчеләре, моңарчы өйрәнгәнчә эшлик, нинди сменалап эшләү инде ул, заводтамыни без, дип каршы төшкән булалар. Аерата өлкән савымчылар сменалап эшләүгә каршы. Бу өлкәдә бераз чиләнергә туры килер әле, күрәсең. Күп кенә сыерларның имчәкләре кыска, машина белән саварга мөмкин түгел. Машиналар холмогор, швед сыерлары кебек эре имчәкле токымнарга гына көйләп эшләнгән. Ә район авыл хуҗалыгы идарәсе сыер савуны тулысы белән маши-

нага кўчерергә куша. Талип сыер савучылар белән киңәште дә токымлы сыерларны машина белән саварга, ә үзебезнекеләрне кулга калдырырга булды. Шуннан соң эшләр бераз җайланды кебек. Ләкин Талип белә иде: бу беренче кыенлыклар гына, комплекс мәшәкатен кичерәселәре алда әле.

Кичә кич белән коммунистларның отчет-сайлау җыелышы булды. Харисов соңгы сүзне алгач «куандырды» Талипны. Торды да Бикмуллинны акылга утыртырга кереште. Имеш, Бикмуллин иптәш, сезгә соңгы сүзем шул: кешеләргә ышаныгыз, тормыш чана түгел, имеш, үзегез генә тарта алмассыз. Киңәшле эш таркалмас, имеш, киңәшеп эшләгез... Һәм башкалар, һәм башкалар. Киңәнде берәү китәр көнендә, куандырды ун елдан артык бергә эшләгән кешесен! Анысы бер хәл инде, җитмәсә, җыелыштан соң янына кереп утырды да... Талипка хат тоттырды.

— Кеше кадерен белү, — дип башлады Харисов, җыелыштагы тонын дәвам итеп, — Талип туган, семьядан башлана. Галимә апаң Казанга барып кайткан иде, Кәфиягә туктаган. Рәнҗегән сиңа Кәфияң, рәнҗегән. Әйттем мин сиңа, чуалма алай дидем. Тыңламадың. Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленер, диләр. Кәфияң дә синең шулай йөргәнеңне белгән икән шул әнә. — Харисов кисәк кенә кузгалды да Талип каршына килеп басты. — Янына кит. Гафу үтен, кичерүен сора...

Харисов шулай диюгә, бите-муены бүртеп чыккан Талип өске сәдәфен ычкындырып галстугын бушатты.

— Төпченүем, гаилә тормышына тыкшынуым өчен мин карт кешене гафу ит, инде гафу итә алмыйсың икән, соңгы тапкыр булса да түз, Талип... Каршы әйтмә, яңадан мондый хәлләр белән борчымам үзеңне, Тота да минем күңел кылларыма кагыла, тота да минем белән булыша дип рәнҗемә... Мин синең өчен аталарча кайгырып яшәдем... якын күрдем...

Харисов нидер көтте, ләкин Талипның бәгыре каткан чак иде. Вөҗданы сыкраудан нишләргә белмичә гаҗизләнеп калган иде ул.

— Инде эшегез зурга киткән икән, — диде Харисов, ишек тоткасына кулын салгач, — барма, йөрмә кеше көлдереп. Кәфияң горур хатын, баш иеп синең алдыңа кайтмаячак. Өйлән дә Миңнисаңа, яши бир!..

Бүлмәдәге һәммә нәрсәдән мунча ташыннан чыккандай эссе бөрки кебек иде. Талипның маңгаен бөрчек-бөрчек тир басты.

— Барырга ният итсәң, үз урыныңа Мидхәтне калдырырсың.

Талип дәшмәде. Харисов чыгып китте. Талип форточканы ачып җибәрде, кайнар битен салкын һавага куеп торды да, өстәл янына килеп, Кәфиянең хатын алды. Ашыгып конвертны ачты, дәфтәр битенә язган кыска гына хат килеп чыкты. Күзе хат юлларына төшү белән Талипның йөрәге ярсып тибә башлады.

«Талип! Кеше үз гомере буена, иртән кояшка борылган чәчкә кебек, реккә омтыла. Һәркемнең үз кояшы була. Әгәр син аны тапкансың икән, мин сиңа комачауларга теләмим. Үзең ничек уйлыйсың, шулай яшә. Мин Казанда калырга булдым... Кәфия».

Юк, утырган урындыгы аумады, гүя аяк астындагы идән убылды. Ул бер мәл хаттагы үтә таныш булган хәрефләрдән күзен ала алмый торды. Кәфия аның Миңниса белән мөнәсәбәтен белгән! Шул турыда яза һәм яңадан бергә торуларына ышанмый. Горур Талип гарьләнү тойды, хурланды. Ләкин аның иң гаҗәпләндергәне, аптыратканы шул булды: барысын белеп-күреп торса да, Кәфия соңгы көнгә кадәр сер бирмәде, сиздермәде. Әллә соң үзенең дә бүтән берәр якыны булдымы?

Талипның күз алдына больница бүлмәсе, бәрхет пинҗәген җилбәгәй җибәреп Кәфия янында утырган Гариф, өстәлдәге ул китергән, әле кыякларында чык тамчылары да кипмәгән чәчәкләр килә. Әллә улмы?..

Сөйләнү, уйлану — эш кылу түгел. Әмма шушындый уйларыннан соң Талип бераз җиңеләеп киткәндәй булды. Аның өчен бу гаять зур сынау иде. Күңелен әллә ниткән сагыш биләгән. Шул ук вакытта борчылу тоя, юксыну...

Талип сәгатенә күз төшереп алды. Ярты сәгатьтән клубта Котдус белән Ләйсәннең комсомол туйлары башлана. Ул анда яшьләргә матур тормыш теләп сүз әйтергә тиеш булачак. Үзе шулай яшәгәндә ни әйтә алыр ул аларга?..

Клуб тирәсендә яшьләр төркеме, гармун тавышы. Гармунчы дәртләнеп-дәртләнеп бию көйләре уйный. Кайчак Талипта шундый хис туа: гүя аңарда ике кеше яши: ул — ул да, ул да түгел. Фойега керү белән аны Равил каршы алды.

Күп тә үтми, кәләше белән Котдус килеп керделәр. Ләйсән җемелдәп торган укалы күлмәктән, ап-ак перчаткалардан. Әллә кемнәргә охшатып куйды Талип кызны. Егет тә чибәр иде: кара костюм, ак күлмәк, галстук. Шат, туктаусыз елмая.

Талип, яшьләргә карап, үзенең дә Кәфиягә өйләнүен исенә төшерде. Нинди яратты ул аны шул чакта! Күргән саен күрәсе, сөйгән саен сөясе килеп тора. Күзләренә кадәр убә-убә иде дә керфекләрен санарга керешә иде. Хәтерендә, уң күз кабагында йөз дә өч,ә сулында туксан тугыз бөртек санаган иде. Нәкъ менә шул туксан тугыздан күзләренә яшь килгәнче көлешкәннәр иде.

Туйны ул ачты. Оста сөйли алмаса да, кирәген әйтте бугай. Мәҗлес башланды, җыр-бию... Талип кына үзе дә аңлап бетермәгән хис кичерә. Күкрәк түрендә ниндидер таш утыра сыман. Эчеп карады, исермәде. Һәм, кәефем юк дип, яшьләрдән рөхсәт алып чыгып китте.

Көнчыгыштагы кара-кучкыл зәңгәрлеккә сизелер-сизелмәс кенә алсулык йөгергән. Салкынча җил исә. Аяк астында кичтән яуган кар шыгырдый. Озак та утырмадылар кебек, ярты төн җитеп тә килә икән.

Өйгә кайткач, Талип утны сүндерде дә диванга ауды һәм төнозын уйланып ятты. Менә аңа да дәһрилек җиле кагылды, менә ул да сынау кичерә.

Ауный-тәгәри ята-ята, йокысызлыктан башы катты. Таң беленербеленмәстә киенеп урамга чыга башлады. Бусагага җиткәч, аңа Миңлекамал әбисе дәште:

— Кәнзел кайткан, өй-каралтыларын сатып йөри, барып күр,— диде.

Талип «ярый» гына диде дә ишекне ачты. Аларның өйләрендә картаеп барган Миңлекамал әбисен карарга дип бер карчык та торганга, аның алдында бүтән сүз катмады.

Ул күңеле белән аулак урын эзләде. Шул ук вакытта Талип бүген үзенә һичкайда тынычлык килмәячәген дә белә иде. Тирә-юньне апакка киендергән кар да ямансу хис тулган күңеленә, ичмасам, аз гына булса да яктылык өстәмәде. Тыкрыкка борылды. Тыкрыкның уң ягында — зират. Биредә гадәти тынлык. Үлгәннәр сөйләшми. Алар турында истәлекләр генә кала. Коммунистлар каберлегендәге бер һәйкәл барысыннан да аерылып тора. Бу — Әюп Латыйповка куелган һәйкәл. Октябрь бәйрәме алдыннан Карамалы ярлылар комитетының беренче председателенә һәйкәл куйдылар, чәчәкләр салдылар.

Әйе, ирлек җирдә ятмый, илле еллар узгач та әйләнеп кайта, каһарман батырлыгы телдән-телгә күчеп, алар исеме ташка яиса китап битләренә язылa, легендага әверелә.

Теге вакытта Әюп Латыйповның сөякләре табылгач, шуны кызыл табутка салып, күмәргә бөтен авыл җыелды. Җилкә аша сөлге асып Әдһәм Харисов белән бергә Талип Бикмуллин да атлады. Кабер янында

Әюпнең хатыны Гөлзифа, улы Гариф, кызы белән Әдилә басып тордылар. Хәйран калырлык тәэсир кичерде Талип шунда. Гүя Әюп Латыйпов ике-өч көн элек кенә үлгән иде. Партком секретаре Харисов ярлылар комитеты председателенең гомер юлы, революция елларындагы көрәше, фаҗигале үлеме турында дулкынланып сөйләде... Усалланып киткән төньяк җиле аның чаларган чәчләрен туздырды. Шунда Талип бу картны да Латыйпов каберендәге һәйкәлгә охшатып куйган иде. Гомер үтә. Берәүләр әнә читән буенда катып үләләр... Икенче берәүләре ирек даулап, көрәш кырында корбан була. Әйе, изге көрәштә түккән кан җирдә ятмый.

Башта Талип идарәгә юнәлгән иде, килеп җитәрәк комплекска таба китеп барды. Иң әүвәл ул дежур диспетчер янына керде. Былтыр гына унны тәмамлап, фермага эшкә килгән егет тәмләп йоклый, йокы аралаш иреннәрен кыймылдатып ала, елмаеп куя иде. Башка вакытта булса эш урынында йоклап утырган өчен Талип егетне уятып кыздырыр иде, бүген исә ул бирегә гүя кермәде дә, ә икенче берәү кереп йөрде. Абзарларда исә ул күшәп яткан сыерларга карап торды. Ләкин монда да аңа тынычлык килмәде. Чыкты да ферма янынннан ук башланган урман полосасы буйлап кырга таба китте.

Инде яктыра башлады. Йөрәге аны каядыр әйди, каядыр алгысындыра иде. Буй урмандагы каен, чаган, тупыл агачларының ботаклары шәрәләнеп калган, очларында җил шаулый. Берара җир киткәч, култык астында чәнчү тоеп туктап торды Талип. Кая ашыга, кая ашкына шулай?..

Һавада җил туздыра башлаган кар исе. Чокыр-чакырларда, сызабуразналарда, тугайларда тырпаеп калган әрем-кура. Таз тау итәгендә бүрек-бүрек ак «чәчле» кылганнар. Әле каядыр йөгерәләр сыман, әле җитендәй йомшак, ефәктәй шома бүрекләрен, коңгырт чәчләрен нәфис иңбашларына сибеп җибәргән сылуларга охшап куялар. Кыр-басулар күгелҗем палас җәйгән шикеле полосалар белән бүлгәләнгән. Рә тавы куенына зәңгәрсу тасма булып әле туңып та өлгермәгән Ык елгасы сузылып яткан. Олы юлдан, ак диңгездә йөзгән корабларны хәтерләтеп, машиналар уза.

Төньяк җиле көчәя төште, Талипның пальто чабуларын йолыккалады. Бераздан ул борылды да авылга таба атлады. Ә икенче көнне Талип ун көнлек ял алды да, үз урынына Мидхәт Бәдретдиновны калдырып, Казанга китеп барды.

*Бетте.*

## Мостафа Ногман

# АЙБУЛАТ

*Борынгы бабаларыбыз яшәгән Идел буендагы Болгар дәүләтен рус елъязмачылары Великий Булгар дип атап йөрткәннәр.*

*Болгар дәүләте славян халыклары белән сәүдә элемтәсе алып барган. Елъязмаларның хәбәр итүенә караганда, Болгар осталары — ташъонарлар, рус җирләренә барып, төрле биналар төзүдә катнашканнар. Мәсәлән, 18 нче йөз мәшһүр рус тарихчысы В. Н. Татищев Юрьев каласындагы зур храмны Болгар осталары салып биргән дип язып калдыра.*

*Бу хәл болгарларның рус халкы белән якын мөнәсәбәттә булуын күрсәтә.*

*Болгар дәүләте көнчыгыш илләре белән дә бәйләнеш тоткан. Болгарга Хәрәзем, Сәмәрканд, Багдад шәһәрләреннән сәүдәгәрләр килеп торган. Болгар егетләре үзләре шул шәһәрләрнең мәдрәсәләренә барып укыганнар.*

*Болгарларның руслар белән булган дуслык мөнәсәбәте турындагы бер тарихи фактка нигезләнеп, мин «Айсолтан» дигән повесть язам. Аны мин Казанның 800 еллыгына багышларга ниятлим.*

*Әсәрнең баш герое Айбулат Идел-Ука елгалары буйлап Владимир шәһәренә сәфәргә китәр алдыннан, үзе укып чыккан мәдрәсәнең баш остазы Мирзагали алдына фатиха алырга дип килә.*

*Повестьның шигырь белән язылган өлешеннән кайбер өзекләр тәкъдим итәм.*

*АВТОР.*

### Айбулатның хушлашуы

Күңелеңдә күп сазың,
Булсын тагын күп язың,
Сабуллашып китмәгә
Килдем сиңа, остазым.

Күңелемне ак кылып,
Зиһенемне пакь кылып,
Гыйлем биргән остазым.

Билемдәге кылычымны
Ак сөт белән юарга,
Буямаска канга аны
Яу килмәсә Болгарга,
Син өйрәттең, остазым.

Өйрәтмәсәң син әгәр
Гыйльме хисап, һәндәсә[1],
Зур сарайлар салырга
Беләрме идек бер нәрсә?!

Өйрәтмәсәң син әгәр
Йолдыз гыйлемен безләргә,
Китәрме иде көймәләр
Диңгезләрдә йөзәргә?!

Билдә алмаз кылычым бар,
Ханиямнән йомышым бар,
Валдимердә[2] сәфәрдә
Хуш теләгең булсын яр.
Без барасы юлларга
Балкыш биргел, остазым,
Изгелекле фатыйха,
Алкыш, биргел, остазым!

## Остазның җавабы

Сәфәреңдә, Айбулат,
Илдән ерак булып та,
Болгар углан икәнең
Һичбер вакыт онытма!

Сәфәреңдә, угланым,
Дошман чыкса юлыңа,
Арка биреп явызга,
Куркакларча йолынма.

Сәфәреңдә, Айбулат,
Ят дин әһелен күргәндә,
Аның белән хуш килеп,
Якын сүзгә кергәндә,
Чит диннән дип ачма фал,
Кешелеген санга ал,
Һөнәрләрен — үрнәк кыл,
Йолаларын — хөрмәт кыл!

Хуш, угланым, хуш,
Алкышлыймын сәфәреңне.

Айбулат Болгар иле белән хушлаша. Идел буйлап көймәләр кәрваны бара. Көн кичкә авышкан. Айбулат табигать тынлыгы белән серләшеп бара.

Катлам-катлам кабарып,
Зәңгәр күккә таралып,
Калкып килә болытлар;
Көн күркенә уралып,
Алтын-көмеш нур алып
Балкып килә болытлар.

[1] Һәндәсә — геометрия.
[2] Валдимер — Владимир.

Кучмә-кучмә болытлар,
Кая болай тизлисез?
Күк тәңренең куенында
Нинди юллар эзлисез?
Ераккамы юлыгыз?
Исән-аман булыгыз!

Баеп килгән ут калкан,
Иңдең таулар артына,
Син, кичке җил, сарылып
Күк тәңре канатына,
Сулыш бөркеп бер уздың,
Йолдызларны кабыздың.

Әй, кичке җил, кичке җил,
Ис син безнең уңайга,
Зәңгәр борма тугайга,
Ишкәкчеләр кинәнеп,
Хәл җыярга туктасын,
Татлы-татлы йокласын.
Юкса, алар кичен дә,
Тизрәк җитү өченгә,
Бертуктамый ишәләр,
Дулкыннарны кичәләр.

Идел өстендә ишкәкче колларның моңлы җыр тавышлары тарала.

## Ишкәкче коллар җыры

Ишкәгең күтәр,
Аркага үткәр,
Каерып ал тагын
Дулкын катламын.
Көймәбез аксын,
Алга юл тапсын,
Тиз барып җитеп
Әйләнеп кайтсын.

Чылбырлы куллар
Суела ишкәктә,
Исмең кол булгач,
Булмый нишләп тә,
Дулкыннар белән
Көрәшү һаман...
Һай, безнең язмыш
Каһәрле, яман!

Айбулат тагын тирән уйга талып, уйлары аша Болгар иле белән серләшүен дәвам итә:

Хуш, Болгарым — илем син,
Күз нурымдай җирем син;
Чылтырап аккан чишмәңнән
Сирпеп сулар алганмын,
Таңнарыңа сокланып,
Яшьтән хәйран калганмын.

Ил-йортларың төзләнгән,
Сылу кыздай бизәнгән,
Дошман күзен кыздырып,
Яу ачтырган Болгарым.

Алып-алып улларың
Ук-җәяле кулларын
Әйләндереп дошманга
Шау качырган Болгарым.

Зәңгәр нурлар уйнаган
Өйләрең дә күп синең,
Җырлап күңелем туймаган
Көйләрең дә күп синең.
Урман-тавың күп синең,
Дошман-явың күп синең.

Борма-борма юлларың,
Тирән-тирән күлләрең,
Җем-җем иткән йолдызлы
Зәңгәр-зәңгәр төннәрең.

Яшьләрең дә күп синең,
Картларың да күп синең,
Күкрәгеңне яу изгән
Тапларың да күп синең.

Үксез калып иңери
Сабый-сабый улларың,
Йортсыз калып ким йөри
Исәбе юк толларың.

Болгар дигән илем син,
Күз нурымдай җирем син.

Сиңа яулар кергәндә,
Кылычым булды эргәмдә;
Йөрәкләрем калтырап,
Нишләргә дип аптырап,
Тау артында калмадым.

Яуга каршы яу булдым,
Дошман үтмәс тау булдым.
Тугай күрке тал булыр,
Тулпар күрке ял булыр,
Ир-егетнең тау күрке
Яуда тапкан дан булыр.
Хуш, бәхил бул, Болгарым,
Ерак барыр юлларым...

## Зиннур Мансуров

### Ипи

Әнкәй сөтеннән аерган:
«Бу бала,— дип,—
Ипи каба башлады...»
. . . . . . . . . . .
Әткәй иңемә таянган:
«Бу бала,— дип,—
Ипи таба башлады!»

●

Чаң какмагыз каланчада —
җирне ялмап
мәк басуы яна.
Чаң какмагыз каланчада —
хәвеф түгел,
шәфәкъ яна.
Чаң какмагыз каланчада —
анда
мәңгелек ут
яна...

●

Үлем лагере — Освенцим
каршысында каен үсә...

Ап-ак шаһит калдырган бит тиран,
Крематорийга да якмаган;
Җәлилчеләр арасына кертеп
Асмаган да сине, атмаган...
Ап-ак тәнең янып торгангамы,
Бигрәк кара монда вәхшилек.
Үлгәннәрнең җан-вөҗданы кебек,
Син һаман да әле ак килеш.

### Диңгез буендагы кыз җыры

Кочагыңа тартып алмак булып
давылланган чагың исемдә...
Тезләремне кочып үптең бүген —
үзгәрәсең бер көн эчендә.

Аягыма егыласың, диңгез,
мин бит бары зәңгәр хыялчы.
Мәңге синең давылыңны сөйгән
акчарлактан бераз оялчы...

●

Карабодай басулары — ак болыт.
Болан аунаган җир ята тап булып.

Ак күлмәкле кыздай уйный пакь җиле;
Кочагымнан чыгып кача — ах, тиле!..

Ак кырларның аклыкларын күз ала.
Ак кырларда йөгереп кал, кыз бала...

●

Оя-оя кошлар китә
түбәләргә орынып.
Кош — ирләр күк, ярты юлдан
кире кайтмый борылып.

Каурый болыт кошкайлардан
калган кебек ябышып.
Баш өстендә ап-ак каурый —
илдән китү сагышы.

## Кышкы Идел

Акчарлагы давыл эзләп киткән.
Давылларда аның оясы.
Боз өстендә зәңгәрләнеп яна,
чәчрәп яна Идел кояшы.
Җил-яңгырда яргаланып беткән
көймәләре чылбыр-йозакта.
Үрсәләнеп язны көтә дулкын
зәңгәр боз астында, тозакта...

## Йөрәктәге исем

Асылда без һаман сагынабыз
мәхәббәтнең сабый мизгелен.
Ул алиһә булып җанда калган.
Җәрәхәте аның изгедер.

Хәләлемнән синең йөзне эзлим,
чәчләреннән — синең исеңне...
Алиһә кыз!
Хәләлләрдән яшереп, кызыбызга
без кушабыз синең исемне...

## Саҗидә Сөләйманова

# САГЫ БАРНЫҢ САГЫ ЯТАР

хикәя



Әкиятләрдә шулай була: үзенә ошамаган батырдан котылырга теләгән падиша тегеңә адәм көче җитмәгән эш бирә. Латәфәткә дә Мөдирә шундыйрак эш кушты, ахрысы.

Латәфәт моны башта бик гади итеп күз алдына китергән иде. Эш сәгате бетәр-бетмәс, Мөдирә бөтен хезмәткәрләрне кечкенә бүлмәсенә җыеп алды. Нәни генә кулының сырты белән өстәл читенә суга-суга сөйләде. Әле генә комсомолның шәһәр комитетыннан кайткан. Казаннан да кеше бар икән. «Хәзерге татар әдәбиятында эшче образы» дигән темага укучылар конференциясе үткәрүне Мөдирә китапханәсенә йөкләгәннәр.

Һәркемгә эш бүлеп бирделәр. Иң мөһиме — эчтәлекле чыгышлар. Латәфәт дүрт сөйләүче әзерләргә тиеш. Нефтьчеләрдән. Берсе гади эшче булсын, икенчесе эшче интеллигенциясе, өченчесе җитәкчеләрдән. «Ә дүртенчесе?» — дип сорады Латәфәт. Анысы саклыкка бирәрсе килми калу очрагына. Запассыз яшиме соң Мөдирә? Элекке конференциягә дә сөйләүчеләрне артыгы белән әзерләтеп, әллә ничә кешегә сүз бирми калдырды. Аның хәтта егете дә икәү, диләр.

Бик җиңел булмаса да, үтеп чыгарлык эш дип кабул иткән иде Латәфәт Мөдирәнең кушканнарын. Уку залында эшләүче Нәҗия Латәфәтне аралап та маташты, беренче елын гына башлаган тәҗрибәсез хезмәткәргә авыр булмасмы? диде. Мөдирә аны ишетмәмешкә үк салышты.

Чыгыш ясаучыларның өчесен Латәфәт күңеленнән шундук билгеләде. Гади эшчесе — көн аралаш китап алмаштыручы Назыйм. Узган ел унны бетереп вузга керә алмагач, монда бораулаучылар мәктәбенә укырга йөри, буровойда нәкъ «эшче» дип аталган урында эшли. Икенчесе — бораулау остасы, Алтын Йолдыз кавалеры, Латәфәтнең күршесе Әхмәт абый. Күренекле кешеләр булсын, ди бит Мөдирә, җыелышка язучыларны да чакырабыз, мәгънәле сүз ишетеп китсеннәр, ди. Өченче сөйләүче — РИТС начальнигы Якупов. Латәфәтнең туганнан туган абыйсы Хәйрулла белән төннәр буе эштән кайтмый

шахмат уйныйлар. «Югалган малны» юллап кайту еш кына сеңел өстенә төшә.

— Җиңги чакыра,— дип барып керә Латәфәт балта эләрлек төтен эченә. Симулянтларны фаш итүче кеше позасында пәйда булган сеңелесен күргәч, Хәйрулла үзенең дөньялыкта яшәвен исенә төшереп, сикереп тора. Ике кулын күн пальтосының кесәсенә тыккан кырыс кызыйның карашы Якуповны, киресенчә, урынына кадаклагандай итә.

— Канатым, шушы партияне генә...— ди ул ялварып. Оттыра да тагын тилмереп карый. Үзе бер откачы шулай. Конференциядә нотык сөйләүдән баш тартып карасын хәзер начальник абзый!

Эш Латәфәт дигәнчә башланды. Әлеге өчәү бик назландырып булса да ризалаштылар.

Иң авыры саклык нотыкчы булды. Хәлиткеч минутта шул коткарды да.

Китапханәче кыз укучы кенәгәләрен актарып чыкты, эшче сыйныфы турында әсәрләр күренгәнен аерып алды. «Сүнмәс утлар», «Гади кешеләр», «Хәзинә»... Талипов Заһит. Егерме алты яшендә. Югары белемле. Нефть участогы начальнигы. Укучының үзен кыз күз алдына китерә алмады, Латәфәт килгәнче укылган китаплар. Адресы бар, өенә кереп чыгарга кирәк.

Яулыгын артка кайтарып бәйләгән өлкән генә яшьтәге сөйкемле апа ишек ачты. Әби дисәң дә Латәфәт өчен таман гына булыр. Кыз сүз озайтып тормастан:

— Миңа Талипов иптәш кирәк иде,— диде.

— Минем үземә дә бик кирәк тә ул, юк бит әле менә...

Әбинең тавышы йомшак булса да, сүзләре каты ишетелде. Бу сүзләрдә азрак рәнҗү дә, бераз үгет-нәсихәт тә бар иде. «Сиңа кирәк икән, ә? Бүтәнгә кирәкми микән соң ул?»

Китапханәче, үзенең хатасын аңлап, югалып калды. Кирәкле кешене кайчан өйдә очратырга мөмкинлеген сорады да шым гына чыгып китте. Урамга чыккач үкенде: эш телефонын сорамаган, тагын киләсе була инде.

Икенче тапкыр килгәч, әбкәй Латәфәттән сорыйсы итте:

— Ни йомыш иде соң, кызым, бу көннәрдә улым бик соң кайта.

Кыз йомышын әйтте. Китапханә турында сүз чыккач, әбкәй бөтенләй ачылды, кыстап-кыстап кызны кунак бүлмәсенә уздырды, улым кайтып җитмәсме дип өметләндерде. Латәфәт китап шүрлекләрен күзе белән сөзеп чыкты, өстәлдә яткан ачык китапны кулына алды. Ни укый икән иптәш нефтьче? Сүзне нәкъ шушы китаптан башлап булмасмы? Китапның тышын карауга Латәфәт гаҗәпләнү катыш күңел кайту хисе кичерде. Боккаччо. «Декамерон». Сөйләш моннан соң хәзерге татар әдәбияты турында! Ундүртенче гасыр кавалерлары һәм дамаларының кәеф-сафа өчен сөйләгән әкиятләре... Ә менә тагын бер китап. Гомер. «Одиссейның күргәннәре». Бүгенге эшче образыннан ничаклы ерак...

Кыз китаплар актарган арада әби кухня ягына барып килде.

— Әйдә, кызым, чәйләп алыйк, чишмә суыннан кайнаттым.

Чишмә суын Заһиты Миңлебай ягыннан бакка тутырып алып кайта икән. Аналы-уллы икәүдән-икәү генә яшиләр. Өлкән уллары өйләнгән, үз тормышы. Иң өлкәне чик буенда хезмәт итеп, сугышның башында ук һәлак булган. Яудан яраланып кайткан әтиләре ята-тора ике ел яшәгән дә дөнья куйган. Чәй янында сөйләшенгән сүзләрдән бу гаилә хакында Латәфәт шуларны белде. Заһитның эштән соң кайда тоткарлануы хакында сорашмады, кыенсынды. Егет кеше кайда йөрмәс. Чәй эчкәч, кыз китмәкче иде, Хәтимә түти аз гына сабыр итәргә кушты, шушы сәгатьләрдә Заһиты кайта икән. Кунакның күңелен

күрергәме, үзенең юксынуын басаргамы, хуҗа түти өстәл тартмасыннан тышы кыршылып беткән калын дәфтәр чыгарды. Дәфтәрнең эчке ягында — хәрби киемле егетнең саргая башлаган фото-рәсеме. Очарга талпынган кош канатыдай кара кашлар. Бу кашларга болыт-чәч сорала, анысы кара козыреклы фуражка астына яшеренгән. Карашында ниндидер моңсулык... Дәфтәр тулы шигырьләр. Чик сакчысының язмалары.

Ил сакчылары без,
Уяу һәр мизгел.
Уяу һәр күзәнәк,
Һәр үлән сизгер.

Латәфәт рәттән берничә шигырь укыды. Ул еллардагы пафос. Үз көченә, ил көченә чиксез ышану. Шуның белән горурлану. Шигырьләрнең авторы — Хәтимә түтинең үги баласы икән. Ана кешенең шуңа да үзәге өзелә: үги булган өчен яудан кайтмагандыр төсле, үзенекеләр исәннәр бит...

Заһит һаман юк. Хуҗаның күңеле булсын өчен генә диярлек, Латәфәт шигырь дәфтәре актара. Берише җете төсләр арасында кинәт күзгә ягымлы нәфис бизәк чагылып киткәндәй була. Менә ул бизәк, кемнеңдер иңеннән очкан ефәк яулыктай йомшак җилдә җилфердәп, күңел дулкыннарында йөзә башлый.

Мин бит синең йомшак чәчләреңне
Сыйпый алмый киттем, матурым.
Төсмерләми, сер сөйләми киттем,
Мине көтәр булсаң, кайтырмын.
Кайтырмын да, ничек танырмын соң,
Сөйгән төсең алмы, зәңгәрме?..

Түр башында, йомшак палас өстендә озын-озаклап утыруыннан Латәфәт уңайсызланып, хәтта куркып куйды. Ишектән шушы шигырь юлларын язган егет кайтып керер төсле тоелды. Заһит белән очрашуга да әзер түгеллеген сизде Латәфәт.

Урыныннан кыз кинәтрәк кузгалды бугай, әбкәй гаепле кеше сыман әйтте:

— Рәнҗеп китмә инде, кызым, кабат кил...

Кыз, әлбәттә, үзенең халәтен аңлатып тормады, саубуллашып чыгып китте. Ишек янында гына телефоннары бар икән, теге юлы ничек искә алынмаган, номерын белеп, бәлки шалтыратыр. Әрсезләнеп кат-кат йөрүе өчен Латәфәт үзен битәрләп тә алды. Өстәвенә, ике туганны бер шәхескә күреп, кемнәрдәндер көнли иде бугай ул. Ә теге нәфис бизәкле ефәк яулык шәрә тирәкләр арасыннан күңелне алгысытып һаман очып бара:

Кайтырмын да, ничек танырмын соң,
Сөйгән төсең алмы, зәңгәрме?
Чәчләреңне җилдән тараттырма,
Табалмыйча йөрсәм әгәр мин...

Мөдирә китапханәчеләр белән сөйләшкәнгә бер атна узган да киткән, инде эшнең барышын тикшерү башланды. Кем нәрсә сөйли, нинди проблемалар күтәрелә дип, Мөдирә мәсьәләне кабыргасы белән куйды. Чыгышларның конспектларын күрсәтергә кушты. Бу кадәресен Латәфәт көтмәгән иде. Кәгазьгә карап сөйләүгә ул гомумән каршы. «Без укучыга кемнеңдер әзер фикерен тагабыз, ә аның үз фикерен белми калабыз»,— дип, яшь хезмәткәр элекке конференциядән соң да кызып-кызып сөйләде. Шуннан яратмый калды бугай аны Мөдирә. Бу юлы да язу таләп итә. Бәлки алар җыен юк-барны сөй-

ләрләр, ди. Мөдирә үзе дә бу китапханәдә яңа кеше. Институтны читтән торып тәмамлаганга чаклы бүтән китапханәдә эшләгән. Югары белем алгач, монда мөдир итеп билгеләгәннәр. Чын исеме Мөнирә аның, китапханәчеләр шулай биләгән дәрәҗәсенә туры китереп, Мөдирә дип йөртәләр. Яңа кешенең күзенә җитешмәгән яклар тиз ташлана бит: яшь мөдир ишек төбендәге кием элгечтән башлап, түрдәге витринага чаклы үзгәртеп чыкты. Шундый яңартып кору чорын кичергәндә, көзге чебеш Латәфәт үз таләпләрен куеп маташа, имеш.

Латәфәт исә эш курсәтергә иң кирәк чакта сыната язып куйды. Конференциягә өч көн калды дигәндә чыгыш ясарга әзерләнгән кешеләр кайсы кая таралды да бетте. Шахматчы начальник Самотлорга командировкага китеп барды. Бораулау остасы биш километр тирәнлегендәге скважинасының соңгы метрларына җитеп бара икән. Мәскәүдән галимнәр килгән, җир астыннан чыккан һәр уч әйберне тикшерәләр ди. Останың теләсә кайсы минутта эштә кирәк булуы бар, скважинаны ташлап ул бер карыш та китә алмый, китапханәче аңа ышанып, уңайсыз хәлдә калачак. Хәтта гади эшче Назыймның волейбол ярышы нәкъ конференция көненә билгеләнгән. Шушы аяныч хәбәрләр белән Латәфәт Мөдирә алдына килеп басарга мәҗбүр булды.

— Бик белдекле күренергә тырышкач, шул инде!

Каты сүз әйтүдән куркып, шунда тукталырга уйлаган иде Мөдирә, ачуын чыгарып бетерми булдыра алмады:

— Җебегән!..

Бу минутта Мөдирә күзләренең усаллыгын беренинди ерткыч җанварныкы белән дә чагыштырырлык түгел иде.

— Элегрәк әйтергә кирәк иде аны, горком аша эшне көйләп була иде! Сөйләүчеңне эзләп Самотлорга оч инде хәзер!

Кызыл кыналы кул сырты өстәлгә пычак булып төшә, йөзекләре елкылдап-елкылдап китә, менә хәзер ул Латәфәтнең башын кисеп төшерәчәк.

— Запаска әзерләгән кешең бармы, ичмасам?!

Запасның ни икәнлеген Латәфәт шушы минутта гына аңлады.

Әйтә иде лә әбисе, сагы барның сагы ятар, сагы юкның башы ятар, дип.

— Анысы бар,— диде кызый, иелгән башын күтәрә төшеп.

Талипов белән телефоннан сөйләшкән иде, өйлә вакытында китапханәдә очрашырга тиешләр. Чыгыш ясаудан баш тартырга уйласа, килеп тә йөрмәс иде, димәк, өмет бар. Мөдиргә яңадан авыз ачарга ирек бирмичә, Латәфәт өстәде:

— Язуы юк әле, иртәгә була.

Барлык чыгыш ясаучыларның адресларын алып, Мөдирә кеш якалы затлы пальтосын кия-кия чыгып китте. Озак та тормый, кире кайтты. Назыймны волейбол ярышыннан азат иттергән.

—Ләкин бер шарт белән,—ди, Латәфәткә карата бераз йомшарып, хәтта бераз кыланчыкланып, — хәзергә әйтмим, конференциядән соң әйтермен.

Бушка гына кеше йомышын йомышлыймы соң Мөдирә! Теге юлы да Латәфәтнең күн пальтосына төс килә дип, лаклы итек китергән иде. Үзенә кысанрак булган, күрәсең. Шуның бәрабәренә Себердән аучы җизнәсе җибәргән кеш тиресен бирергә туры килде. Бу юлы шарты нинди булыр? Юк әйберне сорамас әле, Назыймның конференциягә килүе хак булсын. Талипов та сөйләсә, эш көйләнә яза. Мөдирәнең өч дигәне дә запас белән әйтелә бит аның, чынлыкта Латәфәттән ике генә нотыкчы кирәктер. Әлбәттә, шулай. Һәр китапханәчедән икешәр генә кеше сөйләсә дә, тыңлап бетереп булмас, кемнәрдер сүздән мәхрүм калачак. Мөдирә куячак шартны үтәргә үзен

сәләтле сизеп, Латәфәт аз гына тынычланды. Ләкин бая гына ишеткән әрләү, хәтта мәсхәрәләү сүзләре колак төбеннән мәңге китмәс төсле тоелды. Запас чыгышны наять итеп әзерләгәндә генә алардан арынып булачак.

Билгеләнгән вакытка Латәфәт баскычка чыгып басты. Өстенә кара куртка, башына соры куян бүрек кигән җиңелчә гәүдәле егетне китапханәче кыз ерактан ук күрде. Шул үзе. Очарга талпынган кош канатыдай кашлар... Күбәләк-күбәләк кар ява. Җепшек кар бөртекләре җиргә төшәләр дә эриләр. Октябрь бәйрәме алдыннан ук суытып, халыкка җылы кием кидерде дә, кыш урнаша алмый азаплана. Латәфәт башын иеп уйланып килгән егет каршына басты. Күрештеләр, таныштылар. Латәфәт барган юнәлештә юлны дәвам иттерделәр. «Саклык нотыкчы»ны кызның Мөдирәгә хәзер үк күрсәтәсе килми иде.

— Язучыларны өйрәтердәй акыллы сүз әйтә алмам мин, — диде Заһит, китапханәче кыз эшне аңлатып биргәч.

— Мин бит аларны әни өчен алам,— диде Заһит, татар әсәрләре турында сүз чыккач.

— Нефтьчеләр турында берничә генә бөртек әсәр бар, аларга карата әйтеләсе сүз әйтелгән бит инде,— диде Заһит, кызның шул хакта әңгәмәгә тартырга тырышуын абайлап.

Конференциядә сүз барырдай әсәрләрне Заһит укыган, күренеп тора, сөйлисе килмәгәне дә сизелә. Әмма кырт кистереп баш тартмый, ризалык та бирми. Кызның кайгылы кара күзләре баш тартудан тыеп тора бугай аны. Егетнең икеләнүен күргән Латәфәт чигенү юлын өзү нияте белән әйтеп салды:

— Бүген кич өегездә булыгыз, мин барырмын, сөйлисе фикерләрегезне барлап чыгарбыз.

Хәзер инде егет пошаманга төште, килгән юлыннан дәшми генә китеп барды. Латәфәт җиңеләеп калгандай булды, әйтерсең аның кайгысын Заһит алып китте. Кыз егет киткән якка борылып карады. Кар-күбәләкләр гел Заһитның куян бүреге тирәсендә уралалар сыман күренде.

— Сөйли алмаячагыма мин сезне ышандыра алмадыммыни әле? — диде Заһит, кичен китапханәче шылтыраткач. Латәфәт беравык сүзсез торды.

— Хәзер үзем барам, — диде аннары. Эш сәгате тәмам иде, китте.

Ишекне Заһит ачты. «Намуслы кеше» дип уйлады Латәфәт егетне күргәч. Сәбәп табып, чыгып таярга да мөмкин бит. Авария, җыелыш... Беткәнмени сәбәп? Егетнең намуслылыгы алдында йомшарып калудан үзен саклап, кыз кырыс төс алды:

— Мин комсомол кеше,— диде ул, ике кулын кесәсенә тыгып,— башлаган эшне җиренә җиткерми туктый торган гадәтем юк.

Сүзләрен Латәфәт тыныч әйтте, ләкин керфекләренең җемелдәвендә, ирен тибрәнешләрендә киеренкелек сизелә. Хәтта кулбашына төшкән кара чәченең һәр бөртеге дерелди иде сыман.

— Чишенегез әле, узыгыз,— диде егет, сүзнең болай гына өзелмәячәген аңлап. Ялтырап торган күн пальтоны кызның иңбашыннан алып чөйгә элде, аягына чигүле хәтфә башмак бирде, кызны бүлмәгә уздырды, палас җәйгән диванга утыртты. Үзе өстәл янына, кызның каршысына утырды. Бермәлгә сүзсез калдылар. Заһитның коңгырт чәче ябырылып маңгаена төшкән, күз карашы болыт агылган төнге күк сыман,— бер ачыла, бер караңгылана. Китапханәчегә ул кыз бала итеп, ничек сөйләшсәң моның җаена килеп булыр икән диебрәк карый. Латәфәт үзенең әлеге өстенлекләрен кинәт сизеп ала, һөҗүмне нәкъ шушы позициядән торып башларга кирәклеген ачыклый. Көч сынашу аңа ошап куя, бу халәтне озаккарак сузасы килә.

— Я, Одиссей ничек? — ди кыз, өстәлдә яткан китапны танып.

— Миңа батырлык һәм матурлык ошый,— ди Заһит.

— Безнең Мөдирә сезгә ошыймы? — ди кыз, сорауларының бәйләнешсезлеге белән егетне гаҗәпкә калдырып.

— Мөнирәме? — ди егет, китапханәче әйткән кешене белгәнлеген ачып сала, Латәфәт тә егетне электән күргәнлеген хәтерли. Әйе, Мөдирә бүлмәсенә кергән иде ул, берничә китап кыстырып чыкты. Иң якын кешеләренә генә Мөдирә китапны үзе бирә. Ике егетнең берсе тәгаен шушы. Төп уенчымы, әллә саклыкка куелганымы?

— Сез саклыкка ничек карыйсыз? — ди Латәфәт, егетне тәмам аптырашта калдыра.

— Нинди саклыкка?

«Төп уенчы» һәм «запас уенчы» мисалын китерергә Латәфәтнең теле бармый, моннан алда гына Мөнирә исеме чыкты бит, Заһит сизенер, хәтере калыр төсле тоела. Кызның теленә бөтенләй бүтән мисал килә:

— Әйтик, бик кирәк акча әйләнештә йөри, бик кирәк булмаганы хаҗәте чыкканчы кассада ята...

— Тулаем ил күләмендә бик үк уңай күренеш булмаса да, көнкүрештә акча саклау кирәк нәрсә. Әйтик, минем әни карт, үземә бербер хәл булса...

— Декамерон сезне кай яктан кызыксындыра?

Егет кызның балаларча туры сорауларына шулай ук туры җаваплар бирә:

— Акыл ярышы, тапкырлык...

— Бу сыйфатлар күбрәк сүздә беленәме, әллә эштәме?

— Фән һәм техника заманында — эштә.

Шушы ноктага чаклы Заһит тыныч утырды. Ә ноктаны нык итеп куйгач, торып йөреп китте.

— Әйе, эшче сыйныфы хәзер башка, хәзер һәр эштә фәнни белем алдан йөри, техника заманы. Эшче фидакарь, ул үзенең ил алдындагы бурычын тоеп эш итә. Ул күп укый, опера тыңлый, балет карый. Шулай да дуамаллыклар булып тора, план артыннан куулар, аварияләр. Язучылар аны шулай язалар, дөресе дә шулай. Тормыш гел уңай яклардан гына торса, әсәр дә кызыксыз булыр иде. Тик мин конференциягә баралмыйм.

Әйтерсең Заһит сәхнәгә чыгып монолог сөйләде, сүзен бетерде дә элекке урынына утырды. Хәзер Латәфәт чираты иде:

— Шушы диванда ятып йоклыйм, әшегезгә ияреп барам, китапханәгә җитәкләп алып китәм,— диде ул, бөтенләй исәрләнеп.

— Аңла әле,— диде егет, «син»гә күчеп,— сезнең конференциягез көнне безнең участокта җаваплы эш, мин аннан китә алмыйм.

— Эшнең җавапсызы да буламыни? — диде Латәфәт, һич аңларга теләмичә.

— Шулай дияреңне белеп, башта әйтмәгән идем аны,— диде Заһит, кызны тынычландырырга тырышып.— Беләм, сезнең эшегез дә бик җаваплы. Әмма бездә кеше гомерен куркыныч астына кую белән бәйле: эчендә нефть аккан торбаны кисеп ялгау...

Латәфәт сулып калгандай булды. Тел очына таныш шигырь юллары килде:

Һәр күзәнәк уяу —
Тормыш сагында.

Абыйсының шигырен ишетсә, Заһит, мөгаен, йомшарыр. Латәфәт моны белә, ләкин әрсезләнәсе килми, бу гаиләнең якын кешесе булырга тырышу кебегрәк аңлашылачак.

— Мөдирә минем башны кисәчәк,— диде ул, бөтенләй өметсезләнеп.

— Мөнирә?

Бу исем егеткә Латәфәтнең бөтен тырышлыкларына караганда да ныграк тәэсир итте бугай. Ул уйга калды. Аннары алгы якка чыкты, кем беләндер телефоннан сөйләште. Латәфәт янына акрын гына кереп, үзенең карарын әйтте:

— Ярый, уйлашырбыз.

Һаман боек утырган кызның күңелен күтәрергә теләптер, Заһит командировкада булган бер вакыйга сөйләп алды. Нефтьче дигәч, аны әзербайҗан дип кабул иткәннәр, чөнки Бакудан гайре нефть үзеген белмәүчеләр күп икән. Кызның, чыннан да, йөзе ачылып китте:

— Менә шушы хакта сөйләгез! Бу мәсьәләдә гаеп язучыларга да төшә, Татарстан нефтен тиешенчә яңгырата алганнары юк әле,— диде ул, күптән эзләгән әйберсен тапкандай сөенеп.

Кайтырга җыенганда гына, Хәтимә әби алгы якка чыгып: «Килеп йөр, кызым»,— дип калды. Егет кызны озата китте. Сүз укылган китаплар тирәсендә әйләнде.

— Ничек уйлыйсыз? — диде Заһит, Латәфәтне үзеннән акыллырак күргәндәй итеп.— Берничә кешегә гашыйк булырга мөмкинме?

— Бер юлымы?

— Бер юлы ук түгел инде, күпмедер вакыт узгач.

— Минемчә,— дип башлады Латәфәт, бик белдеклеләнеп,— чынчынлап бер генә тапкыр гашыйк булырга мөмкин. Калганнар алай ук көчле булмый, болай, симпатия генә...

Унҗиде яшьлек кызның катгый фикер йөртерлек бердәнбер нигезе — әдәбият. Чынлап гашыйк итәр кеше тормышта аңа очрамаган әле. Назыймны санап булмый, ул үзе генә очрашулар эзләп йөри, көн аралаш китап алмаштыра. Укысын, әйдә, аннан Латәфәткә ни зыян?

— Ә менә мин бер китап укыдым,— Заһит башлаган сүзен дәвам итте,— анда герой үз гомерендә өч тапкыр бик каты гашыйк була.

— Беренче икесенә сүрелүне автор ничек аңлата соң?

— Тегеләрен үтереп бара ул.

Кычкырып көлеп куйдылар. Капка төбенә җиткәч хушлаштылар. Заһит бик нәзакәтле итеп Латәфәтнең кулын үпкән булды. «Мөнирә кулы кирәк монда», дип уйлады Латәфәт, үзен кемгәдер хыянәт иткән сыман сиздә, йөзексез, кынасыз кулын егеттән тартып диярлек алып кесәсенә яшерде.

— Иртәгә кичкә чаклы,— диде Заһит.

Латәфәт сүз әйтмәде, баш кына иде. Аннары башын текә тотып, керү ягына китте. Конференция үтәр, Заһит белән бүтән очрашмаслар. Йон палас җәйгән йомшак диванда да утыра алмас Латәфәт, Хәтимә әбинең чишмә суыннан кайнаткан чәен дә эчә алмас. Тагын бер күреп калыйм дигәндәй, өй почмагына җиткәч, кыз борылып карады. Заһит электр баганасы яныннан китеп бара. Аксыл ут тирәсендә кар күбәләкләре бөтерелә. «Һәммә нәрсә яктыга тартыла», дип уйлый Латәфәт, ни өчендер үзен күбәләккә тиңләп. «Көясең бит, янасың, нигә күрәләтә утка килеп бәреләсең?» Үзенә-үзе шулай тәкърарлап, кыз йөгерә-атлый баскычтан күтәрелде.

Хәйрулла абыйсы Латәфәтнең эшләреннән бераз хәбәрдар иде. Чыгыш ясар вакыт җиткәч кенә, шахматчы Якупов китеп барды бит. Шуңа сеңелесе алдында Хәйрулла үзен дә гаепле сизә. Менә хәзер дә Латәфәт кайтып керүгә аның хәлен белеште:

— Сөйләүче таптыңмы соң?

— Таптым,— диде Латәфәт җиңүче кыяфәте белән. Аннары, сы-

зым өстенә иелгән абыйсының эшен бүлдергәнгә гафу үтенгәндәй, акрын гына сорады:

— Эчендә нефть аккан торбаны кисеп ялгау куркынычмы?

Хәвефсезлек инспекторы булып эшли Хәйрулла. Шул фән буенча техникумда дәресләр дә алып бара.

— Шуннан була инде шартлаулар, янулар,— ди ул, сызымнарыннан башын күтәрми генә. Бераздан нидер исенә төшкәндәй, башын калкыта:

— Әллә берәрсе нефтьле торба кисәргә җыенамы?

Латәфәт сорауга каршы сорау бирә:

— Ә ни өчен кисәләр соң аны?

— Туза торба, тишелә, нефть саркый башлый. Янәсе, төп торбага икенче чат китереп кушалар.

— Шартламасын өчен нишләтергә кирәк инде аны?

— Саклык чаралары күрергә кирәк,— ди инспектор. Сызымын куеп, сеңелесе каршына баса. Латәфәт артка чигенә, үзе һаман сорау ала:

— Нинди чаралар?..

— Я, әйт, кем нефтьле торба кисә?

— Юуук, ялгаганнар инде аны,— ди Латәфәт, сүзне икенчегә бора.— Ут чыккан, бер егет телогрейка каплап сүндергән, үзенә зыян килмәгән. Аз гына күрми торсалар, трассада зур янгын буласы икән...

Латәфәт алдашмый. Бу очракны аңа Назыйм сөйләгән иде. Вахтадан кайтканда булган хәл. Юл нефть трассасы буеннан уза икән. Торба өстендә башта очкыннар күренгән, аннан ялкын чыга башлаган. Торбаның ялгаган җирендә берәр кимчелек булса, каты басым нәтиҗәсендә шулай ут чыга икән. Арадан бер егет (нигә Назыйм үзе түгел!) йөгереп барган да сырган бишмәтен салып тиз генә ут өстенә каплаган. Егет барып җиткәндә ялкын шактый күтәрелгән, шартлау куркынычы булган, егет аны-моны уйлап тормаган. Трассада янгын башланса, һәлакәт зуррак булыр иде...

Назыйм бу вакыйганы конференциядә сөйләячәк. Латәфәт, чыннан да, җебегән, Мөдирә ярдәменнән башка Назыймны да конференциягә китерә алмый. Булдыклы икән шул Мөдирә, юкка гына кәперенеп йөрми. Шуның өчен дә аңа ике егет гашыйк. Нәҗиягә үзе сөйләгән. Икесе дә ошый, кайсын сайларга белмим, сыныйм әле, дигән. Берсе Заһит булса... Нефтьле торба кисеп ялгауның нидән гыйбарәт икәнлеген Заһитның үзеннән сорашасы бик килсә дә, Латәфәт бая тыелып калган иде. Эшнең үтә җаваплы булуын белгәч, егетне конференциягә чакырудан үзем үк баш тартырмын дип курыкты ул. Менә хәзер Хәйрулла абыйсыннан сорашып белде...

Латәфәт юрганын ничаклы бөркәнмәсен, ялкын эчендәге Заһит күз алдыннан китмәде. Ашыгычлык белән, мөгаен, ул сакдык чараларын күреп җиткермәс. Инспекторга әйтсәң? Әләк була. Хәвефсезлек кагыйдәләрен бозган өчен Хәйрулла абыйсы объектларга пломба сала, ирексездән туктаган предприятиеләрнең планнары өзелә. Шулай да кеше янудан күп яхшы. Бәлки әйтергәдер... Әйтергә һәм бу хакта Заһитның үзенә хәбәр итеп куярга.

Латәфәт дүрт гудокка чаклы тыңлады да трубкасын куйды. Йоклаганнар. Төн уртасы инде. Иртәгә иртүк торып шалтыратасы булыр.

Болганчык төшләр, саташулардан көчкә арынып күзен ачканда иртәнге алты иде. Уянганнар микән? Әнә, Хәйрулла абыйсы торды. Кухняга таба узды. Ишетмәсә яхшырак булыр. Ваннага шаулап су ага башлады. Латәфәт җәһәт кенә ишек катындагы телефон янына килде.

— Сәгать биштән үк чыгып китте, кызым...

Хәтимә әби шулай диде. Кыз Заһитның конторына шалтыратты. Озын гудоклар гына җавап бирде. Бик хәвефле ишетелде ул гудоклар.

Заһит участогына ремонтчылар килергә тиеш. Яңа трасса өчен траншея казыганда экскаваторчылар иске торбаны яньчеп, тишеп киткәннәр, нефть җир өстенә саркып чыккан. Зарарланган урыннан кисеп, торбаны ямап куярга кирәк.

Ремонтчылар килде, җир казылды, нефть сеңгән туфрак читкә чыгарылды. Төп эшкә керешү өчен бар да әзер иде. Ашыгыч ярдәм чаралары, янгын сүндерү әйберләре, чокырга җыелган газның күләмен билгеләү приборлары...

Әллә каян гына инспекция машинасы килеп чыкты. Газны яндырырга торганда гына эш тукталды. Хәвефсезлек инспекторы һәммә нәрсәне яңадан җентекләп тикшереп чыкты. Артык бәйләнер нәрсә табылмады. Зур өй урыны чаклы чокырга дүрт факел ташладылар. Факел утына ияреп газ янып беткәч кенә, кисү-ялгау эшләренә тотынырга мөмкин. Факел таяклары инде күмергә әйләнде, ә торба янында зәңгәр учак ялкыннары һаман ялмана әле. Күпме көтсәң дә сүнәрлек түгел бу. Димәк, торба буйлап газ килүе дәвам итә.

Инспектор скважинаны ябарга кушачак, басымны туктатуның бердәнбер чарасы шул. Хәйрулла нәкъ шундый боерык бирде.

Скважинага пломба салынды. Берләшмәгә китәчәк гаепләү кәгазьләренә имзалар куелды. Дистәләрчә тонна «кара алтын» агымы тукталды.

Гаепләү кәгазендә күрсәтелгән эшләр бүген кичкә тәмамланачак, дип фикер йөртте Заһит. Ләкин иртәгә шимбә, аннан якшәмбе. Гаепләләргә җәза бирү турындагы приказ копиясе кулында булмый торып, инспектор пломбаны алмаячак. План яна... Ел тәмамланып килә, һәр көнне бишкә ярырга торган чак. Яңа елга шәп сюрприз, дип уйлады Заһит ачынып. Коллективны шул чаклы кыен хәлгә куярмын дип башына да китермәгән иде ул. Шушы борчулар арасында китапханәче кызның кайгылы кара күзләре дә күренеп калды.

Латәфәт көне буе җанына тынгылык таба алмады. Хәйрулла абыйсының да эзе-юлы югалды. Талипов участогында берәр хәл булганмы әллә? Кичке якта, ниһаять, телефоннан агасының тавышын ишеткәч, йөгереп өенә кайтты, чөнки тегесе кызның сорауларына ачык җавап бирмәде. Кайтса ишекнең тышкы ягында Хәйрулла белән сөйләшеп торучы Заһитны очратты.

— Бер сәгатьтән башлана, сез әзердер бит? — диде кыз, Заһитны күрүенә чиксез шатланып. Беренче минутта ул егетне үз янына килгән дип уйлады. Заһит Латәфәткә туры карамый гына әйтеп куйды:

— Эшләр хөрти әле безнең...

Латәфәтнең теле тотлыгып калды. Хәйрулла бер сеңелесенә, бер егеткә карап, тамагын кыргалап алды, бу икәүнең кайгысы аңа да тәэсир итте.

— Киенеп чыгыйм әле, барып карарбыз.

Инспектор атлар-атламас өенә кереп китте. Заһит, ниһаять, кызга күтәрелеп карады.

— Туганыңмы әллә?

Кыз баш какты. Заһит объектына пломба салынганын абайлаган иде инде ул. Күрәсең, егетләр инспектор кушканнарны эшләп бетергәннәр дә пломбаны алуны сорап килгәннәр. Латәфәткә мондый ку-

наклар таныш. Хәйрулла агаларына ялынып еш киләләр алар. Коньяк шешәсе кыстырып килүчеләр дә бар. Хата төзәтелгән, күрсәтмәләр үтәлгән, эш туктап торудан кемгә файда? Дәүләткә генә зыян, дип исбатлыйлар әрсез кунаклар. Абыйсының тискәрелегенә Латәфәтнең дә башта ачуы килә иде. Соңыннан Хәйрулла аңлатып бирде: дәүләткә килгән зыян гаепленең кесәсеннән алына икән. Кичә генә ачык нәрсә бүген Латәфәт өчен буталчыкка әйләнде: Заһит бит нефтьне кесәсеннән чыгарып бирә алмый!

Бүгенге хәл Латәфәтнең әләкләве аркасында килеп чыкканын белсә, Заһит нишләр иде икән? Бәлки белә дә торгандыр. Латәфәткә әллә ничек серле итеп карый. Ни булса, шул булыр дип, кыз кинәт әйтеп салды:

— Инспекторны сезгә мин җибәрдем бит.

Юк, моңарчы берни сизенмәгән икән Заһит, кызны үтәли күрердәй итеп, сөзеп карады. Карашын төшерде, тагын бер күтәрелеп карады. Кыз куркынып нидер көтте. Заһитның күзләрендә агылган болытлар арасыннан берни күрә алмады.

Кыска туның төймәли-төймәли, Хәйрулла чыкты.

— Башларын утка илтеп тыкканда уйламыйлар, эш узгач, исләренә төшә... Барып карыйк.

Сукрана-сукрана баскычтан төшүче Хәйруллага Заһит та иярде. Китте, хәтта саубуллашмады да. Башың бетте, Латәфәт, дип уйлады кыз үзе турында, конференцияне өзүең шушы, иң төп тармактан сөйләүчең юк. Тагын да аянычрагы — Заһит алдында алама әләкче булып калдың...

Кеше күзенә чалынмаска теләп, урындыкка сеңгән Латәфәт, китапханәгә Заһит килеп керүен күргәч, кинәт турайды, бермәл сыны каткандай утырды. Заһит каршына тигез тешләренең барысын да күрсәтеп, Мөдирә барды, егетне үз бүлмәсенә алып кереп китте. Озак тормый кире чыктылар, Мөдирә Латәфәткә күз безләрен кадап алды. Латәфәт исә ике гашыйкның берсе Заһит икәнлеген тәмам аңлады. Ә Заһит китапханәче кызга үзләре генә белгән серләре бар сыман елмайды. Карашында болытлар юк, йолдызлар гына! Латәфәтнең йөрәге тыпырдап биеп алгандай булды. Йөрәкнең кайда һәм нинди икәнлеген Латәфәт беренче тапкыр шунда белде.

Язучыларны чакыру турындагы сүз халыкны кызыксындыру чарасы гына булды, ахрысы, шыгрым тулы уку залында чит кешеләр юк иде. Сөйләүчеләр шулай да алдан әзерләнгән кәгазьләреннән аерыла алмый азапландылар. Назыйм белән Заһитның чыгышлары гына бүтәннәрнекеннән аерылып тора иде. Назыйм залны шигърият белән әсир итте. Җир астындагы тәмуг утын чыгарып бетергәч, анда оҗмах кына калуы турында, әлек шәмгә мохтаҗ якларның хәзер Европага нур таратуы турында нефть ягы шагыйрьләренең әсәрләрен яттан сөйләде. Бораулаучы дусларына багышланган үз шигырен яттан укып, залдагы бөтен яшь кызларны бердәй гашыйк итте. Заһит исә әдәби әсәрләргә караганда күбрәк тормыш турында гәп корды бугай, аның чыгышы сорауларга җаваплар төсен алды.

— Герой Әхмәтнең биш чакрымлык скважинасына нигә һаман көч түгәләр, аннан нефть чыкмасы билгеле түгелмени инде?

Моны элек артистлыкта йөргән столяр Самат сорады.

— Астагы хәзинәләрне чыгарып бетергәч, җир иңә, улым, сулар саега, таулар тәбәнәкләнә. Нефтьчеләр бу эшкә ничек карый?

Моны кочегарка Миңненур апа сорады.

— Бораулаучылар Себергә китә, әллә безнең якта нефть бетәме?

Моны укучы бала сорады.

Заһит кайсына уен-көлке белән, кайсына бик тәфсилләп җавап бирде. Ул үзенең утлы-ялкынлы эшенә гашыйк. Латәфәт өстәл артын-

да утыручы Мөдирәгә күз төшерде. Сәер, Мөдирә Латәфәт сыман шатлык кичерми, аның хәтта сөмсере коелган. Әйе, Заһит үзенең эшенә гашыйк. Мөдирә конкурентлар сөйми. Өстәвенә, Заһит үзенең әнисен бик ярата, дип уйлап алды Латәфәт. Мөдирәгә бу бөтенләй ошамас. Заһит алып кайткан чишмә суына ул йөзен сытачак. Заһиттан әнисенә китаплар укытмаячак. Хәтта яу кырында башын салган чик сакчысының шигырь дәфтәрен дә, тузан исе килә дип, өстәлдә тотмаячак. Юк, Мөдирәгә бирергә ярамый Заһитның әнисен! Үзенә көрәштәш итеп, Латәфәт калын дәфтәрдәге шигырьләрне күңеленнән кичерде:

Тыныч йокла, әнкәм,
Улларың сакта.
Дошман үтә алмас
Без исән чакта!

Беренче укыганда шигырь болай ук мәгънәле һәм тәэсирле тоелмаган иде Латәфәткә. Бүтәннәр конференциядән нәрсә алып киткәннәрдер, бу җыелышны әзерләгән көннәрдә китапханәче кыз дөньяда изге әйберләр булуын, аларны тупаслыктан, ваемсызлыктан, «кәгазь» сүзләрдән сакларга кирәклеген тойды.

Конференциядән соң Мөнирә үзенең шартын әйтергә тиеш бит әле. Аһ, бу юлы ул, мөгаен...

Җыелышны йомгаклау белән Мөдирә, ул-бу булганчы өлгереп калыйм дигәндәй, тәрәзәгә якын утырган Латәфәт янына килде.

— Моннан соң сиңа җаваплы эшләр тапшырмам, авырга килер...

Уйлаган алга килә ди, бу Мөдирәнең шарты. Заһит тирәсеннән эзең суынсын дигән сүз бу. Ягымлы итеп, кыйгач кашларын, сөрмәле күзләрен уйнатып әйтте Мөнирә. Әйтерсең хезмәткәре белән түгел, үзенә каратырга теләгән егет белән сөйләшә. Йөзендәге шул елмаюын саклап, кунакларны озатырга китте. Латәфәт почмакка бастырып куелган бала сыман калды.

Конференция узды, баш киселмәде. Латәфәт шуны да ачык аңлады: бу газиз башның көрәселәре күп әле. Кыз ике кулы белән күперенке чәчен сыпырып куйды. Нәфис бизәкле таныш аһәң тылсымчысакчы сыман баш очында тибрәлә иде.

-----------

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

## ИЮЛЬ, 1974 ЕЛ

Мәскәү төзүчеләре автомобиль шәһәренең торак фондын арттыруга үзләреннән шактый өлеш керттеләр: беренче ярты еллыкта Главмосстрой 61 мең квадрат метрдан артык торак фондын файдалануга тапшырды. Бу ярты еллык планда каралганнан җиде мең квадрат метрга артыграк. Әлеге яшь коллективның оешты-рылуына август аенда биш ел тула. Ул үзенең биографиясен Тольяттида башлап җибәрде. Мәскәүлеләр анда 320 мең квадрат метр торак мәйданы төзеделәр. Ә бирeдә, Чаллы шәһәрендә, алар төзегән торак мәйданы 330 мең квадрат метр-дан артып китте.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

Хәзер КамАЗның төзелеш мәйданнарынданиләр эшләнүе турында «Совет-ская Литва» газетасы укучыларына Чаллы шәһәренең партия комитеты секрета-ре Ирина Сергеевна Донская сөйли:

— Бүген төзелешнең ничек барышын күрсәтү өчен ВЛКСМның 50 еллыгы исемендәге бөтенсоюз комсомол отрядын ничек каршылавыбыз турында сөйләү-дән башларга телим. Бу отрядта барлык союздаш республикалардан егетләр һәм кызлар, шулар белән бергә сезнең якташлар да бар. Шул ук кичне алар бездә электр утларына күмелгән шәһәрне һәм төзелешне күреп шаккаттылар.

КамАЗ турында кыскача гына сөйләгәч, без яшьләрне төзелеш мәйданнары-на алып киттек. Автомобиль комплексының 6 заводы бүген 13 гигант корпус булып күтәрелде. Комсомоллар тиздән төп конвейер монтажланачак корпусның ничек панельгә төренүен күрделәр.

Ләкин КамАЗ производство корпусларыннан гына тормый. Анда бүген иң зур промышленность үзәгенең социаль үсеш планы уңышлы рәвештә тормышка ашырыла. Бирегә килүчеләргә иске Чаллыны күптән узып киткән, көннән-көн үсә барган яңа шәһәрне күрсәтеп йөрттек. Хәзер шәһәрдә 170 меңнән артык кеше яши. Һәр көнне бездә 25—30 нәни «камазчы» өстәлә. Бирегә килүчеләр Зәй ГРЭСы һәм Түбән Кама төзелешләрендә булдылар. Отряд комсомолларына индустриаль нигездә төзелә торган куәтле КамАЗ авыл хуҗалыгы зонасы турын-да сөйләдек. Бездә теплицалар гына да 30 гектар булачак. Кошчылык фабрика-сы 340 мең баш тавык асрауга исәпләнгән.

— Сүземнең ахырында шуны әйтергә телим, — диде И. С. Донская, — ком-сомол отряды хәзер үк инде әйбәт кенә эшләп килә. Ул хәзер күп санлы бөтен коллективыбызны бергә алган уртак хисләр, фикерләр, омтылышлар белән эш-ли — бишьеллыкның иң мөһим елының икенче ярты еллыгына алган өстәмә планнарны һәм социалистик йөкләмәләрне үтәү буенча удар ике айлыкны уңыш-лы тәмамлау өчен көрәшә.

**«Советская Литва», Вильнюс.**

Чаллыга Ярославль «Автодизель» берләшмәсенең традицион автомобиль узышында катнашучылар килде. Бу узыш комсомолга В. И. Ленин исеме бирелү-гә 50 ел тулуга багышланган иде. КамАЗның ВЛКСМ комитеты оештырган ми-тингта Ярославль автомобиль төзүчеләр вәкилләре Чаллыдагы хезмәттәшләренә Кама автогигантын коруда уңышлар теләделәр.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

Чаллыда шәһәр киночелтәре дирекциясе булдырылды. Биредә хәзер 60 тан артык дәүләт киноустановкасы эшли. Кинопрокатның яңа бүлекчәсе ачылды, кыска гына вакыт эчендә заманча технологик җиһазлары булган типовой фильм базасы төзелде.

Барлык картиналар да шәһәргә турыдан-туры кинофильмнар күчермәсен алу фабрикаларыннан киләә. Бу исә яңа фильмнарны Татарстан башкаласы Казан кинотеатрлары белән бер үк вакытта экраннарга чыгарырга мөмкинлек бирә. Мәктәпләрнең актлар залы базасында камазчыларның иң яшь буыны өчен 5 кинотеатр ачылды.

Табигый, Камадагы бөтенсоюз комсомол удар төзелешендә кино хезмәте күрсәтүне камиллаштерү өчен байтак эшлисе бар. Мәсәлән, менә икенче ел инде төзүчеләр киң форматлы кинотеатрны төзеп бетерә алмыйлар. Безне шулай ук фильмнарның тар пленкалы вариантларын эшләүнең тоткарлануы һәм башка мәсьәләләр борчый. РСФСР Госкиносы Татарстанның партия һәм совет органнары белән бергә бу мәсьәләләрне хәл итү өчен чаралар күрә.

**РСФСР Госкино председателенең беренче урынбасары М. Соловьевның «Советская культура» газетасы корреспондентына биргән җавабыннан, Мәскәү.**

Июль башында дәүләт комиссиясе Синельниково рессор заводының беренче чиратын файдалануга тапшыру турындагы актка кул куйды. Яңа предприятие — КамАЗның үзенчәлекле бер цехы. Проект куәтен үзләштергәч,— елына биш йөз мең тонна рессор эшләп чыгара башлагач, — бу предприятие авыр йөк күтәрә торган автомобильләр заводларын, шулай ук трактор промышленностен үз продукциясе белән тулысынча тәэмин итеп торачак.

— Безнең завод хәзерге заман техникасы белән җиһазландырылган,— ди партком секретаре Г. Иванющенко,— биредә барлык процесслар — рессорларны чыныктырудан башлап вагоннарга төяүгә кадәрге булган эшләр автоматлаштырылган һәм машинага көйләнгән.

Беренче корпус төзелгәндә үк рессорлар җитештерелә башлады. Хәзер алар Сыйфат билгесе алдылар инде.

**ТАСС, Днепропетровск.**

Чаллыда ике көн буена яшь төзүчеләрнең өченче республика слеты барды. Ул комсомолга В. И. Ленин исеме бирелүгә 50 ел тулуга багышланган иде.

Слетта шәһәр төзү идарәсенең ташчылар бригадиры В. Мәүликов, студентлар отряды вәкиле М. Кандыбина, «Казаньхимстрой»ның балта осталары бригадиры Р. Юнысов һәм башкалар чыгыш ясады.

Слет эшендә партиянең Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре Р. Беляев, ВЛКСМ Үзәк Комитеты секретаре В. В. Григорьев, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре И. Рахманкулов катнашты.

Кызлар һәм егетләр бөтенсоюз удар төзелеше кунакларын — СССРның летчик-космонавты, Советлар Союзы Герое П. И. Климукны, комсомол ветераннарын, данлыклы совет спортчыларын кайнар котладылар.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

«Сибэлектротяжмаш» заводы 2500 киловатт куәтле ток үзгәрткечләрнең беренче партиясен җитештерә башлады. Әлегә кадәр илебез электр машиналары төзелешендә мондый куәтле агрегатлар эшләнгәне юк иде. Быел һәм киләсе елда бу завод коллективы Кама автомобиль заводы өчен 15 ток үзгәрткеч җитештерәчәк. Бу исә КамАЗ төзелешендә бик зур средстволарны янга калдырырга һәм тимерчелек әзерләмәләрен чыныктыру процессын прогрессив технологиягә күчерергә мөмкинлек бирәчәк. Ток үзгәрткечләрне эшләп чыгаруны Новосибирск эшчеләре күптән үзләштергәннәр иде. Ләкин элекке конструкциядә агрегатларның куәте бары тик 1500 киловатт кына иде. Хәзер КамАЗ ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен 25 урынына 15 агрегат та җитәчәк.

**ТАСС, Новосибирск.**

Дәүләт комиссиясе КамАЗның 120 мең квадрат метрдан артык мәйданы булган ремонт-инструмент заводының беренче чиратын «яхшы» билгесе белән кабул итте. Ярдәмче цехлар һәм ремонт-тимерчелек цехы корпусында 2500 дән артык станок эшли башлады.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

## Фәләх Насыйров

# РӘХМӘТ СЕЗГӘ, КЕШЕЛӘР!

Сездә идем, мәңге сездә калам,
Алгы сафлар, алгы мәйданнар:
Сездә генә бары җан азыгы,
Сездә генә бары илһамнар,
Бу яшәүнең тулы мәгънәсе бар,
Сезнең сафта гына, туганнар!

Х. Туфан.

1



— Хатының нигә китте, Фердинанд?

Ишек катында торган егетнең түгәрәк йөзенә кызыллык йөгерде, кара күзләренең карашы түбән иелде.

— Я, нигә китте?—дип кабатлады партоешма секретаре Гөлсем Мусина.

— Әй, хатын-кыз инде ул, билгеле, әнисен сагына...

— Син эчмәгәндә сагынмый бит ул әнисен. Ник эчәсең?

— Әллә нидә бер генә...

— Әллә нидә бер генә? — Партоешма секретаре урыныннан торды.—Печән чапканда кем өч көн буе эчеп йөрде? Кем август аенда эчеп хатынын куды?

Егет колак яфракларына кадәр кызарды. Кара әле, барысын белеп тора! Булды инде аның андый гөнаһлары...

— Көн дә эчәргә акча каян аласың? Акча каян керә?

Монысы тагы да яманрак сорау иде. Каян кергәнен Фердинанд үзе генә белә шул. Ул конюх бит. Атлар үз кулында. Берәүгә шыпырт кына ат бирсә, кесәгә ярты төшә. Төнлә үзе урманга барып кайтса, бер-ике бөтенлек тә була. Була инде ул андый хәлләр, бигрәк тә «кызган» баштан.

— Кемнәр синең дусларың?

Конюх җавап бирмәде.

— Сез дуртәү идегез, — диде Гөлсем апасы, егетнең күзләренә карап. Һәм ул аның кемнәр белән, кайда һәм күпме эчүләренә кадәр әйтеп бирде. Фердинанд башын күтәреп, авызын ачкан килеш шакка-

тып калды. Валлаһи, барысы да дөрес! Ни арада белеп өлгергән?.. Әйе шул, Мөнир, Мулланур, Вәгыйзләр белән эчкән иде ул. Барысы да кирәк кешеләр. Үзләре кирәк булмаса да, урманчыларның агачлары, печәннәре кирәк. Ни хәл итәсең, кул кулны юа.

— Ничәнче елгы син?

— Кырыгынчы...

Партоешма секретаре Мусина уйга калды.

— Нинди заманда үстең син? — диде ул эчке бер кичереш белән. Аның тавышында газап та, әрнү дә, үпкә һәм үгет тә бар иде. Әйтерсең аның каршысында ялгыш юлга баскан үзенең газиз баласы басып тора. Ә ул нишләргә белми өзгәләнә, газаплана. — Нинди чорда яшисең? Нинди вакыйгалар бара дөньяда? Ә син япь-яшь килеш аракы сөреме эчендә алпан-тилпән килеп урам буйлап йөрисеңме? Син нишләдең, Фердинанд? Нинди кайгың бар? Нәрсә җитми сиңа? Әйт, сөйләшик, хәл итик!

— Бер кайгым да юк, Гөлсем апа...

— Әйе, бер кайгың да юк. Алмадай балаларың, менә дигән хатының бар. Әле кайчан гына син өстеңә кияргә кулмәксез малай идең. Кем аркасында син өйле, икмәкле булдың? Я, әйт, кем аркасында син ай саен уч тутырып акча аласың?

Партоешма секретаре стенадагы диаграммага күрсәтте. Ә диаграммалар бик күп нәрсәләр турында сөйлиләр иде. Колхозчыларның хезмәтләренә түләү соңгы җиде елда биш мәртәбәгә арткан.

— Я, әйт, кем аркасында син гөрләтеп тормыш итәсең? — дип кабатлады Гөлсем апасы.

— Билгеле инде, колхоз аркасында.

— Колхоз аркасында булса, ник кичә атларыңны карамадың? Ник син шундый матур тормышның ямен җибәрәсең?

— Эчмәм бүтән...

— Юк, алай гына котылып булмый. Балаң белән хатыныңны куарга синең ни хакың бар? Күршеләреңнең тынычлыгын бозарга ни хакың бар? Әллә инде үзеңне иптәшләр судына биреп, колхозчылар хөкеменә бастырыргамы?

— Бүтән кабатланмас...

Өлкә партия конференциясеннән кайткач, Гөлсемнең эш көне менә шулай борчулы башланды. Аның әле бригадаларны йөреп чыгасы, кичкә агитаторлар киңәшмәсе уздырасы да бар. Эшләр байтак җыелган.

Тышта кояшлы көз. Ерак офыкта ястыктай ак болытлар йөзә. Гөлсем ялангач кырлар буйлап, сөрелгән җир уртасында диңгез утрауларына охшап калган салам эскертләренә, юл буендагы агачларның саргайган яфракларына карап барды, ә үзенең күңелендә һаман да Фердинанд иде. Юк, бу егетнең дөрес юлга басачагына шикләнми ул, ә совет чорында үскән, совет мәктәбендә тәрбияләнгән кешенең менә шундый бозык юлга басуы борчыды аны. Гөлсем Фердинандны бала чагыннан ук белә. Ничек соң ул аның бу кимчелеген элегрәк күрми калды икән? Кайда соң ул ялгышлык җибәрде?

Гөлсемне партоешма секретаре итеп сайлап куйганда, искелекнең бу әшәке чире авылда шактый тамыр җәйгән һәм ул елларда колхоз үзе дә экономик яктан бик зәгыйфь хуҗалыкларның берсе иде. Җиңел булмады аңа башта. Колхозда эшче көче аз. Булганы да шәһәргә китү ягын карый. Уңыш түбән, үстерелгәне дә вакытында җыеп алынмый, яртысы түгелеп-чәчелеп бетә. Коммунистлар аз, дисциплина йомшак. Кая карама — таркаулык, җитмәсә, Гөлсем үзе өч бала анасы. Колхоз зур, ун авыл керә.

Бу кыенлыклар каршында Гөлсемнең бер өстенлеге — тәҗрибәсе бар иде. Укытучы булу өстенә, колхоз эшен ул яхшы белә. Беренче чыныгуны ул авыр сугыш елларында алды. Ул чакта да аңа партоешма секретаре булып эшләү җиңел булмады. Ләкин аның бәхетенә, шул елларда партия чакыруы буенча колхоз белән җитәкчелек итү өчен яңа кеше — Запускалов килде. Белемле булса да, ул да әле тәҗрибәсез, үзе генә бер ни дә эшли алмый иде.

Гөлсем өчен иң авыры кадрлар мәсьәләсе булды. Бригадалар, фермалар белән җитәкчелек итү, резервлардан тулырак файдалану, хезмәтне яхшырак оештыру өчен намуслы кадрлар кирәк. Ә аларны урында табарга, сайлап ала белергә һәм үстерергә кирәк иде. Бу бик четерекле, бик авыр эш булды...

— Нәрсә бик уйга баттыгыз, Гөлсем апа? Исәнмесез!..

Секретарь каршында бригадир Әсәдуллин басып тора иде.

— Ә, Сәгыйдулла! — диде Гөлсем, уйларыннан бүленеп... Кинәт кенә нәрсәдер исенә төшкәндәй, аның йөзе ачылып китте.— Рәхмәт сиңа! — дип, ул бригадирның кулын кысты.

— Нәрсә өчен? — диде бригадир гаҗәпләнеп.

— Хәтерлисеңме, син үстергән кукурузларны күргәзмәгә алып киткәннәр иде? Партия өлкә конференциясе делегатлары ул кукурузларны сокланып карадылар. Гектарыннан 660 центнер яшел масса бит!

— Бу әле чик түгел, Гөлсем апа, — диде бригадир. — Тырышсак, тагын да күбрәк үстерербез.

— Мин дә шулай уйлыйм, Сәгыйдулла. Тик моңа ирешү өчен әзерлекне бүгеннән үк башларга кирәк бит.

— Аңлыйм.

— Я, эшләр ничек?

— Эшләр бетеп бара, Гөлсем апа. Бәрәңге алуны төгәлләдек. Әнә, орлыкка дигәнен аерып саласы гына калды. — Әсәдуллин лапастагы бәрәңге өемнәренә күрсәтте.

Бәрәңге аралап ятучы хатын-кызларның рус, татар телләрендә катнаш сөйләшүләре ишетелде. Кайсы моның рус, кайсы татар, аера торган түгел. Чөкердәшеп сөйләшәләр, вакыт-вакыт яңгыратып көлеп куялар. Берсе русча әйтсә, аңа икенчесе татарча җавап бирә. Әнә, татар кызы Кадрия Гәрәева рус егете Николай Батурин белән гөрләтеп семья корган. Берсеннән-берсе матур балалар үстерәләр, күгәрченнәрдәй гөрләшеп яшиләр. Алар эшләгән бригада колхоз буенча ярышта алдынгылыкны бирми. Иген уңышы да аларда башкаларныкыннан югарырак. Ә кукуруз турында инде әйтеп торасы юк.

Әле кайчан гына таркау, иң арттагы, иң дисциплинасыз бригадаларның берсе иде бит бу. Коммунистлар башкарган могҗизаларны әзләп, әллә кая барып йөрисе юк. Менә ул күз алдында. Алар тырышлыгы, алар көче белән күтәрелде бу коллектив. Әмма ләкин шундый сәләтле коммунистларны тәрбияләп үстерү өчен Гөлсем үзе дә аз көч куймады, аз тырышмады. Армиядән кайткач, Сәгыйдулла да баштарак шәһәргә сызу ягын караган, «колхозда юкка селкенеп йөрер хәлем юк», дигән иде.

Әйе, колхозда хезмәткә түләү түбән иде ул чакта. Шулай да Гөлсем колхозның киләчәген аңлатып, аны авылда калырга үгетләде. Ә егет бер көнне юкка чыкты. «Монысы да тайды, ахры»... — дип торганда, яңадан авылга кайтып төште дә җиң сызганып эшкә тотынды. Секретарьның сүзләре җилгә очмаган иде. Гөлсем аны партия укуына тартты, җәмәгать эшләре бирде һәм акрынлап партия сафларына әзерләде.

Партия сафына алынгач, партбюро аңа менә шушы бригада белән җитәкчелек итәргә тәкъдим итте. Әсәдуллин куркып калмады.

— Партия куша икән, мин риза! — диде.

Башта Гөлсем үзе дә шушы бригадага шефлык итте. Механик Г. Әхәтов, тракторчы С. Низамбиев, комбайнчы М. Нурмөхәммәтов, Я. Азиятов кебек иң алдынгы колхозчыларны да ул партиягә әзерләде. Бригада каршында партгруппа оештырылды, һәм бу зур вакыйга булды: кимчелекләр белән килешмәүче, барысын белеп, күреп торучы сугышчан штаб барлыкка килде. Ялкынлы йөрәкле яшьләр хисабына ул һаман үсә барды. Колхозда әйле-шәйле эшләп, үз хуҗалыгы өчен күбрәк кайгырткан Бану Шакирова, Миңнур Арсланова, Мәрьям Латыйпова кебек колхозчыларны тәрбияләү буенча да, Г. Катаев кебек самогон ясап, дини бәйрәмнәрдә күмәк эчүләр оештыручыларга каршы да шәфкатьсез көрәш ачылды, һәм менә хәзер бригада танымаслык булып үзгәрде.

Партоешма секретаре, колхозчылар белән сөйләшеп, эшнең торышы белән танышканнан соң, канәгать булып өченче бригадага чыгып китте. Анда Гөлсемне бигрәк тә товарлыклы-сөтчелек фермасы кызыксындыра иде. Биредәге терлекчеләр комсомол-яшьләрдән генә тора. Алар коммунистик хезмәт фермасы исеме алу өчен көрәшә башлаганнар иде. Әмма соңгы көннәрдә сөт алу кимеде. Сәбәп нәрсәдә?

Ферма авыл читендәге үзәнлектә урнашкан. Аның алгы башында «Елочка» тибында әле яңа гына салынып беткән абзар. Бүген анда сыерлар беренче мәртәбә ябылачак. Эче чиста, якты, һәр тагарак янында автоэчергечләр. Монда терлекчеләр өчен дә, маллар өчен дә уңайлы.

Гөлсем яңа абзарны карап чыккач, савучылар янына килде.

— Менә шулай интегәбез инде, Гөлсем апа, — диде зур тагаракка тутырылган бәрәңгене көрәк белән болгатып торучы кыз. — Көн саен ике центнерга якын бәрәңге юып, турарга кирәк. Беләкләр калмый...

Чыннан да, бик авыр эш иде бу.

— Күрәм, кызлар, җиңел түгел, — диде партоешма секретаре.

Гөлсем кайтырга чыкканда инде тышта караңгы төшкән, йортлар һәм урамнарда ялт итеп электр утлары кабынган, чаттагы репродуктордан радио сөйләве ишетелә иде.

Мәскәү сөйли! Бөтен ил, бөтен халык партия съезды хөрмәтенә алган йөкләмәләрен үтәүләре, яңа уңышларга ирешүләре турында партиягә рапорт бирә. Тышта көз булса да, йөрәктә яз. Әйе, дәртле җырлар белән тулы чәчәкле яз!

Гөлсем Кырынды авылына юл тотты. Анда озакламый агитаторлар җыелырга тиеш.

Авыл башына җитәрәк, су колонкасы янында аны бер хатын туктатты:

— Бу кем икән дип торам. Син икәнсең әле, Гөлсем җаным,— диде ул яңгыравыклы тавыш белән. — И рәхәтләндек бит шушы колонкаларга. Суга интегеп гомеребез узган икән! Ике чакрымнан ташый идек бит. Рәхмәтләр төшсен сиңа, Гөлсем, рәхмәтләр!

— Миңа түгел, апа, колхозга рәхмәт әйтегез. Торбаларны колхоз салды бит.

— И, Гөлсем җаным, бик беләм, бик... — Ул тавышын әкренәйтеп, якынрак килде. — Син секретарь булганчы ашлыгы да бик чамалы иде. Коммунистларга рәхмәт. Бигрәк алар тырышалар. Ә син — шуларның башлыгы. Сез булмасагыз, картымны әйтәм, эчеп, инде әллә кайчан эштән чыккан булыр иде. Ярый, сез тыйдыгыз, рәхмәтләр төшкере!

Хатынның бу сүзләрендә зур хаклык бар иде.

Кайсы гына тармакка күз салма, иң авыр, иң җаваплы участокларда коммунистларны күрәсең. Әнә, партия өлкә конференциясендә делегат булып катнашкан Мөхтәрәмә Баһавиева мең баш дуңгыз си-

мертергә йөкләмә алды. Ул үзенең йөкләмәсен арттырып үтәде. Комбайнчы Һади Афзалов та үз сүзендә нык тора торган коммунистлардан. Узган еллардагы кебек, быел да аннан күп ашлык урган комбайнчы булмады. Беренче бригаданың партгруппа секретаре Баян Шабаев турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Аннан күп йөк ташыган шофер юк. Нәҗип Насретдинов, бертуган Гыйльмановлар да партоешманың алдынгы коммунистлары, Әнвәр Шәмсетдинов, Шәех Сөләймановлар яшь коммунистлар булсалар да, комплекслы бригадалар белән бик оста җитәкчелек итәләр.

Мондый мисалларны адым саен күрергә мөмкин. Һәр тармак буенча алдынгыларның һәрберсе диярлек — коммунистлар. Партоешма секретаре итеп Гөлсем сайланганнан соң аларның саны бермә-бер артты. Алтмыш коммунистның кырык җидесе турыдан-туры колхоз производствосында эшли.

## II

Төн.

Тынлык.

Агитаторларның киңәшмәдән таралуларына инде шактый вакыт узган. Авыл йокыда.

Бары тик идарә каршысындагы йорт тәрәзәләреннән генә яктылык бөркелә. Өстәл артында башын иеп Гөлсем утыра. Ул нидер укый, яза. Бу көннәрдә аның эше күп.

Гөлсем партиянең XXII съезды делегаты. Ул Мәскәүгә, съездга әзерләнә. Гөлсем анда кешелек тарихында гасырлар буе хыял булып килгән иң изге һәм иң кадерле теләк һәм омтылышларны тормышка ашыру — коммунизм төзү программасын кабул итүгә, якты киләчәгебезгә олы юллар салуга катнашачак.

* *
*

... Мәскәүдән кайтканнан соң Гөлсем авылдашлары белән очрашырга ашыкты. Съезд барган көннәрдә дә ул колхозы белән элемтәдә торды. Тарихи съезд ачылу уңае белән авылдашларын тәбрикләп, алган социалистик йөкләмәләрен үтәүдә уңышлар теләп, телеграмма җибәрде. Җавап телеграммасы һәм Кырынды мәктәбе пионерларыннан хат алу аны чиксез куандырды.

— Партиябезнең тарихи съездында катнашу, Мәскәүдә үткәргән көннәр минем гомеремдә иң кадерле, иң матур көннәр булып калдылар! Съездда алган тәэсирләрне сөйләргә сүзләр таба алмам кебек, — дип башлады ул үзенең беренче чыгышын.

Башкаланың күп катлы матур йортлары, ялт иткән мәрмәр метро станцияләре, Кремльдәге мәһабәт Съездлар сарае, Совет дәүләте җитәкчеләре белән кул кысып күрешүләр, илебезнең карт коммунистлары һәм чит ил Компартия җитәкчеләре белән очрашулар бер-бер артлы аның күз алдыннан йөгереп узды.

— Коммунизм төзү программасын кабул итүдә катнашу миндә, гади татар хатынында, чиксез зур тәэсир калдырды, — дип дәвам итте делегат. — Безнең Советлар иленең бөеклеге, аның дөньяда тынычлыкны саклауда гигант көч булуы, кешене бәхетле итү — Коммунистлар партиясенең иң изге теләге икәнлеге — съездның беренче утырышыннан алып соңгы утырышына кадәр ачык күренде.

Зал йотлыгып тыңлады.

Гади, ягымлы, үз araлapынnан үсеп чыккан Гөлсем бик күп нәрсәләр турында сөйләде. Аның һәр сүзе колхозчыларның йөрәкләренә барып җитте.

### III

Төн узып бара. Палата тып-тын. Бары тик тәрәзә артында гына әче җил улый, кар бөртекләренең тәрәзә пыяласына сибелүе ишетелә.

Авырулар йокыда. Ә Гөлсем йоклый алмый. Ул кайгыда. Профессорның: — Күзеңне алырга кирәк... — дигән сүзләре уеннан китми.

Бу сүзләргә ул башта ышанмый торды. Ул бит күзен алдыру өчен түгел, ә күзле булып кайту өчен килгән иде.

— Юк, юк, Фома Филиппович, бирмим! — дип Гөлсем, кулы белән күзеп каплап, артка чигенде.

— Хәлегез бик җитди, Гөлсем Мортазовна, — диде аңа профессор Сусаев. — Башка чара юк.

— Алайса, мине Одессага, Филатов шәкертләре янына җибәрегез...

Авыруның бу сүзләренә профессор тиз генә җавап кайтармады.

— Анда барып йөргән арада, вакытны кулдан ычкындыруыгыз мөмкин, Гөлсем Мортазовна, — диде ул сабыр гына. — Аңлыйсызмы, соң булуы бар. Күз эченә үскән яман шеш баш миенә күчсә, ул чагында инде бернинди операция дә ярдәм итмәячәк.

— Яман шеш? — дип кычкырып җибәрде авыру.

— Әйе, яман шеш... Бары тик операция!

— Ирем белән киңәшмичә, бер сүз дә әйтә алмыйм, — дип кенә әйтә алды ул.

Мусина, урыныннан акрын гына күтәрелеп, коридорга чыкты. Кемдер аны култыклап палатасына кадәр озатып куйды.

Көн узды, кич булды һәм таң атты, ә ул авыр уйлар диңгезендә йөзде... Күзен алдырырга... сафтан төшеп калырга... Күзен генә югалтып котылырмы әле?.. Аның хезмәт һәм тормыш юлы шушында өзеләме? Ә ул үз гомерендә телгә алырдай, йөрәккә ял бирердәй эш башкара алдымы? Тормышта аның эзе каламы?

Дөрес, утыз елга якын ул яшь буынны тәрбияләүчеләр сафында булды. Бер үк вакытта башлангыч партия оешмасы секретаре булып егерме елга якын эшләде. Монысы инде аның тагын да җаваплырак, тагын да авыррак хезмәт иде.

Юк, Гөлсем үз гомерен бушка уздырган дип әйтеп булмый. Әгәр гомерен яңадан башларга мөмкин булса, ул бүтән юл сайламас, авыр булса да, шушы юлдан китәр иде.

Шулай ук бу юл өзелдемени хәзер?.. Ә аның башында нинди зур планнар, нинди матур хыяллар бар иде. Алар шул килеш каламы? Аз, бик аз эшләргә өлгерде бит әле ул.

Алда аны шомлы билгесезлек көтә. Менә шул билгесезлек аның җанын газаплый.

Иртәгесен Мусина янына сестра керде.

— Гөлсем Мортазовна, сезне бер апа чакыра, — дип хәбәр итте ул.

Күп еллар Әгерҗе райкомында бүлек мөдире булып эшләгән Җамал апа Хәсәнова көтә иде аны. Моннан чирек гасыр элек Көчек авылында укытучы булып эшли башлагач та, аның янына менә шушы Җамал апасы килеп бик күп авырлыкларны җиңәргә булышкан һәм Гөлсемне партиягә тәкъдим иткән иде. Менә хәзер дә, аның

иң авыр көннәрендә, Җамал апасы үзе үстергән коммунистның хәлен белергә килгән.

Гөлсем түзмәде. Хәсәнованың күкрәгенә капланып, үксеп җибәрде һәм йөрәгендәге төерләрен бер-бер артлы чыгара башлады.

— Елама, Гөлсем җаным, нык бул, — дип юатты аны Җамал апасы. — Операция ясасыннар. Бер күзле кешеләр дә яшиләр бит. Эшлиләр дә! Күңелеңне төшермә, Гөлсем җаным.

— Бер күз белән мин ничек укытырмын?.. Балалар янына ничек керермен?..

— Укытырсың, борчылма. Башта әйбәт кенә операцияң узсын.

Җамал апасыннан соң ук ире Йосыф килеп җитте. Гөлсемнең күңеле яңадан йомшарды.

— Ике күзсез калсаң да, мин сине ташламыйм бит! Бары тик исән генә кал! — дип өзгәләнде Йосыф. — Операция ясат, сузма. Зинһар сузма! — дип ялварды.

...Операциягә керергә дип торганда гына Гөлсемгә телеграмма һәм хатлар китереп бирделәр. Телеграмманы ачып, аңа тиз генә күз салды. «Колхоз идарәсе һәм укытучылар коллективы сезгә чын күңелдән саулык һәм сәламәтлек телиләр» дигән юлларны укыгач, аның йөрәгенә рәхәт бер дулкын йөгерде һәм күзләре яшьләнде.

Район мәгариф бүлеге коллективы борчылып аңа хат җибәргән. «Гөлсем апа, сезнең өчен без бик кайгырыштык, — дип башлаганнар алар хатны. — Үзегез бик борчылмагыз инде. Сезгә бик тыныч булырга кирәк. Тиздән сәламәтләнеп кайтуыгызны теләп калабыз...»

Бу минутта менә шушы язулар аңа барлык нәрсәләрдән кыйммәтрәк һәм кадерлерәк иде. Операция бүлмәсенә ул дуслары һәм якыннары җылысын тоеп керде.

Икенче көнне аның янына җитмеш яшьлек Галимәрдән бабай Садыйков килде.

— Авыруыңны ишеткәч, түзмәдем әле, Гөлсем. Тукта, мин әйтәм, янына бер барып килим, — дип сөйли башлады ул. — Син, Гөлсем, күземне югалттым дип борчылма. Шуны әйтү өчен килдем. Мин дә бит бер күзле кеше. Ә яшим. Әйе, бер күз белән илле елга якын яшим. Кешеләрдән бер дә ким яшәмим. Син дә борчылма, Йосыфка да әйттем инде, кайгырышмагыз дип.

— Яхшы сүзләрең өчен рәхмәт! — диде Гөлсем дулкынланып.

— Синең үзеңә рәхмәт әйтергә кирәк, Гөлсем, — диде аңа Галимәрдән бабай. — Балаларыбызны укытып, аларны кеше иттең. — Аннары ул башын кагып бармакларын шартлатып куйды. — Колхозыбыз да районда беренче бит...

Гражданнар сугышында күзен югалткан картның шундый сүзләре Гөлсемнең күңеленә хуш килде, йөзе балкып китте.

Больницадан кайткач та хәлен белергә килгән кешеләр күп булды. Алар арасында кемнәр генә юк иде! Оста җитәкче булып үсеп җиткән колхоз председателе Илгизәр Сәлимгәрәев, һәр елны бишәр йөз гектар ашлык урып-суктырган комбайнчы Һади Афзалов, алдынгы бригадир Сәгыйдулла Әсәдуллин, КПССның Татарстан өлкә комитеты члены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, терлек караучы Минниса Динмөхәммәтова, колхозның иң тырыш сыер савучысы Рәисә Әхмәтова һәм башка бик күпләр бар иде. Алар барысы да Гөлсем үстергән кадрлар, барысы да диярлек аның тарафыннан партиягә әзерләнгән коммунистлар.

Әгерҗе районының башка авылларыннан да хәл белергә килүчеләр аз булмады. «Кызыл маяк», «Алга», «Татарстан», XXII партсъезд исемендәге колхозларның председательләре Мохтар Шабаев, Хәмәт Галиев, Әнвәр һәм Йөзленур Шәмсетдиновлар да килеп, аңа җылы сүзләр әйтеп киттеләр.

Ничек килмәсеннәр, алар да бит Чапаев исемендәге колхозда үскән, аның партия оешмасында тәрбияләнгән коммунистлар. Хәзер менә шулар районның иң эре биш хуҗалыгы белән җитәкчелек итәләр.

Кайчандыр Гөлсем үзе аларга аякка басарга, киң тормыш юлына чыгарга ярдәм иткән булса, хәзер менә шул кешеләр үзләре Гөлсем апаларына рухи көч бирәләр, күңел төшенкелегеннән саклыйлар.

Бер көнне аның өенә Әгерҗе райкомының беренче секретаре Нургали Сафин килеп керде.

— Хәлегезне беләсем килде, Гөлсем Мортазовна, — диде ул, аның кулын кысып. — Ни хәлдә ятасыз? Күзегез бик сызламыймы?

— Хәлләр мактанырлык түгел, Нургали абый, — диде Гөлсем. — Хәзер мин бер күзле кеше, икенче группа инвалид бит. Эшли алуым да икеле инде...

— Ай-һай, Гөлсем Мортазовна, сез эшсез түзә алмассыз, — диде секретарь, аңа сынаулы карап. — Өйдә ятып, авыруыгызның дә көчәюе мөмкин. Гади укытучы гына түгел, мәктәп директоры эшен тәкъдим итәбез сезгә.

Димәк, аның язмышы белән авылдашлары гына түгел, ә район җитәкчеләре дә кызыксына. Ничек итеп ул шундый хөрмәт һәм ышанычтан баш тарта алсын.

Гөлсем үзенең инвалидлык язуын райсобеска илтеп тапшырды да эшкә кереште. Ә эш... эш бик күп иде. Колхоз 320 урынлы зур мәктәп салуны планлаштырды. Моның өчен укучылар көче белән аның нигезен казырга кирәк. Төзелеш материалларын табуда да колхозга булышмыйча мөмкин түгел. Күрше авыллардан килеп укучылар өчен интернат ачасы бар. Укыту-тәрбия мәсьәләләре дә көндәлек игътибар үзәгендә булырга тиеш. Болары өстенә ул колхозның партком члены, бөтен идеология эшенә юнәлеш биреп торырга һәм аңа җитәкчелек итәргә кирәк.

Шундый мәшәкатьләр эчендә тагын ике ел узып китте. Алда әйтеп узган эшләрнең бик күбесе тормышка ашты, иске мәктәп каршында гына кирпечтән салынган ике катлы мәһабәт бина үсеп чыкты, яңа интернат ачылды, укучыларның өлгерешләрендә дә сизелерлек үзгәрешләр булды. Колхоз да бер урында тормый, һаман үсә, ныгый. Иген уңышы алу һәм терлекчелек продуктлары җитештерүдә яңа үрләр яулый, колхозчыларның хезмәтләренә түләү дә елдан-ел арта.

Гөлсем яңадан менә шушы гөрләп торган тормыш агымына кереп чумды. Менә шушы уңышларны оештыручылар һәм әйдәүчеләр сафына басты. Матур җәй айларының берсендә аңа бик шатлыклы хәбәр килде. Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы аңа «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирде.

Алексей Маркелов

# УТЛАРДА ЧЫНЫККАН

169 нчы дивизия кызылармеецлары Бессарабия юллары буйлап бара. Тирә-якта сугыш кирәк-яраклары, азык-төлек төягән машиналар гөрелтесе. Колонналар тын атлый, солдат юморы да, җырлар да ишетелми. Дивизия Совет — Румыния чигенә якынлаша. Сугыш...

Дивизия художнигы Мәхмүт Усманов лейтенант Петр Васильевич Качур белән рәттән атлый. Алар 1939 елдан бирле дус инде — артиллерия полкында бергә хезмәт итә башладылар. Икесенең дә буйлары бертигез, ә характерлары төрлечә: Мәхмүт сабыр, беренче карашка үз-үзенә бикләнгән сыман. Ә Качур хәрәкәтчән, терчә, күп сөйләүчән. Фурмановның Чапаевына охшарга тырыша, хәтта мыек та үстереп җибәргән. Җае чыкканда үзләренең ата-бабалары Дон казаклары булуы белән мактанырга ярата.

Аларның казармада да койкалары рәттән иде. Кичләрен буш вакытта бер-берсенә туган яклары турында сөйлиләр: Мәхмүт Татарстанның Кукмара районы турында, ә Качур Калмык АССР турында. Өйдән килгән хатларын бергәләп укыйлар, бергә шахмат уйныйлар.

Көндезләрен алар бик сирәк күрешә: Качур артиллерия мәктәбендә укыды, ә Усманов полк клубында сугышчан листоклар чыгарды, төрле рәсемнәр ясады, хәрби һәм политик әзерлек отличникларын сурәткә төшерде.

Полкташларының рәсемнәрен күреп, Качур болай дигән иде:

— Талант синдә, Миша, зур талант! — Аннары өстәп куйды: — Тукта әле, Усманов. Сез унбер бала үскәнсез. Бик бай да яшәмәгәнсез, мөгаен. Ә бит рәсем ясау өчен, рәссамлыкка өйрәнү өчен вакыт, шартлар кирәк.

— Ул вакыттагы тормышны искә дә аласы килми минем, Петя. Ярлылык чиктән ашкан иде. Мескен тормыш. Әмма сиңа сөйлим инде, тик бүтәннәргә генә җиткерә күрмә.

Алар утырыштылар, Мәхмүт тәмәке кабызды.

— Сөйлә, Миша. Беркемгә дә әйтмәм.

— Мин рәсем ясарга кинәт кенә өйрәнеп китмәдем, әлбәттә. Башта — ул вакытта миңа сигез яшьләр тирәсе — шешә этикеткалары, шырпы каплары белән мавыктым. Ишегалдын, терлек абзарларын җыештырганнан калган вакытта. Әти күрсә, орыша торган иде: җыен юк-бар җыеп йөрисең, уңмаган малай. Кирәгеңне бирәм әле мин сиңа,— дип, колакны бора иде.

— Әйе, кырыс булган әтиең.

— Шуңа күрә дә мин бар кешедән ятсына торган булып үстем. Дус-ишләр юк инде. Этикеткалар, шырпы каплары миңа барысын да алыштырды. Мин шулар белән уйнап юана идем. Кайчагында аларны күчереп тә ясаштыргаладым. Бер кызык вакыйга булды. Миңа унбер яшь иде. Өченче класста укыган чагым. Укытучы өйдән кем нәрсә тели, шуны ясап килергә кушты. Өйгә кайттым да уйланам: нәрсә ясарга:

өстәлме, урындыкмы, чуенмы?.. Өйдә беркем дә юк иде — шүрлекне актарырга керештем: акчалар! Унлыгы да бар, утызлыгы да... Акча күчереп ясасам...

— Ә кәгазь?..

— Стенада бик яхшы кәгазьгә төшерелгән портрет эленеп тора иде. Шуннан кисеп алдым. Эшкә керештем. Унлыкны да ясадым, кызыл төстәге утызлыкны да. Иртән, мәктәпкә барышлый, иптәш малай керде. «Нәрсә ясадың?» ди. Мин күрсәттем. Куркып калды бу: «Урладыңмы»? ди. «Күчереп ясадым», дим. Ышанмый... Миннән бер яшькә олырак иде, укытучыга күрсәтергә, бер мәзәк эшләргә күндерде.

Мәнә класска укытучы керде. Барысы да ясап килгән рәсемнәрен күрсәтәләр. Минә минем янга да килде. Кесәдән ялган акчаларны чыгарам да: «Әни ваклап килергә кушкан иде»,— дим. Укытучы кесәсеннән берәрлекләр, өчәрлекләр, бишәрлекләр чыгара да миңа суза — нәкъ егерме биш сум. «Калганын иртәгә бирермен, янымда артык акчам юк,— ди.— Ә ясаган рәсемең кайда? Шуннан бөтен класс көлеп җибәрмәсенме — иптәш малай барысына да чишкән».

Завуч янында да әллә ничә тапкыр булырга туры килде аннары, директор янында да. Хәтта район үзәгенә дә чакырдылар. Прокурорга! Ялган акчаларны үзенә алды... Урамга чыгар хәл юк — хатын-кызлар бармак төртеп күрсәтәләр: акча ясаучы малай, дип.

— Өйдә дә эләккәндер!

— Өйдә дә эләкте, әлбәттә. Әмма укытучыларның карашы үзгәрде. Мәктәпне бизәр өчен бик күп рәсемнәр ясый идем. Җидееллыктан соң художество училищесына җибәрделәр.

— Буш кул белән укырга барып булмый бит...

— Бәла да шунда. Аякта чабата. Ертык бишмәт. Әмма яраткан эшең буенча белем аласың. Ничек кирәк алай ерып чыктым.— Аннары Усманов кинәт кенә утырган урыннан торды да, ярым пышылдап:

— Кара аны, акча турында беркемгә дә әйтмә...

Тиздән дусларны аердылар: Усмановны дивизия газетасына алдылар.

Шулай да алар очраштылар. Сугыш башланды. Бу вакытта Качур взвод белән командалык итә иде, ә Усманов — шул ук дивизиядә художник...

*

* *

Дуслар тын гына баралар да баралар. Һәрберсе үз уена чумган. Ә һәркемнең күңелендә шатлык түгел хәзер: фашистлар Киевне, Житомирны, Севастопольне бомбага тоталар... Халкыбызга зур зыян китерде инде алар. Нәрсә көтә сугышчыларны алда?! Билгесезлек. Нинди ул дошман, күпме алар, ни белән коралланганнар?..

Кемдер грузин акценты белән әйтеп куйды:

— Ә алдагы урманда немецлар урнашкандыр? Тупларын, пулеметларын безгә төбәгәннәрдер?

— Разведкасыз алга бармас идек,— диде артына борылып Качур, кырыс кына.

Юлның һәр ягында да иксез-чиксез арыш басуы җәелеп киткән. Өлгергән арыш башаклары җиргә иелгәннәр, әйтерсең үзләрен әлегә кадәр урып-җыярга керешмәгәнгә алар гаҗәпләнәләр. Ә күктә, биектә, табыш эзләп тилгән оча. Еракта, аяз күк белән офык тоташкан урында, зәңгәрләнеп урман күренә. Хәер, урман да булып чыкмады ул — бакчаларга күмелгән авыл икән.

— Полотно өчен матур пейзаж,— дип уйлап куйды Усманов.— Нинди генә төсләр юк! Шулай да Татарстан урманнары матуррак.— Туган якны сурәтләп полотно язасы иде!

...Кинәт авыл өстендәге күк йөзендә кара таплар пәйда булды. Алар күз иярмәс тизлек белән зурайдылар, козгын сурәтенә керделәр. Ямьсез улау тавышы яңгырады.

Колонна өстенә җитәрәк, самолетлар кинәт юнәлешләрен үзгәрттеләр. Беренче килгәне колонналарга каршы пикега күчте.

— Һава! — дип кычкырдылар сафлар буйлап. Сугышчылар арыш арасына ташланды. Юлда һәм юл тирәләрендә бомбалар төшеп шартлады, аннан «козгын»нар пулеметтан сиптерергә керештеләр. Мәхмүт, үзе дә сизмәстән, һөҗүм итүче һава

пиратын хәтерендә калдырырга теләп, торып басты. Әмма кемдер аның җилкәсенә каты итеп сукты, Мәхмүт егылды.

— Тормыштан туйдыңмы әллә, акылдан язган нәрсә!.. Якында гына көчле шартлау ишетелде, җир тетрәп куйды, баш өстеннән сызгырышып бомба ярчыклары узды, гимнастеркаларга тузан кунды, кантар өерләре бәрелде.

Самолетлар кабат әйләнеп килгәнче, якында гына бомба төшеп шартлаган урынны карадылар. Ун метрлап кына ераклыкта ыржаеп зур һәм тирән чокыр күренде.

— Аңлыйсыңмы инде хәзер,— диде Качур дустына,— көлең күккә оча иде бит.

— Әйе, күңелле күренеш түгел.

— Булыр сиңа күренеш,— диде Петя, гимнастеркасын кага-кага.— Кечкенә генә калкулык, ә астында синең гәүдә.

Ул арада «мессер»лар кабат әйләнеп килеп җиттеләр.

— Ятыгыз, егетләр,— дип боерды Качур, ә үзе арыш арасында ниндидер сугышчының башын бәйләп яткан ике солдат янына йөгерде.

Усманов янышнан кечкенә генә буйлы бер кызылармеец йөгереп узды. Ул юлда туктап калган машина әрҗәсенә сикереп менде дә дүрт көпшәле зур калибрлы пулеметны колонна өстенә төшеп килүче «мессер»га төбәде. Яшь кенә сугышчы һава крепостена каршы чыкты! Моны төшеңдә дә күрмәссең! Мәхмүт бу күренешнең һәр детален күңелендә калдырырга тырышты, юлга якынрак шуышты. Алай гына да түгел, чүмәшеп, альбомын чыгарды. Сугышчының тәвәккәл йөзе аңа ачык күренә иде, ул кәгазьгә күчте. Бу арада сугышчының куллары да, йөзе дә дерелдәргә кереште. Мәхмүт баштарак пулемет текелдәвен дә ишетмәде: үз эшенә чумган иде.

Юл буенда берничә бомба шартлап ярылды, автомашина кабинасы тәрәзәләрә бомба ярчыклары, фашист пулеметы пулялары тиеп коелып төште. Юлда, арыш басуы өстендә тузан катыш сөрем күтәрелде. Мәхмүт кыю сугышчы йөзендә, аның күзләрендә, һәр хәрәкәтендә дошманга чиксез нәфрәт, ярсу ташкынын күрде.

Кинәт кенә тынып калгандай булды. Ә «мессер» койрыгыннан кара төтен калдырып, читкә китеп бара иде.

— Ур-ра-ра! — кычкырыштылар сугышчылар. Әмма шатланырга иртә иде әле. Дошман самолетларының яңа өере килеп җитте. Яңадан ятарга боерык булды. Борынын аска караткан яңа «мессер» безнең сугышчылар өстенә ут һәм корыч сибәргә кереште. Ара якынайганнан-якынайды. Ә теге сугышчы дуэльне дәвам итә иде әле. Аның төз атылган пулялары бу козгынны да качарга мәҗбүр итте.

Санитарлар яралыларны бәйләгән арада, күп кенә сугышчылар бәреп төшерелгән самолетны карарга китте. Усманов та аны карандаш белән альбомга төшереп алды. Бәреп төшерелгән фашист самолетын беренче генә күрүләре иде әле. Художникны бигрәк тә гаҗәпләндергәне шул булды, янып бетә язган комбинезон кигән фашист очучысының сөремгә баткан йөзе ерткычнныкы кебек усал иде.

— Җаны-тәне белән фашист инде бу,— диде кемдер.

— Моны исегездән чыгармагыз,— дигән тавыш ишетелде. Полк командирының политик эшләр буенча урынбасары Науменко әйтте бу сүзләрне.— «Җаны-тәне белән фашист». Дошман очучысын бик яхшы характерлый бу сүзләр. Хәтта үле йөзендә дә аның безнең тыныч халыкка нинди яман нәфрәт сизелеп тора. Мондый фашист барысына да — илебезнең авылларын һәм шәһәрләрен бомбага тотарга да, гаепсез ата-аналарыбызны, хатын-кызларны, балаларны атып үтерергә дә сәләтле.

— Әйе, фашист дәһшәтле,— дип сүзгә кушылды сугышчылар янына килгән дивизия командиры генерал-майор Рогачев. Аның самолеты да дәһшәтле. Ә безнең кызылармеец Кольчак аңа караганда да дәһшәтлерәк булып чыкты. Кайда әле ул?

Сугышчылар кечкенә буйлы яшь кызылармеецка уртага үтәргә юл бирделәр.

— Молодец, Яша. Күрсәттең үзеңне.

— Орден инде сиңа!

— Юк, герой бирерләрдер.

— Битләреңне сөрт, пычранып беткән бит. Генерал үзе чакыра.

Яша Кольчак, иптәшләренең бу шаярту сүзләреннән оялып, кызарынды. Генерал алдына ул, гаебе өстендә тотылган малай кебек, килеп басты.

— Алтын егет син, кадерлем,— дип, Яшаның кулын кысты генерал.— Батырлыгың өчен рәхмәт!



*Советлар Союзы Герое Я. Кольчак*

...Олы юлга чыкканда кемдер генералга дивизия художнигының Кольчак белән «мессер» дуэлен рәсемгә төшереп алганын әйткән. Усмановны дивизия командиры янына чакырдылар. Генерал альбомнан озак күзен алмый торды.

— Егет икәнсең,— диде ул аннары,— шундый ыгы-зыгы вакытында барын да төгәл сурәтләгәнсең. Дивизия газетасына басып таратырга кирәк. Йөзләрчә, меңнәрчә сугышчыларның рухын күтәрсен! Зур эш эшләгәнсең!

* * *

169 нчы дивизияне, тулыландыру өчен, Астрахань шәһәре янына китерделәр. 1942 елның җәйге бер киче иде. Дивизия фотографы Аристрах Бегунов Мәхмүт Усманов палаткасына ашыкты.

Рәссам рәсемнәрен тәртипкә салып утыра иде.

— Клубта графика күргәзмәсе оештырырга куштылар,— диде Усманов, фотографның сораулы карашына җавап итеп.

— Шәп эш. Хәзер бигрәк тә вакыты. Полкларга яшь сугышчылар килә.

Бегунов бирелеп рәсемнәрне карарга кереште. Менә уйсу урындагы үлән арасында тамашачыга аркасын куеп бер сугышчы ята. Күзләре Дегтяров пулеметының мушкасына текәлгән. Юлдан зур тизлек белән килүче немец мотоциклчылары өчен бу засада көтелгән хәл түгел. Алар пулеметчы А. Нигъмәтовның төз атылган пуляларыннан яр астына бер-бер артлы тәгәриләр.

— Бу Винница янындамы?

— Юк, Харьков янында. Ново-Николаевка авылы тирәсе.

— Ә монысын беләм, Запорожье янында булды,— диде Бегунов, бер төркем автоматчыларның алга, атакага ыргылуын сурәтләгән рәсемгә күрсәтеп.— Исеме «Контратака».

— Әйе, шунда булды,— диде Усманов, авыр сулап.— Кызганыч, Харьковны да, Запорожьены да саклап калып булмады...

— Кичә Качурны күрдем әле,— дип, аннары сүзне икенчегә борды Мәхмүт.— Алар полкына барырга туры килде. Мыегыннан гына танадым. Ябыккан.

— Нәрсә ди?

— Йоклап булмый, ди. Фронтка ашкына.

— Кендегеңнән югары сикереп булмый шул,— диде Бегунов салкын гына.— Ни эшләргә кирәклеген начальство яхшы белә.— Аннары ул Усмановның җилкәсенә кулын салды:— Әйдә киногa киттек.

— Минем дә эш бетеп килә... Нинди фильм?

— «Волга-Волга». Киносында гына эш түгел. Син фотограф Марияне беләсеңме?


— Беләм, ди.

— Ә аның сеңелесен?

— Әллә аның сеңелесе дә бармы?

— Нинди генә әле! Укытучы булып эшли булса кирәк! Рәсемне дә ярыйсы гына маташтыра икән. Мария күрсәткән иде. Әмма эш анда түгел. Сиңа кәләшлеккә менә дигән...

...Алар килгәндә, клубка кертмиләр иде әле. Ишек төбенә халык җыелган. Менә ике кыз килеп чыкты. Берсе Мәхмүткә таныш — Мария. Икеләнеп торасы юк, димәк, икенчесе — буйга озынрагы аның сеңелесе — Зоя.



*Бәреп төшерелгән фашист самолеты*



— Таныш булыгыз. Минем дустым Миша.— Бегунов Мәхмүтне алгарак этәрде.— Безнең дивизиянең художнигы.

— Сездә художниклар да бармыни? — дип елмайды Мария һәм күрешергә дип кулын сузды.

— Әлбәттә,— дип җавап кайтарды Бегунов.— Иртәгә клубка килегез. Аның күргәзмәсе ачыла.

Зоя кара тут йөзле кызылармеецка кызыксынып күз сирпеп алды. Әмма күрешергә кулын бирмәде. Башын гына кагып куйды да исемен әйтте.

«Горур кыз,— дип уйлады Мәхмүт.— Әмма чыннан да чибәр икән».

Мәхмүт иртәдән кичкә тикле частьларда йөрде, кичләрен клубта эшләде. Ә күргәзмә уңышлы үтте. Сугышчыларга зур тәэсир ясады. Клубтан чыккач, төркем-төркем җыелышып тәэсирләрен уртаклаштылар.

Күргәзмә Зояга да ошады. Ошады гына түгел, чын-чынлап дулкынландырды. «Боларны турыдан-туры алгы сызыкта ясау өчен нинди зур тәвәккәллек кирәк»,— дип уйлады ул...

Әмма 1942 елның җәендә алар аерылыштылар. 169 нчы дивизия Сталинградка — фронтка китте. Зоя Мәхмүтне озата да алмады — окоп казуда иде...

*
* *

Мәхмүт Усманов хезмәт иткән генерал Рогачев дивизиясе Идел буендагы сугышларда немец-фашист гаскәрләрен тар-мар итүгә зур өлеш кертте. Дивизиянең күп кенә сугышчылары: руслар, украиннар, татарлар, казакълар — төрле милләт кешеләре — үзләрен чын герой итеп күрсәттеләр. Аларның исемнәре генә түгел, йөзләре дә Мәхмүт Усманов портретлары аша бөтен дивизиягә танылды. Бу портретларны ул кайда туры килсә, шунда ясады: алгы сызыкта да, блиндажда да, бомба төшеп җимерелгән бина эчендә дә. Әмма ул Сталинградта рәссам гына түгел иде — аңа бик еш кына урам сугышлары вакытында йөгерә-йөгерә, бер кулына пистолет, икенче кулына буяулы чиләк тоткан килеш ярым җимерек стеналарга зур хәрефләр белән: «Фашистларга үлем!»; «Алга, көнбатышка!»; «Җиңү безнең якта булыр!» кебек лозунглар язарга да туры килде.

Бу кыска, әмма үткен сүзләр сугышчыларны тәвәккәллеккә, фидакарьлеккә рухландыра, аларда җиңүгә ышанычны арттыра иде...

*
* *

...Дошман гаскәрләре Идел ярында тар-мар ителде. Әмма ул мәкерле һәм көчле иде әле. Туган илнең һәр карыш җирен кан түгеп азат итәргә туры килде. Дошманны тизрәк тар-мар итү, җиңү өчен бер батырлык, кыюлык кына җитми, хәйләкәрлек тә кирәк иде. Мондый хәйләкәрлек белән бигрәк тә разведчиклар дан казанды.

Дивизиядә баһадир гәүдәле, бинибая көчле, тәвәккәл, җитез һәм кыю Феофан Кочуренко дигән разведчик бар иде. Ул дошман тылына да автомат белән түгел, Дегтяров кул пулеметы белән йөрде. Рядовой солдат вакытында да «тел»нең «вактөяген» түгел, зуррак чинлысын алып кайта иде. Үзе дә бик тиз күтәрелде. Башта взвод белән командалык итте. Белоруссиягә кергәндә инде рота командиры булды. Шулай да дошман тылына «ауга» йөрүен ташламады.

Дивизия штабында Мәхмүт Усмановка газета өчен соңгы сугышларда батырлык күрсәткән сугышчылар портретларын ясарга задание бирделәр. Исемлектә Кочуренко да бар иде.

Кочуренконы ул окопта эзләп тапты. Аның киң күкрәге орденнар белән тулы иде.

— Ә художник! — дип мөлаем елмайды ул һәм бармак сөякләрен сындырырдай итеп Мәхмүтнең кулын кысты.— Сезнең белән танышуыма бик шат.— Хәер, газеталар буенча сезне мин күптән беләм. Рәсемнәрегез менә дигән чыга!

Феофан Петр Качур полкында хезмәт итә икән. Әйе, әйе, хәзер Петр Васильевич Качур полк командиры булып күтәрелгән иде инде. Феофан, портретын ясап бетергәч, полк командирын ничек табарга икәнен әйтте.

Блиндаж баскычыннан төшкәндә үк, Мәхмүт Качурны тавышыннан таныды.

— Артиллерия әзерлегеннән соң ук атакага! — дип кычкыра иде ул телефон трубкасына, аннары Мәхмүткә таба борылды.

Шактый үзгәргән иде Петр Качур. Олыгайган. Ә мыегы һаман Чапаевныкы кебек. Ә орденнары... Кочуренконыкыннан ким түгел.

— Миша!.. Дустым!.. Күрешмәгәнгә күпме инде! Ничек килеп чыгасы иттең? — Ул торып Мәхмүтне кочаклады.

— Синең егетләрнең рәсемнәрен ясадым.

— Алар моңа лаек!

— Командирларыннан үрнәк алалардыр.

— Кызганыч, вакыт юк,— дип чыраен сытты полк командиры. Очрашуны билгеләп үтәсе иде дә бит...

— Рәхмәт, Петя! Без инде Кочуренко белән билгеләдек.

— Шәп егет! — диде Качур, мыегын боргалап.— Геройга тәкъдим иттек. Нигә аяк өстендә торасың? Утыр! — һәм ул буш әрҗәгә төртеп күрсәтте.— Зоядан хат киләме?

— Язгалый!

— Әйбәт кыз. Ычкындырма, фашистларны җиңгәннән соң шундый итеп туй итәрбез!.. Тагын нинди яңалыкларың бар?

Мәхмүт папиросын йомшатты да авызына капты.

— Маруся үлгән...

— Ничек үлгән? — Качур хәтта утырган урыныннан сикереп үк торды.

— Үпкәсенә салкын тигәндер...

— Кызганыч, акыллы хатын иде.

Амбразурадан артиллерия гөрелтесе ишетелде. Полковник аягүрә басты, кобурасыннан пистолетын алды.

— Менә шулай инде ул фронт тормышы,— диде аннары һәм тагын Усмановны кочаклады.— Ярый, Миша, пуля астына барып кермә! Гомереңне сәнгать өчен сакла...

Һәм ул блиндаждан йөгереп чыгып китте...

*
* *

Белоруссиядә, Днепрны кичкәндә, каты сугышлар барган чакта Мәхмүт Усманов чын сәнгатьчә эшләнгән картиналар һәм зарисовкалар иҗат итте.

Менә шуларның берсе. Ул «Днепр өчен сугыш» дип исемләнгән. Анда фашист



*Днепр өчен сугыш*

танклары белән бәрелешнең иң кискен моменты сурәтләнә. «Тигр»лар безнең подразделение урнашкан рубежга дәһшәтле көч булып ыргылалар. Рәссам якын ук килеп өлгергән фашист танкысының төз атылган снарядтан шартлау күренешен чынбарлыктагыча биргән. Биредә фашист «тигр»ларының каберлеге. Туры наводка белән атылган ике снаряд шартлаудан ут, төтен баганалары күтәрелгән — совет артиллериясе немец танкларын җимерә. Металл яна, фашист аяк астында җир яна. Исән калган немец солдаты, паникага бирелеп, яна торган танктан җиргә сикерә.

Үлем белән бәрелеш вакытында ут һәм төтен арасыннан сугышчы рәссам Мәхмүт Усманов, снайпердай үткен күз белән, бөек һәм героик мизгелне тотып ала белә. «Старшина П. Чумаков «тел» алып кайта», «Г. Гафиятуллинның батырлыгы» һ. б. бик күп картиналар шундыйлардан...

Днепр өчен сугышлар гаять авыр булды.

Феофан Кочуренко... Бу куркусыз каһарман туган Днепрын азат итү өчен гомерен бирде [1].

Герой кабере янында полк командиры Петр Васильевич Качур Феофан Кочуренко һәм башка һәлак булган геройлар өчен барлык сугышчылар исеменнән үч алырга ант итте. Һәм чыннан да Качур командалыгындагы полк һәр вакыт алда булды — беренчеләрдән Днепрны кичте, Бобруйск шәһәренә бәреп керде.

Шәһәрдә дошман бик күп ут нокталары корган һәм техника туплаган иде. Сугышчылар ашкынып атакага ташланды. Бер сугышчының пуля тиеп кулбашын яралады. Ул туктап калды һәм икенче кулы белән җилкәсен тотты. Нәкъ шул вакытта сулдагы куаклык артыннан үзйөрешле немец тубы килеп чыкты. Әмма сугышчы югалып калмады, авыртуны да онытып, гранатаны тезләре арасына кыстырды да исән кулы белән аның алкасын тартып чыгарды. Кинәт көчле шартлау яңгырады. Сугышчы һәлак булды, фашист машинасының да гусеницасы өзелде.

Мәхмүт сугыш кырына килгәндә, дошман чигенергә мәҗбүр булса да, атышлар тукталмаган иде әле. Бобруйск юлы буйлары фашист мәетләре, җимерек танклар, автомашиналар белән тулы. Кайчандыр чәчәккә күмелеп утырган аланлыклар снарядлар, миналардан актарылып беткән, урман агачлары чәрдәкләнгән, янып көйгән.

Бер аланлыкта — солдатлар төркеме. Уртада ике санитар кайнаша. Кемдер әйтеп куйды:

---

[1] Феофан Кочуренкога үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеме бирелә.



*Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллинның батырлыгы*

— Полк командирын үтерделәр... Качурны...

— Нәрсә? — Мәхмүт шулай дип ярсып кычкырды да төркем уртасына атылды.

Петр Васильевич носилкада ята иде. Йөзе танырлык та түгел — кан гына. Хәтта күзләре дә күренми. Полковник, ниндидер сизгерлек белән, үзенә куркынып һәм сыкрап карап торган дустын таныды. Зур кыенлык белән уң кулын күтәрде, Мәхмүт тиз генә аны тотып алды. Качур нәрсәдер әйтергә теләде, әмма тамагыннан гырылдау авазы гына чыкты, чәрдәкләнгән иягеннән кан бөркелде.

Ниндидер көч Мәхмүтнең күкрәген кысты, сулыш алуы авырайды, күз аллары томаланды... Ул дустының кулын тоткан килеш елады... Бәлки ул аны соңгы юлга озата торгандыр...

*
* *

Мәхмүт алгы сызыкта үз эше белән мәшгуль иде, ә укчы рота атакага сигнал көтә. Мөгаен, дошманга безнең подразделениенең урыны билгеле булгандыр — кинәт окоплар тирәсендә снарядлар һәм миналар ярыла башлады. Усманов шуны гына хәтерли: ачы чинаган тавыш һәм каты гөрселдәү... Ул госпитальдә генә аңына килде. Гаҗәпләнүчеләр дә булмады түгел башта, әлбәттә: офицерлар палатасында — берсдәнбер рядовой солдат. Баш очындагы тумбочка өстендә яткан калын папканы ачып карагач, аңа карашлар үзгәрде. Терелә башлау белән, аны эшкә күмделәр: һәркемнең үз портретын ясатасы килә иде.

Көннәрдән бер көнне Мәхмүт, койкага утырган килеш, яралы бер офицерның портретын эшләп утырганда, палатага җилкәләренә ак халат салган ике хәрби кеше

килеп керде. Рәссам шунда ук урыныннан торып аларга каршы атлады. Аристрах Бегунов һәм политрук Козельский аның белән кочаклашып күрештеләр. Аннары күчтәнәчләрен чыгарып салдылар.

— Авыру булсаң да, Миша, сиңа биергә туры киләчәк, — диде политрук, елмаеп, һәм аңа ике хат сузды. Берсе Зоядан, икенчесе — Татарстаннан — сеңелесеннән иде. Мәхмүт, шатлыгын яшерергә тырышып, хатларны ашыгып кесәсенә салды.

— Миндә дә сиңа яңалык бар,— дип, Бегунов Усмановка бер бит кәгазь сузды. Бу — Мәхмүт Усмановны, армия художнигы итеп, өченче Армия штабына күчерү турында армия генералы А. В. Горбатов приказы иде...



*
* *

Армия газетасы редакциясендә эшләү тагы да катлаулырак булып чыкты: командировкаларга ешрак йөрергә, батырлык үрнәкләре күрсәткән сугышчыларның портретларын, аерым сугыш күренешләрен күбрәк ясарга кирәк иде. Армия зур тизлек белән көнбатышка ашкынды. «Дошманны көнен дә, төнен дә көнбатышка куабыз, — дип язды Мәхмүт Зояга җибәргән хатларының берсендә. — Аны рәхимсез кыйныйбыз... Бик күп эшләргә, язарга туры килә. Һәм мин ару-талуны белми эшлим».

...һәм менә, ниһаять, күптән көтелгән көн җитте!.. Очлы манаралы куполлар күккә оча, калын диварлар җимерелә, фашистлар тәягән тимер вагоннар авып ята. Анда да, монда да фашист мәетләре тәгәрәгән. Мәхмүт Усмановның «Үч» зарисовкасы шуларны сурәтли. Анда Берлинның бер өлеше чагыла. Рәссам фашист ерткычларны өнен яулап алу моментын тасвирлый. Без бу зарисовканы карагандa, рейхстаг түбәсеннән җимерек Берлин панорамасын альбом битенә төшерүче рәссам образын да күрәбез...

*
* *

Җиңү шатлыгы әле дәвам итә. Һәркайда тыныч хезмәткә кайткан солдатларны кочак җәеп каршы алалар. Мәхмүт тә шундый көннәрнең берендә Минск шәһәрендә вагоннан төште. Монда да фронтовиклар — кадерле кунак. Алар чиста итеп кырынганнар, яңа, спай формадан. Күкрәкләрендә — орден-медальләр. Ә Мәхмүтнең күкрәген сигез хөкүмәт бүләге бизи. Ул инде офицер.

Кинәт ул баскан урынында катып калды: вагон янында кулына чемодан тоткан мыеклы полковник басып тора. Йөрәк еш-еш тибәргә тотынды. Полковникның да күзләре Мәхмүткә төште.

— Мишка!..

— Петька! Син исәнмени?..

Җыелган халыкка да игътибар итмәстән, алар бер-берсен кочакларга, үбәргә башладылар.

— Мин бит сине бу дөньяда очратырга уйламаган да идем инде,— диде Мәхмүт, Качурның күкрәгенә төрткәли-төрткәли.

— Әйе, шартлагыч пуля иякне җимергән иде... Хирурглар тырышты, малай. Стройга кайттым, Эльбага барып җиттем.

— Син дә анда булдыңмыни?

Дуслар тротуар буйлап киттеләр. Ә күктә тыныч май кояшы көлә, агачларда чыпчыклар чыркылдаша, тирә-якта гамьсез балалар уйный. Дүрт ел буена һәр көнне, һәр төнне үлем күзенә карап үткәргән солдат өчен болардан да кадерле нәрсә бар икән!..

Белоруссия хәрби округы командующие приказы белән Мәхмүт Усманов Минск шәһәрендәге Кызыл Армия йортының өлкән художнигы итеп билгеләнгән иде. Ярдәмчеләре — унике художник белән ул җиң сызганып эшкә керешә. Аның катнашында оештырылган фронтовик художниклар күргәзмәсе Мәскәүдә дә, Киевта да, Львовта да булды.

1945 елның җәендә командование Зояны Минск шәһәренә чакырырга рөхсәт бирде...

...Кызыл Армия йортында үткәргән туйда Петр Васильевич Качур шундый тост әйтте.

— Чәчәкле сүзләр сөйли дип үйламагыз, дусларым... Бездәге кебек дуслык хисе беркайда да юк. Бу дуслык дүрт ел дәвамында канлы сугыш кырларында сыналды. Дошманга нәфрәт никадәр зур булса, солдат дуслыгы, хатыннарыбызга, сөйгәннәребезгә, якыннарыбызга мәхәббәт шул кадәр көчле безнең... Мин бу бокалны шул утларда чыныккан корыч дуслыкның, мәхәббәтнең ныклыгы өчен күтәрәм...

*
* *

Бер ел эшләү чорында Минскида Мәхмүт бик күп рәхмәтләр ишетте. Кыйммәтле бүләкләр, премияләр алды. Әмма халык әйтмешли, «Яхшы булса да торган җир, сагындыра туган җир»! шул.

Һәм ул 1946 елда Казанга кайтты.

Татарстан җәмәгатьчелеге Мәхмүт Усмановның фронт графикасына һәм рәсем сәнгатенә зур бәя бирде. Аның күп кенә әсәрләре 1946 елда ук Казанда үткәрелгән зур күргәзмәгә кабул ителде. Аларны «чын реализм, тирән хәрби-патриотик эчтәлек, зур осталык белән аерылып торалар»,— дип бәяләделәр. Усмановның хәрби зарисовкалары һәм картиналары алты автономияле республика күргәзмәләрендә катнашты, һәм аларны тамашачылар яратып карады.

Фронт гадәтедер инде — Мәхмүт Усманов сугыштан соң да көндәлек тормыш вакыйгаларын, бүгенге көн күренешләрен сурәтләүне үз иҗатының төп темасы итеп сайлады. Аның әсәрләрендә хәзер дә якташларының фидакарь хезмәте гәүдәләнә.

Татарстан җирендә «кара алтын» чыгаручыларның хезмәтен рәсем сәнгатендә сурәтләүгә ул зур өлеш кертте. Мәхмүт Усманов, сугыштан соң беренче булып, нефть чыккан якларга китте. «Татарстан нефтьчеләре иртәсе», «Атаклы бораулау мастеры Гимазов бригадасы», «Яңа Кама» һ. б. лар кебек менә дигән картиналар сериясе шунда иҗат ителде. Бу картиналарның барысы да зона һәм Бөтенроссия күргәзмәләрендә булды, репродукцияләре үзәк газета һәм журналларында басылды. Мәскәүдә үткәрелгән Бөтенроссия күргәзмәсендә «Татарстан нефтьчеләре иртәсе» картинасы Беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде, ә «Миңлебай газ-бензин заводы» картинасын «Зур Идел» күргәзмәсе кабул итте һәм ул хәзер дә күргәзмә фондында Мәскәүдә саклана.

Кырык беренче елның җәендә Румыния чигенә барганда, Бессарабиядәге хыялларын да тормышка ашыра ул. Республикабызның индустриаль пейзажы гына түгел, табигать күренешләре дә аның иҗатында шактый зур урын алып тора. График буларак та, рәсем сәнгате остасы буларак та, Усманов иҗатына бер нәрсә хас — оптимизм.

— Мин күргәзмә залларында тамашачының күңеле күтәрелүен телим, — ди ул.

РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Лотфулла Фәттахов Мәхмүт Усмановның «Туган як» исемле персональ күргәзмәсенә карата юкка гына: «Мәхмүт! Хезмәт сөючәнлегең, шат сәнгатең өчен зур рәхмәт сиңа!» — дип отзыв язмаган!

Мәхмүт Усмановның соңгы хезмәте — КамАЗга багышланган зур полотно — триптих. Бу әсәрдә автогигант төзелеше дә, Кама буендагы Яңа шәһәр дә, аларны төзүчеләрнең фидакарь эшләре дә калку һәм сәнгатьчә сурәтләнгән. Триптих шулай ук «Зур Идел» күргәзмәсендә уңай бәя алды.

Әйе, Иделдән Эльбага кадәр авыр сугыш юлы үткән, бала чактан ук туган халкының батырлыгы һәм фидакарьлеге турында сәнгать әсәрләре иҗат итәргә хыялланган рәссам туган ягын данга күмгән бөек вакыйгалардан читтә кала алмый. Ул хәзер дә солдат, ул хәзер дә алгы сызыкта!

**М. ХӘМИТОВ** тәрҗемәсе.

oooooooooooooo

**Габдрахман Таһирҗанов,**
филология фәннәре докторы, профессор

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ КАТЛАУЛЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**Габдрахман Таһирҗанов — гарәп һәм фарсы әдәбиятлары буенча танылган белгеч, Ленинград университетының профессоры. Борынгы фарсы-таҗик шагыйрьләре турында зур-зур хезмәтләр язу белән бергә, ул татар әдәбияты тарихы белән дә якыннан кызыксынып яши. Укучылар хәтерлидер, моннан берничә еллар элек аның «Фирдәүси һәм Колгали» исемле бер мәкаләсе безнең журналда да («Казан утлары». 1968 ел. 12 сан.) басылган иде.**

**Журналыбызның шушы саныннан без Габдрахман ага Таһирҗановның борынгы татар әдәбияты тарихына караган яңа мәкаләләрен баса башлыйбыз. Бай фәнни чыганакларга һәм яңа фактларга нигезләнеп язылган ул мәкаләләрдә күп кенә катлаулы мәсьәләләр күтәрелә, кызыклы фикерләр әйтелә. Шул ук вакытта әлеге мәкаләләрдә әйтелгән аерым тезисларның галимнең үз фикере булуын да онытмаска кирәк. Шуңа күрә җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителә торган бу мәкаләләр гыйльми нигездә фикер алышуның яңа этабы дип каралырга тиеш.**

**Редакциягә тәкъдим ителгән беренче вариантта мәкаләләр катлаулы гыйльми аппарат һәм төрле телләрдәге текстлар белән тәэмин ителгән иде. Журналның үзенчәлеген исәпкә алып, мәкаләләрне җиңеләйтеп, яңадан эшкәртеп чыгарга туры килде. Нәтиҗәдә чыганакларның исемнәре тулы бирелмичә, бары авторга яисә китап исеменә ишарә ясау белән чикләнелде, борынгы атамалар, әсәр һәм кеше исемнәре хәзерге орфографиягә якынайтылып бирелде. Редакциянең үтенече буенча, бу эшләрнең барысын да тарихчы Миркасыйм Госманов башкарды.**

**РЕДАКЦИЯ.**

## Халкыбызның этник тарихы нигезендә әдәбиятның узганына бер караш

**КЕРЕШ**

Кайбер галимнәр Казан татарларының бабалары болгарлар түгел, ә бәлки монгол-татар илбасарларыннан калган килмешәкләр дигән карашны алга сөрәләр. Татар этногенезы мәсьәләсендә мондый позициядә торучылар безнең галимнәр тарафыннан беренче планга куелган болгар теориясен күрмәмешкә салыналар.

Хәзерге татарларның бер өлешен тәшкил итүче мишәрләр хакында да сәер фикерләр әйтелгәләде. Кайберәүләр, бу төркем татарларның матди, рухи культураларын, тел үзенчәлекләрен җентекләп тикшерәсе урынга, «мишәр» сүзен борынгы бер фин кабиләсенең «мещера» дигән исеме белән чагыштыруны, тышкы охшаш-

лыктан эчке уртаклык эзләүне кулайрак күрделәр. Галимнәр арасында бүгенге татарлар белән борынгы болгарларның тел җәһәтеннән якынлыгын инкарь итәргә тырышучылар да юк түгел. Мисал өчен әллә ни ерак барып тормыйча, 1970 елдан бирле чыгып килгән «Советская тюркология» журналындагы кайбер материаллар белән танышу да җитә. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы һәм Алтын Урда чоры Идел буе әдәби әсәрләренең телләре белән хәзерге татар теле арасындагы уртаклыкны күрүдән баш тартучылар да шактый... Мондый карашларның нигезендә «татарлар элекке монгол-татар яулап алучыларның калдыклары, димәк, мәдәниятсез, кыргый кавемнәрнең варисы» дигән тенденция ятуын, яисә аларның гомуми җирлексез, аерым фактларга ябышып ятудан туган адашу икәнлеген исбат итүе артык кыен булмаса кирәк. Хәер, беренче тенденциянең дә ахыр чиктә фактларга формалистик мөнәсәбәттән килеп чыгуы артык зур сер түгел (әйтик, урта гасырлардагы монгол телле «татар» белән хәзерге төрки телле татар арасына төрле форма, төрле алымнар ярдәмендә тигезлек билгеләре кую...). Ә мондый алымның, ягъни аерым, ялгызак фактлар нигезендә зур нәтиҗәләр чыгаруның ялгыш кына түгел, хәтта зарарлы да булуы күптән мәгълүм. Заманында, фактлар белән эш итү мәсьәләсенә махсус тукталып, В. И. Ленин болай дигән иде:

«Вак-төяк фактлар, әгәр тулаем бәйләнешеннән аерым алынсалар, әгәр алар өзек-өзек һәм теләсә ничек итеп алынсалар, нәкъ менә уенчык яки тагы да начаррак бернәрсә булалар...

Моннан чыга торган нәтиҗә ачык: төгәл һәм бәхәссез фактлардан шундый фундамент салырга тырышырга кирәк... Бу чын фундамент булсын өчен, аерым фактларны түгел, бәлки тикшерелә торган мәсьәләгә кагылышлы фактларның бөтен җыелмасын алырга, берсен дә төшереп калдырмаска кирәк» (В. И. Ленин. Әсәрләр. 23 том. Казан. 1960 ел. 295—296 битләр).

В. И. Ленинның бу фикере бер бүгенге көннең иҗтимагый-политик күренешләре өчен генә түгел, бәлки борынгы чорга караган тарихи мәсьәләләрне, җөмләдән, халыклар формалашуын, аларның матди һәм рухи культураларын, телләрен һәм әдәбиятларын өйрәнү өчен дә зарури. Халкыбызның килеп чыгышын ачыклаган чакта без, бер язма истәлекләр яисә гореф-гадәт күренешләре белән генә чикләнмичә, бүгенге фәннең күп төрле тармаклары ирешкән казанышларның барысыннан да төгәл файдаланырга тиешбез. Әйтик, урта гасырларда Идел буенда яшәгән халыклардан хазар, болгар, буртас, угыз, кыпчак һәм монгол-татарлар турында гарәп-фарсы, әрмән, Византия тарихчылары һәм географлары хәбәрләрен, рус елъязмаларын җентекләп өйрәнү өстенә, элекке төрки кабиләләренең телләрен, шул телләрдә иҗат ителгән (сакланып калган) истәлекләрне энәсеннән-җебенә кадәр белергә кирәк. Моннан тыш, без гаять әһәмиятле археологик табылдыкларны, төрле характердагы этнографик материалларны үзләштерергә, шулай ук топонимик мәгълүматларны барларга, ниһаять, халыкларның тышкы кыяфәтләрен (физик типларын) өйрәнүче антропология белеменең нәтиҗәләрен дә игътибарга алырга тиешбез. Бары шулай эшләгәндә генә без халык тарихын, аның матди культурасын җентекләп өйрәнүдә сизелерлек казанышларга ирешә алырбыз. Бары шундый күпьяклы эзләнүләр алып барганда гына социаль үсешнең, иҗтимагый тормышның бер җимеше булган әдәбият тарихын чагыштырмача төгәл һәм гадел яктырта алырбыз.

Дөрес, борынгы чордагы әдәби процессны тикшергәндә тагы өстәмә таләпләр дә туа. Мәсәлән, бер-берсенә якын, кардәш телләрдә иҗат ителгән борынгы әсәрләрнең миллилеген ничек ачыклап, соңгы дәверләрдә оешкан милли әдәбиятларның чикләрен ничек билгеләргә? Мәгълүм булганча, бу сорауларга төгәл җавап бирер өчен, гадәттә, түбәндәгеләрне ачыклау зарури: шагыйрь яки әдип кайда, кайсы халык арасында туып үскән яисә иҗат иткән; әсәр нинди телдә язылган яисә кайсы конкрет тел-шивә мохитында сакланып калган; истәлектә нинди конкрет төбәкнең табигате сурәтләнеп, кайсы халыкның гореф-гадәте, тарихи шартлары чагылыш тапкан һәм башкалар. Менә шушы сорауларның һәммәсенә яки ким дигәндә зур өлешенә җавап биргәндә генә мәсьәләне азмы-күпме дөрес хәл итәргә мөмкин. Кызганычка каршы, аерым-ялгызак сорауларга җавап китерү белән генә дә мәсьәләне кырт кисеп куярга омтылулар шактый. Фикеребез дәлилле булсын өчен, тугандаш әдәбиятлар практикасында булган кайбер гыйбрәтле мисалларга мөрәҗәгать итик.

1967 елда «XI—XVII гасыр төркмән әдәбияты шагыйрьләре» исемле китап басылып чыкты. Анда, төркичә иҗат иткән шагыйрьләр белән беррәттән, хәзерге Төркмәнстан туфрагында яшәп, фарсы телендә иҗат иткән шагыйрьләр дә, чыгышлары буенча төрки халыклардан булып, Иран һәм Һиндстанда фарсыча әсәр язган авторлар да, көньяк Кавказда яшәгән Ак Куюнлы, Кара Куюнлы ханнары да, Әхмәд Ясәви кебек Төркстан һәм Харәзем шагыйрьләре дә асыл төркмән шагыйрьләре рәтенә кертелә. Моннан тыш, кайбер тюркологларның «харәземле түгел микән» дигән фаразларына гына таянып, Кол Гали белән Котбны да шул төркемдә саныйлар.

Үзбәк әдәбияты тарихы буенча чыккан китапларда да сәер фактлар шактый. Мәсәлән, Мәхмүд Кашгари белән «Котадгу белек» авторы Йосыф Хас Хаҗиб, «Һибәтел-хәкаикъ» (дөресе «Гыйбәтел-хәкаикъ» — Г. Т.) әсәрен язган Әхмәд Югнаки, болардан тыш, Әхмәд Ясәви, Насретдин Рабгузи, Котб, Сәйф Сараи һәм тагын бик күпләр бары тик үзбәк шагыйрьләре сыйфатында гына тәкъдим ителгән.

Мондый алым теге яки бу авторның кайсы халык арасыннан чыкканлыгын ачыклау өчен яраса да, бер билгеле иҗатның нинди конкрет милли әдәбият процессына каравын дөрес билгеләүдә җитәрлек дәлил була алмый. Чөнки урта гасырларда еш кына хөкүмәтләр алышынып, дәүләт чикләре сүтелеп, милләт булып формалашып өлгермәгән халыкларның этник бердәмлеге бер җимерелеп, бер тергезелеп, гел үзгәреп торган, бер әдәби телдә төрле-төрле этник группаларның вәкилләре иҗат иткән. Менә шуңа күрә бары бер генә территориаль яисә бер генә ыру-кабилә принцибын алга сөрү мәсьәләне төгәл, гадел чишеп бетерә алмый. Чөнки территория чикләре белән этник география һәм политик-иҗтимагый шартлар күп очракта тәңгәл, тигез булмаган. Шуңа күрә иҗтимагый шартлар тәэсирендә, терекөмеш кебек, гел үзгәреп, гел төрләнеп торган җанлы организмны — әдәби хәрәкәтне соңгы дәвердә барлыкка килгән шартлы географик кысаларга куып кертү буталчыклыктан башка һичнәрсә тудырмый. Моның шулай икәнлеген таҗик әдәбияты тарихында булып узган кайбер тенденцияләр мисалында да ачык күрергә мөмкин. Мәсәлән, илленче елларда урта гасыр фарсы-таҗик әдипләрен бер милли-территориаль нигездә генә аерып карау, борынгы чорда ук иран телле ике мөстәкыйль милли әдәбият булу фикерен алга сөрү омтылышлары көчәйгән иде. Ләкин кайбер таҗик әдәбиятчыларының өметләре акланмады: таҗик халкы гасырлар буе үз җырчылары дип яратып укыган Сәгъди һәм Хафиз кебек Шираз (Ирандагы өлкә — Г. Т.) шагыйрьләрен, чыгышы буенча төрки, ләкин фарсыча язган әсәрләре белән бөтен фарсы-таҗик әдәбиятына көчле тәэсир ясаган һиндстанлы Әмир Хөсрәү Дәһләви, Габделкадыйр Бедил мирасын, шулай ук Әзербәйҗанда яшәгән, әмма нигездә фарсы-таҗик әдәбияты үсешенә өлеш керткән Низами һәм Хакани иҗатларын да таҗик әдәбиятының алтын фондыннан алып ташлау мөмкин түгел иде. Чөнки, киресенчә эшләсәк, дөньякүләм әһәмияткә ия бай фарсы-таҗик әдәбияты бербөтен организм булудан туктап, аерым-ялгыз авторлар, үзара бәйләнешсез әдәби факт кисәкләреннән гыйбарәт булып калыр иде. Шуңа күрә фәндә фарсы телендә иҗат иткән авторларның барысын да, чыгышлары буенча кем булуларына һәм кайда яшәүләренә карамыйча, бер зур әдәбиятның — иранлыларның, таҗикларның, әфганлыларның уртак әдәбиятының уртак вәкилләре дип карау принцибы — тарихи дөрес һәм тормышчан, гадел принцип өстен чыкты.

Урта гасырларда язылган төрки телле әсәрләрнең кайсы милләткә каравын билгеләү аерата кыен мәсьәлә. Төрки халыкларның элегрәк, нигездә, күчмә кабиләләрдән торуы, вакыт-вакыт урын-ватан алмаштырулары, үзара аралашып, хәтта буталып яшәүләре аларның этник составлары белән телләренә, гореф-гадәтләре белән фольклорына нык тәэсир ясаган, тарихи уртаклыкны, якынлыкны көчәйткән (ә кайбер очракта, киресенчә, киметкән). Шуңа күрә хәзерге төрки милләтләренең язма әдәби мирасларын билгеләгәндә, мәсьәләгә берьяклы килергә ярамый. Киресенчә, В. И. Ленин өйрәтмәләренә таянып, фактлар җыелмасы нигезендә хөкем йөртергә, катлаулы күренешләрне артык гадиләштермичә, шул ук вакытта гап-гади тормыш хакыйкатьләренә дә күз йоммыйча эш итәргә кирәк. Шулай эшләгәндә генә без үзебезне кызыксындырган сорауларның күпчелегенә чагыштырмача төгәл җавап таба алачакбыз.

Мәсьәләнең әнә шулай бик катлаулы булуын игътибарга алып, без бу күзәтүдә, аерым язучы иҗатын, конкрет әсәрләрне тикшерүдән бигрәк, шуларны тудырган

тарихи шартларга, җөмләдән, этногенез мәсьәләләренә, тел кардәшлегенә, халыклар арасындагы экономик һәм культура бәйләнешләрына, шулай ук дин һәм идеологиянең әдәби процесска ясаган тәэсиренә тукталып узуны зарури таптык.

Төрле төрки халыклар арасындагы әдәби уртаклыкка зур игътибар бирү тарихи җәһәттән күптән акланган нәрсә. Аларның тел ягыннан якынлыклары азмы-күпме белемле кешегә мәгълүм. Күп кенә төрки кавемнәренең һәм халыкларның борынгы хуннулар, Төрки каганлык, аннары Алтын Урда дәверләрендә, ниһаять, бирегә таба Россия империясе составында уртак язмыш кичерүләре дә бәхәссез нәрсәләр. Шулай ук түбәндәге принципиаль фактларны да истән чыгармаска кирәк: патшалар, ханнар, клерикаль руханилар, халыклар арасына коткы салып, аларны ызгыштырып, сугыштырып яшәргә теләсәләр дә, демократик массаларда, алдынгы карашлы укымышлыларда үзара аралашу ихтыяҗы, шундый аралашу нәтиҗәсендә туган дуслык тойгылары бетмәгән, бәлки чордан-чорга көчәйгән. Моның шулай икәнлеген яңа дәвер тарихыбыз, бүгенге тормышыбыз тулысынча раслый.

Ниһаять, бу күзәтүләрдә без феодализм чоры татар әдәбиятының башка әдәбиятлар белән бәйләнешын бөтен киңлеге белән түгел, бәлки таррак күләмдә — бары төрки әдәбиятлар даирәсендә карыйбыз. Дөрес, вакыт-вакыт гарәп-фарсы әдәбиятына да мөрәҗәгать итәргә туры килде.

## БОЛГАРЛАРНЫҢ ЧЫГЫШЫ, КАРДӘШЛӘРЕ ҺӘМ НӘСЕЛ-НӘСӘПЛӘРЕ

Миладидан[1] элек 209 нчы елда Үзәк Азиядә һәм аның көнчыгышында көчле күчмә дәүләт оеша. Бу—тарихта мәшһүр Хуннулар дәүләте була. Хуннуларның нигездә төрки кабиләләрдән торганлыгы хәзер бер тарихчыда да шөбһә уятмый. Әлбәттә, дәүләт составында башка телдәге халыкларның булуы да инкарь ителми.

Хуннулар гасырлар буена кытайлар белән сугышып яшиләр. Милади ел исәбе буенча 155 елда, кытайлар белән «сянби» дип аталган монгол телле кабиләләрнең берләшүе нәтиҗәсендә, Хуннулар дәүләте җимерелә. Һәм җиңелүчеләр, Көнбатышка таба чигенеп, Идел-Урал араларына килеп урнашалар. Күп тә узмый, җирле халыклардан угорларны, иран телле алан-сармат кабиләләрен буйсындыра-буйсындыра, алар Төньяк Кавказга килеп чыгалар, аннары Көнчыгыш Европага һөҗүм итәләр. Нәкъ менә шул яулап алучыларны көнбатыш авторлары «гуннар» дип атаганнар (бу вакыйгалар хакында совет галиме Л. Н. Гумилев хезмәтләреннән укырга мөмкин).

Хуннулар дүрт йөз елдан артык хөкем сөргәннәр, шул вакыт эчендә алар кул астында булган монгол һәм угор кабиләләренең күпчелеге төркиләшеп өлгергән булырга охшый. Хуннулар берләшмәсе составына кергән «унногундур», «уногур», «сарагур», «катрагур» һәм «савир» дигән кабиләләрнең исемнәре шуңа ишарә ясый. Шул чор тарихын җентекләп тикшергән күренекле совет тарихчысы М. И. Артамонов үзенең «Хазар тарихы» исемле монументаль хезмәтендә аларның бер өлешен төркиләшкән угорлардан гыйбарәт дип уйлый. В. В. Радлов исә «уногур»ларны ун уйгур, «сарагур»ларны сары уйгур дип аңлый. Осетин телчесе В. И. Абаевның әйтүенә карағанда, хәзерге осетин телендә төрки-уйгур тәэсире сизелә икән.

Менә шул кабиләләрдән «утигур» һәм «кутригур» дигәннәре Төньяк Кавказда яшәгән һәм, үзара берләшеп, «болгар» исемле эрерәк кавемне тәшкил иткән. Болгар берләшмәсендә шулай ук «барсула» һәм «савир» (яки «сувар») исемле нәселләрнең дә булуы мәгълүм. Бер ук вакытта болгарларның хазарлар белән тел ягыннан бик якын икәнлекләре дә исбат ителгән факт.

571—632 елларда, ягъни 61 ел дәвамында, бу хун-болгар кабиләләре Төрки каганлык (империя) составына керәләр. Бу чорда хазарлар дәүләт башындагы «нушиби» төркиләре, ә болгарлар исә «дулу» дип аталган кабиләләр белән аралашып яши. Әмма, Җонгария һәм Җидесу өлкәләрендәге дулулар дәүләт башындагы нушибиларга каршы баш күтәргәч, Төньяк Кавказдагы дулуларның җитәкчесе Кубрат мөстәкыйль

---

[1] Милади — гамәлдәге ел хисабы.

Олуг Болгар дәүләтен оештыра. Нәтиҗәдә, бу яктагы дулулар болгарлар белән нык аралашып, яңа болгар союзы туа.

Кубрат үлгәннән соң хазарлар, көчәеп, болгарларны җиңәләр. Кубратның Аспарух исемле бер улы (тюрколог Ашмарин бу исемне Ишбирде дип аңлата...), болгарларның бер төркемен ияртеп, Дунай буйларына китә. Батбай исемле икенче улы, үз кул астындагы сувар кабиләләренең бер өлеше белән хазарларга буйсынып, Төньяк Кавказда кала бирә (Нәкъ менә шул болгар-суварлардан хәзерге балкар һәм карачай төркиләре килеп чыкканга охшый. Чөнки, Артамоновның әйтүенә караганда, хәзер дә кайбер Кавказ халыклары карачайларны «савар» дип атыйлар икән.) Кубратның өченче улы исә, болгар, барсула һәм суварларның зур төркемен ияртеп, Кама-Идел буйларына күтәрелә.

Болгарларның Төньяк Кавказда ничек яшәүләре турында без Византия һәм әрмән тарихчыларының, географларының әсәрләреннән беләбез (ул хәбәрләрне Артамонов, Гумилев хезмәтләреннән табарга мөмкин). Идел буе болгарларының тарихын исә, мәгълүм булганча, гарәп-фарсы чыганаклары, өлешчә рус елъязмалары, ниһаять, археологик материаллар нигезендә тикшерәләр. Ләкин кайбер очракларда мондый мәгълүматларны тәнкыйть иләге аша уздыру җитеп бетми. Мәсәлән, урта гасыр Шәрык авторларыннан Ибне Рустә, Гардизи, әл-Истахриләр болгарлардан төньякта бәҗнәкләр (печенеглар) яши, дип язалар. XVII йөз авторы Хаҗи Хәлфә, борынгы болгарлар турында сөйләп, аларның гореф-гадәтләре, телләре русларныкына охшаган, ди. Нәкъ менә шуңа таянып, археолог А. П. Смирнов Идел буе болгарларының «бик нык славянлашкан» булуы хакында яза. Хәлбуки, Хаҗи Хәлфәнең соңгы чорда гына язылган әсәрендә борынгы Идел буе болгарларына бирерәк дәвердәге Дунай болгарларының сыйфатларын күчерүе, димәк, мәсьәләне бутавы ярылып ята. А. П. Смирнов исә, менә шул буталган фактны җентекләп тикшермичә, еракка китә торган нәтиҗәләр чыгарып ташлый, буталчык өстенә тагы буталчык өсти.

Чынлыкта урта гасыр гарәп-фарсы авторларының әсәрләрендә кайбер хәбәрләрнең буталып бирелү фактлары, анахронизмнар шактый. Моның шулай икәнлеген күренекле совет ориенталисты Б. Н. Заходер үзенең «Көнчыгыш Европа хакындагы хәбәрләрнең Каспий җыелмасы» исемле капиталь хезмәтендә (II том) тулысынча раслый. Аның ачыклавынча, X йөздә язган гарәп һәм фарсы галимнәре болгарлар, буртаслар, бәҗнәкләр һәм маҗарлар (венгерлар) хакындагы материалларның зур өлешен элгәрге чорда яшәгән Византия авторларыннан механик рәвештә күчереп алганнар икән. Менә шуңа күрә Идел буе болгарлары хакында язган Ибне Рустә һәм башкалар, дөрес фактларны хәбәр итү белән бергә, болгарлардан «төньякта бәҗнәкләр (печенег, половецлар) булуын» әйтәләр. Хакыйкатьтә хәбәрләрнең бу өлеше Төньяк Кавказ болгарларына, ягъни VI—VII гасыр болгарларына карый.

Гарәп язучылары славяннарны да, финн-угор халыкларын да «сәкалибә» («сәкъләб»нең күплек формасы) дип йөрткәннәр. Ибне Фазланның болгарларны «сәкалибә» дип атавын А. С. Смирнов славянлашуга дәлил итеп китерә. Хәлбуки, Ш. Мәрҗани үк дөрес ачыклаганча, «сәкалибә» дип гомумән төньяк халыкларын атаганнар.

Ибне Фазлан әсәрен тикшерүче А. П. Ковалевский, борынгы гарәпчә куфи язуында «р», «з», «н» хәрефләренең бер төрлерәк сурәттә булуыннан чыгып, «сувар» урынына «суван» яисә «сувaз» дип үзгәртеп укый. Шуның белән фәнгә күп кенә буталчыклар кертә. Чөнки шушы бер хәреф, дөресрәге, **шөбһәле** хәреф нигезендә кайберәүләр халыклар этногенезы кебек катлаулы мәсьәләләрдә «сувaз» һәм «чуаш» сүзләрен тәңгәлләштерү кебек зур гыйльми «гипотезалар» күтәреп чыгалар. Мәгәр, әлеге бер хәреф белән мавыгып, тарихи фон дигән иң мөһим таләпне онытып калдыралар. Шулай ук, куфи язуындагы «тъ» һәм «к» (-г) хәрефләренең охшашлыгын исәпкә алмыйча, «Белеге вар» урынына «Белтавар» дип ялгыш укып, хәзергә хәтле үзләре тудырган буталчыклыктан котыла алмыйлар. Мондый укылышның ялгыш һәм перспективасыз булуын заманында Ш. Мәрҗани дә күрсәткән иде...

Бу китерелгән мәгълүматлардан болгарларның борынгы бабалары Хунну дәүләте составына керүе, аннан соң, Төрки каганлык чорын кичереп, Идел буена килеп чыгулары ачык чалымлана. Шул ук вакытта болгарларның төрле төрки кабиләләрдән торган берләшмә булуы да бәхәс тудырмый.

Тарихи мәгълүматларны җентекләп тикшерүне дәвам итсәк, болгарларның насел-

варислары кем булуын да ачыкларга мөмкин. Бер сүз белән әйткәндә, Кама-Идел буе болгарларының төп варислары, һичшиксез, Казан татарлары. Ләкин «татарлар — Алтын Урда чоры килмешәкләре» дигән караштан арынып бетмәүчеләрнең әле дә барлыгын исәпкә алып, бу мәсьәләгә, ягъни болгар-татар кардәшлеге мәсьәләсенә махсус тукталуны кирәк табабыз. Тик, урын тарлыгын игътибарга алып, аеруча мөһим фактларны санап узу белән генә чикләнергә туры килә.

Беренчедән, антропологик фактлар бик гыйбрәтле нәтиҗә бирәләр. Мәсәлән, Идел буе татарларының бит кыяфәтләрен, физик типларын җентекләп тикшергән Т. А. Трофимова (1949 ел) хәзерге татарлар белән борынгы болгарлар арасындагы нәсел уртаклыгын тулысынча раслый. Археолог А. Х. Халиковның яңа эзләнүләре дә бу фикергә өстәмә дәлил була ала («Урта Идел буе халыкларының этногенез мәсьәләләре» дигән китапка карагыз). Мәскәү профессоры В. П. Алексеевның яңа материалларына караганда, хәзерге татарларда европеоид болгарлар, алардан элек үк Идел буенда яшәгән монгол кыяфәтле физик типларның эзләре мул очрау белән бергә, Алтын Урда чорына хас киң маңгайлы кыпчакларның мисаллары да шактый икән (әле генә күрсәтелгән китап).

Икенчедән, этнографик материаллар да бик характерлы. Мәсәлән, Ибне Фазлан сүзләренә караганда, борынгы болгарлар, соңгы дәвер Казан татарлары кебек үк, мәетләрен кабер төбендә казылган ләхеттә күмгәннәр. (Мәет күмү йоласының этногенез мәсьәләсендә иң мөһим критерийлардан икәнлеген искәртеп узу артык булмастыр.) Болгарлар Төньяк Кавказда яшәгән чакта да, Идел буена килеп төпләнгәч тә чәчләрен кырып, такыр баш белән йөргәннәр. Соңгы чор Казан татарларының да чәч йөртмәүләре мәгълүм (чәч кыру мөселманлык галәмәте генә түгел). Археологик тикшеренүләрнең нәтиҗәләренә караганда, татарларның матди культурасы да (эш кораллары, савыт-саба һәм кием-салымнары, архитектура һәм зиннәт-бизәнү әйберләре, көнкүреш сәнгате) болгар чорына барып тоташа икән. Дөрес, болгарларга хас материаль культураның кайбер элементларын күршедәге угор-финн халыкларында да очратырга мөмкин. Ләкин моннан берьяклы нәтиҗә чыгарырга ярамый, чөнки болгарларда хөкем сөргән рухи культура эзләре угро-финнарга бөтенләй диярлек кермәгән. Без язу, фәлсәфә һәм дин, язма әдәбият традицияләрен күздә тотабыз. (Болар хакында этнограф Н. И. Воробьев хезмәтләрен укырга мөмкин.)

Өченчедән, Идел буе болгарларының башка төрки халыклар белән мөнәсәбәтләре тарихын да онытмаска кирәк. Билгеле булганча, Болгар ханы Алмас угызлар башлыгының кызына өйләнгән. Ибне Фазлан илчелеге составындагы тылмач гарәпләргә угызлар белән дә, болгарлар белән дә аңлашырга ярдәм иткән. Болгарлардагы «турун» (хан нәселеннән булган түрә) һәм «тархан», «тәгин», «инал», «боерык» кебек чин-дәрәҗә сүзләренең угызларда киң таралуы әлеге фикерләрне өстәмә рәвештә дәлилли.

Святослав Болгарга һөҗүм иткәч, болгар-суварларның бер төркеме Түбән Иделгә күчеп китүе хәбәр ителә. Ихтимал, алар шул яктагы Сәксин шәһәрен төзүдә дә катнашканнардыр. Мәсәлән, Мәхмүд Кашгари Сәксинне «сувар шәһәре» дип атый. Моннан тыш, кайбер рус елъязмаларында Иделнең түбән агымындагы халыкларның «нижние болгары» дип аталуы да бик мөһим. Ә кайбер гарәп-фарсы авторлары Сәксиннең зур төрки шәһәр булуын, анда «кырык таифә угызлар» яшәвен әйтәләр. 1229 елда, монголлар һөҗүме башлангач, Сәксин халкының бер өлеше Кама болгарларына килеп кушыла. Кыскасы, болгарлар, кайбер тюркологлар уйлаганча, үз алдына аерым, бик хосусиятле бер төрки кавем түгел икән. Хәзерге татарлар да башка угыз һәм кыпчак телле төрки милләтләргә шундый ук дәрәҗәдә якын мөнәсәбәттә торалар.

Ниһаять, дүртенчедән, болгар җиренә хас топонимнарның (географик атамаларның) да гомум төрки дөнья белән тыгыз мөнәсәбәттә булуын искәртергә кирәк. Әйтик, мәрхүм эпиграфист Һарун Йосыповның ачыклавынча, болгарлар яшәгән җирләрдәге географик исемнәрнең күпчелеге Үзәк һәм Урта Азиядә яшәгән туба, тәләс, төргәш, карлук, кыят кабиләләре белән тарихи мөнәсәбәткә ишарә ясыйлар икән.

Җыеп әйткәндә, борынгы болгарларның гомум төрки дөнья белән бердәмлеге бәхәс тудырмаса, аларның бүгенге нәселләренең дә төркилек ягыннан «ялгыз утрау» булмавы һәркемгә мәгълүм нәрсә. Тел фактлары да моны тулысынча раслый, ләкин бу хакта чак кына алга таба узгач сөйләрбез.

Болгарлар бер Казан татарларының гына түгел, бәлки мишәрләрнең дә бабалары. Моны исбат итә торган фактлар шактый. Дөрес, татарларның бу төркемен, яшәгән урыннары буенча аларга соңыннан кушылган исеменнән чыгып, «мажар» яисә «мещера» белән бәйләүчеләр бар. Аларны төркиләшкән бортаслар дип уйлаучылар да очрый. Соңгы фикергә дәлил итеп хәзер мишәрләр яши торган җирләрнең кайберләрендә элек бортаслар торуын күрсәтәләр (мишәрләр хакындагы төрле карашлар белән Р. Мөхәммәдованың 1972 елда Мәскәүдә чыккан китабыннан танышырга мөмкин).

«Бортас» сүзен ишетүгә болар нинди халык соң? дигән сорауның тууы ихтимал. Әйе, хәзер мондый исемне йөртүче бер милләт тә, этник группа да юк. Мәгәр җәмәгатьчелеккә аз мәгълүм язма чыганаклар һәм башка өстәмә дәлилләр әлеге сорауга җавап табарга мөмкинлек бирә, өстәвенә «мишәр мәсьәләсен» ачыкларга да булышлык итә.

Б. Н. Заходер үзенең югарыда телгә алынган хезмәтендә бортаслар турындагы X йөз гарәп-фарсы хәбәрләренең элеккерәк чорга караган булуын, ә X гасырда исә шул исемне йөртүче аерым халыкның булмавын ышанычлы итеп дәлилли. Шул ук вакытта галим борынгы чор бортасларның төрле кабиләләр берләшмәсе булуын күрсәтә. Чыннан да, X гасырдагы Идел буе халыкларыннан төркиләр, башкортлар, угызлар, болгарлар, руслар кебек кавемнәрне аерым-аерым атаган Ибне Фазлан бортас дигән бер мөстәкыйль халыкны бөтенләй телгә алмый.

Югарыда Җаек-Идел араларында элгәрәк угор-финн кабиләләре яшәгәнлеге, милади башында килгән хуннуларның аларны буйсындыруы, хәтта җирле халыклар белән аралашып китүләре хакында әйтелгән иде. Археологик материаллар, бигрәк тә, мәет җыю (җирләү яисә яндыру) йолалары Җаек-Идел төбәгендәге халыкларның этник җәһәттән үзгәрүен раслый. Менә шуннан чыгып, бортас дигән кабилә берләшмәсе шушы чорда барлыкка килгән дип уйларга кала. Бу союз составында, җирле угор-финнар белән бергә, мажарлар (венгерлар), төркиләр дә булганга охшый. Соңгылары берләшмәнең башында торган булырга тиеш, чөнки күп кенә чыганакларның бортасларны тулаемы белән төркиләрдән дип исәпләве шуңа ишарә ясый. Ихтимал, тора-бара әлеге хаким төркиләрнең бер өлеше җирле халыклар арасында эреп, телләрен югалтканнардыр, чөнки кайбер чыганаклар, киресенчә, бортасларның тел ягыннан хазар һәм болгарларга охшамауларын әйтәләр.

Бортасларның Иделнең уң ягына күченүләре VIII йөзгә караса кирәк. Мәсәлән, әл-Балазури һәм Ибне Агсам Куфи кебек язучыларның әйтүләренә караганда, 737 елда Төньяк Кавказ һәм Хазарда сугышучы гарәп полководецы Мәрван, хазар каганын эзәрлекли-эзәрлекли Урта Иделгә кадәр күтәрелә, юл уңаенда, бортаслар белән дә сугыша. Һәм аларның күбесен кыра. Шулай ук 813 елда Әзербәйҗан һәм Ширван якларына ясалган һөҗүмнән кайтучы руслар, Иделдән Донга күчкәндә, бортасларның хәрби көчләре тарафыннан эзәрлекләнәләр. (М. И. Артамонов. Хазар тарихы. 371 бит.)

Соңрак дәверләрдә бортаслар төньяккарак, хәзерге мордвалар җиренә таба күченгәннәр булса кирәк. Әйтик, кайбер гарәп авторларының «бортаслар урманнарда яшиләр», аларда җәнлек тиреләре, бал күп, балдан исерткеч эчемлек ясыйлар, дигән хәбәрләре шуңа ишарәли. Шул ук вакытта бортасларның бер өлеше хәзерге мордваларның бабалары белән аралашып яшәгән булырга тиеш. Безнеңчә, Лаврентьев елъязмасында: «...придаша Мордва с Пургасом к Новгороду» дип, «мордва» белән «пургас»ның тиңдәшләр итеп бирелүе шуны күрсәтә. Димәк, А. П. Смирновның Пургас исемле мордва князен уйлап чыгаруы бөтенләй нигезсез. Соңрак чорда яшәгән кавказлы галим әл-Бакувинең бортас урынына «боргас» дип язуы бу фикерне өстәмә рәвештә дәлилли. Мәшһүр Рәшидетдин белән Плано Карпини да, монголлар тарафыннан буйсындырылган халыкларны санаган чакта, мордва, мукшылар белән янәшә бортасларны да саныйлар: XVI—XVII йөзләрдә язылган русча «писцовый» китапларда да нәкъ шундый ук хәл. Кыскасы, бортас белән мордва тәңгәл түгел. Археологик истәлекләр дә ахыр чиктә шушы фикер файдасына сөйли.

Ниһаять, мишәрләр яши торган җирләрдә «Бортас» исемле саф мишәр авылының

очрамавы да бер дә сәбәпсезгә түгелдер. Аның каравы, 1771—73 елларда төзелгән географик белешмә күрсәткәнчә, Тәтеш өязендә шул исемдәге өч татар авылы, Ядрин һәм Цивиль өязләрендә ө- чуваш авылы булган икән. Димәк, нигездә угро-финн телле булган бортасларның төрле чорларда өлешчә мордвалар, өлешчә чувашлар, өлешчә Казан татарлары арасында «эреп», шуларның составына керүләре бик ихтимал. Бәс, мишәр мәсьәләсен хәл кылганда бортасларга ябышып ятарга бернинди дә җитди дәлил юк икән.

Шулай итеп, без тагы мишәрләргә әйләнеп кайттык. Исеме төрлечә аңлатылып, нәселе дә төрле якка тарткаланган бу халыкның килеп чыгуын ачыклый торган фактларны, безнеңчә, борынгы төркиләр, төрки телле кабиләләр дөньясыннан эзләргә кирәк. Югарыда мишәрләрнең дә, болгарларның да нәселе бер булуы әйтелгән иде. Төгәлрәк әйтсәк, алар болгарлар составындагы «искил» исемле кабиләдән килеп чыкканга охшый. Моны түбәндәге фактлар куәтли.

Ибне Рустә һәм Ибне Фазлан санап күрсәткән Болгар берләшмәсе кабиләләреннән болгарлар үзләре, барсулалар һәм суварлар Идел буена Төньяк Кавказдан килгәннәр. Болар арасында искилләр күрсәтелми. Әмма 903 елда төрле чыганакларга таянып язган шул ук Ибне Рустә, маҗарлар хакында сөйләп, аларның бәҗнәкләр белән искил (яисә «ишкил») дип атала торган болгар кабиләләре арасындагы территориядә яшәүләрен күрсәтә. Югарыда маҗарларның бортас кабилә берләшмәсе составына керү ихтималы әйтелгән иде. Алар Көньяк Урал сахраларында күчеп йөргәннәр, шуңа күрә дә әлеге Мәрванга эләкмәгәннәр. Ә IX гасырның беренче яртысында исә бәҗнәкләр маҗарларны Иделнең уң ягына таба сөрәләр (тулырак мәгълүматны М. И. Артамонов китабыннан карагыз). 890 елда, угызлар һәм хазарлар кысрыклавы нәтиҗәсендә, бәҗнәкләр көнбатышка таба күчкәч, маҗарлар да Дон буйларына китәргә мәҗбүр булалар. Димәк, IX гасырда маҗарлар, чыннан да, Ибне Рустә әйткәнчә, бәҗнәкләр белән искилләр арасында булып чыга. Бу искил-ишкилләр болгарлар янына кайчан килеп утырганнар соң?

Тарихта мәгълүм булганча, төркиләрнең бер өлеше (тэлэ һәм изгил кабиләләре) хуннуларга ияреп китмичә, уйгурлар белән бергә, Үзәк Азиядә кала. Болардан изгилләр соңрак Төрки каганлыгының башында торган Кул-Тәгингә каршы чыгалар; тагы бераз соңрак, Уйгур дәүләте составына кереп, Сэленгә елгасы буенда яшиләр (Л. Н. Гумилевның «Борынгы төркиләр» исемле китабын карагыз).

VIII йөз ахырында, Уйгур каганлыгы белән Тибет арасында сугыш кызып, дәүләт составындагы кыргызлар уйгурларга каршы баш күтәргән чорда, Сэленгә изгилләренең ватаннарын ташлап китәргә мәҗбүр булулары фараз кылына. Байкал, Балхаш күлләре, Обь, Енисей, Иртыш, Ишим елгалары буйларында сугышчан башка төркиләр яшәгәнлектән, элекке урыннарыннан кузгалган изгилләргә ераккарак юл тотарга — Көнбатыш Себер аша узып, Идел-Җаек якларына китәргә туры килә. Соңгырак дәвер тарихи чыганаклар (Ибне Рустә һәм башкалар) искилләрнең Дон буйларына барып чыгулары хакында хәбәр итә.

Ихтимал, Үзәк Азия изгилләренең Көнчыгыш Европада искилләргә әверелүе кайберәүләргә гаҗәп булып тоелыр. Ләкин монда искитәрлек бернәрсә дә юк, чөнки урта гасырларда төрле җирләрдә, төрле телләрдә язылган әсәрләрдә бер үк халыкларның төрлечә аталуы күптән мәгълүм. Мәсәлән, безгә таныш кыргызларны иранлылар һәм гарәпләр «хыргыз» дисәләр, кытайлар «хагяс» яисә «хахас» дип йөрткәннәр. Искилләрне дә шәрык чыганаклары төрлечә атаганнар. Әйтик, иранлы Рәшидетдин аларны «ичкил» ди, гарәп авторлары «искил» яисә «ишкил» дип язалар, чөнки гарәпләрдә «ч» авазы да, аны белдергән хәреф тә юк. Төрки халыклары турында аларның үзләреннән материал җыйган Мәхмүд Кашгари исә аларны бөтенләй башкача — «чигил» дип атый. Кыскасы, бер кабиләнең төрле төшләрдә төрлечә аталуы (**чигил, ичкил, ишкил, искил, изгил** дип йөртелүе) артык гаҗәп түгел икән. Хәер, мондый хәлнең төрле төрки телләр үзенчәлеге белән дә бәйләнгән булуы бик ихтимал. Мәсәлән, хәзерге төрки телләрдә дә з-с-ш-ч күчешләрен күзәтергә мөмкин бит. Кыскасы, VIII гасырда Үзәк Азиядә яшәгән, соңрак аннан кысрыкланып чыгарылган искилләрнең бер өлеше болгар-сувар-барсулалар биләп торган Идел-Урал араларын узып, Дон якларына ук барып чыгуы әллә ни гаҗәп түгел икән.

Топонимик материаллар да мишәрләрнең искилләргә барып тоташуына ишарә

ясый. Мәсәлән, Мордва АССР белән Пенза өлкәсе чикләрендә Мокша елгасына коя торган бер кипкән елга бар. Инешне һәм аның буендагы ике авылны руслар Лундан дип йөртәләр. Ә безнең «пинзәкләр» елганы «Искил», авылларны исә «Рус Искиле», «Татар Искиле» дип атыйлар; тарихи тикшеренүләр исә әлеге мишәрләрнең элек-электән үк шунда яшәүләрен күрсәтә (Р. Мөхәммәдова китабын карагыз).

Мондый аңлатмага антропологик материаллар да каршы килми. Профессор В. П. Алексеев бөтен Идел буе татарларының (димәк, мишәрләрнең дә!) фәндә «понтий тибы» дип йөртелә торган бер антропологик типка каравын раслый. Әгәр мишәрләр «төркиләшкән» финн-угорларның нәселләре булса, мондый тирән уртаклыкка урын калмас иде. Ә искилләрнең борынгы болгарлар белән күрше яшәүләре, димәк, аралашып торулары хакында югарыда әйтелде инде.

Ниһаять, мишәрләрнең искилләргә барып тоташуын раслый торган фактларның иң әһәмиятлесе тел фактлары икәнлеген әйтергә кирәк. Мәсәлән, Мәхмүд Кашгари ягма кабиләләре һәм аларның якын кардәшләре булган чигилләрнең «мәниң баргым», «сәниң баргың» дип сөйләүләрен, кыпчаклар белән болгар-суварларның исә «мәнең барасым», «сәнең барасың» диюләрен билгеләп уза. Димәк, хәзерге мишәрләрнең «минең баргым (кели)», «синең баргың (кели)» дип сөйләүләре тарихи яктан шул искил-ичкил-чигил теленнән килгән күренеш икән!

Дөрес, мишәрләргә кыпчак теле дә көчле тәэсир ясаган. Ләкин бу аларның Алтын Урда чорында кыпчаклар белән тыгыз мөнәсәбәттә торуларыннан туган күренеш булырга охшый. Шул ук вакытта Казан татарларын һәм мишәрләрне аларның телләрендәге гомум кыпчаклык сыйфаты гына түгел, бәлки тарихи-социаль психологияләре дә берләштерә. Мәсәлән, Сембер мишәрләреннән булган XVII йөз шагыйре Мәүла Колый үз әсәрләренең «Болгар кәндләрендә» язылуын әйткән. Шуның белән ул үз кавемен дә болгарларга нисбәт иткән булса, хәзерге мишәрләр дә «без мишәр» дип, гомум татарлардан үзләрен аерып куймыйлар, бәлки бу исемне кимсетү кушаматы сыманрак кабул итәләр.

Җыеп әйткәндә, болгар һәм угыз-кыпчакларның нәселләре булган казанлыларга «татар» исеме соңрак һәм мәгълүм тарихи шартларда тагылган булса, төп-тамыры белән искил-ичкилләргә барып тоташкан, шул ук вакытта башка төрле халыкларның да вәкилләрен эченә алган «мишәр»ләргә дә бу исем соңгы чорларда ябышканга охшый. Ихтимал, аларның зур өлеше элекке мещералар җиренә килеп урнашуы да моңа җирлек тудыргандыр.

Шулай итеп, төрле характердагы чыганаклар безгә хәзерге халкыбызның төп өлешләрен тәшкил итүче ике төркемнең — Казан татарларының һәм «мишәр»ләрнең төп бабалары элек бер союзга, **болгар кабилә берләшмәсенә** кергәнлеген сөйли. Ул исә Европага Урта һәм Үзәк Азиядән килгән, теге яки бу күләмдә җирле халыклардан да «өлешләр» алып, яңа халык булып формалашкан. Алтын Урда чорында яңа төркем угыз һәм кыпчак компонентлары өстәлеп, этник процесстагы сан үзгәрү нәтиҗәсендә сыйфатка да үзгәрүләр кергән. Бер үк вакытта Алтын Урда дәвере китергән яңалыклар Үзәк һәм Урта Азия белән булган тирән этник һәм тарихи мөнәсәбәтләрне тагы да көчәйтеп җибәргән.

Менә боларның барысы да, бер яктан, хәзерге Казан татарлары белән «мишәр» татарларының бер милләтне тәшкил итүен тәэмин кылган; икенче яктан, бу фактлар безнең этник тарихыбызның әзербәйҗан, балкар, башкорт, казакъ, кара-калпак, карачай, нугай, төркмән, үзбәк һәм уйгурларның этник тарихларыннан аерылгысыз булуын күрсәтә.

## ТЕЛ — ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНЫҢ БЕР АЧКЫЧЫ

Югарыда сөйләнгән, халыклар арасындагы тарихи, дөресрәге, этник якынлык аларның тел кардәшлеген тәэмин иткән. Болай төрки халыклар хакында сүз барган чакта, тел якынлыгы мәсьәләсен күтәрүгә «моның нәрсәсе яңа?» дип гаҗәпләнергә ашыкмыйк. Чөнки сүз гомум-лингвистик уртаклык турында түгел, бәлки шул уртаклык эчендәге аерым хосусиятләр хакында бара. Әйтик, бер төрки группага кергән татар-якут тел уртаклыгы бер нәрсә, ә татар-карачай якынлыгы бөтенләй икенче нәрсә. Шуңа күрә, әдәбият тарихына тотынганчы, этногенез мәсьәләләренә тукталу естенә, кайбер мөһим тел фактларына да кагылып узу зарури.

Бик борынгы дәверләрдә монгол һәм төрки телләре гаять якын, хәтта бөтенләй аңлаешлы булган дип чамалыйлар. Ләкин бу ыруларга башка ырулар кушылып, яңа кабиләләр барлыкка килә-килә этник аерымлану нык көчәйгән, нәтиҗәдә кайчандыр бер тамырдан үсеп чыккан телләр үзара ерагая-ерагая бөтенләй үзгәреп, яңарып киткән. Гыйльми фаразларга караганда, мондый процесс хуннулар формалашкан чорга туры килә (лингвистлар с-р, з-р күчешләрен, шулай ук д-й, й-р алмашуларын шул дәвергә кайтарып калдыралар). Соңрак хуннулар үзләренә угор кабиләләрен кушкач, «ш» урынына «л» авазын әйткәннәрдер дип уйлыйлар. Болгарлар Кавказдагы иранлы кабиләләр белән аралашу нәтиҗәсендә яңа сыйфатлар барлыкка килгән (әйтик, тәртип санына ом-ем кушымчалары кушылу). Ләкин, язма истәлекләр күрсәтүенчә, Урхан-Енисей төркиләре белән болгарлар тел җәһәтеннән бер-берсеннән әллә ни аерылмаганнар. Руник язулы текстлар һәм болгар эпиграфикасы материаллары моны тулысынча раслый.

Дөрес, болгар язуларын укуда кайбер бәхәсләр дә бар әле. Мәсәлән, шул чордан калган гарәпчә язуларның борынгы хосусиятләрен аңламыйча, сүз башында әлифсез язылган «вау» хәрефен тартык итеп укыйлар («укуш» урынына «вкуш», яисә «вокуш» дигән кебек). Хәлбуки, бу очракта «вау» өстенә хәрәкә генә куелмаган. Ә мондый кыскартып язуларның тарихи факт булуын урта гасыр гарәп кульязмалары орфографиясе һәм гарәп илләрендә төзелгән төркичә сүзлекләрнең материаллары ярдәмендә расларга мөмкин (әйтик, «үчүн» урынына «вчүн» формасында язулар). Аерым очракларда «күн» (көн) сүзендәге «вау» хәрефеннән килгән «әлиф» кайберәүләрне аптырашка калдыра — «куан» дип укый башлыйлар. Чынлыкта бу «әлиф» гарәпчә тартыкны да белдергән «вау»ның озын «ү» икәнлеген күрсәтә торган махсус галәмәт кенә. Шуңа күрә болгар телен төрки телләр эчендә әллә нинди бер серле итеп күз алдына китерү ул борынгы язуларның техникасындагы төгәлсезлекләрдән туган нәтиҗә генә. Моның шулай икәнлеген түбәндәге таблица бик ачык күрсәтә.

| Урхан-Енисей язуларында | Уйгурча истәлекләрдә | Болгар кабер ташларында | Хәзерге татар әдәби телендә |
|---|---|---|---|
| бир, биринч | бир, биринч | бир, биринҗи | бер, беренче |
| әки | әки | әки, әкиши | ике, икенче |
| үч, үчинч | үч, үчинч | үч, үчөм | өч, өченче |
| түрт | түрт, түртенч | төөт, төөтөм | дүрт, дүртенче |
| алты, алтынч | алты, алтынч | алтыши, алты, алтынши | алты, алтынчы |
| йәти | йәти | җйәти, җйәтиши | җиде, җиденче |
| сәкиз | сәказ | сәкир, сәкәр | сигез |
| токуз | токуз | тохур [1] | тугыз |
| о:н | о:н | оон, ун | ун |
| йәгирми, йәгирминч | йәгирминч | җйәрми, җйәрминши | егерме, егерменче |
| отуз | отуз | отур | утыз |
| кырк | кырк | хырх | кырык |
| әлиг | әлиг | әли, әлү | илле |
| йүз | йүз | җөр, җөз | йөз (җөз) |
| күн | күн | күүн, көөн, кен | көн |
| оглы | оглы | оулы | улы |
| болты | болты, болто | болты | булды |
| айий | айий | айиһ | айы |

Бу чагыштырулар борынгы Урхан-Енисей төркиләре һәм уйгурлар белән болгарлар арасындагы якынлыкны аермачык күрсәтсә кирәк (болгарча мисаллардагы «р»ның төшеп калуы әллә ни гаҗәп эш түгел, чөнки хәзерге уйгурларның сөйләм телендә, Кавказдагы карачайларда да «р»ның йотылуы системага әверелгән). Урхан һәм уйгур телләре белән тарихи якынлыкның эзләрен хәзерге татар теленнән дә шактый табарга мөмкин. Хәтта өлү-йитү һәм үлем-җитем, әркли-әрксиз һәм иреклеирексез кебек тотнаклы сүз тезмәләрен дә дистәләп китереп булыр иде.

[1] Дунай болгарларының ханнар исемлегендә «тохос».

Шулай ук болгар һәм хазар телләре арасындагы тирән уртаклык хакында да бик күп язып булыр иде. Ләкин без күренекле поляк тюркологы А. Зайончковскийның бу мәсьәләгә багышлап зур-зур хезмәтләр бастыруын искәртү белән генә канәгатьләнергә мәҗбүрбез.

Әлбәттә, болгар теле гел бер калыпта гына тормаган, бәлки үзгәргән, үскән, камилләшкән. Хәтта, көнчыгыштагы башка төрки кабиләләр белән тыгыз этник һәм мәдәни мөнәсәбәттә торулары нәтиҗәсендә, элекке үзләренә генә хас тел элементларыннан да арына барган. Әйтик, 922 елны Ибне Фазлан белән килгән тылмачның угызлар, бәҗнәкләр, башкортлар, болгарлар белән җиңел аңлаша алуы шуңа ишарә ясый. Нәкъ менә шуның өчен дә XI йөзнең икенче яртысында иҗат иткән бөек лингвист Мәхмүд Кашгари болгарлар телендә башка төркиләргә нисбәтән әллә ни аермалар таба алмаган.

Урхан-уйгур әдәби традицияләренең «Котадгу белек» һәм «Гыйбәтел-хәкаикъ» әсәрләрендә дәвам ителүе хәзер бәхәссез факт. Әмма бу соңгы әсәрләрнең болгарлар өчен дә аңлаешлы булулары шик тудырмаска тиеш. Әйтик, алардагы «тоттачы», «булдачы», «китдәче» шикелле киләчәк заман сыйфат фигыль формаларының болгар кабер ташларында да очравы (өметләре өзеп китдәче һ. б.) шуны күрсәтә.

Мишәрләрнең «баргым кели»ләре ичкил (искил) теленә барып тоташуы әйтелгән иде. Мондый формаларны «Котадгу белек»тә дә күп табарга мөмкин (кәлгү, күренгү, ичкү, кылгу, йәгү һ. б.). һәм бу бик табигый. Чөнки Йосыф Хас Хаҗиб үз әсәрен чигил-искилләр телендә язган. «Котадгу белек» теленә бик якын булганы өчен С. Е. Малов «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын язучы Котбны уйгурлардан микән дип фараз кылган иде. Ә без, югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, Котбны чигилләрнең Идел буена килеп утырган бер төркеме вәкиле дип исәплибез. һәм бу караш, чигил-ичкилләрнең уйгурлар белән бик якынлыгын искә алсак, С. Е. Малов фикерен ачыклый гына төшә. Хәер, бу турыда сүз алга таба да булыр әле.

Югарыда болгар теленең башка төрки шивәләр тәэсирендә үзгәрүе, шуның нәтиҗәсендә татар теле формалашуы әйтелгән иде. Моның шулай икәнлеген раслый торган бер мисал китерик.

«Ибраһим инал оулы Шәһид Хаҗи бәләйге... вафат болтай тарих җиәти җөр җиәрминши җал мөхәррәм айих бәшинҗи күүн ити».

Бу — болгар эпиграфикасының II стиль дип аталган төркеменнән. Текстның хәзерге телгә тәрҗемәсе болай яңгырый:

«Ибраһим инал улы Шәһид Хаҗи билгесе... вафат булды тарих җиде йөз җегерменче җыл мөхәррәм айы(һ) бишенче көн иде».

Ә 1 стильгә кергәннәре исә, мәгълүм булганча, татар әдәби теленә бөтенләй якын, һәм болары — болгар теленең үзгәрә баруын күрсәтүче дәлилләр.

Хәзер алда әйтелгән фикерләрнең берсен, ягъни Төньяк Кавказда яши торган балкар-карачайлар белән борынгы болгарларның нәселе булган хәзерге татарларның тел кардәшлеген исбатлый торган мисалларга мөрәҗәгать итик (балкар-карачай орфографиясендәге «дж» гади «җ» белән алмаштырыла; къ, гъ — калын әйтелешле тартыкларны аңлата; йотыла торган «р» квадрат җәяләр эчендә бирелә; нг — «ң», «е» — русча әйтелештә):

«Тюнне таула[р]да жангурла[р] жаудыла[р]»...

«Чыпчыкла[р]нынг учуб келиб терекле[р]ге къонганларын киши кёрмеди...»

«Къоюн кютюб, ашын ашаб, жыр жырлаб, Жашаганды къейчу Аймут таула[р]-да» һ. б.

Өстәп шуны гына әйтергә кирәк, «ырга-ергә» тәгәлләнә торган инфинитив фигыль формасы төрки телләрдә бары татарлар һәм балкар-карачайларда гына очрый. Күренә ки, халыкларыбыз аерым яши башлаганга унике-унөч гасыр узса да, борынгы уртаклыклар һаман саклана икән!

Әдәбиятыбызның «елга башын» дөрес билгеләү максаты белән этногенез мәсьәләләренә кагылып, тел фактларына да тукталган чакта сөйләм теле белән әдәби тел мөнәсәбәтләренә карата да берничә сүз әйтәсе килә. Чөнки язма тел хосусиятларын ачыкламыйча торып, әдәбият тарихының катлаулы мәсьәләләренә керүе читенрәк.

Тел белемендә, гадәттә, грамматик формаларга таянып фикер йөртәләр. Әгәр шул формалар белән эш итүне үзмаксатка әйләндерә башласак, гаять көлке хәл-

ләргә калырга мөмкин. Мәсәлән, төрки телләр синтаксисы белгече Н. З. Гаджиева Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә «мыш-меш» (бармыш, килмеш) формалары күп булуга карап, аның татар теленә, татар халкына нисбәт ителүен инкарь кылып маташа, янәсе, бу истәлектә «госманлы теле формалары» бар. Тел белгечләренең болай «аффиксларга» күмелеп, башка төр фактлардан, тарихи обстановкадан күз йомулары бик гаҗәп эш!

Телнең аралашу коралы икәнлеге һәркемгә мәгълүм. Шуның өчен тел тарихын, бигрәк тә борынгы әсәрләрнең телен тикшергәндә нәсел-ыру мәсьәләләрен ачыклаудан тыш, иҗтимагый фактларны да, мәдәни-әдәби бәйләнешләрнең нәтиҗәләрен дә игътибардан читтә калдырмаска кирәк. Менә шундый таләпләрдән чыгып фикер йөрткәндә, Н. З. Гаджиеваның «госманлы формалары» дигән сүзләре тупас анахронизм гына. Чөнки, Кол Гали әсәре 1232 елда иҗат ителгән булса, «госманлы теле» дигән әдәби тел төрек солтаны Госман 1 (1258—1326) хакимлегеннән соң гына формалашкан тел бит ул! Әгәр без Төрек империясенең XV—XVI йөзләрдәге сәяси кодрәтен һәм шул соңгы дәвер төрек әдәби теленең [госманлы теленең!] сыйфатын механик рәвештә элгәрге чорларга күчерү белән шөгыльләнмәсәк, ягъни тарихи эзлеклелек сакласак, бөтенләй икенче картинаны күзәтәбез: XIII гасырда түгел, бәлки XIV йөздә дә төрек-язма теле Урта Азия һәм Алтын Урда әдәби телләренең тәэсирендә булган (моның конкрет мисалларын алга таба әдәби мөнәсәбәтләр мәсьәләсенә күчкәч күздән кичерербез).

Кол Гали поэмасы угыз һәм кыпчак телләре нигезендә иҗат ителгән истәлек. Ул үзенә хәтле төрки дөньяда таралган язма әсәрләрнең тәэсирендә болгар җирендә барлыкка килгән (бу хакта 1970 елда Ленинградта басылган «Палистанский сборник» дигән җыентыкның 21 кисәгендәге безнең мәкаләне карагыз). Ә конкрет «мыш-меш» формаларына килсәк, ул госманлы төрекләре оешканчы әллә ничә гасырлар элек язылган Урхан-Енисей текстларында, шулай ук уйгурча истәлекләрдә дә күп очрый. Ә бу телләрнең болгар теленә мөнәсәбәтләре хакында югарыда әйтелде инде.

Болгар теленә Караханилар чоры әдәби теленең тәэсире көчле булуын да онытмаска кирәк. Болгар-Казан җирлегендә яшәп иҗат иткән Мөхәммәдъяр поэмаларында «мыш-меш» кушымчасы гына түгел, борынгы төрки грамматик формалар, аерым архаик сүзләр дә бик күп (уш — менә; тәгмә — һәркем; әсрү — бик, бигрәк; үгәр — мактар; әгри — кәкре; әсиргәмәк — кызганмак; йыдыг — ис; көни — дөрес һ. б.).

Мондый иске китаби тел элементлары Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорының башка истәлекләрендә дә күп табыла. Алай гына түгел, андыйларны Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салиховларның әсәрләреннән дә шактый җыйнарга мөмкин. Болай килеп чыгуның тарихи сәбәпләре бар. Беренчедән, моңа гасырлар буена дәвам кылган әдәби традиция тәэсир итсә, икенчедән, элгәрге чор авторларында язганнарын бөтен төрки дөнья аңласын дигән омтылыш та булган (үзләре дә башка төрки регион әсәрләрен иркен укый алганнар бит!).

Әлбәттә, татар әдәби теленә госманлы төрекләренең теле дә билгеле бер күләмдә тәэсир ясаган. Ләкин бу процесс тулаемы белән соңгырак дәверләргә — госманлыча басма китаплар таралу чорына хас. Димәк, борынгы «мыш-меш»ләрне соңгы заман төрек-угыз элементларыннан аерып карарга кирәк икән. Бары шулай эшләгәндә генә чорларны бутау куркынычыннан котылырга мөмкин.

Җыеп әйткәндә, әдәби әсәрләрнең миллилеген дөрес ачыклар өчен, тел фактларын төгәл барлау зарури булса, шул тел материалларының этногенез мәсьәләләре һәм иҗтимагый тарих шартлары белән берлектә каралуы шарт. Бары шулай эшләгәндә генә без аерым-ялгыз фактларга ябышып ятудан туа торган формализмнан азат булачакбыз.

Дөрес, иҗтимагый тормыш җимеше булган әдәби хәрәкәтнең тарихын төгәл ачыклау юлында бер этногенез яки телләр тарихы гына бөтен мәсьәләләрне дә хәл кылып бетерә алмый әле. Чөнки билгеле бер «милли» даирәдә туган, формалашкан, ягъни этник традиция һәм тел белән тәэмин ителгән әдәбиятның алга таба үсүенә, камилләшүенә (яисә регресс кичерүенә) иҗтимагый шартлар, бигрәк тә башка күрше һәм кардәш халыклар белән өзлексез барган экономик, идеологик һәм мәдәни мөнәсәбәтләр көчле тәэсир ясый. Мәсьәләнең бу ягына без алдагы мәкаләдә тукталырбыз.

# МӘГЪРИФӘТЧЕ ГАЛИМ ШӘМСЕТДИН КҮЛТӘСИ

Дөньядагы һәрбер халык кебек, татар халкы да гомум кешелек культурасына үзеннән билгеле күләмдә өлеш кертте, иҗтимагый-политик һәм философик фикер үсеше азатлык хәрәкәте дәверендә фидакарь көрәшчеләрне тудырды. Бу шәхесләрнең күбесен без яхшы беләбез, ихтирам итәбез, хезмәтләреннән бүген дә идеологик эшебездә файдаланабыз. Ләкин татарлар арасында иҗтимагый-политик һәм философик фикер үсеше тарихы җитәрлек дәрәҗәдә тирәнтен өйрәнелмәгән әле. Эзләнүләр дәвам итә, яңадан-яңа күркәм сәхифәләр ачыла, моңа кадәр безгә билгеле булмаган яки аз таныш булган алдынгы фикер ияләренең эшчәнлеге ачыклана.

«Казан утлары» журналының 1972 ел 12 нче санында философия фәннәре кандидаты Яхъя Абдуллинның «Татар мәгърифәтчеләре философиясенең кайбер мәсьәләләре» исемле мәкаләсе басылып чыкты. Бу мәкалә — татар иҗтимагый-философия фәннәре тарихын өйрәнү өлкәсендә яңа бер куандыргыч күренеш. Безгә мәгълүм булганча, автор татарлар арасында мәгърифәтчелекнең формалашуы һәм үсүе мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнә һәм тиздән җәмәгатьчелеккә зур күләмле фәнни хезмәт бүләк итәргә тора. Аның әлеге мәкаләсендә, XIX гасырның икенче яртысында яшәп иҗат иткән Шиһабетдин Мәрҗани һәм Каюм Насыйри кебек зур мәгърифәтче галимнәр белән беррәттән, тагы бер шәхес телгә алына. Бу шәхес — Шәмсетдин Күлтәси — безне күптән кызыксындырган булса да, аның философик карашлары турында беренче язып чыгу вазифасын коллегабыз Абдуллин башкарды. (Күлтәси турында эзләнүләрне исә, гомумән, Арча район газетасы редакциясе башлап җибәрде).

Яхъя иптәш Абдуллин мәкаләсендә Ш. Күлтәсинең философик карашларына бирелгән кыскача обзор, табигый рәвештә, бу кеше белән кызыксынуны арттырып җибәрде, аның әсәрләрен ныклабрак өйрәнү теләген үстерде.

Шәмсетдин Күлтәси шактый зур әдәби мирас калдырган икән. Минә безнең кулыбызда аның имзасы белән басылып чыккан берничә китап:

1. Һәйьәте җәдидә осулене носусе шәргыйә тәтбик. Казан, 1896 ел, 64 бит.
2. Һәйьәте җәдидә. Казан, университет матбагасы, 1899 ел, 72 бит.
3. Мөфассаль һәйьәте җәдидә. Казан, университет матбагасы, 1900 ел, 55 бит.
4. Мөхакәмәт. Казан, мәктәп ширкәте басмасы, 1900 ел, 55 бит.
5. Халемездән шикайәт. 2 нче басма, Казан, 1903 ел, 16 бит.
6. Шул ук. Казан, 1907 ел, 16 бит.
7. Мәктәп баласы яхуд Сәхилә әби (кечкенә балалар өчен). Казан, 1909 ел.
8. Хикмәте җәдидә. Казан, университет басмасы, 1899 ел, 65 бит.
9. Шул ук. Казан, 1904 һәм 1909 еллар.

Җентекләп танышканнан соң, бу китапларның эчтәлеге һәм авторның позициясе гаять дәрәҗәдә кызыклы һәм игътибарга лаеклы икәнлеге күренде. Бу әсәрләрне татарлар арасында мәгърифәт, философик фикер үсеше тарихында билгеле бер кыйммәтле хәзинә дип бәяләми мөмкин түгел.

Авторның чын исеме Шәмсемөхәммәт Нурмөхәммәт улы Таһиров. Республикабызның Арча районы, Кұлтәс авылы кешесе булганга, күрәсең, ул Кұлтәси псевдонимын алган һәм әсәрләрен шул исем белән чыгарган. 1857 елда туып, 1932 елда шушы авылда вафат булган. Шәмсемөхәммәтнең әтисе Нурмөхәммәт Кұлтәскә Мамадыш районы, Новогорелое Ельниктан (татарча Максим авылы) күчеп килгән. Шәмсемөхәммәтнең Арчада яшәүче кече улы Ибраһим әйтүенчә, әтисе һәм бабасы да рус телен яхшы белгәннәр. Шәмсемөхәммәт солдатта вакытта полковой писарь хезмәтен үтәгән. Әтисе үлгәннән соң Кұлтәстә имам булып кала, балалар укыта, аларга дөньяви фәннәрдән сабак бирә. Октябрь революциясеннән соң да, каты авыруына карамастан, ул 1920 елга кадәр мәктәптә укыта, яшь укытучыларга ярдәм итә. Язган әсәрләренә караганда, ул үз заманының фән дәрәҗәсе белән, рус һәм көнчыгыш әдәбияты белән шактый таныш булган, гарәп телен бик яхшы белгән һәм киң файдаланган.

Шәмсемөхәммәтнең туганнары һәм балалары да алдынгы фикерле, культуралы кешеләр булган. Мәсәлән, аның бертуганы Мөхәммәтфатих Кұлтәси дингә каршы фикерләр әйткәне өчен муллалыктан куылган, шуннан соң Астраханьда сәүдә эше белән шөгыльләнгән, «Җәмгыяте хәйрия» рәисе урынбасары булган. Ул 1903 елда «Изһарельхак» исемле китап бастыра. Гыйбадулла Минзәләви дигән кеше үзенең «Әзкярь» (Оренбург, 1905) исемле китабында аны «җитлеккән әдип, фазыл кеше» дип атый, Мөхәммәтфатихның «Әнвар» исемле тагын бер әсәре барлыгын яза. Ш. Кұлтәсинең икенче туганы Мөхәммәтзакир Казан артындагы пыяла заводы управляющие булган. 1905 елда хөкүмәткә мөрәҗәгать итеп «Хөррият» исемле газета чыгаруга рөхсәт сораган, тик үтенече кире кагылган (кара: И. Рәми. Татар телендә вакытлы матбугат, 201 бит). Шәмсемөхәммәтнең улы Нух советлар властеның беренче елларында укытучылык итә, аннан соң озак еллар совет органнарында эшли. Кұлтәсинең кызы Рәйханә үзенең бөтен гомерен балалар укытуга багышлый. Кече улы Ибраһим Арчада совет учреждениеләрендә эшли, Ватан сугышында күрсәткән батырлыгы өчен ике орден, дүрт медаль белән бүләкләнә. Ш. Кұлтәсинең тагын бер улы Сәгыйделислам Таһиров Казанда реальное училищены тәмамлый, укыган вакытында Вахитовлар өендә яши, Мулланур белән хат алыша (кара: Р. Нафиков. Мулланур Вахитов. Казан, 1960, 39 бит). 1907 елда Неждановның «Хезмәт һәм капитал» исемле әсәрен татар теленә тәрҗемә итеп бастыра. Октябрь революциясеннән соң С. Таһиров — КПСС члены, Совет Армиясендә командир, аннары, үлгәнгә кадәр, Казанда завод директоры.

Шәмсетдин Кұлтәси үз заманында прогрессив даирәләргә яхшы билгеле булган һәм ихтирам казанган. Дөрес, татар демократик культурасы эшлеклеләре язмаларында без аның исемен сирәк очратабыз. Моның сәбәбен ачыкларга кирәк әле. Шулай да Кұлтәсинең алар игътибарына лаеклы булуын күрсәтүче мәгълүматлар да бар. Мәсәлән, Ибраһим Таһиров әйтүенә караганда, 1925 елда Кұлтәскә татар халкының бөек әдибе Галимҗан Ибраһимов килгән. Шәмсемөхәммәт Кұлтәси белән очрашып, көннәр буе әңгәмә алып барган.

*

* *

Үзенең югарыда саналган әсәрләре белән Шәмсетдин (Шәмсемөхәммәт) Кұлтәси безнең алга Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри традицияләрен дәвам иттерүче мәгърифәтче булып килеп баса. Үз халкын наданлыктан арындыру һәм кешелек цивилизациясе тудырган аң-белемгә якынайту — аның изге хыялы булган. Дөрес, ул чордагы бик күп акыл ияләре кебек үк, Кұлтәси дә халык мәгърифәте мәсьәләсенең социаль һәм милли азатлык өчен көрәш бурычлары белән турыдан-туры бәйли алмаган. Ул асылда буржуаз мәгърифәтчелек позицияләреннән чыгып һәм үз заманында рәсми закон төсен алган ислам-шәригать боерыкларына буйсынып эш иткән. «Һәйате җәдидә» әсәренең исеме астына да ул «Шәригать ысуле мәгънәсенә туры китереп» дип язып куйган. Әмма аның карашлары XX гасыр башындагы татар буржуазиясенең реакцион идеологлары позициясеннән аерылып тора, анда милләтчелек, ачыктан-ачык диндарлык, феодаль җәмгыять кадимчелегенә ташлама ясау күренми.

Культура прогрессы — нинди дә булса бер халыкның яки халыкларның аерым бер группасын гына эченә алган йомык процесс түгел. Ул интернациональ күренеш. Иртә-

ме-соңмы, аның көчле агымы әле арттарак калган халыкларны да хәрәкәткә китерә. Бу объектив закончалык. Ләкин моннан стихияле рәвештә алга бара торган объектив процесска сукырларча буйсынып, «язмыш»ның кайчан һәм нинди хәлгә китерүен көтеп яту тиешле дигән нәтиҗә чыкмый. Мәсьәләнең гаять әһәмиятле ягы — объектив процессларның тенденциясен сизеп, күреп, аңлап, шуңа кулдан килгәнчә этәргеч бирүдән, прогрессив үсентеләргә ярдәм итүдән, җәмгыять фикерен шуңа җәлеп итүдән гыйбарәт. Алдынгы фикер ияләренең вазифасы һәм тарихи роле шунда.

Безнең фикеребезчә, Ш. Күлтәси әнә шундый рольне башкарган, үз халкын дөнья-күләм культура прогрессына тартырга тырышкан. Ул ата-бабалардан мирас булып килгән, гадәти хәлгә әйләнгән һәм, кайбер милләтче ретроградлар раслаганча, хәтта «милли үзенчәлек» төсен алган рухи караңгылык, дини хорафатлык, милли чикләнгәнлек белән килешмәгән.

Хаким сыйныфлар һәм дин әһелләре тарафыннан татар халкына тәкъдим ителеп килгән «рухи азык» нидән гыйбарәт соң? Бу мәсьәлә Ш. Күлтәсине бик нык борчый, ул гаять дәрәҗәдә аяныч хәлне констатацияләргә мәҗбүр була һәм шуңа каршы баш күтәрә. «Без бүген өйрәнеп килгән фән һәм гыйлем дип аталган нәрсәләребез,— ди ул,— фәкать имеш-мимештән, бәхәс-тартыштан гыйбарәт». («һәйәте җәдидә», 6 бит). Бәхәс-тартыш башлыча дини язмаларга тегенди яки мондый трактовка бирүдән узмый, төрле фәннәрдән хәбәрдарлык исә имеш-мимеш белән чикләнә һәм анда да мөселман кеше «лимә ла йәҗүзе ла нөсәллиме» (дөрес булса да ышанмыйм) дигән принциптан чыгып эш итәргә тиеш. Муллалар аны әнә шулай һәрбер яңа фикергә, корьәннән читкә чыга торган хакыйкатькә шикләнеп карарга өйрәткәннәр. Шуңа күрә табигать фәнен өйрәнү, тормыш серләренә төшенү турында кайгыртучылар да юк диярлек. «Бездә,— ди Күлтәси,— дини гыйлем бар, әмма тән һәм терекчелек гыйлеменнән бөтенләй хәбәрсезбез һәм өлешсезбез... яшәү чыганагыннан, сәнагатьтән бернәрсәбез юк» (шунда ук, 6—7 битләр). Фәнгә, гыйлемгә каршы чыгучы черек консерватизмның тормыш агымы, заман таләпләре белән килешә алмавын, милләтнең артта сөйрәлүенә сәбәп, халыкны караңгылык упкынында тотучы каһәр булуын Күлтәси яхшы аңлаган. Үзләрен галимнәр дип санап та, кадимчелеккә мөкиббән киткән кешеләрне тәнкыйтьләп, ул болай яза: «Әгәр иске әдәбиятыбыз тәмам камил, яңалыкка ихтыяҗыбыз юк дип, заман тәрәккыятенә иярмәсәк, заманыбызның әдипләре вә галимнәре янында сабыйлар дәрәҗәсендә калуыбыз ачык» (шунда ук, 3 бит).

«һәйәте җәдидә» (Яңа астрономия) китабы, исеменнән күренгәнчә, астрономиягә багышланган булса да, эчтәлеге бу фәнгә генә кайтып калмый. Автор анда танып-белү белән бәйләнешле гомуми принципиаль методологик мәсьәләләрне күтәрә һәм материалистик рухта кыйммәтле фикерләрне яклый. Дөрес, татар иҗтимагый фикере үсеше тарихында стихияле материализм һәм дөньяга диалектик караш элементлары моңа кадәр дә фольклор әсәрләрендә, Ш. Мәрҗани белән К. Насыйри хезмәтләрендә күренә. Әмма бу яктан караганда Ш. Күлтәси алга таба тагын бер адым атлаган. Аның әсәрләрен әлегә безгә мәгълүм булган башка чыганаклар белән чагыштыру шул нәтиҗәгә китерә.

Ш. Күлтәси китабының «һәйәте җәдидә ысулы» дип аталган беренче бүлегендә дөньяга караш мәсьәләсенең нәкъ менә төп, иң мөһим ягы — чынбарлыкны танып-белү методы яктыртыла. Авторның сүзне шуннан башлавы тикшеренү логикасының югары таләбенә җавап бирә. Методологик принципларны ачыкламый торып, фәнни эштә төпле бер позициягә басу һәм уңышка ирешү мөмкин түгел. һәм Күлтәси бу позицияне объектив диалектикада таба, дөньяга бердәнбер дөрес — материалистик карашка якынлаша. Күк һәм җир җисемнәренең ярлуы, күзгә күренгән матди галәмнең асылы, җир һәм күкнең тәрләнүе, үзгәрүе турында философ галимнәр арасында күп төрле капма-каршы фикерләр булган, дип яза Ш. Күлтәси. Шуларның кайсысын дөрес дип танырга кирәк соң? һәм дөреслекнең критерие нәрсә? Моңа мәгърифәтченең җавабы бер генә: тәҗрибә, төпле дәлил. Тәҗрибәдә расланмаган карашның кыйммәте юк, ул буш уйдырма гына булып кала. «Фәкать тәҗрибә вә дәлил илә соңгы галимнәр тарафыннан расланган мәсләк (принцип) түбәндәгедән гыйбарәт: гомумән, бөтен галәмнең асыл башлануы вә чыганагы ике шәйдер — бере матдә вә икенчесе ул матдәдәге хәрәкәтдер. Бу хәрәкәт мәтдәнең лазим маһияте (кирәкле сыйфаты) булып, боларның аерылуын күзаллап булмый» (шунда ук, 8 бит). Күрәсез: Күлтәси дөньяга материалистик һәм диалек-

тик карашны шактый төгәл бәян итә, хәрәкәтне материянең төп эчке сыйфаты, аерылгысыз атрибуты дип саный, материянең һәм хәрәкәтнең бердәмлеген раслый.

Бу татар иҗтимагый-философик фикер үсешендә зур бәягә лаеклы казаныш, чөнки, әйткәнебезчә, моңа кадәр татар матбугатында материаль дөнья тәрәккыяте турында сүз йөртелгән булса да, яшәеш чыганагын эзлекле рәвештә бердәнбер нәрсә — материя һәм аның хәрәкәте белән аңлатуга ирешелмәгән иде әле.

Табигатьтән тыш ниндидер илаһи көч түгел, бәлки материаль чынбарлыкның үз хәрәкәте тормыш күренешләренең барысын да аңлата. Күлтәси әнә шул төп субстанцияне таный һәм яклый. «Матдә,— ди ул,— галәм бушлыгын тутырып торган эфирдыр ки, аны һәйюлә (башлангыч материя) дип әйтеләә» (шунда ук). Мәгърифәтче галим, материяне эфир төсендә күзаллап, борынгы грек философларының беркатлылыгын кабатлый, эфир-матдәне бөтен галәмгә тиңли һәм тәүге башлангыч дип саный. Ләкин безне кызыксындырган мәсьәләнең асылы анда түгел, бәлки авторның идеализм белән араны өзүендә, философиядәге төп сорауга — «Яшәешме, әллә аңмы беренчел?» дигән сорауга материалистик позициядән чыгып җавап бирүендә.

Дүрт елдан соң язган «Хикмәте җәдидә» (Яңа гыйлем-фәлсәфә) әсәрендә Шәмсетдин Күлтәси материя турындагы карашларын тагы да ачыклый, «матдә», «бушлык», «һава», «хәрәкәт каршылыклары» турында конкрет сүз йөртә. Әгәр элегрәк материяне дүрт кенә төрдә күзаллаган булсалар, хәзер галимнәргә аның 70 төрле элементы билгеле, дип яза автор («Хикмәте җәдидә», 19 бит). Фән белән таныш булмаган кешеләр кулга тотарлык каты әйберләр күренмәгән урынны бушлык дип беләләр. Ләкин галәмдә бушлык юк. «Бушлык димәк фәкать безнең күрүебездә. Хакыйкатьтә исә галәм һава кеби, эфир кеби, һәйюлә (башлангыч материя) кеби җисемнәр илә тулы» (шунда ук).

Бу җөмләдән күренгәнчә, Күлтәси әле материягә төгәл философик билгеләмә таба алмаган, һаваны, эфирны, башлангыч материяне бер-берсенә тиң төшенчәләр рәвешендә кулланган. Әмма мәгърифәтченең галәмдәге бушлыкны инкарь итүе һәм шуннан соң материянең хәрәкәтен пространствода күзаллавы XX гасыр башында да әле яшәп килгән дини, идеалистик һәм метафизик карашларны юкка чыгару юнәлешендә башкарган бик зур хезмәте булып тора. Пространство һәм хәрәкәтне тудыручы каршылыклар турында ул болай яза: «Матдә хизда (пространствода) хәрәкәтләнә, аны капма-каршылыклар хәрәкәткә китерә, чөнки җисемнәрнең бәгъзеләре керентеле (уңай), бәгъзеләре чыгынтылы (кире)» (шунда ук, 20 бит). Икенче урында ул «дәфга» (этәрүче) һәм «җазба» (тартучы) чикләрнең матдәгә хас булуын әйтә (шунда ук, 41 бит).

Нәрсә беренчел: материяме, әллә аңмы? дигән сорауның философиядә хәлиткеч мәсьәлә булуын күрсәтеп, Ф. Энгельс болай язган иде: «Бу сорауга ничек җавап бирүләренә карап, философлар ике зур лагерьга аерылдылар. Табигатьтән элек рух булган дип раслаучылар... идеалистик лагерьны тәшкил итте. Табигатьне төп башлангыч дип исәпләүчеләр исә материализмның төрле мәктәпләренә кушылдылар» (К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр, 21 том, 283 б.).

Тормыш һәм хезмәт тәҗрибәсе дә, фән үсеше дә кешеләрнең сәламәт аңында дөньяга материалистик карашны үстерә. Ләкин шул ук вакытта кешеләрне чорнап алган чынбарлыкта серенә төшенеп җителмәгән күренешләр шул кадәр күп ки, бу хәл ихтыярсыз рәвештә кешеләрнең аңында, чынбарлыктан өстен торучы һәм андагы катлаулы күренешләр белән идарә итүче ниндидер аерым бер көч, бөек рух юкмы икән, дигән уйны тудыра. Кешеләрне бик озак саташтырып килгән идеализм һәм диннәрнең гносеологик тамыры шунда. Мондый ялгыш һәм ялган карашларга каршы баш күтәргән алдынгы кешеләр арасында без Күлтәсине дә күрәбез. «Матдәнең затлары, рәвеш вә сыйфатлары мөтәхалиф (капма-каршы), шәкелләре мөтәгайер (төрлечә)» булуын күрсәтеп, бу капма-каршылыкны һәм форма төрлелеген ул матдәнең вак кисәкчәләренең табигый хәрәкәте белән аңлата, «шул төрле-төрле шәкелләрдән торган вак кисәкчәләр даимән хәрәкәт итмәктәләр», дигән нәтиҗә чыгара. Шулай итеп, безнең автор материянең беренчел субстанция булуын да, аның бетмәс-төкәнмәс төрлелеген дә, галәмнең бары тик материягә даими хас булган эчке каршылыклы хәрәкәт нәтиҗәсе икәнен дә яхшы аңлаган һәм шул хакыйкатьне пропагандалаган.

Бу, әлбәттә, гасырлар буенча кешеләрнең аңына сеңдерелеп килгән дини уйдырмаларга көчле удар иде.

*
* *

Ш. Күлтәси үзенең философик карашларын Кояш системасының барлыкка килүе һәм хәрәкәте турындагы язмаларында аеруча ачык бәян итә. Аның аңлатуынча, «матдәнең вак кисәкчәләре үзенә хас хәрәкәт нәтиҗәсендә җыйналып, мәтдәи сәдимия (томанлык) хасил улмыштыр... Шул әҗсаме сәгыйрәнең (кечкенә җисемнәрнең үзара тартыш кануны илә иҗтимагъларында (җыелуында) бер көррә (шар) барлыкка килеп, ул үзенең кучәрендә дәврана (әйләнү) башламыш... Шулай Кояш барлыкка килә, аның әйләнү дәвамында кәвакибе саирә (башка планеталар) аерылып, һәрбере көррә уларак тәкявен итмеш (хасил була) вә михварләрендә (үз күчәрләрендә) хәрәкәт итә башлый. Без яшәгән җир шары да бер кәвакибдер (планетадыр). Озак заман үзенең михварендә хәрәкәт иткәнлектән, аның кабыгы суынып, җир катлаулары ясала... Җәмадәт (каты әйберләр) вә нәбабат (үсемлекләр) вә хәйванат туа» («Һәйәте җәдидә». 9 бит).

Бу сүзләрдән күренгәнчә, Күлтәси, хәрәкәтсез Җирне галәмнең үзәге дип санаган һәм асылда динне «фәнни» нигезләргә тырышкан геоцентрик системаны кире кагып, бердәнбер фәнни дөрес гелиоцентрик системаны яклап чыга. Капма-каршы философик юнәлешләр бәрелешендә ул материализм позициясенә баса һәм үз халкын шуңа чакыра: «Хөрмәтле укучыларым! Морасилә (телеграф), мохабирә (почта) вә фикер алмашу булып торганда гыйлем яктылыгы вә мәгърифәт бөтен галәмне нурландыра. Бу кеби (Җир әйләнми, Кояш Җир тирәсендә йөри кебек — ред.) хата фикергә бирелмичә, ислам вә гайре ислам булсын, бөтен галәмне мәгърифәт вә мәдәниятнең кабул әйләдекләре — Җирнең хәрәкәтен кабул итик» (шунда ук, 18 бит).

XIX гасырда һәм XX гасыр башында да җирнең хәрәкәтсез хәлдә, галәмнең үзәге булып торуы турында Птоломей теориясен бәян итүгә багышланган китаплар бик күп санда басылып тарала. Шәмсетдин Күлтәси үз халкын бу китапларны укымаска, уйдырмаларга ышанмаска чакыра, чөнки «җирне галәм үзәге дип санаган Птоломей карашы Коперник заманына хәтле генә яшәп килгән» («Хикмәте җәдидә», 13 бит), шуннан соң галәм яратылышы турында яңа дөрес теория туган. Хәлбуки, әле хәзер дә Җирнең даими хәрәкәттә булуын әйтсәң, «әстәгъфирулла», «нәгузебиллаһ» дип төкеренүчеләр шактый күп, дип әрнеп яза мәгърифәтче.

Гелиоцентрик теориянең җиңүе Европада XV—XVI гасырларда фәнне дин богауларыннан азат итүдә, дөньяның материаль бердәм булуын раслауда хәлиткеч роль уйный. Татарлар, артта калган һәм милли яктан изелгән бик күп башка халыклар арасында исә XX гасыр башларында да әле галәм хәрәкәте турында геоцентрик идеяләр хөкем сөрә, башкача уйлау ислам диненә хыянәт итү дип санала. Шуңа күрә Шәмсетдин Күлтәси тарафыннан гелиоцентрик системаны ачыктан-ачык матбугатта пропагандалау татар иҗтимагый-философик фикерендә дә ренессанс (яңарыш) чорын хәтерләтә, дөньяга фәнни-материалистик карашның киң тарала башлавы турында сөйли.

Тагы шунысы да игътибарга лаеклы. Безгә күренгән гелиоцентрик системаны танырга мәҗбүр булган ислам сакчылары да һәм алар йогынтысыннан арынмаган кайбер «галимнәр» дә шушы системадан башка хәрәкәтнең булу мөмкинлеген катгый инкарь итәләр. Шәмсетдин Күлтәси бу чикләнгәнлеккә дә каршы чыга, иксез-чиксез галәм киңлегендә башка системалар булырга һәм аларның да барлыкка килүе, хәрәкәте без яши торган системага охшарга тиеш, дип белдерә. Ул болай ди: «Кәвакибе сабика (башка галәмнәр яки системалар)ның барлыкка килү кәйфияте (ысулы) дә Кояш әйләнәсе туу кәйфиятенә охшаш. Аларның да һәрбер безнең шәмс (Кояш) кеби зыя заты сәхибидер (яктылык затына иядер) вә үзләренә тәгатьлыклы (хас) булган бер галәмдә ишрак итмәктәдер (яктыртадыр)» («Һәйәте җәдидә», 9 бит). Һәм тагы: «һәрбере безнең галәме шәмс кеби галәме азыйм (зур системалар) улдыклары беленмештер» (шунда ук, 21 бит).

Татар мәгърифәтчесенең югарыда бәян ителгән фикерләре аның үз заманындагы фән үсешен якыннан күзәтүе Европа һәм Россия галимнәре хезмәтләре белән таныш булуы турында сөйли. Үзенең «Материализм һәм эмпириокритицизм» исемле бөек хезмәтендә В. И. Ленин: Россиядә материализмның шактый бай традицияләре бар, дип язган иде. Бу традицияләрнең туплануында, рус галимнәре белән бергәттән, аларның булышлыгы һәм үрнәге нәтиҗәсендә, Россиянең башка халыклары арасыннан үсеп чык-

кан укымышлылар да билгеле дәрәҗәдә уңай роль уйнаганнар. Ш. Күлтәси, һичшиксез, шуларның алдынгы сафында.

Инде шуны әйтергә кирәк, башка мәгърифәтчеләрдәге кебек, Күлтәси язмаларында да ул чакта хакимлек иткән, татарлар һәм башка мөселманнар өчен бердәнбер тәгълимат булып хисапланган ислам диненә билгеле бер күләмдә ташлама ясала. Ачыктан-ачык материалистик карашларны яклап чыккан галимнең шул карашларны дин белән бәйләве гаҗәп нәрсә булып күренә, әлбәттә. Моның серенә төшенү исә кыен түгел. Язмаларының асылына караганда, Күлтәси дингә ышанмагандыр дип тә уйларга мөмкин. Ләкин без моны тәгаен раслый алмыйбыз. Беренчедән, аның аңы диннән тәмам азат түгел. Икенчедән, ул үзе муллалык вазифасын башкарган. Ә бу вазифа ул чакта үз фикерләреңне ачыктан-ачык әйтергә мөмкинлек бирүче бердәнбер диярлек дәрәҗә булган. Демократик иҗтимагый фикерне, фәнне, сәнгатьне яклаучыларга каршы кадимче фанатиклар котырынып сугышсалар да, мулла, хәзрәт каршында, хәтта ул бик кыю, «тузга язмаган» сүзләр сөйләсә дә, алар артык батырлык күрсәтә алмаганнар.

Безнең уйлавыбызча, Күлтәси үзенең муллалык хәленнән шәхси тормышын тәэмин итү өчен генә түгел, бәлки мәгърифәтчелеккә хезмәт итү өчен дә уңышлы файдаланган. Әлбәттә, мулла буларак, ул фәнне дә диннән аермыйча таратырга, үз фикерләрен дини авторитетларга таянып үткәрергә тиеш булган. Җирнең хәрәкәтсез хәлдә, бөтен галәмнең үзәге дигән ялгыш фикерне кире какканда Күлтәси: «Акылга сыймаслык нәрсәне кабул итүне дин һич мәҗбүр итми» (шунда ук, 18 бит), дип яза. Ә инде җирнең иң әүвәл утлы шар хәлендә булуы һәм ул чакта хайваннар һәм үсемлекләр булмавы турында сөйләгәндә, ул ирония белән: «Ихтимал, риваятьләрдәге шайтаннар, җеннәр шул уттан яралгандыр?» (шунда ук, 14 бит) дип, мондый «акылга сыймаслык» уйдырмаларга урын калдырмый. «Һәйәте җәдидә» китабында Күлтәси дин башлыкларының ялган вәгазьләренә еш кына турыдан-туры һөҗүм итә, аларның сүзенә сукырларча ышанмыйча, табигатьне, тормышны, аның нигезе булган материяне өйрәнергә өнди. «Дин әһелләренең аңлатуынча, пәйгамбәр ничек әйтсә — шуңа ышанырга кирәк,— дип яза ул.— Әйтерсең, матдәнең үзен өйрәнү кирәк түгел!» (шунда ук, 36 бит). Кадим заманнарда, ди Күлтәси, җилне фәрештә сулавы дип саныйлар иде. Динчеләр хәзер дә шуны дәгъва итәләр. Әмма чынында «җил — хәрәкәтләнгән һава» («Хикмәте җәдидә», 24 бит).

Корьән — белемнең бердәнбер чишмәсе, барлык сорауларга тулы җавап бирүче, һәр сүзенә һичшиксез ышанырга тиешле изге китап дип саналган вакытта, Шәмсетдин Күлтәси аңа тәнкыйть күзе белән карарга, кешеләр аңын борчыган мәсьәләләргә җавапны фәнни китаплардан эзләргә чакырып, гаять кыю адым ясаган. «Галәмнең барлыкка килүе хакында Носусы шәргыябездә (Корьәндә) тәфсилат (ачыклык) юктыр,— дип яза ул. — Корьәндә галәмнең яратылуы хакында алланың әмере күп урында әйтелсә дә, боларның барысы да саниг мохтарә (үз теләве белән юктан бар итүчегә) мохтаҗлыгын аңлату өчен генә» («Һәйәте җәдидә», 38 бит). Күлтәси аңлатканча, Корьәндәге галәмне, тереклекне алла яратты дигән сүзләр материаль чынбарлык тәрәккыяте законнарын белмәүгә, шуңа күрә барысын да ниндидер бер илаһи, ихтыярлы бөек көчкә сылтау ихтыяҗына нигезләнгән. Руханилар исә, шуны тәкрарлап, мәсьәләне ансат кына хәл итәргә, кешеләрне шуңа ышандырып тотарга тырышалар.

Әмма җирдә тормыш алга киткән саен, кешеләр күбрәк тәҗрибә алалар, табигать серләрен ача баралар, аң-белем үсә, дөньяга караш үзгәрә. Менә, мәсәлән, шул ук җир яралуы турында: «Боның бер атнада, бер сәнәдә, бер гасырда вөҗүдә килмәеп, кем белер, ничә миллион сәнәләр дәверендә бүгенге көн күрмәктә булындыгымыз — хәл һәм шәкелгә кермештер диярлек» (шунда ук, 43 бит), дип яза Күлтәси. «Бу фикерне,— ди ул,— Корьәндә алла күкне һәм җирне алты көндә яратты дигән сүзгә хилаф булса да, кабул итми мөмкин түгел». Динчеләрнең «Җирне үгез күтәреп тора, үгез балык өстендә, балык диңгездә», дип өйрәтүләреннән ул, аны бары тик әкият кенә» дип, көлә (шунда ук, 49 бит).

Корьәнгә, дингә каршы килүе өчен Күлтәси кыенсынып гафу үтенгән сыман. Әмма объектив хакыйкать аның өчен иң кадерле нәрсә. Шуңа күрә, «Корьәнгә хилаф булса да», ул фәнни карашларны яклый, диннең какшавына ярдәм итә. «Коперник аллаларны күктән куып төшерде» («Һәйәте җәдидә», 44 бит) дип игълан итү өчен мәгърифәтченең фән нигезләренә нык таянган булуы, кыюлыгы, дини фанатизм белән принципиаль килешмәүчәнлеге кирәк иде.

Шәмсетдин Күлтәси диннең фән каршында көчсезлеген сизә һәм бу хакта ачыктан-ачык яза: «Дин галимнәренең төрле фикерләре фәнне инкарь итә алмыйлар» (шунда ук, 49 бит). Ислам дине исеменнән фән үсешенә каршы килүче, мәгърифәтне тоткарлаучы кадимчеләрне Күлтәси рәхимсез тәнкыйтьли.

Мәгълүм булганча, дөньяга материалистик карашны алга сөргән, җирнең һәм башка планеталарның кояш тирәсендә һәм үз күчәрләрендә хәрәкәт итүе турындагы идеяне яклаган күп галимнәр динче фанатикларның каргышына һәм җәзага дучар ителделәр. Аристарх Самосский әле безнең эрага кадәр 3 нче гасыр башында ук дингә каршы чыгуда гаепләнеп эзәрлекләнде, ә аннары Коперник китабы тыелды, Галилей инквизиция хөкеменә тартылды, Бруно утта яндырылды.

Шәмсетдин Күлтәси бу аяныч хәлләрдән хәбәрдар булган. «Коперникның хәрәкәте әрз (җир хәрәкәтен) бәян иткән рисаләләре утка ягылган,— дип яза ул. — Аның мәсләгендә булганнар хөкем ителгәннәр. Кешеләрне тере-тере утка якмышлар» («Хикмәте җәдидә», 16 бит). Аннары Күлтәси инквизиция хөкемен искә төшерә. Галилейны үз карашларыннан ваз кичәргә мәҗбүр иткәч, бер монах шатланып: «Җир хәрәкәтләнә дип тынычлыкны боздыгыз. Хәзер инде сез, судьялар, җиргә тынычлык бирдегез» дип, инквизитор судьяларга рәхмәт белдергән. Шул вакыт, дип яза Күлтәси: «Галилей үзен тыя алмый аягын җиргә орып да: «Юк, Җир хәрәкәт итәдер», диер» (шунда ук).

Үз әсәрләрен язганда аларның динчеләр һөҗүменә дучар булачагын яхшы аңлап эш иткән Күлтәси. «Һәйәте җәдидә» китабында ул: «Галимнәр хозурында расланган бер мәсләк бар, мин моны әйтсәм ихваны кирам (ягъни муллалар, ишаннар) каршында җавапка тартылуым ихтимал»,— ди. Ләкин бу перспектива аны куркытмый, ул хакыйкатьне яшерми һәм фәнни мәсләкнең асылын әйтеп бирә: «Заманән гадәм илә мәсбух улмаеп, даимән хәрәкәт итмәктә булган бер җисем исбатларыдыр» (51 бит), ягъни галәмнең юк урында барлыкка килмәгәнлеген, өзлексез хәрәкәттәге материянең беренчел булуын раслау, ди.

*

* *

Шәмсетдин Күлтәсинең ачыктан-ачык материалистик карашларны бәян итеп чыгып чыннан да динчеләр арасында зур гауга һәм тәшвиш тудыра, аның беренче әсәре кадимче даирәләр өстенә бомба булып төшә. «Һәйәте җәдидә»гә каршы чыктылар, инсанияткә золым дип атадылар»,— дип яза Күлтәси үзе («Хикмәте җәдидә», 2 бит). Күлтәси әсәрен яманлап, аны сүгеп Олуг Мәнгәрдәге өченче мәчет имамы Шаһиәхмәт мулла Мөхәммәди «Бәянелхак» (Хакыйкатьне аныклау) исемле 66 битле китап бастыра (Казан, 1897). Шул ук елны Алабуга өязенең Морты имамы Хәбибрахман әл Мәсьгуди «Мизанелмигъяр» (Акыл дәрәҗәсен үлчәү) исемле 50 битлек китабын язып, Күлтәси фикерләрен «юкка чыгара». Болардан башка тагын Казанда 44 битлек «Иршад» исемле гарәп телендә китап таратыла. Аның авторы Ш. Күлтәсине Ш. Мәрҗани белән янәшә бастырып «кыйный», аларны кәферлектә гаепли һәм тәүбә итүләрен таләп итә. Мулла Мөхәммәтҗан Зәитов («әл Күгәрчени әл Лаеши әл Казани») 1900 елда Казанда 176 бит күләмендә «Хәллел мөшкилат фи кейфияте тәкүне ал галәме» (Галәм яралу турында читен мәсьәләләрне хәл кылу) исемле китап чыгара. Ул баштан ахыргача Шәмсетдин Күлтәси карашларын инкарь итүгә багышланган. Автор «читен мәсьәләләрне хәл кылу» юлын бары тик диннән эзли, шуннан ары китүчеләрне каргый. Аның өчен Әбугалисина да, Әл-Фараби да — бозык кешеләр. Ә аларга иярүчеләр, шул исәптән Күлтәси — кяферләр («Хәллел мөшкилат...», 122 бит). Тәнкыйтьче мулланың логикасы исткиткеч гади: «Гакыл идрак итмәдеке нәрсәнең дәлиле шәргы илә сабит улмасы мәмнугъдыр» («Акыл ирешмәслек нәрсәне дәлилләү шәригать тарафыннан тыелган»). Димәк, галәм тәрәккыяте турында фәнне яклап теләсә никадәр дәлилләр китерсәң дә, моны ислам киртәсендә бозланып каткан акыл сыйдыра алмый икән, ул дәлилләргә таяну хәрам эш. Мулла Мөхәммәтҗан ислам әһелләренең һәр бәхәстә «көчле коралы» булган Күлтәси тарафыннан кискен тәнкыйтьләнгән принципны алга сөрүендә дәвам итә: «Лимә ла йәҗүзе ла нәсәллиме», ягъни дөрес булса да ышанмыйм, төшенергә тырышып баш ватып та тормыйм, Корьәндә ни язган, ишан-муллалар ни әйткән — шуны гына тәкърарлыйм.

Шәмсетдин Күлтәси галәм тәрәккыяте тарихын миллион еллар белән исәпләп, җирнең, андагы тереклекнең алла тарафыннан 6 көндә яратылуы турындагы әкиятне кире

кага. Ислам дине гасырлар буенча тырышып-тырмашып халык аңына сеңдереп килгән, хаким сыйныфларның идеологик терәге булган шушы «хакыйкатьләр хакыйкатен» юкка чыгару белән кадимчеләр килешә аламы соң? Әлбәттә, алар Күлтәси яклаган концепцияне утка тоталар. Ләкин келке дәрәҗәсендә примитив һәм наданнарча эш итәләр. Мәсәлән, Мөхәммәтҗан Зәитовның «логикасы» болай: Корьәндә әйтелгәнчә, ди ул, алланың бер көне дөньяның илле мең елына тиң тора. Димәк, шулай булганда, ягъни көннәрне елларга кабатлаганда да, дөнья миллион еллар дәвамында түгел, 300 мең елда яратылган. Бу исә алланың 6 көненә тигез. «Миллионнар дию — дингә хилаф» («Хәлләл мөшкилат», 77—78 битләр).

Объектив чынбарлык үсеше законнарын танырга теләмичә, бар нәрсәне алла кодрәте белән аңлатып, дөньяга материалистик һәм диалектик карашның халык арасына таралуын туктату — феодаль-буржуаз даирәләрнең һәм аларның ялчылары реакцион руханиларның максаты шуннан гыйбарәт иде. Шуңа күрә, алар Шиһап Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Шакир Мөхәммәдов кебек үз халкын наданлык, милли-дини чикләнгәнлек хәленнән азат итү өчен көрәшчеләрне дошман күрделәр, каһәрләделәр, эзәрлекләделәр. Шәмсетдин Күлтәсигә дә бу һөҗүмне татырга туры килгән, чөнки ул да үз милләтенең күтәрелеп бара торган культура, аң-белем хәрәкәтенә кулыннан килгәнчә өлеш кертергә тырышкан. Ислам руханилары күз алдында бу «зур гөнаһ» эшләү була, шуның өчен Күлтәсине тиргәп, аны кеше үтерүдән дә зуррак җинаятьтә гаепләүләр. Аның үз хатыны үзенә хәрам, артына иярел намаз уку ярамый, үлсә аңа җеназа укылмас, дип шаулыйлар. Дошманнары доносы нәтиҗәсендә Күлтәси өендә обыск ясала, аңа йөзләгән хурлыклы хатлар килә. Әмма болар кыю мәгърифәтчене башлаган эшеннән чигенергә мәҗбүр итә алмый. «Һәйәте җәдидә»нең икенче һәм өченче басмасында ул, үзенә каршы ут ачучыларны «тынычландыру» өчен, галәм ярату турындагы карашлары дингә хилаф түгел дип әйтергә мәҗбүр булса да, нигез фикерләреннән баш тартмый.

Искелекне, рухи караңгылыкны яклап, һәрбер яңа фикергә, фән казанышларына, материалистик философиягә котырынып каршы чыгучы консерваторларга Күлтәси бик оста бәя бирә, аларның гаҗиз адәмнәр булуын күрсәтә: «Бүгенге наданнар,— дип яза ул,— борынгы фанатиклар кебек. Ләкин алар яхшы белсеннәр ки, ул тәгассып заманнары кичмеш, мәгариф вә хакыйкать дәвре килмештер» («Хикмәте җәдидә», 17 бит).

Фәннең, алдынгы философик фикернең, теләсә нинди каршылыкларга карамастан, җиңәчәгенә, халык аңын тәмам биләячәгенә Күлтәси нык ышана: «Тугры фикер зыяэ шәмес кебидер» (шунда ук). Ул объектив хак сүзне, аң-белемне кояшка тиңли, кояш нурын сүндерү мөмкин булмаган кебек, фән үсешен дә туктатырлык көч юк, дип саный. Күлтәси үз хезмәтләренең алдынгы җәмәгатьчелек тарафыннан котлап каршы алынуына шатлана. «Хикмәте җәдидә» әсәрендә ул «һәйәте җәдидә» турында ягымлы сүз әйтеп чыгучылар булды, дип яза, «Троицк мөгаллиме Мөхәммәтзакир бик гүзәл бер мәкалә көндерде»,— ди (2 бит). Күлтәси әсәрләренә карата уңай фикер «Тәрҗеман» газетасында да күренә. Газетаның 1896 ел 31 санында: «һәйәте җәдидә» табигать белемнәрен өйрәнүдә гүзәл кулланма дип, ә 1899 елның 30 санында «Хикмәте җәдидә» әсәре «файдалы китап» дип бәяләнә.

Шәмсетдин Күлтәси эшчәнлегенә зур бәя бирүчеләрнең берсе — Шаһимәрдән Мирзаев үз фикерләрен, шигъри юлларга салып, «Хикмәте җәдидә»гә кушымта рәвешендә игълан иткән. Китапны фитнә дип санаучы муллаларны һәм куштаннарны ул «тәгассып хәсисләр» (түбән кешеләр) дип атый, мәгърифәт мәйданында яңа бер хөрмәтле көрәшче пәйда булды, дип яза.

**Һәмишә тәэлиф [1] илә мәшгуль ул зат,**
**Афәриннар идәм кәррат вә мәррат [2],**
**Менә бу тәхкыйкъ нинди нәфистер!**
**Тәгассып әйләгән үзе хәсистер...**
**Фазыл Күлтәси чыкты-калыкты.**
**Мәрҗани кеби ул рәһбәр даныкты [3].**

(«Хикмәте җәдидә», 64 бит).

[1] Тәэлиф — язу, сочинение.
[2] Кәррат вә мәррат — кат-кат.
[3] Рәһбәр даныкты — юл күрсәтүче данын казанды.

Кұлтәси җәмәгатьчелекнең игътибарын мәгърифәт үсешенә тупларга теләгән. Насыйри кебек үк, ул дини китаплар урынына күбрәк фән нигезләрен аңлатучы китаплар бастырып чыгарырга, мәктәпләрдә табигать белемен өйрәтергә чакыра, кадимчә укыту тәртипләрен тәнкыйтьли.

Бу уңайдан аның «Мәктәп баласы яхуд Сахилә әби» исемле 26 битлек кечкенә әсәре игътибарга лаеклы. Анда ул гыйлемнең кеше тормышында гаять зур ролен күрсәтә, надан кеше ничек кенә тәкәбберләнеп кыланса да, теләсә нинди асыл киемгә төренсә дә, камил кеше була алмый. «Кешегә зиннәт биргән түгел кием, бәлки зиннәт — гыйлем, гыйлем, ялгыз гыйлем», ди ул (1 бит). Аннан соң автор татар балаларының абыстайлар, надан Сахилә әби кебек «укытучылар» кулы астында интегүләрен, төрле аятьләр ятлаудан башка бернәрсә дә өйрәнә алмауларын, шушы аяныч хәлнең күпчелек тарафыннан законлаштырылуын ачынып яза: «Надан хәлфә, абыстайлар, әлебби укытып, яңа ысул төркине «бу ысул илә укыту хәрам, ул шайтан укыту, аның ахыры бик яман» дип, төрле ялганнар, гайбәтләр илә дөньяны тутырдылар. Бу хәл Сахилә әби белән надан хәлфәдә генә булса, ни булса ул иде. Ләкин ни үкенеч, ни хурлыктыр ки, халкымыз арасында исемнәре мәшһүр булган галимнәребез, күп кешеләргә остаз булган мөдәррисләребез Сахилә әбиләргә табакташ булып киттеләр, Сахилә әбинең сүзләрен гарәпчәләп китап итеп язып чыгардылар» (23 бит).

Дини мәктәп-мәдрәсәләрдә урнашкан укыту ысулларын гаепләп, «галим», «хәлфә» исеменә лаексыз муллаларны тәнкыйтьләп, Ш. Кұлтәси «Хәлемездән шикаять» исемле кечкенә шигъри китап тә язып чыгарган (Казан, 1903 ел). Менә аннан кайбер өекләр:

Илдә имам булганнар,
Галим исемен алганнар,
Бигрәк надан калганнар,
Инде нишлик, дусларым!
Мәктәбемездә иҗек,
Мәдрәсәмездә мантыйкъ,
Ташланган схоластик,
Гомер череткәч, дусларым!

...Иҗек укып күп бала
Язу танымый кала,
Бөтенләй надан кала,
Бик кызганыч, дусларым!
...Гарәпчәдән өлеш юк,
Төркине укыган юк,
Ана телен белгән юк,
Бик гафилмез, дусларым.

Ш. Кұлтәси әсәрләренең эчтәлеге әнә шундый. Әлбәттә, бер мәкаләдә аның бөтен эшчәнлегенә тулы анализ ясау мөмкин түгел. Аның иҗатын, тормыш юлын, аралашкан даирәсен, үз чорының башка алдынгы фикер ияләре белән мөнәсәбәтен, иҗтимагый-политик позициясен тирәнрәк өйрәнәсе бар әле. Әмма Яхъя иптәш Абдуллин мәкаләсеннән һәм бу мәкаләдә әйтелгәннәрдән дә шул ачык булса кирәк: Ш. Кұлтәси XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башы татар культура хәрәкәтенең күренекле бер вәкиле, халык мәгърифәте өчен көрәшче.

Дини фанатизмга, урта гасырлар туңлыгына каршы көрәшкән, социаль прогресска хезмәт иткән, аң-белемне, культураны яклап чыккан шәхесләрне без ихтирам белән искә алабыз. Мәкаләбезне татар һәм башкорт халкының олы әдибе Сәйфи Кудашның хак сүзләрен искә төшереп тәмамлыйсы килә: «Феодаль искелек белән мәгърифәтче яңалык арасында башланган аяусыз көрәштә күп кенә кыю кешеләрнең тавышлары яңгырый. Дөрес, алар әле искелек стеналарын ярып чыга алмыйлар. Чөнки ничә гасырлар буенча яшәп вәхши гыйфрит хәленә әйләнгән дини искелек андый берәм-сәрәм кешеләрнең авызларын бик тиз томалаган. Шулай да бу шәхесләрнең хезмәте зур бәягә лаеклы. Алар культурабыз үсеше тарихында гүзәл сәхифәләрне ачтылар» («Яшьлек эзләре буйлап», Казан, 1964 ел, 29 бит).

Шәмсетдин (Шәмсемөхәммәт) Кұлтәси-Таһири — әнә шундый шәхесләрнең берсе.

**КАМИЛ ФАСЕЕВ, философия фәннәре докторы,**
**ӘХМӘТ БУЛАТОВ, СССР Журналистлар союзы члены.**

Тәлгат Галиуллин

# ҖЫРДАН-ҖЫРГА

Шәүкәт Галиев, барыннан да элек, нечкә хисле лирик. Ул дөньяны һәм кеше хисләрен лирик шагыйрь буларак кабул итә, кабул иткәннәрен лирика чаралары ярдәмендә шигырь юлларына күчерә. Хәтта сатира-юмор элементлары өстенлек иткән әсәрләрендә һәм балалар өчен язылган шигырьләрендә дә Ш. Галиев нигездә лирик булып кала.

Сигез юллык шигырьләренең берсендә үзен ул моңсу һәм уйчан табигатьле лирик дип атый:

**Кай арада, белмим, күнеккәннәр —**
**Көлгән, көлдергәнне көтәләр.**
**«Ник үзгәрдең!» — диеп, шул ролемә**
**Кирәргә гел мәҗбүр итәләр.**

**Сер бирмәскә тырышып көлгән идем**
**Һәм шаярткан идем кайчандыр...**
**Ә бәлки мин үзем моңсумындыр,**
**Табигатем белән уйчандыр!..**

Бу юллардагы бер фикер аерым игътибарга лаек: лиризм Ш. Галиев талантының эчке хасияте, табигый халәте, төп сыйфаты икән. Аның «Әткәйгә хат», «Кипарислар мине аңламаслар», «Таң шатлыгы», «Раушаниям, бәгырем», «Хәтимә апа», «Нюра» кебек шигырьләре, дүрт һәм сигез юлдан торган парчалары нәкъ менә лирик интонацияләре, кеше хисләренә сизгер булулары, психологик тирәнлекләре белән аерылып торалар. Шагыйрь эчкерсез интонациясе, самими тавышы белән кеше күңелендәге якты истәлекләрне уята, рухи камил, әхлакый тотнаклы шәхесне олылый.

Ш. Галиев лирикасы интимлыкка һәм эчке уйлануларга тартымлык күрсәтә. Хәтта җыентыкларының, шигъри циклларының исемнәре үк шул хакта сөйли: «Күңел күзе», «Сөенечләрем, көенечләрем», «Уйларым, серләрем», «Фикердәшкә», «Чынлык»... Аның шигырьләре туктаусыз алга ашкынган мул сулы елганы, тормыш моңы белән тулы музыкаль симфонияне хәтерләтә. Бер шигырь икенчесенә барып тоташа, бер җыр икенчесеннән үсеп чыга. Аның лирикасы башка шагыйрьләр иҗатыннан нинди сыйфатлары белән аерылып тора соң? Г. Афзал иҗатында, мәсәлән, публицистик аһәң, гомум иҗтимагый фикер зуррак урын били. Аның лирик герое, шайтан үтмәс упкыннарны кичеп, тау-тау киенлыкларны җиңеп, йолдызларга омтыла, галәм кичә («Дөнья көлсен», «Матур кеше», «Татарстан», «Могҗизалар чоры» һ. б.). Үзенең шигърияткә бирелгәнлеген, аннан юаныч-куаныч, шатлык-ләззәт эзләвен Р. Фәйзуллин романтик-экспрессив буяулар, кискен борылышлар, өермәле хисләр ярдәмендә сурәтли. Ш. Галиев исә поэзиягә мөнәсәбәтен гадәти ситуация, күзгә бәрелеп тормаган тормыш-көнкүреш детальләре аша ачып сала. Аның фикерләү рәвеше дә, поэзияне олылавы да үзенчә:

**Биш ел буе счет төймәсе тарттым**
**(Төп эштән соң яздым шигырьләр).**
**Журналист та булып ун ел чаптым**
**(Төп эштән соң яздым шигырьләр).**
**«Эш»,— диделәр, эшне сорадылар.**
**Беркем сорамады тегесен.**
**Эштән арып кайткач, яшны урлап,**
**Эшләнгән бу минем төп эшем.**

(«Биш ел буе...»)

Ш. Галиев — татар поэзиясенең реалистик традицияләренә, Тукай мирасына, халык иҗаты казанышларына турылыклы шагыйрьләрнең берсе. Ул «мода» артыннан кумый, шәкли «ачышлар» һәм экспериментлар белән укучыны шаккатырырга тырышмый. Ул традицион поэзия кысаларында, аның ачышларына таянып, яңа шигъри биеклекләр яулый, шул җирлектә новатор шагыйрь буларак танылa.

*
* *

Шәүкәт Галиев поэзиягә Бөек Ватан сугышыннан соң килеп керә. Күршеләренә йомышка кергән малай шикеллерәк, оялыбрак, кыймыйчарак килеп керә [1]. «Яңа көйләр», «Кечке утлар» кебек беренче китаплары буенча без хәзер белгән Шәүкәт Галиевне тануы кыен. Шагыйрь ул китапларга кергән шигырьләрендә сугыш елларына туры килгән авыр яшьлеге, туган авылы һәм аның эшчән кешеләре, мәхәббәт хисләре турында яза («Мисал», «Тәнәфестә», «Гарәф» һ. б.). Кеше кичерешләренең катлаулылыгын, тормыш күренешләренең эчке логикасын, закончалыгын аңларга омтылудан бигрәк, ул күргән-белгәннәрен төкми-чәчми сөйләп бирү юлыннан китә. Шундый характердагы җитешсезлекләре дә булуга карамастан, Әхмәт Фәйзи аның «Яңа көйләр» җыентыгына нигездә уңай бәя бирә, Өлкән әдип яшь шагыйрьнең традицион калыпта язылган эчкерсез шигъри юлларында киләчәктә үсеп китәрдәй тормышчан үрентеләр күрә. Бу әсәрләр «мөстәкыйль уйлый белә торган, индивидуаль йөзе булган шагыйрьнең иҗади омтылыш нәтиҗәләре. Аларда шигырь өчен кирәк булган ике элемент: уй һәм тойгы» бар, ди ул [2]. Шагыйрь иҗаты турында соңрак Х. Туфан, С. Хәким, Ш. Маннур, З. Мансур, З. Нури, Н. Юзиев һәм Р. Мостафиннарның мәкалә-рецензияләре басыла. Алар да Ш. Галиев иҗатының шул сыйфатына игътибар итәләр, авторның үз әсәрләрендә «уй һәм тойгы» бердәмлегенә омтылуын хуплап чыгалар.

Еллар узу белән Ш. Галиев максатсыз тасвирлаулардан, иллюстрациячелектән һәм башлангыч чор иҗатына хас үгет-нәсихәтчелектән арына бара. «Әткәйгә хат» исемле өченче җыентыгында инде драматик башлангыч көчәя, хис тирәнәя, шигъри кичерешләр киеренке бер төс ала. Алдагы елларда ул шигырьнең эчке мөмкинлекләрен киңәйтү, фәлсәфи анализны тирәнәйтү юнәлешендә нәтиҗәле эзләнүләр алып бара, шагыйрь үз йөзен, үз тавышын табарга тырыша. Дөрес, форма өлкәсендә әллә ни зур яңалык күренми. Хәтта аның «Чынлык», «Фикердәшкә» кебек, соңгы елларда басылып чыккан китапларында да шул ук табигый интонация саклана, халыкның сурәтле фикерләү алымына якын образлылык өстенлек итә. Ләкин шул арада, шәхес һәм иҗат кешесе буларак, шагыйрь бик нык үсә, микъдари үсештән сыйфат үсешенә таба хәрәкәт итә. Бүген безнең каршыда үзенә чаклы ирешелгән шигъри казанышларны ныклап үзләштергән, югары зәвыклы, сизгер рухлы һәм үз принципларын булдыруга, дөньяны һәм кешене үзенчә тасвирларга омтылган шагыйрь басып тора. Ул инде «офыкларга карап очар өчен иңнәрендә» канатлар тоя. Тормыш турында, яшәешнең максаты һәм мәгънәсе турында, кеше язмышы турында уйланулар рухында язылган шигырьләр күбәя. Шагыйрь кеше белән җәмгыять, кеше белән тарих, кеше белән табигать арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр турында күп уйлана. Ш. Галиевнең лирик герое үзенең интим серләрен, «Мең кешенең мең тавышына» якын күңел

[1] С. Хәким. Үз тавышың белән. Казан. 1969. 215 бит.
[2] Ә. Фәйзи. Әдипнең эрудициясе. Казан. 1973. 203 бит.

тибрәлешләрен, шәхси тәҗрибәсен укучысына ышанып сөйли, аны киңәшкә, бәхәскә чакыра, эчке монолог диалог белән аралаша. Шәхси кичереш кеше язмышына һәм олы дөнья турында уйлануларга алып чыга, «уй һәм тойгы» арасында бердәмлек табыла. Еш кына лирик герой белән шагыйрь шәхесе ахыргача кушылып китәрләр. Дөресрәге, лирик героеның уй-тойгылары аша Ш. Галиев үз биографиясен, үз хисләрен, үз кичерешләрен образлы телгә күчерә.

**Җиргә якын, җырга якын үстем,**
**Эш түмен мин белдем шушында,**
**Татлы ару, талу рәхәтлеген**
**Тәнем тойды минем шушында.**

(«Җиргә якын...»)

Тормышның ачысын-төчесен татыган, «лаеш шулпасын» эчеп үскән шагыйрьнең рухи дөньясы, крестьян хезмәтенә хөрмәте «Киткән чакта...» шигырендә аерым бер сәнгатьчә нәфислек һәм пөхтәлек белән сурәтләнә.

**Киткән чакта мин дә яшел идем,**
**Арышлар да яшел иделәр.**
**Бүген менә, җиткән сакал кебек,**
**Башаклары биткә тиделәр;**

**Кырыс ирләр булып очраштык без,**
**Елаткан да дөнья, көлдергән,**
**Икебез дә инде җитлеккәнбез,**
**Икебез дә инде өлгергән.**

Кыскасы, Ш. Галиевнең шигырьләрен укып, шагыйрьнең туган ягын, балалык һәм үсмер елларын, поэзиягә беренче адымнарын, яшьлек хисләрен һәм хәзерге халәтен, художник буларак җитлегү этапларын күз алдына бастырып була. Бер әдип, «минем биографиямне шигырьләремнән эзләгез», дигән. Аның бу сүзләрен Ш. Галиев тә кабатлый алыр иде. Шәхси башлангыч шигырьләрнең аһәң һәм яңгырашына да тирән йогынты ясый. Шагыйрьнең үз тормыш тәҗрибәсе, үз биографиясе белән тыгыз бәйләнгән бу шигырьләр саклык белән эш итүне, нәзакәтле мөнәсәбәтне таләп итәләр.

Мәгълүм булганча, лирик поэзиянең үзәгендә гадәттә шагыйрьнең шәхси кичерешләре һәм уйланулары ята. А. Блок, С. Есенин, Х. Туфан, С. Хәким поэзияләре шул сыйфатлары белән көчле. «...Автобиографиягә килсәк,— дип яза Ә. Фәйзи,— бу инде лирикага чит нәрсә генә түгел, киресенчә, лириканың тууында ул төп сәбәпләрнең берсе булып тора»[1].

Шәхси биографияңне «җырга салу» җиңел эш түгел, билгеле. Күреп үттек: «Яңа көйләр», «Кичке утлар» кебек беренче җыентыкларында да «шагыйрь үзен яза». Ләкин ул җыентыкларга тупланган күпчелек шигырьләргә поэтик гомумиләштерү җитенкерәми. Соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрендә исә шагыйрь малай чаклары кәтәр сынау елларына туры килгән тулы бер буынның уй-хисләрен, теләк-омтылышларын, шатлык-куанычларын үз тормыш тәҗрибәсе аша гәүдәләндерә. Әлбәттә, шагыйрь яшьлегендә күргәннәрен бөтен ваклыклары белән кәгазьгә төшерү юлына басмый. Ул үткәненә хәзерге казанышларыбыз югарылыгыннан килеп бәя бирә, шигъри фикер гомумирәк төшенчәләрне игътибар үзәгенә ала. Шагыйрьнең шәхси биографиясе укучыны, үтеп киткән елларның аерым сәхифәләре белән таныштырып, иҗтимагый-тарихи прогресс чорына алып килә, бүгенге көн турында җитди уйлануларга этәрә.

**Әйтерсең лә пар атларда үтте**
**Кыңгыраулы мәктәп еллары;**
**Онытылмас, кая юл тотсак та,**
**Сагындырыр таныш чыңлавы,**

---

[1] Әхмәт Фәйзи. Әдипнең эрудициясе. 172 бит.

**Кыңгыраулы мәктәп еллары,**
**Кыңгыраулы мәктәп еллары...**

(«Кыңгыраулы мәктәп еллары».)



Еллар уза һәм канатлы яшьлек, «кыңгыраулы мәктәп еллары», зәңгәр томанга төрелеп, синнән ераклаша барган саен, яшьлегең ешрак искә төшә, ешрак сагындыра икән. Шигырь кичерешенең самимилеге һәм гаҗизлеге белән хәтердә кала. Аерым юллары барыбызга да таныш кыңгырауның «моңлы чыңлавы»н ишеттерә, шәхес кичерешен хәрәкәттә, үсештә бирүгә ирешә. Без алдарак, шагыйрь тулы бер буын исеменнән чыгыш ясый, дигән идек. «Кыңгыраулы мәктәп еллары»... кебек, һәркемне үз яшьлегенә һәм үз хыялына якынлаштыра торган шигырьләр зуррак гомумиләштерүгә ия.

Шагыйрь шәхси башлангыч белән гомуми арасындагы якынлыкны, гармонияне эзли. Кешенең дөньяга карашын, кичерешләрен сурәтләү аша ул социалистик җәмгыятьтә тәрбияләнгән күпчелек кешеләргә хас сыйфатларны, бөтен илне борчыган әхлакый проблемаларны, иҗтимагый коллизияләрне калку итеп сурәтли. Лириканың индивидуаль аша гомумине чагылдыра алу сыйфаты, алар арасындагы бәйләнеш турында рус шагыйре В. Луговской болай дигән иде: «Поэзия шагыйрь йөрәгенең, ә аның аша халык йөрәгенең чагылышы ул... Югары лирика — халыкның шигырьдә чагылган йөрәге» [1]. Ш. Галиев тә сәнгатьчә нәфис һәм тирән эчтәлекле шигырьләрендә үз йөрәге аша халык йөрәгенә юл ала. Ләкин шул кадәресен дә искәртеп узасы килә: реаль җирлектән, үз тормыш тәҗрибәсеннән читләшкәндә, шагыйрьнең илһамы тоныклана, кояшта озак торган бизәкле материя шикелле, төссезләнә. «Шактый еллар...», «Ах, син кояш кыйпылчыгы...», «Әйбәт дуслар...» кебек шигырьләрендә «хәләл көч» вак фикерне матур киемгә төреп бирүгә сарыф ителә. Беришә әсәрләрендә әдип, артык акыллы сүз әйтергә омтылып, кабатлана («Мин кешегә...») яисә үз шәхесе белән мавыгып, аны төрле яклап өйрәнә һәм «урта кул» кеше позасына басып, шуның белән масая («Бер дә гөнаһсыз...» һ. б.).

*

* *

Күпчелек татар шагыйрьләре кебек үк, Ш. Галиев тә поэзиягә авыл темасы белән килеп керә. Уйлана-эзләнә торгач, ул бу традицион теманың башка сүз осталары игътибар итеп җиткермәгән яңа якларын, яңа бизәкләрен таба. Туган ягы — шагыйрь өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы, күңелендә шигъри ялкын, дәрт кабызган җир. Ул шунда татар халкының моңлы һәм шаян, сагышлы һәм омтылышлы җырларын күңеленә сеңдерә.

Талантын, язмышын халкына багышлаган шагыйрь шатлыгы белән дә, кайгысы белән дә туган ил образына килә. Чөнки «җир язмышы — һәрчак ил язмышы, ил язмышы ул — ир язмышы».

Тормыш тәҗрибәсе, рухи һәм әхлакый мөмкинлегеннән чыгып, туган җире турында һәр шагыйрь үзенчә яза дигән идек. Ш. Галиев иҗатына туган як сурәте истәлекләр, хатирәләр һәм тормышчан ассоциацияләр аша килеп керә. Шагыйрьнең биографиясе, шәхси кичерешләре туган ягының үткәне белән бүгенгесен якынлаштыра. Ул кешене туган ил, аның үткәне, хәзергесе һәм киләчәге белән якынлаштыручы уртак нигезне, җанлы җепләрне эзли.

Ш. Галиев — табигать ямен, аның матурлыгын сиземли һәм аңлый белүче шагыйрь. Ул, әрәмәләр арасыннан саркып чыгып, каядыр ашыккан чишмәләр тавышын яратып тыңлый, искән җилләр уңаена талпынып торган яфракларны күреп шатлана, салкыннан өшәнгән язгы үләнне кызгана. Йөрәген борчулар талаганда, «шом үртәп торганда» да ул табигать кочагына чыга. Мәхәббәт һәм серле урман эчендә кеше рухи тынычлык таба, хәвефләрен һәм борчуларын онытып, тормышка һәм вакыт агышына җитдирәк карый башлый.

[1] «Литературная газета», 1957 ел, 9 май саны.

**Кутәрәм күземне түбәннән,**
**Текәләм наратлар башына;**
**Югала минутлык йомшаклык**
**Йөз еллык сабырлык каршында.**

(«Борчулар йөрәкне...»)

Ш. Галиев табигатьтә сафлык һәм матурлык гармониясе күрә. «Каен турында йөзенче җыр» исемле әсәрендә ул болай ди: «Яшьли сөйгән ярлар кебек, сез пакьләр дә, сафлар да». Шагыйрьнең лирикасына назлылык, мөлаемлек һәм тормыш яме белән соклана, гаҗәпләнә белү хисе хас. Бу хис тә күпмедер күләмдә табигатькә якынлык белән аңлатыла булса кирәк.

Туган ягының җанга якын сурәтләренә таянып, әдип тормыштагы туктаусыз хәрәкәтне һәм яңгырашны образлы итеп тасвирлауга ирешә. «Язгы сөенечләр» шигыре бу яктан бигрәк тә кызыклы. «Яз килә, яз, җирнең яшьлеге...» дип башланып киткән шигырьне баштарак гадәти «пейзаж лирикасы» дип кабул итәсең. Баксаң, аның максаты һәм хикмәте бөтенләй үзгә икән. Ахырга таба яз иҗтимагый тормыштагы яңарышларны символлаштыручы сурәт буларак ачыла:

**Яз килә, яз, хисләр яңара,**
**Яңа, якты уйлар ярала.**
**Ташуларда ага чүп-чарлар,**
**Барыр юлдан китә юк-барлар,**
**Туң йөрәкләр бетә баралар,**
**Бетә бара уе каралар.**
**Күләгәләр көн дә кыскара,**
**Сандугачлар җырга остара.**
**Ил яктыра бара, яктыра,**
**Җир яхшыра бара, яхшыра.**

Табигать күренешләре шагыйрьне хезмәт кешесе турында уйлануларга алып килә. Югары әхлак сыйфатларына ия булган, күркәмлеге һәм тыйнаклыгы белән аерылып торган хезмәт кешесе — Ш. Галиев поэзиясенең үзәк герое. Бу төр шигырьләрдә укучы үзенең замандашын таный, күңелендә йөртеп тә, исемен таба алмаган хисләрен исемли, дөресрәге, «кеше үзе әйтеп бирә алмаганны шагыйрь әйтеп бирә».

**Җиргә якын кеше гади була,**
**Купшы сүзләрне ул ятламый;**
**Йөргәндә дә йөри хуҗа булып,**
**Кунак кебек көяз атламый.**

**Белмәгәнгә тупас тоеладыр,**
**Юк, ашыгып алай димәгез —**
**Каты куллы булса, күңеле йомшак,**
**Күңеленә аның тимәгез.**

(«Җиргә якын...»)

Хезмәт кешесенең иң характерлы сыйфатларын үзендә туплаган бу образ безнең күңелләрдә ихтирам һәм хөрмәт хисе уята, шул ук вакытта ул шагыйрьнең күзәтүчәнлеге һәм гомумиләштерү сәләте үсә бару турында да сөйли. Кипарислы җылы якларда да хезмәт кешесе өзелеп-өзелеп туган җирен сагына. Әлбәттә, ул «арышлы кыр, таллы инешләрне» магнолияләр, каштаннар, кипарислар үскән яклардан «өстен куярга» җыенмый. «Тик шулай да, күңел ашкынганда кая барып бүген сыеныйм», «шат чагында яхшы ят якта да, моңайганда кирәк туган як», дип өзгәләнә. «Кипарислар мине аңламаслар» шигыре рухы белән «яхшы булса да торган җир, сагындыра туган җир» дигән халык афоризмына якын тора, әйтерсең лә шуңардан үсеп чыга.

Туып-үскән җирен, Татарстан табигатен генә җырлап, шагыйрь зур һәм олы чынбарлыктан йөз чөермиме? Тарлык күрсәтмиме?.. Безнеңчә, мондый шөбһәгә нигез юк. Беренчедән, туып-үскән якны җырлауны тарлык билгесе дип карау үзе дөрес булмас иде. Шагыйрь үзе яхшы белгән күренешләр һәм кешеләр турында яза. Икенчедән,

ул авылны, аның үткәнен идеаллаштырудан, «шәһәр шәһәр инде, тын авылга шаушулары аның пармы соң», дип чабагачын һәм чабатасын сагынып яшәгән агайга табынудан ерак тора. «Шәһәр керде басу капкасыннан» шигыре әнә шул хакта сөйли. Бу шигырь «Кипарислар мине аңламаслар» әсәрен тулыландырып һәм ачыклап кына калмый, ә шагыйрьнең фикер йөртүе тирәнәя һәм үсә баруы хакында сөйләүче өстәмә бер дәлил була ала.



*

* *

Бөек Ватан сугышы беткәнгә байтак еллар үтте, җимерелгән шәһәрләр, авыллар күптән торгызылды, яңа завод-фабрикалар үсеп чыкты. Бәлки сугыш китергән афәтләр турында әледән-әле искә төшереп торуның кирәге юктыр? Ул хакта онытү, укучыны авыр истәлекләр белән борчымау хәерлерәктер? Ш. Галиевнең «Кулын кыса алмадым» шигыре әнә шул хакта. Шигырь лирик геройның төшенке хисләрен тасвирлау белән башланып китә. Тормыштагы юк-бар нәрсәләргә аның кәефе кырылган. Кешеләрдән һәм шау-шудан качып, башын иеп һәм кулын салындырып, ул бер читтә утыра. Көтмәгәндә аның янына шат күңелле, һәр нәрсәгә «исе китүчән» бер кеше килеп утыра. Баштарак әле, «бар бит җирдә ваемсызлар» дип, шагыйрь әлеге күршесеннән көнләшеп тә куя. Бераздан, үзе дә сизмәстән, сүзгә катнашып китә, авыр уйларын оныта... Ниһаять, «рәхмәт, туган, син булмасаң әле, утырыр идем кәеф кырылып», дип, күршесенең кулын кысарга борыла. Бакса, шат күңелле, бәхетле тавышлы егетнең ике кулы урынында буш җиңнәр асылынып тора. Шигырьнең тоны үзгәрә. Кичереш тыгызлана. Лирик герой кирәкмәгәнгә кәеф бозып, каш салындырып йөргән өчен үзен әрләргә тотына. Йөрәгендә сугышка, шундый оптимист егетләрне кулсыз калдырган явызлыкка нәфрәт уяна:

**Дөнья тыныч түгел,**
**Юк, ярамый**
**Җебеп калып күзне йомарга.**
**Буш җиңнәргә карап төшең кыс та**
**Исән кулларыңны йомарла.**

Фикер ачык: совет кешеләренә исәпсез-хисапсыз казалар алып килгән сугышны бер генә минутка да истән чыгарырга ярамый. Әлеге фаҗига кабатланмасын, фашизм, утлы кисәвен күтәреп, яңадан халыклар өстенә ябырылмасын дисәк, без яшь буынга ата-бабаларыбызның батырлыгы турында туктаусыз искәртеп торырга тиешбез. «Әткәйгә хат», «Ике дус турында баллада», «Кулын кыса алмадым», «Муса елмаюы турында баллада» әсәрләре менә шул максатны күздә тотып язылган.

Бөек Ватан сугышы темасына һәр шагыйрь үз тормыш тәҗрибәсе аша килә. Урта буын шагыйрьләр күбрәк сугыш калдырган авыр яралар, совет тылының, бигрәк тә хатын-кызларның, гаҗәеп батырлыгы турында яза. Ш. Галиев тә сугыш калдырган күңел ярасы, ятимнәр һәм толлар сагышы, шул афәтнең шаукымлы җиле кагылып, физик яисә рухи яктан имгәнеп калган, мәхәббәтен, яшьлеген һәм бәхетен югалткан авыр язмышлы кешеләр, аларның нәфрәте һәм өмете турында күп яза. «Хәтимә апа», «Нюра», «Сугышларда калган...» кебек шигырь-поэмаларда тормыш драматизмы, киеренке хис үзәктә тора.

**Сугышларда калган егетләрнең**
**Баш очында — ялкын йолдызлар.**
**Янууларын тышка чыгармыйча,**
**Сыңар-сыңар яши тол кызлар.**
**Тол кызларның күңелен, тол кызларның**
**Аңласагыз иде әгәр сез...**
**Күпме яңа, туар буыннар бит**
**Югалдылар ана хәбәрсез...**

(«Сугышларда калган...»)

Нибары сигез юл шигырь. Күз алдына өч буынның үкенечле язмышы килеп баса. Кайбер озын-озын поэмалар белән ярышырлык тирән эчтәлекле, тыгыз фикерле лирик парча бу.

«Сугышларда калган...» шигыре әдипнең башка әсәрләрендә конкретлаша, реаль шәхес һәм вакыйгалар хәрәкәтендә ачыла. Менә, язгы чәчәк шикелле, көннән-көн матурлана, нәфисләнә барган чибәр кыз Хәдичә. Чибәрлеге белән генә түгел, ул эшчәнлеге, тырышлыгы белән дә авылда дан тота. Тик аның гүзәллегенә сокланырдай, шатланырдай кеше генә юк: егетләрнең һәммәсе дә сугышта... Дошманны тар-мар итү өчен, егетләр өйләренә тизрәк кайтсын өчен, тагын да тырышыбрак эшләргә кирәк. Хәдичә үзен-үзе аямыйча терлекләр карый һәм алмагачларны да салкын суккан фаҗигале кышта, суык тидереп, матурлыгын җиргә алып китә. Хәдичә образы мәңгегә кешеләр йөрәгендә, шагыйрь күңелендә кала:

**...Кара күзле бер кыз бар иде...**
**Авылдашым минем, Хәдичә.**
**Истә һаман яшь-яшь көенчә,**
**Түзәлмадым сөйләп бирмичә.**

Хәтимә апа яраткан Насыйбулласы белән нибары өч көн торып кала. Сөйгәнен явыз сугыш тартып ала. Ире эзсез-хәбәрсез югала. Сугыш бетеп, күп еллар узганнан соң да, Хәтимә апаның күңеле бу югалтуга ышанмый, һаман көтә, һаман өметләнә, һаман сөя... Тормышы ничек кенә авыр һәм аянычлы булмасын, Хәтимә апа мәхәббәтенә һәм яшьлек истәлегенә турылыклы кала, шул сыйфаты белән соклану хисләре уята.

Зифа буйлы шәфкать туташы Нюраның язмышы тагы да кыенрак. Ул сугыштан бала белән кайтып керә. Кызымның әтисе сугышта, ди. «Хат җибәреп тора, акча салып» тора, ди. Ләкин ата кеше «эз югалтыр өчен генә үзен үлгән дигән хәбәр» тарата да яңа семья кора.

**...Уен гына**
**Булды микән бөтен узганнар!..**
**— Нәрсә булды, әни, ник елыйсың!**
**— Әтиең үлгән диеп язганнар...**

Тормыш фаҗигасе, шигырьне югары сәнгать әсәре иткән трагизм алгы нәүбәткә чыга. Нюраның гуманизмы һәм югары әхлагы соңгы елларда гаҗәеп матурлыгы белән ачылып китә. Нарасые боегып, кимсенеп үсмәсен дип, ана кайгысын эченә бикли, изге алдау юлына баса.

Кеше язмышы катлаулы, четерекле, сагышы да, драмасы да булып тора. Шагыйрьнең бу язмышларны читләтеп үтеп, тормышны бизәп, алсу буяуларда гына күрсәтергә хакы юк. Хәдичә, Хәтимә апа, Нюра — олы бәхеткә лаеклы, кристаллдай саф, югары әхлак кешеләре. Тормыш авырлыгы, язмыш сынавы аларның характерын сындырмый. Һәр очракта да алар идеалларына һәм принципларына турылыклы калалар. Шагыйрь героиняларын хөрмәт һәм тирән эчке кичереш, мәхәббәт белән тасвирлый. Лирик җылылык, кешелекле интонация эпик сюжет белән кушыла.

*
* *

Ш. Галиев иҗатында яшьлек һәм мәхәббәт темасы һәр вакыт зур урын биләп килде. Кайбер шагыйрьләр кебек, ул мәхәббәтне тар, интим хисләргә генә кайтарып калдырмый. Шагыйрь күбрәк кешене үстерә, рухи баета торган мәхәббәтне игътибар үзәгенә ала. Әхлакый сафлык һәм яшьлек хисләренә турылык, якын кешесенә тирән ышаныч лирик геройга төрле каршылыкларны, тормыш авырлыкларын җиңеп чыгарга ярдәм итә. «Күпме күзләр күреп онытылган», «Ник яңара сагышлар?», «Раушаниям, бәгырем», «Тамчылар тамар чаклар», «Мин яндым, син янмадың», «Янып-көясем килә» кебек лирик шигырьләр шуңа мисал була ала. Кешенең изге хисләре турында шагыйрь үзгә бер иплелек һәм нәзакәтлек белән яза. «Яшьлек үтте... Ул көннәрдән

нилəр калды? Сагындырып ромашкалы еллар калды... Күңеллəрдə суынмаслык җылы калды. Мəхəббəтнең бер гөнаһсыз җыры калды...»

Әйе, яшьлек елларының үткəнен кеше сизмичə дə кала. Чигəлəре көмешлəнə, маңгаена сырлар төшə. Кеше «ромашкалы» елларның кадерен белергə, яшьлек хыялларына турылыклы калырга тиеш. «Карашларың шундый ягымлы...» шигыренең дə үзəгендə шул ук фикер ята.

Лирик герой хəтер канатында яшьлек истəлеклəренə кайта һəм сөйгəненең гүзəл сынын күз алдына китерə:

> **Нурлы иде зəңгəр күзлəрең,**
> **Нурлы иде һəрбер көлгəнең,**
> **Нурлы иде һəрбер көлгəнең,**
> **Нурлы иде ап-ак күлмəгең.**

Анафорадан һəм аерым юлларны кабатлау алымыннан уңышлы файдаланып, шагыйрь «зəңгəр күзле», «ап-ак» күлмəкле кызның тере сынын күз алдына бастыра. Тик ул кыз каядыр үткəндə калган. Лирик геройның янəшəсендə үзе шикелле үк олыгайган, чəчлəренə кырау төшкəн өлкəн кеше басып тора. Ә мəхəббəт... «Ак күлмəкле кызны сагындым... Син көрсенмə бер дə моңарга, син бирелмə бер дə моңнарга, синең белəн минем арада шул кыз йөри нурлы юлларда...» Натуралистик ваклык та, хисне һəм яшьлек сагышын гайре табигый күпертү дə, сине элекке кебек үк яратам дип, «күзгə төтен» җибəрү дə юк...

Алтмышынчы еллар башында Н. Юзиев болай дип язган иде: «Шəүкəт Галиев соңгы елларда хискə, юморга бай бик күп җыр текстлары язды. Вакытында алар газета-журнал битлəрендə басыла килделəр. Хəзер аерым җыентык булып чыгалар. Бу җырлар шулай ук композиторлар карашыннан читтə калдылар, көйчелəр игътибар итмəделəр» [1].

Хəзер хəл бөтенлəй башкача. Көйчелəр шагыйрьнең яшьлек һəм мəхəббəт турындагы тирəн тойгылы һəм тирəн эчтəлекле əсəрлəрен көтеп кенə торалар. Әлеге шигырьлəргə хас нəфислек, тыйнаклык, реалистик аһəң, композицион камиллек композиторларны бик күп көйлəр язуга рухландырды. «Раушаниям, бəгырем» (композиторы В. Хəбисламов), «Утыр əле яннарыма» (Е. Хисамов), «Ник яңара сагышлар?» (Ф. Әхмəдиев), «Бар икəн күрəселəр...» (Х. Вəлиуллин) кебек җырлар халык теленнəн төшми. Мондый популярлыкның сəбəплəре күп төрле. Шуларның иң мөһиме халык зəвыгына, халык фикерлəренə якынлык, табигый образлылык һəм ритмик оешканлык булса кирəк. Бу сыйфат һəм үзенчəлеклəргə шагыйрь күпмедер күлəмдə халык иҗаты казанышларыннан өйрəнə. Тамырлары белəн җиргə тирəнгə береккəн агач нык утыра, озак яши, дилəр. Образлы гадилеккə, осталыкка, эчтəлек белəн форма бердəмлегенə ирешү юлында Ш. Галиев, язма поэзия казанышлары белəн бергəттəн, халык хыялы, халык зиһене ачышларына да киң таяна.

Аның лирикасы əйтерсең лə халык җырларыннан үсеп чыга да, хəзерге поэзия тəҗрибəсе, авторның шəхси талант көче белəн тулыландырылып, яңа югарылыкта халыкка кайта. Халык җырыннан ул кичерешне төгəл һəм образлы итеп əйтеп бирү, сурəтле фикерлəү алымнарын төрлəндерү, эчке рифма, рефрен, аллитерациялəрне урынлы куллана белү осталыгына өйрəнə.

> **Мин яндым, син эндəшмəдең,**
> **Мин яндым, син янмадың,**
> **Йөрəгемне бирдем сиңа,**
> **Йөрəгемне алмадың...**
>
> («Мин яндым, син янмадың».)

> **Күпме күзлəр күреп онытылган,**
> **Күпме йөзлəр чыккан исемнəн,**
> **Күпме сүзлəр киткəн хəтеремнəн,**
> **Ә син һаман, һаман исемдə.**
>
> («Күпме күзлəр күреп онытылган».)

[1] Н. Юзиев. Тормыш поэзиясе. Казан, 1961 ел, 74 бит.

Пөхтәлекләре, музыкаль аһәңнәре, эчкерсез интонацияләре һәм тел-стиль чаралары буенча бу юллар халык җырларын хәтерләтә.

«Ник яңара сагышлар?» шигыре, күпчелек халык җырлары үрнәгендә, символик сурәт белән башланып китә: «Шомырт тагын чәчәк койды, сиңа дип өзалмадым». Халык иҗатында «чәчәк коелу» күренеше авыр тойгыны, аерылышуны, ялгызлыкны сурәтләгәндә кулланыла. Ш. Галиев тә халык символының семантик мәгънәсенә һәм эстетик эчтәлегенә турылыклы кала. Лирик герой, шул чәчәкләргә кушылып, сөйгәне янына килү турында хыяллана: «табышмыйча калмас идек, йөрсәң дә кай илләрдә».

**Инде ничә язлар үтте,**
**Күптән тынды сугышлар,**
**Яз килгән саен яңара,**
**Ник яңара сагышлар!**

«Раушаниям, бәгырем» — шактый катлаулы поэтикалы җыр. «Агыйдел», «диңгез», «җил», «акчарлак», «тугай», «чәчәк» кебек табигать сурәтләре, мәрҗән төймәләре шикелле, бер-бер артлы тезелеп, бер-берсен тулыландырып киләләр. Сагыну хисен, күңеленең сөйгәненә өзлексез тартылуын ачыграк аңлату нияте белән, лирик герой чынбарлыкның төрле символларына сүз ката. Романтик образны реалистик сурәт алыштыра. Ләкин бирedә, әйтик, И. Юзеевның «Төнбоек», «Яшь наратлар» җырларындагы шикелле, кичерешне җәеп, үстереп һәм әйдәп барган үзәк образ юк. Раушания үзе дә индивидуальләштерелгән образ дәрәҗәсенә күтәрелми. Шагыйрь аның буй-сынын, килеш-килбәтен, холкын-фигылен тәфсилләүне кирәк тапмый. Җыр жанры, гомумән, детальләштерүне яратмый.

Кыз исемен атап, аңа багышлап шигырь-җыр язу татар халык иҗатының гүзәл бер сыйфаты. Ничәмә буыннар тыңлаучыларда матурлык хисе, эстетик зәвык тәрбияләп килгән «Гөлҗамал», тормышның үзе шикелле катлаулы композицияле «Гөлмәрфуга», «Сажидә», «Зөбәрҗәт», «Фирдәвескәй» кебек җырларны искә төшерик. «Һәр ягы да килгән, матур буй-сынлы, күркәм чырайлы кыз образы — җыелма-традицион образ ул. Гасырлар үтүенә карамастан, бу образның матурлыгы югалмый, чөнки анда һәр заман кешеләренә ләззәт бирә торган объектив матурлык шигъри чагылышын тапкан» [1]. Раушания образы да менә шул традицион образларның дәвамы булып кабул ителә.

Шул рәвешчә, замандашын тере камиллегендә сурәтләү нияте белән, Ш. Галиев татар поэзиясенең 12—13 гасырлардан килә торган бай традицияләренә, халык поэзиясе энҗеләренә, Тукай, Такташ, Җәлил һәм Хәким поэзиясе ачышларына таяна, шулар ярдәмендә үз тавышын, үз аһәңен раслый. Шагыйрь традиция белән яңачалык, язма поэзия белән халык лирикасы арасындагы якынлыкны да, аерманы да тоеп эш итә. Аның югарыда телгә алынган шигырь-җырлары бер караганда халык җырларына бик якын. Ләкин нәкъ шундый юлларны, фразаларны халык авыз иҗатыннан бер фольклорчы да таба алмас.

*

* *

Ш. Галиев уңышлы әсәрләрендә, вакыйганың үзен тасвирлаудан бигрәк, аның эчке мәгънәсен ачуга таба хәрәкәт итә дигән идек. Шул фикернең дөреслеген «Бабайлардан калган...» исемле шигырь мисалында күздән кичерик. Әсәр борынгы язма документларны саклый белмәгән бабайларны «әрләү»дән башлана. Ләкин соңга таба ул үзе үк бу фикеренә каршы чыга. Антитеза алымыннан файдаланып, лирик герой бабаларын «аклау» юлына баса. «Борынгылар җыйнак булмаган, дип әйтер идең, алар аклана: шкаф өсләрендә төргәк-төргәк налог кәгазьләре саклана». Шуннан соң гына шигырьнең төп фикере алга чыгарыла, вакыйга агышы гомумирәк фикергә, нәтиҗәгә юл бирә:

**Йөз саргайткан сары кәгазьләргә**
**Карап утырдым да буш чакта,**
**Тузан җыеп аунап ятмасын дип,**
**Илтеп аттым янган учакка.**

---

[1] И. Надиров. Татар халык җырлары. Сүз башы. Татарстан китап нәшрияты. 1965. 25 бит.

**Йодрык-йодрык мөһер сурәтләрен**
**Утта яндырдым мин үч итеп;**
**Карап тордым кызыл ялкыннарга,**
**Бабайлардан калган төс итеп...**

«Балалар туп уйныйлар», «Яңгыр ява» шигырьләре дә әдипнең сюжет һәм композиция «серләрен» белеп һәм сиземләп эш итүенә дәлил була ала. Һәр шигырьнең эчке киеренкелеге, үз драматургиясе бар. Шуннан башка шигырь юк. «Яңгыр ява» шигырендә табигатьнең гадәти бер күренеше тасвирлана: «яңгыр ява, яңгыр ява, рәхәтләнеп биеп ява, күр, чистарып китте һава»; «тере суы иңә күктән», «саргайганнан яңгыр дәва»... Шигырь дәвам итә. Балаларча саф, күтәренке интонация кинәт җитди, кискен юллар белән алышына:

**Куенымнан яңгыр ага...**
**Кинәт мин сискәнеп китәм —**
**Радиоактив түгел микән,**
**Күктән афәт иңми микән!**

Фикер һәм хис үсешенә яңа юнәлеш биргән әлеге композицион борылыш алдагы юлларны да башкачарак кабул итәргә мәҗбүр итә. Балаларча беркатлылык һәм хыялый ваемсызлык иҗтимагый афәтләр һәм фаҗигаләр турында да онытгырмасын ди шагыйрь. Шигъри осталык фикерне укучыга тулырак һәм төгәлрәк җиткерү максатына буйсындырыла.

Шагыйрьне күбрәк тышкы каршылык аша ачылган эчке уртаклык һәм гармония кызыксындыра. Еш кына материаль һәм рухи дөнья билгеләре, реаль чынбарлык һәм гомуми, фәлсәфи төшенчәләр бер шигъри бәйләмдә очраша. Шагыйрьнең тынгысыз, эзләнүчән фикере «катализатор» ролен уйный. Тормыш-көнкүреш предметлары «җанлана», эчке матурлыгын һәм мәгънәсен ача бара. «Бер карасаң...» шигырен укып багыйк:

**Бер карасаң, тормыш — циферблат —**
**Гап-гадигә аны саныйсың,**
**Өстән-өстән күз төшереп кенә**
**Заманыңны гүя таныйсың.**

**Сәгать телләре күк аңлаешлы**
**Тормыш ул, шәт, асат барадыр!**
**Нәрсә йөртә микән ул телләрне,**
**Сәгатьне син ачып кара бер...**

Сәгать теле һәм тормыш... Алар арасында якынлык табу өчен дөньяга шагыйрь күзе белән карый белү кирәктер. Төрле яссылыкларда яткан төшенчәләрне янәшә урнаштыру, сүз һәм фикер уйнату («сәгать телләре күк аңлаешлы тормыш ул, шәт, асат барадыр?») дикъкатьне күренешнең икенче, мөһимрәк ягына юнәлтергә мөмкинлек бирә («нәрсә йөртә икән ул телләрне, сәгатьне син ачып кара бер...»). Сүз тормышны, заманны алга әйдәгән иҗтимагый көч турында бара. Шагыйрь фәлсәфи-иҗтимагый проблеманы калкытып кую белән чикләнә. Тормыш тәҗрибәсеннән, дөньяны аңлавыннан һәм акыл бизмәненнән чыгып, җавапны һәркем үзе эзләсен. Кыскасы, шигырь олы фикерне, тормыш тәҗрибәсе сөземтәсен нибары сигез юлга сыйдыра алуы, афористик төгәллеге белән игътибарга лаеклы.

«Тормыш сәхнәсендә» шигырендә тормыш театр сәхнәсенә, ә кеше артистка тиңләнә. Дөнья ыгы-зыгысы белән мәшгуль адәм баласы үзе моны сизми дә икән: «иксез-чиксез зур бер сәхнә тормыш, уртасында йөргәч тоймыйбыз, гомер буе шунда һәркайсыбыз үзебезнең рольне уйныйбыз». Тормыш сәхнәсендә баш режиссер кем дисезме? Заман үзе. Кешенең яшенә һәм чыраена карап, гримне вакыт сала. Шагыйрь менә шул шартлы ситуация аша тормышчан фәлсәфи фикер уздыра:

**...Син дә шушы тормыш сәхнәсендә,**
**Үз хакыңда ничек уйлыйсың:**
**Үзеңә бер читтән кара әле,**
**Үзең нинди рольне уйныйсың!**

Бу мисаллар бер нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Шагыйрь дөньяны һәм кешене җитди һәм төпле итеп өйрәнә, яшәешнең тирән мәгънәсен ачып салырга омтыла. Ул вакыйга-хәлләр турында җәелеп сөйләү юлына басмый, ә аның нәтиҗәсен ачып салырга, эчке логикасына үтеп керергә тырыша.

Табигать күренешләрен сынландыру, янәшәлек алымы, тормышчан деталь, шигъри образ ахыр чиктә барысы да шәхес кичерешләрен, аның рухи халәтенең катлаулы чагылышларын тулырак чагылдыру максатына буйсындырыла. Югарыда китерелгән үрнәкләрдән күренгәнчә, Ш. Галиев иҗатында психологик анализга, кеше характерының кабатланмас үзенчәлекләрен шигъри детальләр аша ачуга игътибар һәм омтылыш көчәя бара.

Ш. Галиев иҗатында төрле төшенчәләрне янәшә куюга, эффектлы бетемгә корылган парчалар аерым урын тота. Мәсәлән, лирик герой, чәчләрен «чүмәлә сыман» кыландырган, күлмәкләрен «тәненә сыландырган», «керфек ялгаулы, күз кыек» бер чибәрне әрли-әрли дә, шундый нәтиҗә ясап куя:

**Ә үзем күзне алалмыйм,**
**Бу ни хәлдер, аңламыйм.**
(«Чәчләре чүмәлә...»)

«Җилбәзәк кыз» шигырендә дә шул ук алым кулланылган:

**Сизсәм дә гомер буена**
**Иза чигәчәгемне,**
**Синсез булмый, син юньсезгә**
**Бәйлим киләчәгемне.**
(«Җилбәзәк кыз...»)

Ш. Галиевнең шигыре күләм ягыннан кыскара, тыгызлана бара. Ике, өч, дүрт һәм сигез юллык шигырьләрдә ул үзен тапты, татар поэзиясен күп санлы лирик парчалары, лирик шедеврлары белән баетты. Афористик киная, шома һәм йөгерек тел шагыйрьгә лирик-фәлсәфи миниатюраларында шәхес кичерешен, нинди дә булса хакыйкатьне ачып салу мөмкинлеген бирә. Аның һәр афоризмы — хәрәкәттәге фикер. Кыска шигырьләренең тематикасы елдан-ел киңәя бара. Әдип аларда туган илнең матур киләчәге, тормыш һәм үлем, шатлык һәм кайгы, тиз узучан вакыт һәм мәңгелек турында уйлана. Сигез юл бөтен кешелекне борчыган проблемаларны, яшәешнең катлаулы мәсьәләләрен фәлсәфи тирәнлек белән калкытып куярга да мөмкинлек бирә. Менә бер мисал.

**Ерак планетаның вәкилләре**
**Килеп төшсә җиргә, фаразан,**
**Ничек аңлашырбыз! — диеп инде**
**Галимнәр баш ватып караган.**

**Төшенерләр иде дуслык ымын,**
**Күрешергә кулны сузганда.**
**Тик аныңчы, җирдә яшәүчеләр**
**Аңлашалсак иде үзара.**

Кыска шигырь теленең бөтен нечкәлекләрен, рифма-ритм байлыкларын тирәнтен аңлап һәм белеп эш итүне сорый. «Иң зур нәрсә,— дип яза С. Хәким,— туган телнең барлык мөмкинлекләрен үлчәп, белеп, тоеп язу, үзеңне шуның стихиясендә хис итү... Шәүкәт Галиевнең нигезе нык. Ул әле безгә күп нәрсәләр вәгъдә итә»[1].

Шагыйрь катлаулы метафоралар эзләп баш ватмый. Беренче чиратта, сүзнең күп мәгънәлелегенә, төс бизәкләренә, эпитетларга, парлы сүзләргә, синонимнарга киң таяна. «Тирән тамырлар», «Тормыш тозы», «Яңгыр ява», «Сөйгән ярым минем тылсымчы», «Чәчәкләрне юлда таратсам да», «Балалар туп уйныйлар» шигырьләре — татар теленең бай мөмкинлекләрен, мәгънәви нюансларын исәпкә алып, шуларга таянып язылган уңышлы әсәрләр. Һәр шигырен диярлек ул оста ювелир шикелле эшкәртә, соң чиккәчә җиткереп матурлый.

Ш. Галиев — үсештә, юлда. Юл кешесенең юлда булуы хәерле, ди халык. Аның

[1] Сибгат Хәким. Үз тавышың белән. 218 бит.

шигъри фикерләве елдан-ел камилләшә, яңа төсмерләргә байый, тыгызлана, композицион һәм ритмик алымнары төрләнә, теле шомара. Тынгысыз уе аны яшәешнең яңа проблемаларына, яңа коллизияләренә алып чыга. Шагыйрьнең поэзиягә мөнәсәбәте җитди.

Ш. Галиев һәр шигыре, һәр юлы өчен укучылар каршында, халык каршында үзен җаваплы тоя. Җаваплылык хисе аның поэзиясен илаһи рух һәм иҗат ялкыны белән сугара, туктаусыз алга, яңага әйди.

**Шагыйрь сөйли халкы исеменнән,**
**Халык сүзен итә үз сүзе.**
**Дан алса ул бирә халкына,**
**Ә җавапны тота берүзе.**

(«Шагыйрь сөйли...»)

«Фикердәшкә», «Чынлык» кебек китаплары Ш. Галиевнең зур иҗади казанышы булды. Шулай да аның иң яхшы китабы чираттагысы, алдагысы, иң яхшы шигыре язылачагы дип ышанасы килә. Ышанычның нигезе нык.

Ш. Галиев өзер юлдан йөрергә яратмый. Ул, альпинистлар яисә җир байлыгы эзләүчеләр шикелле, бер үрдән икенчесенә үзе салган, үзе тапкан сукмак буйлап күтәрелә. Бу юлда кыенлыклары да, авыр үрләре дә очрый. Әйтик, Ш. Галиевнең кайбер шигырьләренә күзәтүдән синтезга күчү, нәтиҗә ясау җитенкерәми, темасы белән күп мәгънәлелеккә дәгъва иткән беришә парчалары шактый сай һәм артык гадәти фәлсәфәле булып чыга. «Рәхмәт сиңа...» сигезьюллыгында мәгънә тыгызлыгын һәм эмоциональ-хисси киеренкелекне гомуми пафос, риторик җөмләләр алыштыра. «Кайтар кеше...» шигыре дә артык традицион канва буенча язылган әсәргә мисал була ала. Шагыйрь дилбегәне иҗат фантазиясенә түгел, ә тормыш материалы стихиясенә тапшырган. Бәхеткә каршы, мондый мисаллар аның иҗатында аз очрый.

Тулаем алганда, шагыйрьнең таланты төпле, ул җанлы җепләр аша җиргә береккән, халык йөрәгенә тоташкан. Шул якынлыкны, рухи уртаклыкны күздә тотып, «шунда аунаганда җир сулышын җаным белән тоя идем мин», дип язган иде шагыйрь. Ш. Галиевнең иҗат эшенә сәләтлеге сокланырлык. Хикмәт аның һәр елны диярлек яңа җыентык биреп баруында гына да түгел. Аның иҗат диапазоны елдан-ел киңәя, сулышы иркенәя бара. Бу мәкаләдә без шагыйрь иҗатының бер юнәлеше, бер тармагы хакында гына сүз алып бардык. Шуның өстенә ул юмористик әсәрләре, үткен, җор телле миниатюралары белән дә шөһрәт казанды. Ш. Галиев — балаларның яратып укый торган шагыйре. С. Хәким язганча, «хәзер ул балалар әдәбиятында иң актив эшләүче шагыйрьләрнең берсе һәм иң талантлысы» [1].

«Кайчакта мин Шәүкәтне өч кеше итеп күз алдына китерәм,— дип яза шагыйрь Илдар Юзеев.— Беренчесе — кыска формада зур фикерле, уйландыра торган, үзеннән-үзе җыр сораган шигырьләр язучы уйчан, моңлы Шәүкәт, икенчесе — кешенең кимчелегеннән «көлә-көлә саубуллашучы», үзенең геройларын йомшак җәеп, катыга утыртучы изге ниятле усал Шәүкәт һәм, ниһаять, балаларның шаян табигатен һич тә ясамыйча-нитмичә бирә белгән, мәктәп турында язса да, үгет-нәсихәттән шигъри хәйләләр белән котыла алган шаян Шәүкәт» [2].

Шәүкәт Галиевнең сатирик һәм юмористик шигырьләре турында да, хәзерге балалар әдәбияты үсешендә тоткан урыны турында да әлегә төпле фикер әйтелгәне юк. «Шәүкәтне өч кеше» итеп күз алдына бастыру, иҗатының һәр тармагын аерым-аерым өйрәнү белән беррәттән, аның әдәби юлын бербөтен итеп яисә шагыйрьнең эстетик идеалын, тормыш материалына, тирәнлеккә мөнәсәбәтен, кешенең рухи дөньясын тасвирлау алымнарын гомумирәк планда тикшерү дә файдалы нәтиҗәләргә алып килер иде. Хәзергә бер хакыйкать ачык: Ш. Галиев эчтәлекле, ил каршында торган бурычлар, киләчәктә чишелешен көтеп торган проблемалар турында борчылып, уйланып язылган һәм халык рухы, халык тәҗрибәсе белән баетылган төрле шигъри жанрларда иҗат ителгән шигырьләре белән хәзерге татар совет поэзиясенең алгы сафында атлый.

---

[1] С. Хәким. Үз тавышың белән. 217 бит.
[2] Ш. Галиевнең «Шалт Мөхәммәтҗан» җыентыгына сүз башы. Казан. 1970. 4 бит.

# КҮП БИЗӘКЛЕ, БЕРДӘМ ӘДӘБИЯТ

Алдыбызда ягатып һәм пөхтәләп чыгарылган калын-калын алты том китап. Аларны эчке бер горурлык, хөрмәт һәм ихтирам хисләре белән кулга аласың. Бу — илебездәге җитмештән артык милли әдәбиятның күмәк тәҗрибәсен гомумиләштергән беренче фәнни хезмәт бит. Йомгак характерындагы хезмәт, барлык милли республикалар, өлкә һәм округлардагы тәнкыйтьчеләрнең, әдәбият галимнәренең уртак тырышлыгы белән язылган хезмәт. Шикләнми әйтергә була, совет әдәбият фәне тарихында казаныш булып калачак хезмәт.

«Күп милләтле совет әдәбияты тарихы»[1]н язу өчен җирлек алдан әзерләнде. Соңгы елларда аерым язучылар иҗаты, шулай ук бөтен бер әдәбиятлар үсеше буенча күп санлы монографияләр, төрлетөрле җыентыклар барлыкка килде, совет әдәбияты тарихының аерым дәверләрен, теге яки бу жанрның формалашу тарихын һәм үзенчәлекләрен тикшерүгә багышланган махсус хезмәтләр чыкты. Мисал рәвешендә «Рус совет әдәбияты тарихы»ның М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты тарафыннан чыгарылган ике басмасын, академик харакгерда язылган «Украина совет әдәбияты тарихы»н, башка милли әдәбиятлар тарихы буенча чыккан уннарча «Очерклар»ны күрсәтергә була. Алар барысы да зур күләмле, капиталь хезмәтләр. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре тарафыннан язылган һәм 1960 елда Казанда аерым китап булып чыккан «Татар совет әдәбияты тарихы (очерклар)», мәсәлән, 50 табактан артыграк булып, анда татар совет әдәбиятындагы төп жанрларның формалашу һәм үсү юлы күздән кичерелгән иде. Шул рәвешчә, күп милләтле совет әдәбияты тарихына караган яңа хезмәт нык, тирән фәнни база нигезендә язылган, һәм ул әдәбият фәне, шулай ук тәнкыйть фикере өлкәсендә илле ел буена ирешелгән казанышларны гомумиләштергән.

Әлеге фундаменталь хезмәтне язганда, галимнәребез башкарган эшнең күләмен күз алдына китерүе дә кыен. Мәсәлән, беренче томда гына да 1400 дән артык совет язучысының иҗаты бәяләнә. Милли әдәбиятларның кызу темплар белән үсешенә бәйле рәвештә, алдагы томнарда исемнәр даирәсе тагын да төрләнә һәм киңәя төшә. Әгәр әдәбият тарихының беренче томында урнаштырылган мәкаләләрдә күп дигәндә егермеләп милли әдәбиятның үсеш юлы һәм иҗат йөзе тикшерелгән булса, бишенче томда инде андый мәкаләләрнең саны иллегә якыная. Бу саннар, милли әдәбиятларның бик нык чәчәк атуларын күрсәтү белән бергә, аларның ил күләмендәге әдәби процесска нинди темпта кушыла барулары хакында да сөйлиләр.

«Күп милләтле совет әдәбияты тарихы» югары уку йортларында, техникумнарда, шулай ук урта мәктәпләрнең югары классларында милли әдәбият укытучылары өчен алыштыргысыз кулланма булыр дип уйларга кирәк. Шуның белән бергә, ул гади бер әдәби-тарихи фактлар җыелмасы гына түгел, ә зур теоретик әһәмияткә ия булган тирән хезмәт. Анда күп милләтле совет әдәбиятының ярты гасырлык үсеш юлы күзәтелә, әдәби тормыш фактлары иҗтимагый-тарихи процесслар, социаль һәм культура төзелеше-

[1] История советской многонациональной литературы. Рус телендә. 6 томда. Мәскәү. «Наука» нәшрияты. 1970—1974 еллар.

нең иң мөһим вакыйгалары белән аерылгысыз бәйләнештә тикшерелә. Әдәбият тарихы томнары белән танышканда, СССРдагы культура революциясенең үзенчәлеге һәм ленинчыл милли политиканы тормышка ашыруның нәтиҗәләре ачык булып күз алдына баса, өр-яңа сәнгать күренеше булган совет әдәбиятының формалашу һәм үсү тарихы, аның гомуми закончалыклары, шулай ук һәр милли әдәбиятка хас үзенчәлекләр ачыла. Томнарда социалистик культура барлыкка килү белән бәйле катлаулы процесслар күздән кичерелә, тугандаш әдәбиятлар арасындагы бәйләнешләрнең көчәя, ә бердәмлекнең ныгый баруы күрсәтелә, совет сәнгатенең бердәм методы булган социалистик реализмның формалашу этаплары хакында конкрет төшенчә бирелә.

Халыклар бердәмлеге — әдәбиятлар бердәмлеге... Хезмәтнең төп идеясен әнә шул сүзләр белән билгеләргә мөмкин. Партиянең XXIV съездында бик дөрес әйтелгәнчә, совет власте елларында бездә кешеләрнең яңа тарихи гомумилеге — совет халкы барлыкка килде. «...Әдәбият тарихы»ндагы күпчелек мәкалә һәм материаллар тегеләйме-болаймы шул тезисны раслауга хезмәт итә. Совет халкы — тарихта бер кайчан күрелмәгән, ифрат нык һәм монолит бердәмлеге белән аерылып торган гомумилек. Территориаль, экономик, политик гомумилек кенә түгел, ә дөньяга караш һәм идеяләр бердәмлеге, рухи бердәмлек белән бәйле гомумилек. Совет власте елларында төрле милләт кешеләре арасында уртак рухи сыйфатлар формалашты, башкача без аны совет характеры дип йөртәбез. Тагын да конкретлаштырып әйткәндә, совет кешеләрендә искиткеч кыйммәтле бер сыйфат барлыкка килде, үз вакытында П. Тычина аны, бик кыска һәм төгәл итеп, «гаилә бердәмлеге хисе» дип атаган иде.

Күп милләтле илебез халыкларының аерылмас бердәмлеге совет әдәбиятының да бердәм булуын китереп чыгара. Безнең илдә милли әдәбиятлар җитмештән артык телдә тәрәккый итә — дөньяда башка андый ил юк; милли әдәбиятларның бездәгедәй тыгыз һәм туганнарча хезмәттәшлеген тарих башкача белми. Совет әдәбияты үз составына кергән милли әдәбиятларның гади суммасыннан гына тормый. Ул — ифрат кызыклы һәм үзенчәлекле өр-яңа тарихи күренеш. Аерым милли әдәбиятларга хас форма һәм үзенчәлекләр ни хәтле генә төрле-төрле булып күренмәсен, совет әдәбияты искиткеч нык идея-эстетик бердәмлеге, процесслар уртаклыгы, бурыч һәм омтылышларның органик якын булуы белән аерылып тора. Шул нәрсә һәр томга урнаштырылган кереш мәкаләләрдә күп милләтле бөтен совет әдәбиятына хас уртак закончалыкларны тирәнтен һәм киң итеп ачарга мөмкинлек биргән.

«...Әдәбият тарихы»ндагы материаллардан тагын бер нәрсә ачык күренә: бөтен совет әдәбиятына хас бердәмлек һәр халыкның әдәбияты, һәр әдәбиятның кабатланмас үзенчәлекләре җирлегендә, һәр милли әдәбиятка хас төп, хәлиткеч типологик сыйфатларның синтезы төсендә үсеп чыккан икән. Аерым алганда, моны үзебезнең татар әдәбияты мисалында да ачык күрергә мөмкин. Алты томлыкта безнең әдәбиятка шактый зур урын бирелгән. Һәр томда диярлек татар совет әдәбияты үсешенең аерым чорлары турында төпле язылган мәкаләләр урнаштырылган.

Миңа калса, әдәбият тарихын өйрәнүгә шушы рәвешчә якын килү бик табигый һәм законлы күренеш. Авторлар күп милләтле совет әдәбиятына алдан уйланган нинди дер сыйфатларны көчләп такмыйлар, ә аларны һәр әдәбиятны җентекләп өйрәнү җирлегендә күзәтеп баралар. Шулай тиеш тә, чөнки һәр милли әдәбиятның үз үсеш юлы, үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Бер өлеш әдәбиятларның күп гасырларга сузылган бай тарихы булган, икенче халыкларда Октябрьдән соң гына язу барлыкка килгән. Әмма барлык совет әдәбиятлары — уртак тарихи язмышка ия әдәбиятлар. Һәр әдәбиятның тарихын тикшергәндә, галимнәр аларның бер үк этаплар аша (Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы; халык хуҗалыгын торгызу һәм социалистик төзелеш еллары; Бөек Ватан сугышы; сугыштан соңгы чор һ. б.) узуларын күрсәтәләр. Әлеге этаплар төрле әдәбиятлар арасындагы идея-тематик уртаклыкны гына билгеләп калмый, ә тагын да тирәнрәк эстетик сыйфатларны китереп чыгара (сугыш елларында очерк һәм публицистика жанрының активлашуы; эпик жанрларның эволюциясе; лириканың үзенчәлеге һ. б.). Әгәр М. Җәлил белән Ф. Кәримнең фронт лирикасы күпмедер дәрәҗәдә К. Симонов, А. Сурков кебек шагыйрьләрнең шул еллардагы лирик шигырь циклларына аваз-

даш икән, моны гади ияру белән генә аңлатып булмый. Сәбәп тирәндәрәк ята. Ул елларда бөтен халык, бөтен совет әдәбияты алдына бер үк бурычлар килеп баскан иде — аваздашлык шуннан килә. Аннан соң, барлык милли әдәбиятлар Коммунистлар партиясенең зирәк җитәкчелеге астында үсә, барлык язучылар бердәм союзга тупланган була. Менә шуңа күрә әдәбият тарихы томнарында барлык милли әдәбиятлар идея омтылышлары уртак булган, уртак иҗат методы — социалистик реализм җирлегендә үскән бердәм совет әдәбиятының аерылмас кисәкләре итеп карала, бербөтеннең аерылмас өлешләре итеп тикшерелә.

Томнарда тугандаш әдәбиятларның үзара тәэсире һәм бер-берләрен баету процессларын өйрәнүгә аеруча зур игътибар бирелгән. Тегеләйме-болаймы әлеге мәсьәләгә кагылмаган бүлек яки мәкалә бөтенләй юк дияргә була. Хезмәттә әдәбиятларыбызның үзара бәйләнеше бөтен байлыгы һәм төрлелеге белән яктыртыла, туу, үзгәрү, ныгу процессында карала. Әйтик, егерменче елларда тугандаш әдәбиятларның үзара бәйләнеше нигездә берьяклырак характерда була һәм алга киткән, өлкән әдәбиятларның яңа формалашып килгән әдәбиятларга йогынтысы төсендә чагыла. Бу чорда өйрәнчекләрчә кабатлау, ачыктан-ачык ияру күренешләре еш очрый. Егерменче елларда чын мәгънәсендәге тәэсирләр турында сөйләргә иртәрәк әле. Алга таба, утызынчы, кырыгынчы елларда һәм илленче елларның беренче яртысында әдәбиятлар арасындагы иҗади бәйләнешләр кызу темплар белән үсә башлый, язучылар арасында шәхси контактлар ныгый, тәрҗемә эше күрелмәгән колач ала.

Кыскасы, бу чорда күпьяклы һәм даими йогынтылар өчен ныклы нигез салына. Ниһаять, илленче елларның уртасыннан башлап тугандаш әдәбиятларның үзара тәэсире һәм бер-берләрен баетулары системалы, планлы төс ала. Совет тәрҗемәчеләренең искиткеч актив иҗат эшчәнлеге төрле милләт укучыларына тугандаш әдәбиятларда барлыкка килгән иң яхшы әсәрләр белән танышып бару мөмкинлеге тудыра. Совет әдәбиятының үз эчендә рухи байлыклар алмашу тарих беркайчан белмәгән масштабларга җитә. Бөтенсоюз тәнкыйте дигән матур күренеш барлыкка килә, ул күп милләтле бөтен сәнгать процессын күз уңында тота башлый. М. Кузнецов, З. Османова, Н. Надъярных һәм Новиченколарның бишенче томга язган кереш мәкаләләрендә дөрес күрсәтелгәнчә, илленче елларның урталарыннан башлап безнең әдәбиятларның үзара йогынтысы һәм бер-берләрен баетулары чын-чыннан күпьяклы, даими һәм тигез хокуклы төс ала.

Күп кенә буржуаз галимнәр: «психологик, эмоциональ һәм акыл үзенчәлекләре ягыннан кайбер халыклар, имештер, үсешкә сәләтсез, алар торгынлыкка һәм үлемгә хөкем ителгән» дип лаф оралар иде. СССРдагы милли мөнәсәбәтләр тәҗрибәсе аларның бу ялганын юкка чыгарды. Октябрь революциясе җиңгәндә безнең илдәге милли культураларның үсеш дәрәҗәсе төрле югарылыкта була. Һәм менә характерлары, үсеш дәрәҗәләре белән төрле-төрле булган шушы культуралар тарихта беренче мәртәбә, бердәм социаль типтагы культуралар буларак, бер эздән үсә башлыйлар. Акрынлап аерым әдәбиятлар арасындагы кискен аермалар бетә бара, әдәбиятларның үсеш дәрәҗәсендәге беренче карашка атлап чыга алмаслык булып күренгән аерымлыклар акрынлап кими, бөтен халыкларга аңлаешлы һәм якын булган бердәм әдәбият формалаша башлый.

Моннан чыгып, совет халыкларының сәнгатьчә аңы абсолют бер төсле булып калган икән, дип уйларга ярамый, билгеле. Милли совет культуралары арасында ирекле һәм тигез хокуклы бәйләнеш, алга киткән әдәбиятларның, беренче чиратта, рус әдәбиятының, туганнарча ярдәме арттарак калган һәм яңа туып килгән әдәбиятларга үз йөзләрен табарга, капиталистик җәмгыять шартларында котылгысыз булган аерым яшәү юлыннан котылырга булыша. Шуның белән бергә, яшь һәм яңа туып килгән әдәбиятларның тизләтелгән үсешен бары алга киткән әдәбиятлар йогынтысы белән генә аңлату дөрес булмас иде. «...Әдәбият тарихы» белән танышканда, бер нәрсә ачык күренә: патша строе чорында изелгән, кысылган, эзәрлекләнгән әдәбиятлар Октябрьдан соң уяналар, алар алдында торган киртәләр алып ташлана, үзләренең бөтен сәнгатьчә потенцияләрен күрсәтү өчен ул әдәбиятларга чикләнмәгән мөмкинлекләр ачыла.

Авторлар дөрес язганча, безнең чорда теләсә кайсы милли әдәбияттагы табыш һәм ачышлар, тәҗрибә һәм алдынгы казаныш шунда ук башка әдәбиятларның

да байлыгына, уртак «милкенә» әверелә, алай гына да түгел, аларның үсешенә актив тәэсир итүче көчкә әйләнә. Милли әдәбиятларның үзара тәэсире һәм бер-берсен баетулары безнең алда яңа киңлекләр ача, эстетик диапазоныбызны киңәйтергә булыша, элек милли тәҗрибәдә булмаган яңалыкларны китереп чыгара. Шул ук вакытта «...Әдәбият тарихы»ның авторлары даими рәвештә бер нәрсәгә басым ясыйлар: үз йөзләре, үз бизәкләре булган кабатланмас үзенчәлекле әдәбиятлар, ләкин бер социаль тамырдан үсеп чыккан, шуңа күрә антогонистик каршылыклардан азат әдәбиятлар якыная.

...«Күп милләтле совет әдәбияты тарихы»н язуга Г. Халит, Н. Гыйззәтуллин, Б. Гыйззәт, Р. Башкуров, В. Воздвиженский, Н. Юзиев, Х. Хәйри һәм безнең республиканың башка әдәбият галимнәре актив катнашкан. Татар әдәбиятына караган бүлекләр, күләм ягыннан зур булмасалар да, ышандырырлык һәм фәнни яктан нигезле итеп язылганнар. Тагын шунысы куанычлы, татар совет әдәбиятына караган фактлар һәр томга урнаштырылган кереш мәкаләләрдә дә чагыла.

Совет галимнәренең хезмәте аерым милли әдәбиятларның, шулай ук гомуми совет әдәбиятының язмышы турында уйлану өчен бай материал бирә. Ул күп милләтле әдәби процесс белән кызыксынучыларга, совет әдәбияты узган бай үсеш юлын белергә теләүчеләргә әле күп еллар буена файдалы кулланма булыр, дип ышанасы килә.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ КҮП ТӨРЛЕ ГЕРОЙЛАРЫ

Мәскәүнең «Современник» нәшрияты күренекле татар прозаигы Әмирхан Еникинең бер томлык сайланма әсәрләрен басып чыгарды. Җыентык «Тауларга карап» [1] дип атала. Ә. Еники әсәрләре Татарстанда гына түгел, ә бөтен союз күләмендә дә укучыларның игътибарын күптән үзенә җәлеп итеп килә. Моның сере — язучы иҗатының үзенчәлекле, халыкчан булуында, тирән психологизмда, эмоциональ тәэсир көченең зурлыгында.

Билгеле булганча, татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре ягымлы аһәңе, лексиканың музыкальлеге, һәр яктан пөхтәләп эшләнгән булуы белән аерылып тора, кай ягы беләндер ул украина әдәбиятын хәтерләтә. Авторның бер томлыгына язган кереш сүзендә тәнкыйтьче Р. Мостафин да шул ук фикерне куәтли. Ул язучы иҗатына хас үзенчәлекләр хакында язып килә-килә дә фикерен мондый сүзләр белән тәмамлый: «Әгәр Әмирхан Еникинең художник буларак төп үзенчәлеген бер-ике сүз белән билгеләргә кирәк булса, ул — татар язучылары арасында иң музыкаль әдип, дияр идем».

Җыентык төрле характердагы әсәрләрдән тора, әмма, миңа калса, ул ифрат дәрәҗәдә максатка омтылышлы итеп төзелгән; яшәү шатлыгы, хезмәткә һәм кеше көченә, физик һәм акыл хезмәтенә дан җырлау — аның төп пафосын шул хисләр тәшкил итә. Шуның белән бергә, мещанлыкка каршы рәхимсез көрәш рухы, тормышта очрый торган аерым ямьсез күренешләргә актив каршы тору хисе аңа гражданлык ялкыны өсти.

Ә. Еники әсәрләрен уку тагын шуның өчен кызык, ул милли көнкүрешне һәм гореф-гадәтләрне бөтен нечкәлекләре белән бирә ала, үз халкы, туган теле һәм аның җыры белән горурлана белә. Аның әсәрләрендә яңгыраган горурлык хисенә милли чикләнгәнлек, тәкәбберлек ят, ул совет кешеләренең гомум горурлык хисе белән органик төстә бергә кушыла.

Үзе дә авыл җиреннән чыккан кеше буларак, Ә. Еники күбрәк авыл турында яза. Аның иң яраткан жанры — хикәя. Тагын шул кадәресе кызык, аны бигрәк тә тормыш тәҗрибәсе зур булган өлкән кешеләр үзенә тарта. Андый кешеләр бүгенгене үткән белән чагыштырып бәяли алалар, бәлки бу — шуның белән аңлатыладыр? Алар хезмәт шатлыгын да, гомер-

[1] А. Еникеев. Глядя на горы. Рус телендә. «Современник» нәшрияты. 1974 ел. Бәясе 86 тиен.

гомердән килгән халык бәйрәмнәренең ямен дә әйбәт беләләр. Мисалга «Әйтелмәгән васыять» исемле хикәядән үз токымының дүртенче буынын күрү бәхетенә ирешкән Миңлебай картны алыйк. «Дөньяда чамасыз озак яши торгач, кайчандыр паровоз тавышын да ишетмәгән бабай тракторын да күрде, автомашинасын да, самолетын да, радиосын да күрде; алар аның авылына һәм өенә килеп керделәр... Бу заманның барышына искитеп өлгерерлек түгел иде».

Яшермим, баштарак нигә автор җыентыгына «Тауларга карап» дигән исем бирде икән дип аптырап калган идем. «Тауларга карап» — моңсу хикәя, ахыры бәхетле тәмамланса да, бәгырьне телгәли торган хикәя. Китапның соңгы битенә кадәр укып чыккач, яңадан шул хикәягә әйләнеп кайттым һәм шунда аның бөтен җыентыкны фәлсәфи яктан берләштереп килүен аңладым. Мин тормышның мәңгелек булуы турындагы фәлсәфәне күздә тотам.

Шушы уңайдан Р. Мостафинның кереш сүзендәге тагын бер фикерне куәтләп үтәсе килә. Сүз Ә. Еники әсәрләрендәге моңсулыкның характеры турында бара. «Барыннан да бигрәк,— дип яза тәнкыйтьче, — бу якты, бөтенләй диярлек сизелмәслек моң, әбиләр җәенең зәңгәр күген ураган көмеш пәрәвез җепләре кебек, ул хикәяләүнең буеннан-буена сузылып бара».

Ә. Еникинең аерым хикәяләрендә үткән тормыштагы барлык яхшы нәрсәләргә күз йомарга, традицияләрне, миллилекне, халыкның рухи байлыгын онытырга әзер торган үтә сул карашларга каршы юнәлдерелгән авазлар сизелеп кала. Андый кешеләр фикеренчә, авылда бары караңгылык кына хөкем сөргән. «Матурлык» исемле хикәянең лирик герое, мәсәлән, ундүрт яшьлек шәкерт чагыннан ук, чын кешелек бәхете бары шәһәр җирендә генә мөмкин, дип ышанып яшәгән була.

«Туган туфрак» дигән хикәядә институтның соңгы курсында укучы Клара исемле кыз мондый карашларын тагын да ачыграк итеп белдерә. Туган як белән соклану, авылның «яланнары, таулары матур, халкы бик әйбәт, кунакчыл» дигән сүзләрне ул бабасыннан гына ишеткән була. Ләкин кызның бабасы озак тормый үлеп китә. Ә менә әтисе, бабасы кебек үк, шул авылда туып-үскән булса да, Каракошны сагынып бер дә телгә алмый. «Әтисе аның алдынгы кеше шул, — ди автор ирония белән, — капитализм чорындагы авылны сагынып, мактап сөйләүнең килешмәгәнлеген бик яхшы белә ул». Шуңа күрә Клара да «иске авылда бары хәерчелек, караңгылык, наданлык, вәхшилек кенә булган» дип ышанып яши.

Әсәрнең ахырына таба Ә. Еники шулай да Клараны туган туфракка алып кайта (чөнки бабасының васыяте шундый). Һәм шунда кыз үзенең никадәр ялгышканын аңлый. Юк, үткәндәге һәммә нәрсә начар түгел икән, гасырлар тирәнлегеннән килә һәм кешеләрне кеше итә торган әхлак нигезләре бар икән — кыз шуны аңлый.

* * *

Җыентыкның тематик диапазоны шактый киң һәм газета рецензиясендә генә андагы әсәрләрнең һәркайсына анализ ясау мөмкин түгел. Әмма «Рәшә» повестена тукталмый үтә алмыйм. Әсәрдәге төп нәрсә — искиткеч кызыклы әдәби тип булган Зөфәр Сабитов. Нәкъ менә тип, социаль тип. Аның турында күмәк төстә, сабитовчылык күренеше буларак сөйләргә мөмкин.

Зөфәр Сабитов — югары экономик белем алган коммерсант, тәэминатчы. Аңа зур белгеч итеп карыйлар һәм аның белән хисаплашалар. Юкка гына бит Ватан сугышына да җибәрмичә, броньнар биреп саклап тотмыйлар. Ул үзен кирәкле, булдыклы кеше итеп күрсәтә белә... Өстәвенә, ул үзен һич кенә дә материаль җаваплы эшләр белән бәйләргә теләми. Юк, аның эше — гомуми җитәкчелек, коммерция. Ревизияләр аның Орстагы коммерция эшчәнлеген читләтеп узалар. Дөрес, күпләр аның хәйләкәр карак икәнен чамалый, ләкин бәйләнерлек дәлилләре юк. Оста, бик оста рәвештә ул кеше кулы белән утлы күмер көри.

Бу кешенең мораль йөзен беләсегез киләме? Рәхим итегез, менә аның тормыш турындагы фәлсәфәсе.

«Эшенә күрә әҗере бар икән, аңа шул җиткән. Һәркемнең үз исәбе — дөньясы шул!»

«Чукынган заман... курыкмыйча, яшәренмичә бер генә нәрсә дә эшләп булмый бит!»

«Һичшиксез, моннан соң да аның тормышы иске эздән барачак, ягъни әй-

бәт кенә эшләп, үз рәхәте өчен яшәргә тиеш булачак».

«...Яшәр өчен, тормышны үзең теләгәнчәрәк корыр өчен, һичшиксез, агым уңаена агарга кирәк, ...һәр вакытта уяу, тыйнак, мыштым булырга кирәк. Бу, аныңча, үзең өчен яшәүнең иң дөрес юлы» һ. б. һ. б.

Һәм менә Зөфәргә автор биргән характеристика:

«Зөфәр көн яктысы күрми торган яркапат кебек сукыр булса да, төлкедәй сизгер кеше иде. Аңардагы бу сизгерлек заманга да яраклашып, үз максатына ирешергә дә тырышып яшәү аркасында гаҗәп камилләште. Эшен бик шома йөртте, куркынычны алдан күрә белде, хәтәр-хәвефләрдән тайпылып кала алды».

Зөфәргә хәтта сәүдә министрының урынбасары да ышана. Хәер, өч ел буе яратып йөргән кешесе, бер көн килеп: «Кем син, Зөфәр, кем?» — дип сорарга мәҗбүр булган икән, нигә әле министр урынбасары хакында сөйләп торырга.

Шулай да нинди кеше соң ул? Автор бәлки тагын бер мәртәбә вак милекчеләргә хас эгоистлык психологиясен фаш итәдер? Юк дип уйлыйм, сүз катлаулырак һәм тирәнрәк күренеш турында бара. Автор моны шәп белә һәм тагын да шәбрәк итеп сурәтли дә. Мәхәббәткә кимсетеп караучы, үз-үзләрен генә яратучы Зөфәргә тартым образлар бу җыентыкта тагын да бар. Шулай да Зөфәр Сабитов башка кавемнән. Бу образның реаль прототибы булгандырмы-юкмы, ул кадәресе билгесез. Әмма бер нәрсә бәхәссез: Сабитов ышандыра, бу җәһәттән Ә. Еники укучының ышанычын яулый алган. Милли әдәбиятларда мондый характерның шулай ук очрагане юк иде шикелле, ул — язучының ачышы...

Ярар, дәгъвалар белән эш ничегрәк тора, бармы алар? Дөресен әйткәндә, дәгъвалар турында түгел, ә талантлы язучыга теләкләр хакында сөйләү урынлырак булыр төсле. Язучы хикәяләренең тематикасын турыдан-туры бүгенге көн исәбенә киңәйтә төшсен иде — теләкләрнең иң зурысы әнә шул. Билгеле, әгәр автор әхлаксызлык күренешләренә каршы чыга, ул күренешләрне сәнгатьчә көчәйтеп сурәтли икән, моны турыдан-туры конкрет заман кысалары белән бәйләп бетерү мөмкин дә түгелдер. Ләкин бүгенге көн ихтыяҗларыннан еракльк аның иҗат мөмкинлекләрен ярлыландыра да. Әйтик, шундый мисал. Ә. Еники әсәрләрендә татар һәм башкорт хатын-кызлары аеруча уңышлы чыга. Бер томлыкта өлкән зоотехник Тамара Сергеевна («Ялгызлык» исемле хикәя) һәм талантлы артистка Рәшидә Сафинаның («Рәшә» повесте) пластик һәм психологик портретлары искиткеч шәп эшләнгән. Болар көчле, матур характерлар. Ләкин һәр ике очракта да мәсьәлә шулай килеп чыга ки, ике образ да тормышның хуҗалары булып түгел, ә аның корбаннары булып күз алдына килә.

Тормышны нечкәләп күзәтә белгән автор үз көчен эпик планда да кыюрак сынап карасын иде, дигән теләк белдерәсе килә. Ул эшчеләр арасыннан чыккан шәһәр кешеләренең һәм авыл эшчәннәренең үзара мөнәсәбәтләрен дөрес сурәтли алыр иде. Монда әхлакка караган актуаль мәсьәләләрне яктырту өчен зур җирлек бар.

**ГРИГОРИЙ КУКЛУС.**

**«Литературная Россия» газетасының 1975 елгы 7 февраль саныннан.**

# Мөхәммәт Мәһдиев

## Көтелмәгән сораулар



Искәндәрнең һәр вакытта да сораулары була. Әйтерсең ул гел сорау гына уйлап йөри.

Без аның белән җитәкләшеп иртән бакчага барабыз. Сораулар күп булгач, юлның озынлыгы сизелми дә кала. Безнең урам турысында трамвай юлы борылыбрак китә. Трамвайның шул урыннан узганын карап торырга бик ярата Искәндәр. Һәр көнне бер сорау:

— Әти, борылган вакытта ул трамвай ничек сынмый?

Мин тегеләй дә, болай да аңлатып карыйм, малай риза булмый.

— Юк, тимер булгач, борылганда ничек сынмый ул? — ди.

Көн саен шулай. Ә кайвакыт сорап куя:

— Ә трамвай ник кызыл була ул? — ди. Мин аптырыйм.

— Килгәне ерактан күренсен өчен,— дим.

— Алайса, автобус ник кызыл түгел?

Мин сүзне икенчегә борырга тырышам. Чыннан да, автобус ник кызыл түгел?

## Кичке сәяхәт

Кайвакытта без аның белән кич йөрергә чыгабыз. Ул Казанка тирәсендәге куаклыкларны бик ярата. Мин аңа әкиятләр сөйлим. Төлкеләр, бүреләр, куяннар турында. Һәр әкиятнең ахырында Искәндәрнең бер соравы була. Мин аңа бер кичне шулай төлкенең тавык яратуын, тавык тотар өчен кетәклеккә килүен һәм шунда тар кувшинга башын тыгып, ала алмыйча, кешеләр кулына эләгүен сөйләгән идем. Сизәм, малай бу әкияттән риза булмады.

— Әти, төлке нигә тавыкны ашый ул?

— Төлке тавык ярата ул,— дим мин, берни дә уйламыйча.

— Юк, яратмый ул аны,— ди Искәндәр кайгырып.

— Нигә алай дисең?

— Яратса, ашамас иде ул аны.

## Ай нигә йөри?

Айлы кич иде. Без урамнар аркылы борыла-борыла кайтып барабыз. Искәндәр гел күккә карап ала. Казанка буенда йөргәндә дә, үзебезнең урамга кайтып җиткәндә дә ай һаман безнең белән булды.

— Әти, ай нигә гел безнең арттан йөри ул? — дип сорый Искәндәр.

Чыннан да, ай нигә гел безнең белән йөри соң ул? Моны ничек аңлатырга? Искәндәргә бит әле биш кенә яшь.

## Алтынчы яшькә чыккач

Искәндәргә алтынчы яшь китте. Ул инде хәреф таный. Беркемнән дә сорамый, картиналы әлифба буенча үзлегеннән өйрәнә. Ул инде газета-журнал битләреннән аерым хәрефләрне табып күрсәтә.

Бер көнне мин журнал укып утыра идем. Янга килеп карап тордыторды да сорап куйды:

— Әти, монда «кем ул?» дигәндәге хәреф бармы? — ди.

— Ник булмасын,— мин әйтәм,— менә, бик күп.— һәм мин аңа берничә «к» хәрефен күрсәтәм. Ләкин ул риза булмый. Икенче хәреф эзли. Картинасында ул хәрефкә нинди рәсем ясалганын хәтерләми, картиналы таблицасын да тиз генә таба алмый. Китте йөгереп. Мин сорыйм:

— Нинди хәреф соң ул?

Малай журналны әйләндергәли торгач бер хәрефне төртеп күрсәтә: күзләре ут булган!

— Менә! Менә! — дип кычкыра.

— «М» хәрефе бит ул!

— Шул инде, шул! «М» хәрефе!

— «Кем ул?» дигәнгә ни катнашы бар аның?

— Ник, ишек ачканда сез гел «Кем ул?» — дип сорыйсыз бит.

— Сорасани?

— Ә теге кеше: «Мин ул»,— дип әйтә.

Ул «мин» сүзендәге «м» хәрефен эзли икән.

## Капитан, кил әле...

Малай бер вакыт җырлап йөри башлады. Без аңлап бетерә алмыйбыз, ләкин һәр вакыт нәрсәдер көйли-көйли дә:

— Капитан, кил әле... — дип тәмамлый.

Моның хикмәтен аңлаганчы байтак көн үтте. Бервакыт телевизордан «Капитан Грант балалары»н күрсәттеләр. Искәндәр алдан ук йөгереп йөрде:

— Әти, әти, монда теге «Капитан, кил әле»не җырлыйлар,— диде.

Мин, моның хикмәтен аңламыйча, әллә ничә тапкыр каралган фильмны тагын бер карарга мәҗбүр булдым.

Менә бер вакыт җыр яңгырады.

Капитан, капитан, улыбнитесь...

Искәндәр шул вакытта нишләргә дә белмәде.

— Менә! Менә! — дип чыркылдады.

Мин әйтәм:

— «Улыбнитесь»,— дип әйтә бит ул,— дим.

— Ә җәй көне караганда татарча үзең шулай дидең бит: «Капитан, капитан, кил әле» дип җырладың.

Мин хәтерләдем: чыннан да, җырны тәрҗемә итеп күрсәткән идем. Ләкин мин «Капитан, капитан, көл әле» дип җырлаган идем.

## Доктор янында

Өстәл янында рәсем ясап утырганда Искәндәрнең урындыгы таеп китте дә егылып төште. Йөгереп килеп күтәреп алсак — башында яра. Ул да, без дә куркып калдык. Ашыгыч ярдәм машинасын чакырттык. Безне иң куркытканы Искәндәрнең еламавы булды. Миенә зарар килмәдеме икән дип шикләндек.

Ярдәм машинасы тиз килеп җитте. Пальто өстеннән ак халат кигән бер апа студентка охшаган бер егет белән Искәндәрнең ярасын юдылар да башын бинт белән бәйләделәр. Киенергә куштылар. Безне бер поликлиникага алып китәләр икән. Малайны алга утыртып шәһәр буенча барабыз. Күрәм, Искәндәрнең авызы колагына җиткән.

— Яраң авыртамы? — дим. Ул үзенекен әйтә:

— Әти, кайтышлый шушы марля белән бәйләнгән көе бакчага кереп чыгыйк әле,— ди.

— Анда нәрсә калган тагын?

— Бәйләнгән көе бер күрсеннәр әле мине,— ди.— Мин бит яралы солдатка охшаган...

Бакчада ял көне икәнен әйткәч, аның кәефе китә. Шулай да иртәгә бер күренеп чыгарбыз дигәч, шатлана. Операция өстәлендә ярасын теккәндә дә түзә, столбнякка каршы укол кадаганда да еламый. Аны битекүзе генә күренә торган итеп ап-ак бинтка чорнап чыгардылар. Поликлиника коридорындагы көзгедән үзенең рәвешен күргәч, ул шул кадәр шатланды, бөтен авыртканнары онытылды. Без трамвай белән кайтып киттек. Трамвайга кергәч тә бөтен кайгысы шул булды: аны кеше күрәме, юкмы?

## Нахак бәла

Бакчада аларның группасында аквариум бар. Анда вак кына балыклар йөзә. Әтәч дигәне, гупешка дигәне бар. Аларны балалар үзләре ашата. Бер көнне бу балыкларны тәрбияче югында ашата башлаганнар. Кеше-кара юктан файдаланып, бәләкәй балыкларны тотып та караганнар. Алар арасында Искәндәр дә булган. Аның да тотып карыйсы килгән дә, җиңен сызганып үрелә башлаган. Нәкъ шул вакытта тәрбияче килеп кергән дә, балыкларны тотарга ярамый, дип, балаларны ачуланган.

Ә төш вакытында балыкларның берсе үлгән.

Тәрбияче Искәндәрне ачуланган. Кич белән мин аны алырга килгәндә Искәндәр бик күңелсез йөри иде. Сәбәбен сорадым, әйтмәде. Кайтканда:

— Әти, иртәгә өйдә калыйм әле,— дип, бер-ике тапкыр сорады. Сәбәбен һаман да әйтмәде.

Кич сәгать тугызда малайны яткырдык. Бер-ике әкият сөйләүгә йокыга да китте. Ләкин озак та үтмәде, мышык-мышык килеп елый башлады. Караваты янына йөгереп килдек. Ул әнисен кочаклап сөйләде:

— Ә мин гаепле түгел. Балыкны Радик тотып карады. Ул Регинага бирде. Миңа тоттырмадылар. Мин җиңемне генә сызганган идем. Мине күреп алдылар. Мин үтергән дип сөйләделәр аннан.

— Ә нигә соң мин түгел дип әйтмәдең?

— Алай дисәм, Радик белән Регинаны почмакка бастыралар иде.
— Я, иртәгә баргач, үзем әйтермен: Радик белән Регина үтергән дип.
— Әйтмә! Алар да үтермәде. Тотып кына карадылар.
— Я, алайса, елама инде...
— Ә бит мин үтермәдем! Мин үтермәдем!
Күренеп тора — нахак бәла малайның күңелен җәрәхәтләгән...



## Үзебез әкият чыгарабыз

Бакчага барганда без һәр көнне бер үк урамнардан йөрибез. Шуңа күрә без инде ияләнеп беткән: кайда нинди агач, кайда нинди газон барын беләбез. Менә без бер йортны карап йөрибез. Ул сарыга буялган. Аның төньякка караган башында ни өчендер буяу купкан. Стена кубакланган. Күрәсең, стена җирдән дым тартып утыра. Я түбә кырыеннан стенага су китә. Искәндәр көн саен диярлек моның сәбәбен сорый. Ләкин мин аңлатканга риза булмый. Шуннан без икәүләп бу йорт турында әкият чыгарабыз. Ул әкияткә көн саен берәр кәл өстәлә бара.
— Ул йорт авыру,— мин әйтәм.
— Аның тиресе авырый,— дип өсти Искәндәр.
— Аны тазартырга кирәк.
— Аңа укол кадарга кирәк.
— Әйе шул, кирәк...
— Ә йортның врачы буламы?
— Була. Ул врач зур йөк машинасында йөри.
— Ә йортның укол кадый торган әйберсе (шприцны әйтә) зур буламы?
Шул йорт янында гына зур тимер-бетон багана ята.
— Әнә шуның кадәр була,— дим.
— Ә аны йортның кай төшенә кадыйлар?
— Утыра торган җиренә — нигезенә.
Искәндәр дерелдәп ала һәм үзенең артын тотып куя. Йортка ул кызганыч караш ташлый.
Җәй ахырында без яңадан бакчага йөри башлаганда йорт «терелгән» иде. Ләкин йортның авыруы, йорт врачы турындагы әкиятне Искәндәр бик нык хәтерләп калды...

## Мактанчык

Кичен өйдә сөйләшеп утырабыз.
— Улым, сезнең группада иң матур рәсем ясаучы бала кем?
Ул ике дә уйламыйча җавап бирә:
— Мин.
— Ә пластилиннан иң матур уенчыклар ясаучы?
— Мин.
— Ә ябыштырып ясауда иң оста бала кем?
— Мин.
— Ә санау буенча?
— Мин.
Шул вакытта әнисе аңа җайсыз бер сорау бирә.
— Ә почмакта иң күп басып торучы?
Малай мактана-мактана кызып киткәнгә, монысына да:
— Мин! — дип җавап бирде һәм күзләрен җелтерәтеп аптырап калды.

## Түзмәгән...

Кайвакытта без бакчадан кайтышлый юл өстендәге бер буфетка керәбез. Анда томат согы эчәбез. Искәндәрнең сок эчкәч авыз кырыйлары кып-кызыл булып кала. Өйгә кайтканчы ул аларны сөртми. Чөнки буфетта эшләүче апа аны «кызыл мыеклы малай» дип йөртә, ә бу исем аңа ошый. Буфетчы апаның шундый көләч йөзен күреп малай көннән-көн кыюлана. Мин акча түләгән арада ул инде буфетның эчке якларына да кергәләп йөри башлый. Мин ачулансам да, буфетчы апа:

— Йөрсен, йөрсен, мин рөхсәт итәм,— дип әйтә.

Ә бер көнне малай буфетка миннән алдарак кереп китте. Мин бер танышым белән очрашып урамда сөйләшеп калган идем. Керсәм, малайның кулында бер плитка шоколад. Буфетчы апа янында эчтә басып тора. Үзара сөйләшәләр.

Сок эчеп тормадык: шоколад өчен буфетчы апага рәхмәт әйттердем дә, чыгып киттек.

Кич йоклар алдыннан Искәндәр әнисенә сөйли икән:

— Буфетчы апа янына керешли витринадагы тәлинкәдән бер шоколадны алып карадым. Аннан бер башын аз гына сүтеп карадым. Аннан телне тидереп карыйсы килде. Аннан түзмәдем, кабып карадым. Бик тәмле икән. Аннан инде кире куясы килмәде...

Икенче көнне без буфетчы апага кичәге шоколад өчен акча кертеп бирдек.

## Безнең дус

Бер көнне эштән кайтышлый балык кибетенә кердем. Анда Арча күленнән китерелгән карп балыклары саталар икән. Целлофан пакетка салдырып мин дә өч балык үлчәттем. Өйгә алып кайткач, бу балыкларның берсе тере икәнлеге беленде. Искәндәр дөньясын онытты: ваннага су тутырды да карпны шунда җибәрде. Ашарга да утырмады, ваннага печенье валчыклары, шикәр вагы, кофе сипте, пешкән вермишельләр салды. Ә тегесе чап та чоп йөзеп йөрде. Бер-ике мәртәбә сикереп чыгып ванна бүлмәсенең идәненә дә төште.

Ул төнне Искәндәрнең йокысы йокы булмады. Чөнки ванна бүлмәсенең ишеген ачык калдырткан иде. Ә аннан вакыт-вакыт чупылдаган тавыш ишетелеп торды.

Карп шулай ваннада өч көн яшәде. Бакчадан без гел йөгереп кайтабыз, юлда әкият сөйләүләр, буфетта сок эчүләр онытылды. Инде карпның исеме дә булды, Искәндәр ул исемне үзе тапты. Ни өчендер ул аны «Федя» дип атады.

— Соң, Федяны нишләтәбез! — мин әйтәм.— Ваннада юынасы бар бит. Ванна кирәк.

Малай кайгыга калды.

— Әллә, дим, тегеләре кебек куырып кына ашыйкмы?

Искәндәрнең күзләре дымлана. Төнлә ул начар йоклады.

Иртәгесен ул бездән алдарак торган да ваннага кереп Федяны печенье вагы белән сыйлап маташа.

Төн чыкканчы минем башта да бер план өлгергән иде инде. Без киендек тә, целлофан пакетка су тутырдык. Федяны шунда салдык та, Казанкага киттек.

Искәндәр Федяны үз кулы белән суга җибәрде. Федя бер секунд чамасы судан безгә карап торды да ялт итеп койрыгын селкеп йөзеп китте.

...Хәзер Искәндәр Казанкада су коенганда крокодилдан да, акуладан да курыкмый. Хәтта сигезаяктан да. Чөнки берәр хәл була калса, аның дусты Федя ярдәмгә килеп җитәчәгенә ышана ул.



## Адәм баласыниләр күрми?

Бакчага йөрүнең соңгы атналары иде.

Тиздән җәй, аннан дача, авыл, аннан инде мәктәпкә. Без Искәндәргә кызык булсын өчен бакчадан аны әнисе белән икәү алабыз.

Ул йорт өсләрендәге бөтен лозунгларны укып кайта. Ул инде дөрес укый.

Ә менә соңгы көннәрнең берсендә без бәхетсезлеккә очрадык: зур гастрономда әйберләр алып йөргәндә Искәндәр югалды. Без аны «соклар бүлеге янында торып тор» дип калдырып киткән идек.

Малайны гастрономда булган бөтен халык эзләште. Күрше йортларның ишегалларын да карадык. Юк. Билгеле, без кайгыга төштек. Тротуарда булган кешеләрдән сораша-сораша йөгерештек. Аның саен куркуга калдык.

...Шул вакыт мәйдан уртасына өстенә зәңгәр фонарь беркеткән радиолы сары машина килеп туктады. Бөтен мәйданга милиционерның көчле тавышы яңгырады:

— Искәндәр исемле малай югалткан кешеләр, машина янына килегез!

Әлбәттә, мәйданны ярып иң башта мин йөгердем. Минем арттан эзләшүчеләр дә иярделәр.

Мин килгәндә Искәндәр машина эчендә приборларга карап утыра иде. Ул туйганчы елаган булса кирәк, битендәге тузанны сызык-сызык булып күз яше ермачлаган. Елаудан, куркудан аның колаклары тырпаеп калган сыман.

Әнисе белән мине күргәч, ул елмаеп куйды.

— Төзелеш барган участокка килгән. Экскаваторлар арасында йөри иде,— диде милиционер.— Карап йөртергә кирәк. Ярый әле, урам адресын белә икән...

Юлда сорашып кайттык:

— Нигә безне ташлап киттең? — дибез.

— Кибет тәрәзәсеннән карап торганда, атлар төягән грузовик узды,— диде малай.— Мин әллә цирк киләме дип карарга гына чыккан идем. Аларны аэропортка алып киттеләр. Мин шулар артыннан бармакчы идем...

Соңыннан Искәндәр моның белән гел горурланды. Өйгә берәр кунак килсә, минем колакка гына үрелеп Искәндәр болай дип әйтә торган булды:

— Эти, эти! Минем ничек итеп милициягә эләккәнне бу абыйларга, апаларга сөйләрсең әле, яме?

Мин, әлбәттә, җае килгәндә сөйлим. Бу вакытта Искәндәрнең рәхәтлектән колаклары кып-кызыл була иде.

## «Нагут зебели»

Безнең урамда зур телефон станциясе бар. Аның стенасына өстән аска таба неон лампалар белән «Телефон» дип язганнар. Кичләрен ул бик ерактан күренеп тора. Яшькелт хәрефләрне Искәндәр урам буйлап укый-укый бара. «Трактор — т, ель — е, лиса — л, ель — е, флаг — ф, очки — о, ножницы — н». Ул шулай өстән

аска таба язылганнарны укырга ярата. Бераздан ул теләсә кайда язылган сүзләрне укый башлады. Тик ул хәрефләр белән цифрларны бутый.

— Әти, бу ничәле хәреф? — дип сорый.

Без инде бөтен хәрефләрне дә таныгач, аны укый белә дип йөри идек. Ләкин урамда йөргәндә ул шул телефоннан башка бер генә сүзне дә юньләп укып күрсәтмәде. Кайбер көнне ул үзеннән сүзләр ясап, шуның мәгънәсен сорап алҗыта. Бер ял көнне иртәдән кичкә кадәр әнисеннән гел бер сүзне сорады.

— Әни, «нагут зебели» нәрсә ул?

Билгеле, моны беребез дә белми идек. Малай аның саен борчыды.

— «Зебели» нәрсә ул?

Без моны ачыкларга тырышып карадык. Малай урамда шундый сүзнең бар икәнен әйтте.

Кичке якта кибеткә барырга дип урамга чыксак, күрәбез: безнең урамда кызыл полотнога зур хәрефләр белән лозунг язып элгәннәр икән. Бәйрәм алды бит!

— Әнә бит инде, әнә! — дип өзгәләнә Искәндәр.— Әнә, үзең укып кара!

Баксаң, Искәндәр сулдан уңга түгел, уңнан сулга укый икән. Ә теге кызыл полотнога болай дип язганнар:

«Яшәсен һәм чәчәк атсын туган илебез!»

Ул әлеге лозунгның уң ягыннан эчкә таба кереп маташа икән.

## Олы юлга

Менә ул көтелгән көн дә килеп җитте...

Бала чакның бик матур, бик күңелле бер чоры үтеп тә китте.

Бүген беренче сентябрь. Искәндәр беренче тапкыр сумка асып укырга бара. Хәрефләрне ул инде белә. Шуңа күрә укудан курыкмый. Ә менә кичә үзләренең классын карап кайткач, ул бераз гына борчуга төште: класста ул кыек сызыклар белән буялган кара такта һәм анда акбур белән язылган хәрефләр күрде. Мәктәптә язасы да була икән! Ә язарга ул бик яратмый иде. Шуңа күрә ул бүген бик җитди кыяфәт белән йөри: шатлана да, бераз гына шикләнә дә.

Искәндәр үзенең мәктәп формасын киде. Аның чалбары әле зуррак. Кыш чыкканчы аның үсәсе бар дип шулай зуррак костюм алынды. Ул көзге каршына басып каешын буды. Аннан кырын гына береткасын киде. Ак якаларын рәтләде.

Әнисе аңа ранецын киертте. Аннан тротуарга кадәр озата чыктык. Укытучы апасына ул бер букет, тәрбияче апасына бер букет чәчәк алып бара. Тәрбияче апалары бүген мәктәпкә килеп аларны укытучыларга тапшыра икән.

Искәндәрнең мәктәпкә бездән башка барасы килде. Менә ул дәү ранец асып, ике кулына ике букет тотып яңа ботинкалары белән шерт-шерт басып мәктәпкә таба китеп барды.

Без шатланып та, моңаеп та басып калдык. Ул үз гомерендә беренче мәртәбә бездән башка юлга чыгып китте. Мәктәп дигән изге, олы юлга. Ул анда октябрятка, пионерга, аннан комсомолга керер. Ул анда «ай ник безнең арттан йөри» дигән сорауга җавап табар. Ул анда «әни», «туган ил», «Ленин» дип язарга өйрәнер. Ул анда Туган илебезгә турылыклы булып тәрбияләнер. Чөнки ул бакчада йөргәндә үк инде турылыкны, гаделлекне ярата иде. Без шуңа шатланып карап калдык. Дәү ранец селкенә-селкенә бара, Искәндәр ераклашкан саен аның яңа ботинкаларының асфальтка бәрелүеннән чыккан шертләү тавышы акрыная.

Хәерле юл сиңа, Искәндәр!

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ШАГЫЙРЬ ҺАМАН САФТА

В. В. Куйбышев исемендәге Казан химия заводында магнит тасмалары житештерү цехының нигез кою бүлеге коллективы шагыйрь Муса Җәлил өчен көнлек норманы үтәп барырга карар кылды. Шагыйрь өлешенә тигән акчаны алар Бөек Ватан сугышында һәлак булган химзавод эшчеләре истәлегенә куелачак һәйкәл фондына бирәчәкләр.

## СЫНЛЫ СӘНГАТЬ МУЗЕЕНДА

Татарстан сынлы сәнгать музеенда фашизмны җиңүгә утыз ел тулуга багышлап республика художество күргәзмәсе үткәрелде. Анда сиксән өч рәссамның ике йөзләп әсәре куелган иде. Фронтовик рәссамнардан Л. Фәттахов, В. Куделькин, С. Лывин, В. Маликов, А. Родионов әсәрләре тамашачыларда аеруча нык тәэсир калдырды.

## ЯҢА ПРОГРАММА

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле Бөек Җиңүгә багышланган яңа программа әзерләде. Ул — «Идел буе тугаенда» дип исемләнгән музыкаль-хореографик композиция. Аның музыкасын өлкән композиторыбыз З. Хәбибуллин иҗат иткән. Постановка авторы — Башкортстан АССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Ф. Гаскәров.

## КАНАШ — ПОЗНАНЬ

Чувашстан хезмәт ияләре 1943 елда үз хисапларына «За родину» бронепоездын төзеп, аны фронтка бүләк иткәннәр иде. Шул бронепоезд экипажы составында рус, белорус, чуваш, башкорт уллары белән бергә татарлардан язучы Хәй Вахит дошманга каршы сугышты. Бу интернациональ экипаж I нче Белоруссия фронты составында Белоруссия һәм Польша җирләрен фашистлардан азат итүдә катнашты һәм сугышчан юлын Познань шәһәрендә тәмамлады.

«Советская Чувашия» газетасының быелгы 30 март санында «За родину» бронепоезды үткән сугышчан юл турында очерк басылды. Анда сугыш елларында артиллерия разведчигы, ә хәзер күренекле драматург Хәй Вахит хакында да җылы сүзләр әйтелгән.

## БӨЕК ҖИҢҮГӘ БАГЫШЛАП

23—25 апрель көннәрендә Мәскәүдә СССР Язучылар союзы идарәсенең балалар әдәбияты советы «Яшьләр — балалар әдәбиятында Ватан сугышы геройлары» дигән темага пленум үткәрде. Пленумда катнашучылар яшьләр күңелендә патриотизм хисләре тәрбияләү хакында сүз алып бардылар, фронтовик язучылар һәм башкала мәктәпләре укучылары белән очраштылар. Пленумда безнең язучылар оешмасыннан СССР балалар әдәбияты советы члены Ләбибә Ихсанова катнашты.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Март аенда Язучылар союзы каршындагы тәнкыйть һәм поэзия секцияләре үзара берләшеп хәзерге татар поэмасы турында җитди сөйләшү үткәрделәр. Филология фәннәре кандидаты З. Рәмиевнең әлеге мәсьәләгә багышланган докладыннан соң фикер алышуларда шагыйрьләрдән Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Илдар Юзеев, Әхсән Баянов, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, идарә председателе прозаик Гариф Ахунов һәм әдәбият белгече Тәлгат Галиуллин катнашты. Алар хәзерге татар поэмасы хакында күп кенә кызыклы фикерләр әйттеләр.

* * *

Проза секциясенең чираттагы утырышында әдипләребезнең проза әсәрләрендәге стилистик чаралар хакында сүз барды. Филология фәннәре кандидаты Ф. Сафиуллинаның әнә шул мәсьәләгә багышланган докладын секция члены зур игътибар белән тыңладылар һәм соңыннан үз фикерләре белән дә уртаклаштылар.

* * *

Балалар әдәбияты секциясенең чираттагы утырышы Казан дәүләт курчак театрында үткәрелде. Балалар язучылары һәм театр коллективы белән берлектә үткәрелгән бу утырышта балалар драматургиясе һәм курчак театрының спецификасы турында сүз барды. Артистлар репертуарга кергән аерым әсәрләрдән өзекләр уйнап күрсәттеләр. Язучыларны сәхнә алымнары, аерым цехлардагы эшләр белән таныштырдылар.

Фикер алышуларда балалар әдәбияты секциясе җитәкчесе Ләбибә Ихсанова, Курчак театры директоры Әзһәр Хәсәенов, Курчак театры баш режиссеры, язучы Роберт Батуллин, Татарстанның атказанган артисты Фоат Таһиров, язучылардан Гөлшат Зәйнашова, Нәби Дәүли, Госман Бакиров һ. б. катнашты.

*
* *

Тәрҗемәчеләр секциясе үзенең чираттагы утырышында Марк Зарецкий тәрҗемәләрен тикшерде. Утырышта чыгыш ясаган тәрҗемәчеләрдән Т. Нурмөхәммәтов, М. Рафиков, Р. Такташ, Р. Бадюгина һәм З. Халитова М. Зарецкийның татар әсәрләрен рус укучысына җиткерүдәге уңышлы һәм кимчелекле якларына тукталдылар һәм тәрҗемәчегә файдалы киңәшләр бирделәр.

*
* *

Рус язучылары секциясенең соңгы утырышы КамАЗда эшләп иҗат итүче яшь рус язучылары әсәрләреннән төзелгән коллектив җыентыкны тикшерүгә багышланды. Шул җыентыктагы әсәрләр буенча фикер алышуда Г. Паушкин, Т. Журавлев, М. Зарипов иптәшләр катнашты. Китап итеп бастырып чыгару өчен, җыентык Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителде.

## СПЕКТАКЛЬЛӘР УҢЫШЛЫ ҮТТЕ

Апрель аенда Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында Башкорт дәүләт опера һәм балет театры артистлары Хәй Вахит пьесасы буенча эшләнгән (музыкасын С. Садыйкова белән Р. Гобәйдуллин язганнар) «Кияүләр» спектаклен сәхнәгә куйдылар. Тугандаш башкорт артистлары уйнаган ул спектакльне Казан тамашачылары яратып карады. Җамали ролен башкарган РСФСРның халык артисты, Салават Юлаев премиясе лауреаты Мәгафур Хисматуллин, Мәйсәрә ролен башкарган РСФСРның атказанган артисткасы Сажидә Галимова, Банат ролен башкарган БАССРның атказанган артисткасы Нажия Аллаярова уеннары казанлыларда аеруча җылы тәэсир калдырды. Спектакльдә РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты Хәсби Фазлуллин дирижерлык итте.

Шул ук көннәрдә шушы ук спектакльне Башкортстанның башкаласы Уфа шәһәрендә татар артистлары башкорт тамашачыларына уйнап күрсәттеләр һәм уфалыларда шулай ук әйбәт тәэсир калдырдылар.

## МУЗЫКАЛЬ ФОЛЬКЛОР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

РСФСР композиторлар союзы һәм аның фольклор комиссиясе, Чувашстан АССР композиторлар союзы һәм Чувашстан Министрлар Советы каршындагы фәнни-тикшеренү институты бергәләп «Идел буе халыкларының традицион һәм хәзерге заман музыкаль фольклоры һәм аның тарихи үзара бәйләнешләре» дигән темага фәнни конференция үткәрделәр. Март аеның ахырында Чабаксарда үткәрелгән ул конференциягә Татарстан музыка белгечләре дә чакырылган иде. Сәнгать фәннәре кандидатлары М. Нигъмәтҗанов «Урал буе һәм Идел буе халыклары музыкасының тарихи бәйләнешләре», А. Абдуллин «Татарларның музыка сәнгате», фәнни хезмәткәрләр О. Егорова «Мари халык җырларының стиль үзенчәлекләре», И. Кадыйров «Себер татарларының йола җырлары» дигән темаларга докладлар ясадылар.

Конференциягә РСФСР композиторлар союзының фольклор комиссиясе председателе А. Медведев җитәкчелек итте.

## ҖЫЛЫ ХИСЛӘР БЕЛӘН

Шушы елның апрель аенда Казан консерваториясенең актлар залында үткәрелгән концертта ТАССР симфоник оркестрына Төркиянең Әнкара шәһәре Президент симфоник оркестры дирижеры Гюрер Айкал дирижерлык итте. «Мин,— диде ул концерттан соң «Социалистик Татарстан» газетасы корреспонденты белән әңгәмәсендә,— Советлар Союзына беренче тапкыр килдем һәм Татарстанда беренче тапкыр чыгыш ясадым. Мондый мөмкинлек тудырылуга чиксез шатмын. Сезнең халыкның мәхәббәтен казану һәм шәһәрегезнең матурлыгына соклану хисе белән киту минем өчен бик зур бәхет. Оркестрыгызның музыкантлары яшь һәм энергияле. Мин моңа Шостакович, Прокофьев һәм күренекле төрек композиторы Ильхан Усманбашның катлаулы әсәрләрен әзерләгәндә ышандым. Оркестр белән бик теләп эшләдем. Мине Татарстан дәүләт симфоник оркестры белән бәйләгән дуслык җепләре киләчәктә тагын да ныгыр дип ышанам. Музыкантларыгызны яраттым, алар да мине яраткандыр дип уйлыйм. Бу ярату хисе минем илемдә — Төркиядә дә дәвам иттерелер. Әнә шундый өмет белән үзебезнең кумәк концерт һәм Татарстанның иң яхшы музыкантлары әсәрләре язмаларын алып китәм. Халкымны татар халкының гүзәл музыка сәнгате белән таныштырырга уйлыйм.

## ТЕМАТИК КИЧӘЛӘРГӘ КОНКУРС

Профсоюзларның Татарстан өлкә советы «Тугызынчы бишьеллыкны төгәлләү елына — удар хезмәт» дигән девиз белән үткәрелә торган тематик кичәләргә конкурс-смотр игълан итте. Шушы елның декабрь аена кадәр дәвам итәчәк ул конкурска производство алдынгыларын, социалистик ярышны әйдәп баручы хезмәт ударникларын һәм эшче династияләрен хөрмәтләүгә багышлап, культура сарайларында, предприятие, оешма, колхоз һәм совхозларда үткәрелгән кичәләр тәкъдим ителергә тиеш. Конкурска тәкъдим ителә торган кичәләрдә

коллективларның тормышын, иң яхшы рационализатор һәм уйлап табучыларны, остазларны яктыртучы күргәзмә-агитацион материал ни дәрәҗәдә уңышлы файдаланууга аеруча зур игътибар ителәчәк.

Конкурста җиңеп чыгучыларга 1000, 750, 500 сум күләмендә акчалата премияләр биреләчәк. Ә җиңеп чыккан коллективларның оештыручыларына профсоюзларның Татарстан өлкә советы Почет грамоталары тапшырылачак.

## ҖӘЛИЛ КИЧӘЛӘРЕ

Мәскәүдәге «Газстроймаш» заводының «Маяк» культура сараенда узган кичә патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең якты истәлегенә багышланган иде.

Кичәне М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре» циклыннан байтак тәрҗемә иткән күренекле рус шагыйре Илья Френкель ачты. Үзенең чыгышында ул Муса Җәлилнең патриотик поэзиясенең тәрбияви әһәмиятенә басым ясады.

Кичәдә катнашучылар күренекле хәрби начальник, мәшһүр М. Фрунзеның якын көрәштәше, отставкадагы генерал-лейтенант Я. Чанышевның чыгышын зур кызыксыну белән тыңладылар. Ул совет халкының узган сугышта күрсәткән батырлыгы хакында сөйләде.

Татарстан язучылар союзы правлениесе исеменнән шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов «Маяк» культура сараена истәлек бүләкләре — М. Җәлилнең юбилей альбомын һәм «Моабит дәфтәре»нең яңа басмасын бүләк итте һәм шагыйрьгә багышланган яңа шигырьләрен укыды.

Кичәдә бенгаль халкының милли герое, Бангладеш шагыйре Бадрул Хасан Баблу да катнашты. Халкым өчен кыен елларда, диде ул, Муса Җәлил образы бенгаль шагыйрьләре өчен какшамас рух чыганагы, патриотизм үрнәге булды.

Аннары мәскәүле яшь шагыйрь Әхмәт Саттар М. Җәлилнең башкаладагы чоры иҗаты һәм иҗтимагый эшчәнлеге хакында сөйләде.

Соңыннан Муса Җәлил исемендәге әдәби берләшмәнең яшь көчләреннән Спартак Әхмәтов, Равил Азизов, Александр Шведов һәм Вера Свилих шагыйрьгә багышланган шигырьләрен укыдылар.

Әдәби-музыкаль кичәдә үзешчән композитор Сәйяр Хәбибуллин катнашындагы үзешчән коллектив та чыгыш ясады.

* * *

Бөек Җиңүгә 30 ел тулу уңаеннан Чиләбе станок төзү заводының 4 нче тулай торагында Советлар Союзы Герое, патриот шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган кичә булды. Анда Муса Җәлил исемендәге татар-башкорт әдәби берләшмәсе члены Салисә Гәрәева шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында сөйләде.

Соңыннан кичәдә катнашучыларга Муса Җәлилнең татар һәм рус телләрендәге шигырьләре укылды.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Бөек Җиңүнең утыз еллыгы көннәрендә Казан дәүләт педагогия институтында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Анда язучылардан Г. Минский, М. Садри катнашты. Алар студентларга Ватан сугышы елларында халкыбызның фидакарь хезмәте һәм батырлыгы турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Март аенда Бөтенсоюз балалар китабы атналыгы үткәрелде. Шул атналык барышында язучы Шамил Рәкыйпов Казанның 38 нче, 35 нче, 3 нче мәктәпләрендә, 51 нче техник училищеда, шагыйрь Шәүкәт Галиев 51 нче һәм 7 нче мәктәпләрдә, балалар язучысы Ләбибә Ихсанова Киров районы Культура сараенда укучы балалар белән очрашып, аларга бүгенге әдәбиятыбыздагы яңалыклар турында сөйләделәр һәм үзләренең әсәрләрен укыдылар.

## ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ МУЗЕЕНДА

Язучы Шамил Рәкыйпов беренче трамвай паркы комсомоллары, трамвай-троллейбус идарәсе хезмәткәрләре каршында һәм Татарстан дәүләт музеенда Советлар Союзы Герое Иван Кабушкин турында чыгышлар ясады. «Кайда син, Жан» повестеның язылуы турында сөйләде. Музейда үткәрелгән очрашуга Белоруссия партизан хәрәкәтләренә актив катнашкан, Иван Кабушкин белән элемтәдә булган А. К. Якулис һәм кызыл эзтабарлар җитәкчесе А. Д. Недведцкая иптәшләр дә катнашты.

## КОМПОЗИТОРНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Казанның химиклар культура сараенда композитор Б. Мулюковның иҗат кичәсе булды. Шәһәребез химиклары, интеллигенция вәкилләре композиторның соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрен тыңладылар. ТАССРның атказанган артисткасы Н. Теркулова, яшь җырчы М. Галиев чыгышлары тамашачылар тарафыннан җылы каршыланды.

* * *

Татарстан дәүләт музееның әдәбият бүлегендә сугыш елларында иҗат ителгән җырлар кичәсе үткәрелде. Ул әдәби-музыкаль кичәдә Татарстанның халык артистлары Г. Кайбицкая, М. Миңлебаева, Татарстанның атказанган артистлары С. Садыйкова, Ә. Яһүдин, артистлардан Р. Ибраһимова, М. Әбкәниева һәм Татарстанның халык артисты композитор З. Хәбибуллин катнашты. Кичәгә килгән кешеләргә алар сугыш елларында иҗат ителгән һәм халык арасында популяр булган җырларны җырлап һәм уйнап күрсәттеләр, шул елларда фронтта, хәрби частьларда һәм госпитальләрдә сугышчылар алдында чыгыш ясаган вакытларында күңелләренә тирән сеңеп калган истәлекләрен сөйләделәр.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге нефть районнарында яшәп иҗат итүче яшь авторлар белән даими элемтәдә тора. Алар өчен әледән-әле индивидуаль консультацияләр, семинарлар үткәрә, әсәрләрен урыннарга барып тикшерүне оештыра.

Яшь шагыйрь Рәшит Бәшәров Лениногорск районының Куакбаш авылында укытучы булып эшли. Аның «Каенлы юл» исемле повесть һәм хикәяләр җыентыгын тикшерү өчен Әлмәттән драматург Юныс Әминов, яшь шагыйрь Газиз Кашапов, Лениногорскидан язучы Шамил Бикчурин һәм яшь язучылар Альберт Хәсәнов, Әсрар Галиев, Җәмит Рәхимов Куакбаш авылына бардылар. Әсәрне яхшырту юнәлешендә авторга файдалы киңәшләр бирелде. Кичен авыл клубында булган әдәби-музыкаль кичәдә язучылар бүгенге хезмәт кешеләре һәм Бөек Ватан сугышы темасына язылган әсәрләрен укыдылар.

* * *

Азнакай поселогында яшәүче яшь шагыйрь Нур Әхмидиевнең «Аһәң» исемле шигырьләре җыентыгы буенча фикер алышу булды. Язучылардан Г. Афзал, К. Булатова, Ә. Маликов, Э. Мөэминова, С. Сөләйманова һ. б. җыентыкка нигездә уңай бәя бирделәр, нефть ягы тормышын чагылдырган яңа шигырьләр белән тулыландырырга кирәклеген әйттеләр.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР, ПОЧЕТ ГРАМОТАЛАРЫ

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм илле яше тулу уңае белән язучы Мәҗит Мәгъсум улы Рафиков КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

* * *

КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Почет грамотасы белән, совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Бөгелмә дәүләт рус театры актрисасы Наталья Геннадьевна Чижик һәм шул театрның өлкән костюмеры Фәридә Әбубәкер кызы Тонких та бүләкләнделәр.

* * *

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен ТАССР Верховный Советы исемендәге Казан музыка училищесы директоры Гумеров Марс Һилал улына РСФСРның атказанган культура хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Сынлы сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен СССР художниклар союзы членнары скульптор Васил Малик улы Маликовка һәм рәссам Владимир Александрович Поповка Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелде.

## ТӨЗӘТҮ:

Журналыбызның 5 санында, 108 битнең өстән 12 нче юлында Г. Кутуй сүзе, типография гаебе белән, Г. Тукай дип басылган.

Шуны төзәтеп укыгызны үтенәбез.




*Уч. М. Усманов зарисовкасы.*

*Берлин, 1945 ел.*

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210